# Казан утлары

10

ОКТЯБРЬ·1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**10**

ОКТЯБРЬ
1969

## БУ САНДА:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**ПАУЛ МИХНЯ.** Аппассионата. Шигырь . . . . . 3
**ЭМИЛЬ ЛОТЯНУ.** Ленин. Шигырь . . . . . . . 4
**ВИНЬ ЛЕ.** Солдат рәхмәте. Шигырь . . . . . . 5
Гаҗәеп кошлар. Әкият . . . . . . . . . . 6
**Г. МӨХӘММӘТШИН.** Шушенскоеда яз . . . . 11

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

**А. ГЫЙЛӘҖЕВ.** Урамнар артында яшел болын. Роман . . . . . . . . . . . . . . . . 25
**Ф. ХӨСНИ.** ...Кешеләр килә шагыйрьгә. . . . . 84
**М. КӘРИМ.** Сабантуйдан кайтып киләм. Әйләнә карусель... Ярсу Танып... Шагыйрь шатлыгы. Дау күтәрә җаным. Сандугачка нигә буй-сын. Котчыккыч төш күрдем. Шигырьләр . . . 86
**Г. ЛАТЫЙП.** Кызыл Яр. Поэма . . . . . . . . . 90
**Ә. БАЯНОВ.** Декабрьның уникенче көне. Дүрт монолог . . . . . . . . . . . . . . . . 98
**Г. АФЗАЛ.** Борчылу. Шигырь . . . . . . . . . 127

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**С. ХӘЙРУЛЛИН.** Муса эзе калган колхозда. Очерк . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**Т. НАСЫЙРОВ.** Ул В. И. Ленин белән бергә эшләде . . . . . . . . . . . . . . . . 135

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**И. НУРУЛЛИН.** Онытылмас еллар шаһите . . . 140

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

**Р. МОСТАФИН.** Муса көрәштәшләре . . . . . 148

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Ә. ҖӘЛИЛОВА. Кояш чыккан Алман җирендә . 152

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Й. Гәрәй. Сүз җыярга килегез! . . . . . . . 155

МӘДӘНИЯТ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Я. АБДУЛЛИН. Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләренә карата . . . . . . . . . . . . 158

ТӨРЛЕСЕННӘН

К. ЗАРИПОВ. Легендар Севастопольдә. Юл язмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

Ә. КАМАЛ. Аны үз юлыннан тайпылдырмакчылар иде. . . . . . . . . . . . . . . . . 177

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

И. СИБГАТУЛЛИН. Якты истәлеге күңел түрендә . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Ф. ХӨСНИ. Үземне югалттым! Хикәя . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 12/VIII-1969 ел. Басарга кул куелды 23/IX-1969 ел. ПФ 09032.
Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 36306.
Заказ В-418. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




# ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

*Төрле иләрдән, төрле телләрдән*

## Паул Михня.

Молдаван шагыйре

## Аппассионата

*«Аппавсионата»дан да яхшырак һичнн белмим, аны һәркөн тыңларга әзермен».*

**В. И. Ленин.**

I

Беренче аккордлар — ни сөйлиләр алар?
Нинди ярсуларның ул иң тирән өне?
Мәһабәт болытлар калкып гүя таудай баса,
Һәм яныйлар кебек ерактан күренеп.
Бу — яшерен яну, бу — язмыш көчләре тавышы!
Иреннәр тетрәп
Сөекленнең исемен әйткән кебек,
Дәшә, тревога уйный, яуга чакыра өндәп.
Аккордларда — ачу тавышы, төндәй кара көннәр,
Халыкларнын ризасызлык өне, шавы;
Һәм Ленинның йөрәгендә ургып кайный
Бөтен хезмәт сыйныфының гаме, давы.
Көрәш гөрләвендә аңа тиңдәш булып туа,
Ачыклана бара,
Гүя ярга ерактан килгән дулкын көче —
Көйнең пульсы... үсә, үсә бара, гүя
Көрәштән көч, ләззәт алган төсле! —
Килә төнгә алмаш көн шикелле,
Җимерә барысын. Халыкларның адымы ул!
Ленин йөрәгендә ургый ташкын —
Хезмәт сыйныфының дулкын-давылы ул!

II

Анданте. Сөеклен күзләре нурымы,
Я хыяллар үсеп чынга әверелдеме? —
Чәчәк кебек гүя ачылдылар алда
Адаштырыр киңлек-ераклыклар сере.

О, нинди яр анда — кояшлы яр
Еракта калка, нурда уйный төсле.
Ул — Ленинның йөрәгендә чагыла
Безнең бөек көннәребез төсе.

III

Аккорд — гүя шартлау тавышы.
Һәм давыл чыгып,
Кабат күтәрелә, күкри анда.
Упкыннар кайный, бөтерелә, үсә бара...
Әмма менә марш чыңлар яуда — алда...
Җиңү аһәңендә янгырый соңгы көрәш давы
Музыкада! Халыкларда — бөек шатлык.
Һәм Ленинның йөрәгенә бәрелә инде
Хезмәт сыйныфының тантанасы, җиңү шавы!

## Эмиль Лотяну.

Молдаван шагыйре

## Ленин

Исемең синең
ядымда мәңгегә! —
йөрәгемдә — биш хәреф
якты йолдызның ул
биш нуры!
Хыялымда булдың
иң сөекле, бик якын кешем,
әтием кебек
күз алдымда тордың!

Туганлаштым синең белән
мәңгегә!
Җан белән, тән белән.
Мин сине күрдем
алтын Кояш чыгышы күк итеп.
Карагандай аңа
гаҗәпләнеп,
каушап,
кыюсыз,
әмма матурлыгына ис китеп!

Сорасалар:
күрдеңме, дип Аны?
Әйтермен,
шикләнми әйтермен:
«Күрдем, әлбәттә!»
Сөйләрмен безнең күп,
исәпсез очрашу турында:
гәрчә, белсәм дә
кайчан үлүең,
үземнең тууны,
һәм ике арада
күпме ел ята!

Әйтермен: «Ул иде
искиткеч һөнәрмәнд, зур оста.
Аның күк икенче останы
без тапмабыз җирдә! —
Күперләр салды ул,
күперләр! —
Кешедән — хыялга,
хыялдан — максатка,
Кояштан — Кешегә,
Кешедән — Кояшка,
күңелдән — күңелгә!

Безгә мирас итте
осталык, һөнәрен...
Һәм безнең күперләр,
салават күпередәй!
Сузылды:
халыктан — халыкка,
буыннан — буынга —
Җир, Кешеләр өчен
иң бөек Туганлык символы».

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН
тәрҗемәләре

## Винь Ле.

Вьетнам шагыйре

# Солдат рәхмәте

Атакада әгәр пуля екса,
Үтәлмәсәм юлның ерагын мин,
Исәннәргә васыять булып калсын
Хәзинәсе кайнар йөрәгемнең.

Зур Хәзинә, изге Хәзинә ул;
Елга түгел, ул — тиң киң диңгезгә.
Байрак итеп аны саклагыз сез,
Шул байлыкны мирас итәм сезгә.

Ул хәзинә — Вьетнам горурлыгы,
Ул хәзинә — безнең көрәш даны.
Ул хәзинә — минем якын дуслар,
Сез беләсез, бик күп алар саны!

Ләкин, дуслар, телим һәм тырышам
Зур җиңүгә барып җитәргә мин.
Һәм барырмын бер Октябрь көнен
Мәскәүләрдә бәйрәм итәргә мин.

Мавзолейга керми калмам баргач,
Һәм әйтермен шунда мин Ленинга:
— Җирнең бөек юлбашчысы, сиңа
Рәхмәте зур солдат Винь Ленын да.

Әйтермен мин: — Йөрәкләрдә булдың,
Безнең белән яуда атладың син.
Мин дөньяга килгәнче үк хәтта
Дошманнардан мине якладың син.

Уртак җырлар төрле телдә яңгырый...
Һөҗүмнәргә барган юлыбызда
Пресня белән Нге Анда бер үк
Байрак йөрде безнең кулыбызда.

Җиңү генә куандырды безне,
Без елмайдык — күздән яшь чыкмады.
Бинокльдән күккә карый идек
Күренер дип галәм «Восток»лары.

...Атакага кергән солдат антын
Кат-кат әйтәм һәрбер сулышта мин:
— Утлар кичеп мавзолейга килдем,
Синең белән җиңдем сугышта мин!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

# ГАҖӘЕП КОШЛАР

ӘКИЯТ

Ерак Себер урманнары уртасындагы кечкенә генә бер аланда Степан исемле аучы яшәгән. Хатыны һәм Иван атлы улы да булган аның.

Утыз елдан артык ауга йөргән Степан. Бик борынгы чакмалы мылтыгы булган. Шул мылтыгы белән бик күп аю, тиен, кешләр аткан бу.

Аннары картайган. Ялгызы гына ауга йөри алмый башлаган.

Бер дә бер көнне Степан улын ияртеп ауга киткән.

— Мин әйткәннәрне күңеленә салып бар, улым, кирәге чыгар. Тиздән үзең генә ауга йөри башларсың, әниең белән безне туйдырырсың. Мин ауга күп бара алмам инде,— дип, Степан улын аучылык һөнәренә өйрәтә башлаган.

Байтак вакыт шулай өйрәтеп йөри ул аны. Бер көнне болар аудан кайтып, ашарга утыргач, әнисе сорый Иваннан:

— Я, Иван, тайганы ошаттыңмы соң? — ди.

— Әй, әнкәй! — ди Иван.— Тайга миңа бик ошады, гомер буе шунда яшәр идем. Әмма сезне калдырып китәсем килми шул. Кайткалап, хәлегезне белеп йөргәләргә туры килер инде.

Шулай сөйләшеп чәй эчкәннән соң, йокларга ята болар.

Ә иртән торгач, Иван ауга китәргә җыена, әти-әнисеннән рөхсәт сорый. Степан улына рөхсәт бирә, хәерле юл тели һәм бу дөньяда ничек-ничек яшәргә, ничек аучылык итәргә киңәш бирә. Ярлыларны, толларны һәм ятимнәрне кимсетмәскә куша.

Шуннан соң Ваня чакмалы мылтыгын аса да ерак сәфәргә — ауга китә. Әтисе белән әнисе, капка төпләренә чыгып, аны озатып калалар.

Карурманга кереп китә Ваня. Бик күп йөри ул урманда, әмма бер җәнлек тә очрата алмый. «Көнем бушка үтәр, ахры», дип уйлый, борчылып.

Шулай дип уйлавы була, бугалакка эләккән бер куянны күреп ала бу. Чәбәләнә куян, сикергәли, әмма бугалактан һич тә ычкынып китә алмый. Карап-карап тора да: «Бу мескен җәнлек тә иреккә омтыла бит», дип уйлый Ваня. Шулчак куян телгә килә:

— Аучы, җибәр мине иреккә, бәлки, берәр вакыт мин дә сиңа кирәк булырмын,— ди куян.

Гаҗәпкә кала Иван: бу мескен җәнлек миңа ни файда итә алыр икән, ди. Шунда әтисенең, көчсезләргә ярдәм ит, дигән сүзләрен исенә ала да бугалакны чишә. Куян уктай атылып урманга шыла, ә Иван үз юлы белән китеп бара.

Тагын бик күп җир йөри бу. Әмма атардай бер җәнлек тә очрата алмый. Аптырый Иван: «Юкка җибәрдем теге куянны. Хәзер буш кул белән кайтырга туры килә инде миңа», ди.

Барыбер рәт чыкмас инде дип, күңелсезләнеп кайтыр якка китә. Бара торгач, бер бик шәп ага торган елга буена килеп чыга һәм елга-

ның аргы ягында коточкыч бер йонлач хәшәрәт җанвар торуын күрә. Ул да булмый, теге хәшәрәт җанвар, ажгырып, Иванга таба килә башлый. Иван чакмалы мылтыгын иңеннән сала да төзәп торып атып җибәрә. Әмма хәшәрәт җанвар үлми. Тагын да ныграк ярсып, Иванга ыргыла. Бүтән чарасы калмагач, Иван башындагы бүреген салып ыргыта. Җанвар бер мәлгә каушап-аптырап кала. Ул арада Иван мылтыгын корып өлгерә дә тегеңә икенче тапкыр ата. Җанвар тагын Иванга ыргыла. Бу юлы Иван өстендәге бишмәтен салып ыргыта. Шулай итеп, тагын тегене бер мәлгә куркытып калдыра. Шул арада үзе мылтыгын өченче тапкыр кора да тагын атып җибәрә. Теге җанвар аңа тагын ныграк котырынып ташлана. Иван аягындагы итекләрен салып ыргыта. Җанвар итекләр белән булышкан арада мылтыгын корып, дүртенче тапкыр ата Иван. Аннары биштәр капчыгын, бөтен ау кирәк-яракларын ыргыта. Шулай итеп, унике рәт ата бу теге хәшәрәткә. Бөтен әйберен ыргытып бетергәч, җанварны куркытыр әйбере калмый моның.



Йонлач җанварга шул гына кирәк тә: бөтен ачуын җыеп, Иван өстенә ташлана да аны таларга, буарга тотына. Иван, аңын югалтып, егыла. Йонлач хәшәрәтнең дә каны бик күп аккан була. Ул да, хәле китеп, бер агач төбенә барып ава.

Ә бу вакытта Степан карт өйдә була. Алар, карчыгы белән икәү, улыбыз ник кайтмый икән инде дип борчылып, төн буе тәрәзәдән карап, көтеп утыралар.

— Әгәр таң аткач та кайтмаса, берәр чарасын күрмичә булмас,— ди Степан карчыгына.

Таң да ата, ә Иван юк та юк.

— Әйдә, карчык, биштәр капчыгын әзерлә! Малайны эзләргә үзем барып карыйм,— ди Степан карт.

— Син бит өйдә дә көч-хәл белән генә йөрисең, кая бармак буласың? Сөртенеп егылып, тора алмыйча үлеп китсәң, мин бер башым ничек торырмын? — ди карчыгы.

Ә карты әйтә:

— Әллә өйдә утырып мәгънә бар дип уйлыйсыңмы? Малайга андый-мондый хәл була калса, икәүләп утырып үләчәкбез ләбаса! — ди.

— Шулай да икәү үлү ялгыз үлүгә караганда ансатрак булыр шикелле,— ди карчыгы.

Ә Степан һаман үз сүзендә тора: барам булгач барам, ди. Бүтән чарасы калмагач, карчык картына биштәр капчыгы хәстәрләргә тотына, ә карты күгәреп беткән борынгы чакмалы мылтыгын алып керә. Аны корып куя да өс-башына киенә. Аннары, аркасына биштәрен, иңенә мылтыгын асып, улы Иванны эзләргә китә. Карчыгы, капка төбенә чыгып, Степан тәмам күздән югалганчы карап тора.

Көн буе улын эзләп йөри Степан. Кичкә таба тәмам ара бу. Аяк атлар хәле дә калмый. Менә авам, менә егылам дип кенә торганда, кинәт җир астыннан үсеп чыккандай, каршына куян килеп баса моның. Килеп баса да телгә килеп:

— Нигә болай аптырап, боегып калдың, бабакай? — дип сорый.

Степан куянның кешечә сөйләшүенә беркавым шаккатып тора да әйтә:

— Аптырамый нишлим соң? Бердәнбер улым — туйдыручым бар иде, ул да югалды: кичә иртүк ауга киткәннән бирле кайтмады,— ди.

— Мин синең улыңны да, аның кайда ятканын да беләм, Степан бабай. Синең улың миңа изгелек итте, мин дә сиңа изгелек итмәкче булам. Әйдә минем арттан, күрсәтәм мин сиңа улыңны,— ди моңа куян.

Шулай ди дә Степанны ияртеп китә. Чыннан да, малае янына алып бара ул аны. Малаен күргәч, Степан карт кычкырып елап җибәрә:

— Улым, йөрәк парәм, нишләдең син, нинди хәлләргә юлыктың? — ди. Аннары малае өстенә капланып, аны коча, үбә һәм шунда үзе дә аңын югалта.

Төн буе шулай өнсез ята карт. Бары икенче көнне иртән генә аңына килеп, ни булды икән моңа дип, малаеның гәүдәсен тикшерә башлый. Шул чак үзе янында утырган куянны күреп ала бу. Аннары кичә куян әйткән сүзләр исенә төшә дә, сөйләп бирче, куян, ничек-ничек булды соң монда хәлләр? дип сорый. Куян барысын да тәртибе белән сөйләп бирә картка:

— Иван мине бугалактан ычкындырды, шул яхшылыгы өчен минем дә аңар яхшылык эшлисем килеп, малаеңны күзәтеп йөрдем,— ди.— Бу тайга урманнарында Совет властеннан качып киткән йонлач җанварлар шактый күп. Улың Иван шуларның берсе белән очрашты. Хәшәрәт үзе турында Совет властена житкермәсен дип куркып, улыңны буарга тотынды. Улың аңа бик күп мәртәбә атты. Әмма тиз генә үтерә алмады. Бик озак тартышканнан соң, теге хәшәрәт, ниһаять, Иванны буып үтерде. Аннары, Иван аткан җирләреннән бик күп каны акканлыктан хәле китеп, хәшәрәт үзе дә бер читкә китеп егылды. Әнә ул да үлеп ята,— дип, картка теге хәшәрәтне күрсәтә. Аннары:

— Мин үз бурычымны үтәдем, бабакай, башкача мин сиңа булыша алмыйм,— ди.

Шулай дип, үз юлы белән китә куян. Ә карт, нишләргә инде дип, уйга кала: улын күтәреп алып кайтыр иде — көче юк, сөйрәткеч ясап, сөйрәп кайтыр иде — үзе дә аягында чак-чак басып тора.

Шулай ни эшләргә дә белмичә аһ орып утырганда, күктә дөнья шаулатып, җилләр уйнатып очып баручы өч кошны күреп ала Степан карт. Күреп ала да, тез чүгеп, кулларын сузып, бар көченә теге кошларны чакыра башлый. Кошлар өчесе дә карт янына җиргә төшәләр. Аннары шул өч кош эченнән өсләренә күн киемнәр кигән өч бик чибәр егет килеп чыгалар да карттан:

— Ни кирәк, бабай, сиңа? — дип сорыйлар.

Степан карт барысын да куян әйткәнчә сөйләп бирә дә:

— Ванямны өйгә алып кайта алмассызмы икән? — дип үтенә.

Теге чибәр егетләр картка Ленин кушкан эш белән йөрүләрен — Җир шарында ниләр барлыгын тикшереп-белеп кайтырга чыкканлыкларын әйтәләр. Аннары үзара сөйләшеп алалар да:

— Ярар, алайса, бабай, безнең икебез юлын дәвам итәр, ә беребез улың белән сине өегезгә илтеп куяр,— диләр.

Шулай дип икесе төньякка таба очып китә, ә берсе, Степан белән Иванны тимер кошына утыртып, өйләренә илтә китә.

Тимер кош өйләре янына килеп төшкәч, Степанның карчыгы аптырап китә: «Нинди гаҗәеп кош икән бу, нишләп монда төшеп кунаклады икән?» — дип уйлый. Чукынырга да, нишләргә дә белми. Аннары улы белән ире Степанны күреп ала да, үз күзләренә үзе ышанмыйча, өнемме бу, әллә төшемме, дип шаккатып кала. Ул арада Степан белән теге чибәр егет Иванны, тимер кош эченнән алып чыгып, өйгә алып керәләр дә караватка салалар. Карчык та өйгә керә һәм кычкырып елап, улы өстенә каплана. Елап арыгач, улы турында сораштыра башлый. Степан карт карчыгына барысын да сөйләп бирә. Аннары карт белән карчык, уларын утыртып алып кайткан өчен, теге чибәр егеткә рәхмәт әйтәләр. Улыбыз Иванны нишләтик икән инде, дип киңәш сорыйлар. Берәр төрле ярдәм итә алмассыңмы, дип үтенәләр.

— Бик рәхәтләнеп булышыр идем,— ди аларга чибәр егет,— әмма башта мин сезгә ярдәм итүем турында кадерле Ильичка хәбәр итәргә тиешмен шул.

Шулай ди дә, тимер кошына утырып, очып китә. Карт белән карчык аны озатып калалар.

Аннары икесе дә, нишләргә инде дип, кайгыга баталар. Аптырагач, карчык Степанга багучыга барып карарга куша:

— Ул нишләргә икәнен әйтер,— ди.

— Багучыга барганчы, им-томчы янына барырга кирәк. Бәлки ул Ваняны терелтү җаен табар,— ди Степан карт.

Карчык һаман үз сүзендә тора, Степан багучыны алып килергә мәҗбүр була. Багучы болар өенә кереп, өстәлгә карталарын таратып ташлый да, улыгыз ничек-ничек вафат булды, дип сорый. Степан улы Иванның ауга китүен, анда йонлач хәшәрәт җанвар белән сугышуын, шул сугыш вакытында үлеп калуын, аннары гаҗәеп кошка утыртып, бер чибәр егет Иванны өйләренә кайтарып куюын сөйләп бирә.

«Нинди кош икән соң ул?» — дип, борчылып уйга кала багучы. Аннары карталарын тиз генә җыя да, багып тормыйча, өенә кайтып китә.

— Менә,— ди Степан карчыгына.— Әйттем бит мин сиңа багучыдан рәт чыкмас, им-томчыга барып карарга кирәк, дип. Тәки минем сүз дөрес булып чыкты. Вакытны гына әрәм иттек аның артыннан йөреп.

Шулай ди дә, тиз генә барып, им-томчыны алып килә Степан. Им-томчы үзе алып килгән үләннәрне кайнатырга куя да карт белән карчыктан уллары Иванның ничек-ничек үлүе турында сораштыра башлый. Степан карт моңа да багучыга сөйләгәнчә сөйләп бирә. Иванны тимер кошка утыртып бер чибәр егет китереп куюын, аннары ул егетнең Ленин янына очып китүен дә әйтә.

Им-томчы да куркып кала хәзер. Ул тиз генә үләннәрен җыештыра да өенә кайтып китә.

Карт белән карчык тагын да ныграк кайгыра башлыйлар. Елашалар, төн буе йокламыйлар. Ә иртән Степан карт терлекләренә печән салырга дип ишек алдына чыга. Шунда җилләр уйнатып, күкләр күкрәтеп килгән тимер кошны күрә бу. Күрә дә тиз генә карчыгын алып чыга. Кош эченнән башта Степан белән Иванны алып кайткан чибәр егет, аның артыннан ак халат һәм култыгына тартма кыстырган бер кеше килеп чыга. Икесе дә, карт белән карчык янына килеп, исәнләшәләр. Актан киенгәне дә яшь кенә, чибәр генә егет икән. Сүзне шунысы башлый:

— Сезгә ярдәм итәр өчен мине монда Ильич җибәрде,— ди ул Степанга.

Аннары барысы да өйгә керәләр. Ак кием кигән егет теге тартмасын ача да аннан төрле дарулар, табип кораллары алып, Иванны дәвалый башлый. Башта Иванның кулына ниндидер дару сөртә. Аннары кечкенә генә шешәсеннән авызына ниндидер дару сала. Шуннан соң күп тә үтми, Иван аңына килә. Берни булмаган кебек, тора да йөри үк башлый. Аннары Степан карт та, карчыгы да, Иван үзе дә теге чибәр егетләргә рәхмәт укыйлар. Ә егетләр әйтә:

— Сез безгә түгел, Ильичка рәхмәт әйтегез! — диләр.

— Сез китми торыгыз. Мин урманга барып кайтыйм әле, берәр бүләк алып кайта алмаммы,— ди аларга Степан.

Степан иске чакмалы мылтыгын ала да урманга кереп китә. Озак та тормый, бик шәп бер кеш атып алып кайта. Һәм әйтә теге егетләргә:

— Шушыны кадерле Ильичка алып кайтыгыз. Бу аңа кешеләр турында кайгыртканы өчен миннән бүләк булсын! Үзем илтеп бирер идем дә барып җитә алмам дип куркам: бик нык картайдым шул инде,— ди.

— Алайса без сине тимер кошыбызга утыртып алып барабыз. Бүләгеңне Ильичка үзең тапшырырсың,— ди теге егетләр.

Аннары Степан картны, гаҗәеп кошка утыртып, үзләре белән алып китәләр. Ә карчык белән Иван, Ильичка сәлам тапшырырга ку-

шып. кул болгап озатып калалар. Гаҗәеп кош күккә күтәрелеп күздән югалгач кына өйләренә керәләр.

Чибәр егетләр һәм Степан карт Мәскәүгә бик тиз барып җитәләр. Гаҗәеп кош Кремльгә килеп төшә. Аннары теге ике чибәр егет Степан картны кадерле Ильич янына алып китәләр. Ильич аларга үзе каршы чыга. Степан карт баш иеп тезләнә дә кешне, Ильич алсын өчен, баш түбәсенә куя. Ильич килеп картны кочаклый, үбә дә әйтә:

— Хәзер тез чүгә торган заман түгел инде, бабай. Элек кенә ул тез чүгә торганнар иде, ә хәзер Совет властенда без барыбыз да бертигез, барыбыз да иптәшләр,— ди. Аннары теге чибәр егетләргә әйтә: — Бабайга Мәскәүнең бөтен матур урыннарын күрсәтергә кирәк. Иң элек Кызыл мәйданны күрсен, аннары метрода, Мәскәү — Идел каналында йөрсен,— ди.

Шуннан соң Степан бабайны Мәскәү буйлап йөртә башлыйлар. Кызыл мәйданга алып киләләр. Метрога барып кергәч, карт андагы чисталыкны, матурлыкны күреп, хәйран кала.

Аннары Степан карт яңадан Кремльгә кайта да илебез ирешкән уңышлар өчен, кешеләр турында чын күңеленнән кайгыртуы өчен, кадерле Ильичка рәхмәт әйтә. Кадерле Ильич Степан картка кыйммәтле бүләкләр бирә. Аннары аны өенә кайтарып куярга куша.

Теге көн киемле чибәр егет Степан картны гаҗәеп кошка утырта да очыртып алып китә. Озак та үтми, Степан картның өенә кайтып җитәләр. Улы белән карчыгы Степанны ишек алдында көтеп торган булалар. Гаҗәеп кошның тавышын ишеткәч, куанычларыннан нишләргә дә белмиләр. Чибәр егет тимер кошны боларның өе янына ук китереп төшерә дә, Степанны калдырып, яңадан Мәскәүгә кайтып китә.

Аны озаткач, Степан карт карчыгы белән улын өйләренә алып керә, аларга кадерле Ильич турында, аның ничек итеп кешеләрне кайгыртуы турында, кайларда булуы,ниләр күрүе турында сөйләп бирә. Аннары өчесе дә кадерле Ильичка рәхмәт әйтәләр [1].

**ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН** тәрҗемәсе.

---

[1] Бу әкият күренекле рус әкиятчесе Е. И. Сороковиков-Магайдан 1938 елда Л. Е. Элиасов тарафыннан язып алынган һәм күп тапкыр басылып чыккан «Фольклор Тункинской долины» исемле җыентыктан алынды. Җыентык 1966 елда Улан-Удэдә басылган.

## Газиз Мөхәммәтшин

# ШУШЕНСКОЕДА ЯЗ

Мин быел кыш көне туган авылым Яңа Бикчәнтәйгә кайткач, гадәтемчә, әтинең бертуган энесе — шәкерт абыйларга бардым. Ул гражданнар сугышында катнашкан, үзе әйткәнчә, «революция ачып» йөргән кеше. Хәзер пенсиядә. Кәгазьләрен актарган чакта аның гади дәфтәр битләреннән тегелгән блокноты килеп чыкты. Ул анда һава хәлләрен, төрле даталарны, исем-фамилияләр, адреслар һәм башка үзенә кирәк булган, я булачак дип уйлаган «белешмәләрне» язып бара икән. Шуның бер битендә мин: «Владимир Ильич Ленин туды 1870 елда, җоклады 1924 тә», дигән юлларны укыдым.

«Җоклады» дигән!

Менә шул сүз мине бик уйландырды һәм тәэсирләндерде.

Әйе, Ленин үлмәгән, һәркемнең күңел түрендә. Ленин исән, ул гүяки эшләгән-эшләгән дә бераз хәл җыю өчен ял итәргә генә яткан. Йоклап кына киткән. Менә уяныр, торыр, яңадан авыр эшенә керешер төсле...

1924 елның 23 гыйнварында, Ленин үлгәннән соң өченче көнне, РКП(б) Үзәк Комитетының «Партиягә. Барлык хезмәт ияләренә» мөрәҗәгате игълан ителде. Үзәк Комитет анда, Ленин эшләренең үлемсезлеген күрсәтеп: «...Әмма аның физик үлеме аның эшләренең үлеме түгел. Ленин безнең партиябезнең һәр члены күңелендә яши. Безнең партиябезнең һәр члены Ленинның бер кисәкчеге ул...»,— дип язды.

Моннан соң инде ничәмә-ничә буыннарның «Ленин бабай» сүзе белән телләре ачылды. Аның оныклары Ленин исеме белән утларга-суларга керделәр, дошман яуларын тар-мар иттеләр, дөньяда беренче социализм дәүләтен төзеделәр.

Мин дә, иптәшләрем кебек үк, аның оныгы. Ул төзегән бөек партиянең гади бер члены, ягъни Ленин бабайның бер кисәкчеге. Мин ул укыган, революцион көрәшнең беренче «чиркәнчеген» алган башкалабыз Казанда яшим. Минем университетта, аның музеенда, ул сөргендә яшәгән Кокушкинода булганым бар. Аның туган шәһәре Ульяновскида, Ленинградның аның исеме һәм эше белән бәйләнгән күп урыннарында, Смольныйда, Разливта, Мәскәүдә В. И. Ленинның Үзәк музеенда, Кремльдә дулкынлана-дулкынлана көннәр буе йөргәнем, берничә мәртәбә озын-озын чиратлар торып, мавзолеена керә алганым бар.

Надежда Константиновна Крупская белән Ильич сөргендә яшәгән ерак Красноярск краенда, Шушенское авылында булу, ул йөргән урыннарны күрү минем күптәнге хыялым иде. Ниһаять, бу теләгем дә тормышка ашты.

1895 елның көзендә В. И. Ленин җитәкчелегендә Петербургның барлык марксистик түгәрәкләре бер политик оешмага берләшәләр. Ул Россиядә пролетар партиясенең башлангычы була һәм декабрь аенда «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы» дигән исемне ала. Ләкин «Көрәш союзы» озак яши алмый. 9 нчы декабрьга каршы төндә Ленинны һәм аның байтак кына көрәштәшләрен кулга алалар. Ленин төрмәдә 14

айдан артык утыра. 1897 елның 13 февралендә аны өч елга Көнбатыш Себергә сөргенгә җибәрү хакында суд карары була. 17 февральдә Ленин озын һәм авыр юлга чыга һәм 8 майда билгеләнгән урынына — Шушенское авылына килеп җитә.

Шулай итеп, Ленинга Петербургтан Шушенскоега барып җиту өчен 81 көн вакыт кирәк була.

Красноярск крае — илебездәге иң зур крайларның берсе. Аның мәйданы илебезнең ун процентын биләп тора. Ягъни, Англия, Франция, ГДР, ФРГ, Италия һәм Испания территориясе кадәр. Красноярскидан Мәскәүгә хәтле 4000, Владивостокка 5000 километр. Бу крайда СССР урманнарының биштән бере үсә. Җирендә тимер, бакыр, бокситлар, кургаш, цинк, алтын, нефелиннар, гипс, мәрмәр, тоз, графит, кара, соры күмер һәм башка кыйммәтле казылма байлыклар бар. Ләкин әлегә халык әз. Бер квадрат километр җиргә фәкать 1 генә кеше туры килә.

Ленин Себергә сөргенгә 1897 елның 17 февралендә чыгып китә. Аны башта арестантлар вагонына утыртып этап белән җибәрмәкче булалар. Ләкин Владимир Ильичның әнисе Мария Александровна Ульянова, полиция департаменты аркылы, улына пассажир вагонында үз хисабына барырга рөхсәт алуга ирешә.

Ленин, юл уңаенда, берничә көнгә Мәскәүгә — әнисе янына туктый. 22 февральдә төнлә белән Мәскәүдән чыгып китә һәм март башында Красноярскига килеп җитә. Хәзер ул туктаган тимер юл вокзалы юк. Аны 1960 елда сүткәннәр һәм ике катлы бина салып куйганнар. Яңа вокзалда «Патша хөкүмәте тарафыннан Себергә сөргенгә җибәрелгән Владимир Ильич Ленин Красноярск станциясенә 1897 елның 4 мартында килеп җитте» дип язылган истәлекле такта кадакланган.

Красноярск 1628 елда салына башлаган. Кача елгасы Енисейга койган тамакта кызыл балчыклы текә яр бар. Исеме шуннан алынган — Красный яр, ягъни.

Иксез-чиксез крайның төньягында — Подкаменная Тунгускада — кар ява. Термометр 25 градус суыкны күрсәтә. Ә көньякта — яңгыр, 8 градус җылылык. Красноярскиның үзендә дә кояш, җылы. Шәһәр үзәге — Тынычлык проспектында кызыл һәм ал чәчәкләр саталар. Тротуарлардан халык агыла. Шәһәр Ленин көннәре белән яши. Красноярскида һәм крайның башка урыннарында, районнарында Ленин музыкаль фестивале дәвам итә. Абаканда, Шушенскоеда, Дивногорскида, Ачинскида, Боготолда, Ужурда, Норильскида, Минусинскида һәм урман хуҗалыкларында башкалабыз кунаклары — СССРның халык артисты, Зур театр солисты Павел Герасимович Лисициан, Ленинградның Римский-Корсаков исемендәге дәүләт квартеты, Мәскәүнең Прокофьев исемендәге квартеты, скрипкачы Игорь Безродный, виолончельчы Яков Слободкин, Татарстанның атказанган артисты, Бөтенроссия конкурсы лауреаты Георгий Бальян, Магнитогорск дәүләт хор капелласы, Новосибирскиның симфоник оркестры һәм башка коллективлар үз һөнәрләрен күрсәтәләр.

Кино-театрларда В. И. Ленинга багышланган кинофестивальләр үткәрелә. Мәсәлән, «Пионер»да «Беренче курьер», «Ленин Октябрьда», «Юбилейный»да «Ленин Польшада» фильмнары, бик күп документаль ленталар күрсәтелә, күргәзмәләр оештырыла.

Красноярскиның А. С. Пушкин исемендәге драма театры, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап, М. Шатровның «Большевиклар» исемле драмасын сәхнәләштерген. 22 апрельдә аның премьерасы булды. Тамашачылар драманы яратып кабул иттеләр.


Декабрь аенда Красноярскида «Социалистик Себер» исемле өченче зона сәнгать күргәзмәсе ачылачак. Анда Алтай, Красноярск крайлары, Иркутск, Кемерово, Новосибирск, Омск, Томск өлкәләре, Тува автономияле республикасы рәссамнары катнаша. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Б. Ряузов «Ленин урыннары буйлап» дигән гомуми баш астына берләштерелгән табигать күренешләре сериясен эшли. В. Мешков, Т. Ряннель, К. Вальдман, В. Сергиннар да шул ук темага картиналар язалар. А. Климанов белән Б. Белый икесе бергәләп «Ленин һәм халык. Шушенскоеда очрашулар» дигән композиция әзерлиләр. Ул бик кызык кына булырга охшый. Яшь рәссам В. Башмаков «Ленин Шушенскоеда» исемле полотно өстендә эшли. Бу — аның беренче җитди картинасы.

Скульптор В. Павленко Ленинның Шушенскоеда яшәгән чорын чагылдырган мәрмәр портретын, А. Абдрахимов Ермаково авылында куяю өчен революционер Ванеевның һәйкәлен эшли.

Башка рәссамнарның һәм скульпторларның хезмәтләрендә дә Ленин темасы, бигрәк тә аның Шушенскоедагы тормышы күп чагыла. Иҗат кешеләре күңелләренә якын шушы темага кабат-кабат әйләнеп кайталар, юлбашчының 100 еллыгын яңа иҗат бүләкләре белән каршыларга тырышалар.

РСФСР художниклар союзының Красноярск бүлегендә мин югарыда исемнәре телгә алынган картиналарның берничәсе белән таныштым. Художник Владимир Николаевич Сванов «Казан утлары» журналында бастыру өчен, үзе эшләгән берничә ксилографиясен бүләк итте.

Красноярскида Ленинның 100 еллык юбилеена әзерлек эшләре әйбәт куелган. Һәркайда хезмәт кайный. Ә крайда Ильичның сөргендә булуы белән турыдан-туры



Красноярскида К. Г. Попова йорты.
В. Н. Сванов рәсеме

бәйләнешле урыннар әз түгел — 22. Болардан тыш тагын истәлек такталары һәм һәйкәлләр куелган 8 урын бар. Край советы башкарма комитеты бу урыннарны үрнәк тәстә тәртипкә китерү турында махсус карар кабул итте. Мәсәлән, Минусинскида элек Кржижановский белән Старков яшәгән квартирада (монда Ленин еш булган) «В. И. Ленин Минусинскида» дигән музей экспозициясе ачылачак. Ермаково райсоветы да, атаклы «17 нең протесты» язылган йортны рәтләп, анда «Политик сөргендәгеләрнең В. И. Ленин җитәкчелегендә революцион эшчәнлеге» исемле экспозиция ачачак. А. А. Ванеев каберенә һәйкәл (бюст) кую һәм аны ачу тантанасы булды.

Ленин Красноярскига килгәч, К. Г. Попова йортында туктала. Ул политик тоткындагылар килеп йөри торган бик билгеле йорт була. Ленин анда сөргендәге социал-демократлар, поляк революционерлары белән сөйләшә.

Бу йорт та хәзер юк. Аны 1909 елда ук сүткәннәр. Соңыннан мин бу хакта край музееның Октябрьга кадәрле тарих бүлеге мөдире Валентина Ивановна Парамонова һәм шул ук бүлекнең фәнни хезмәткәре Зина Николаевна Нефедева белән сөйләштем. Алар миңа шул ук урында күрше Белянинннар йортында тарихи экспозиция эшләнүен һәм озакламый әзер булачагын әйттеләр. Ә хәзергә ул ишек алдында В. И. Ленин барельефы уелган таш обелиск тора.

Ленин Красноярскида ничек ике айга якын яши алган соң? Рөхсәте ничек алынган? Красноярскида Ленин Иркутск генерал-губернаторына үтенеч яза. Сәламәтлеге как-

шавын сәбәп итеп, үзен Енисей губернасының көньягына җибәрүләрен сорый. Үтенечене җавап китә. Ә чиновниклар аппараты бик әкрен кыймылдый. Әмма Ленин ептырамый. Аңа нәкъ шул гына кирәк була да. Бик күп эшли, укый. Шәһәр китапханәсенә даими рәвештә йөри. 1897 елның 15 мартында әнисенә җибәргән хатында ул болай дип яза:



Красноярск шәһәр китапханәсе.
В. Н. Сванов рәсеме

«Шәһәр китапханәсенә йөрим: анда журналлар һәм газеталар карарга мөмкин; алар монда 11 нче көнне килеп җитәләр, һәм мин андый соңгы «яңалыкларга» һаман да күнегә алмыйм әле.» (В. И. Ленин. 55 нче том. 26 бит.)



Г. В. Юдин китапханәсе.
В. Н. Сванов рәсеме

Шәһәр китапханәсе ул чакта Покров тыкрыгында булган. Хәзер ул Суриков урамы дип атала. Мин аны барып карадым. Аскы каты җиргә нык кына казып салынган ике катлы йорт. Фасадына: «Монда 1897 елның март—апрелендә, 1898 елның сентябрендә

В. И. Ленин йөргән шәһәр китапханәсе урнашкан иде» дигән истәлек тактасы кадакланган.

Ленин сәүдәгәр Г. В. Юдин китапханәсенә дә бик еш йөри. Аның 100 мең китабы, кулъязмалары һәм журналлары була. Ленин анда көн саен бара, әшли, Россия экономикасы үсешен өйрәнә.

Ә бу вакытта полиция ведомстволарында дау куба: полиция В. И. Ленин фамилиясен дәүләт исәбенә баручылар исемлегеннән сызарга оныткан була. Тикшергәндә күрәләр — Ленин юкка чыккан. Хатлар язышалар, дөнья бетереп Ульяновны эзлиләр һәм аны... Красноярскида полиция күзәтүе астында яшәгән хәлдә табалар.

Элек Юдин китапханәсе буяган йорт хәзер истәлекле йорт булып санала. Анда Красноярск край музееның экспозициясе урнаштырылган...

1897 елның 24 апрелендә Ленинны губерна идарәсенә чакыралар һәм аның сөрген урыны итеп Шушенское авылы билгеләнүен әйтәләр. 30 апрельдә, иптәшләре Кржижановский һәм Старков белән бергә, Ленин «Изге Николай» пароходында утырып Минусинскига китә.

Хәзер бу пароход та, иске вокзал да юк. Яңа вокзал каршында мәрмәр постаментта «Изге Николай» пароходының үтә күренмәле калпак белән капланган макеты тора.

Енисейдан биш тәүлек барганнан соң пароход Сорокино пристанена туктый. Ленин иптәшләре белән Минусинскига кадәр 80 чакрым араны ат белән үтә. Минусинскида ике көн торганнан соң, ике жандарм сагы астында Ленин Шушенскоега чыгып китә һәм 8 майда үзенең сөрген урынына: тимер юлдан 600 чакрым читтә торган, 254 өйле, 1 чиркәүле, 4 лавкалы, 2 кабаклы, 1 укытучысы һәм 30 укучысы булган Шушенское авылына килеп җитә.

Аны крестьян Зырянов йортына урнаштыралар. Кечкенә генә бүлмәгә агач кровать, өстәл, дүрт урындык куела. Хөкүмәт аңа аена 8 сум пособие билгели. Тыйнаклыкны сөюче, азга да канәгать кылучы Ленин сөргендә, башлыча, әнә шул акчага яши.

Хәзер Шушенское зур поселок. Аңа поезд белән дә, автобус, пароход һәм самолет белән дә килергә, китәргә мөмкин.

Шушенскоеда башта В. И. Ленин һәм Н. К. Крупская исемендәге колхоз була. 1963 елда ул В. И. Ленин исемендәге совхоз итеlә. Совхозның 24 890 гектар җире, 75 тракторы, 32 комбайны, 50 автомашинасы, 4000 эре терлеге, 20 000 кош-корты, җиләкҗимеш бакчасы бар.

Элек бер башлангыч мәктәбе булган Шушенскоеда хәзер 150 укытучы эшли. Авыл хуҗалыгы техникумында гына да 1200 студент укый. 262 медицина хезмәткәре халыкның сәламәтлеге хакында кайгырта.

Элек монда китапханә булмаган, бөтен Шушенское өязендә 7 кеше газета алдырган, ә хәзер 6 китапханәдә йөз мең китап бар, халык егерме меңнән артык газета һәм журналга язылган.

«Бездә кешеләр әйбәт, тырыш,— ди совхоз директоры Н. Сергиенко.— Дүртенче бүлек җитәкчесе Николай Иванович Бушмеловны чын мәгънәсендә иген үстерү остасы дияргә мөмкин. Сыер савучы Социалистик Хезмәт Герое А. В. Косыхны бөтен край белә. Растова, Жукова, Тамара Примиренко да аңардан калышмый».

Әйткәнемчә, Шушенскоега төрле юллар белән барырга була: җирдән дә, судан да, күктән дә. Мин Хакассия автономияле өлкәсенең башкаласы Абаканга самолетта очтым. Абакан белән Шушенское арасы 79 чакрым. Монда комфортабельле автобуслар йөреп тора.

Автобус асфальт шоссе буйлап алга чаба, Абакан һәм Енисей елгаларын үтә, Абаканнан Тайшетка ашыгучы поезд белән ярышырга теләгән шикелле, бераз тимер юл белән янәшә бара. Ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, сул якта Минусинск шәһәре күренә. Ләкин автобус аңа кереп тормый, киң далага килеп чыга да тагын да шәбрәк чаба башлый. Уң кулда зур күл ярында Тагарское курорты күзгә чалынып кала. Знаменка авылын үткәч, автобус Думная тавына күтәрелә. Тау башыннан Шушенское күренә башлый. Таудан төшкәч, Оя елгасын, Казанцево авылын үтсәң, Борылышта таш обелиск. Анда: «1897 елдан алып 1900 елга кадәр бөтендөнья пролетариатының юлбашчысы В. И. Ленин яшәгән Шушенское авылына», дип язылган. Бу юл күрсәткечтән Шушенскоега кадәр тагын 12 чакрым кала.

Автобус туры һәм тип-тигез юлдан тизлеген арттырганнан арттыра барып алга ыргыла. Уңда — колхоз басулары, сулда — нарат урманы. Еракта Енисей борылмалары ялтырый, ә тагын да арырак түбәсендә җәй көне дә кар эреми торган Саян сыртлары зәңгәрләнеп күренә...

Автобус Шушенскоеның үзәк мәйданына җитеп туктады. Бер якта өч катлы Советлар йорты, аның каршысында шулай ук өч катлы Культура йорты, өченче якта «Саян» гостиницасы, ашханә, гостиницага каршы — универмаг.

Бу урын, әйтергә кирәк, Советлар Союзы кешеләрен генә түгел, бөтендөнья хезмәт ияләрен тартып тора. Монда җәйге экскурсиягә, яңгырларга, кышкы салкыннарга, бураннарга карамастан, һәр көнне җирнең төрле почмагыннан төрле кешеләр килә. Алар, килү белән, Ленин һәм аның тормыш иптәше, көрәштәше Н. К. Крупская яшәгән йортларга ашыгалар.



Ульянов-Ленин. 1898 ел.
В. Н. Сванов рәсеме

Йорт-музейлар икәү. Беренчесе крестьян Аполлон Долмантьевич Зырянов йорты. Анда Ильич Надежда Константиновна килгәнче яшәгән. Икенче музей — Петрова йорты. Н. К. Крупская һәм аның әнисе килгәч, Зыряновлар өендәге кечкенә бүлмә өч кешегә тору өчен тыгыз, уңайсыз булып кала. Шуннан алар тол хатын Петрова йортына күчәләр һәм сөрген срогы беткәнче шунда яшиләр.

Зыряновлар йорты хәзер нәкъ Ленин торган чактагы хәлгә китерелгән. Бу эшне Михаил Пушкарев бригадасы башкарган. Аска мәңге торырлык итеп бетон нигез салынган. Нигез өстенә, якынча, элек өй салыр өчен киселгән яшьтәге агач өрлек салынган. Өй эчендә штукатурка куптарып алынган. Ике рус миче, бер голланд миче чыгарылган. Чолан, сәндерәләр эшләнгән. Ишек алдында юан бүрәнәләрдән мал-туар абзары, келәтләр салынган.

Ул 14 ай яшәгән 14 квадрат метрлы кечкенә бүлмәгә ак ашъяулыклы гади өстәл, өстәлгә яшел абажурлы лампа, өстәл тирәсенә 4 урындык, почмакка Ленин йоклаган борынгы агач кровать куелган. Йорт хуҗасы ясап биргән такта киштәгә һәм почмаклардагы ике өстәлгә китаплар, газета-журналлар тезелгән, стенага барометр эленгән һәм идәнгә гади крестьян паласлары җәелгән.

1896 елның августында «Көрәш союзы»ндагы эшләре өчен Н. К. Крупская да кулга алына.

Ул В. И. Ленин белән беренче мәртәбә 1894 елда Петербург марксистларының Р. Э. Классон квартирасында уздырылган җыелышларында очраша. Шуннан соң алар ныклап танышып китәләр, дуслыклары әкренләп чын мәхәббәткә әйләнә.

Н. К. Крупскаяны Уфа губернасына өч елга сөргенгә җибәрергә хөкем итәләр. Ләкин ул, В. И. Ленинның кәләше буларак, үзен Шушенскоега җибәрүләрен сорап эчке эшләр министрына мөрәҗәгать итә. Крупская Ленин янына барып җитү белән законлы никахка кермәсәләр, кире Уфага кайтарылу шарты белән, аңа рөхсәт бирелә.

1898 елның 7 маенда Н. К. Крупская, әнисе Елизавета Васильевна белән, Шушенскоега килеп җитә. 10 июльдә Крупская белән Ленин Шушенское чиркәвендә никахланалар. Чөнки властьлар чиркәү никахын гына таный. Ильичның сөргендәге иптәше Путилов эшчесе Оскар Александрович Энгберг аларның икесенә дә бакыр балдаклар ясап бирә.

Шул ук июль аенда алар иген сәүдәгәренең тол хатыны Прасковья Олимпиевна Петрова йортына күчәләр һәм анда сөрген срогы беткәнче яшиләр.

Бу квартира беренчесеннән ерак түгел, Шушь елгасы ярында. Бу алты почмаклы йортны 1840 елда декабрист А. Фролов проекты буенча икенче бер декабрист П. Фаленберг өчен салганнар. Ә 1856 елда, амнистия игълан ителгәч, Фаленберг аны Петровка сатып киткән. 130 еллап торса да, әле ул бик яхшы сакланган. Музей каршысына биек пьедесталга Ленинның бронза скульптурасы куелган, өйнең урам як стенасына: «Бу йортта 1898 елның июленнән 1900 елның февраленә кадәр дөнья пролетариатының юлбашчысы В. И. Ленин яшәде» дип язылган истәлекле мәрмәр такта кадакланган.

Ишек алдындагы каралты-кураларны музей ачкан чакта сүтеп бетергәннәр һәм алар урынына бакча утыртканнар.

Ленин эзләреннән Шушенскоега килгән һәр кеше кебек үк, мин дә шушы кадерле йортка ашыктым. Ишек алдында, капкадан кергәч тә уң якта, тал чыбыкларыннан



Шушенскоеда В. И. Ленин музей-йорты.
К. Т. Луканин рәсеме

ясалган беседка тора. Ул — Ленин һәм Крупская ясаган беседканың төгәл копиясе. Җәй көннәрендә аны колмак каплап китә торган булган. Ленинннар шул яшел «куыш» эчендә ял итәргә яратканнар. Ленин эссе көннәрдә шуның җиләс күләгәсендә эшләп тә утырган.

Баскычтан менгәч, кечкенә өйалдына, аннан кухняга килеп керәсең. Уң кулдагы бәләкәй бүлмәдә Маша Мозина исемле кыз йоклаган. Ул Надежда Константиновнага һәм аның әнисе Елизавета Васильевнага йорт эшләрендә булышкан. Хәзер бу бүлмәдә Советлар Союзы һәм чит ил хезмәт ияләреннән музей-йортка килгән бүләкләр саклана. Менә Ленинның ак фарфордан эшләнгән бюсты. Ул — Ленинград комсомол-студентларының бүләге. Ленин 1897 елда үткән юллардан алар Шушенскоега мотоцикллар белән килгәннәр. Волгоградның эшче яшьләре музейга Мамай курганының кан сеңгән, снаряд кыйпылчыклары белән буталган туфрагын һәм андагы һәйкәлнең бронза макетын бүләк иткәннәр. Бу бүлмәдә Тын океан хәрби диңгез флоты моряклары китергән корабль макеты, матрос тельняшкасы белән бескозыркасы, РСФСРның халык художнигы Н. Н. Жуков тапшырган рәсемнәр. Корея — Совет дуслыгы оешмасы бүләк иткән Ленин әсәрләренең корея телендә чыккан 47 томлыгы, Кытайның Хэйлун-Цзян провинциясе эшчеләренең үзләре килгәч бүләк итеп калдырган ефәк белән чигелгән ике картинасы, тагын йөзләрчә урыннардан, йөзләрчә кешеләрдән килгән бүләкләр саклана.

Кухня да зур түгел. Сыңар тәрәзәсе ишек алдына карый. Почмакта зур мич тора.

Ул мичтә Н. К. Крупская, әнисе белән бергәләп, ашлар пешергән. Бу бүлмәдә тагын кухня өстәле, савыт-саба шүрлеге, юынгыч бар.

Чираттагы бүлмә — аш бүлмәсе. Анда Елизавета Васильевна йоклаган. Монда өстәл, агач диван, ике кресло, дүрт урындык, кровать һәм борынгы буфет бар. Буфетта стаканнар, агач кашыклар, пычак, агач саплы чәнечкеләр, тәлинкәләр, кәстрүлләр һәм бүтән савыт-саба.

Ленин янына еш кына крестьяннар килеп йөргәннәр. Ленин аларның хәлләре белән кызыксынган, якшәмбе саен юридик консультацияләр биреп торган булган. Ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торган. Шуның өчен Шушенское һәм тирә-як кешеләре Ленинны бик яратканнар.

Ленин һәрвакыт эштә булган. Күп укыган, язган. Россиядә марксистик-революцион партия төзүне үзенә максат итеп куйган. Бары тик шундый партия гына Россия пролетариатының юлбашчысы була ала.

Аш бүлмәсеннән соң коридор шикеллерәк бер кечкенә бүлмә бар. Анда хәзер Ленин Шушенскоега алып килгән кәрзиннең копиясе, Петрова милкенең макеты куелган.

Моннан соң почмактагы зуррак бүлмәгә керәсең. Ул Ленинның эш бүлмәсе дә, аларның йокы бүлмәсе дә. Бүлмәнең түр ягындагы агач конторкада Ленинның ручкасы, кара савыты һәм аяклы яшел абажурлы лампа. Ленин шул конторка артына басып төннәр буе язган. Тәрәзә янында кечкенә өстәл. Өстәл өстендә бакыр шәмдәл. Ике борынгы кресло. Почмакта китап-журналлар белән тулган шкаф.

Мондагы социал-демократларның кайберләре сөргенне бик авыр кичерәләр, күбесе авырый башлый, корбаннар да аз булмый. 1898 елның җәендә Верхоленскида, полиция эзәрлекләүләренә, шундагы берәүнең яла ягуларына, авыр мохтаҗлыкка түзә алмыйча, Николай Евграфович Федосеев үзен-үзе үтерә. Бу үлем рус социал-демократлары өчен зур югалту була. Ленин аны бик авыр кичерә.

Елга якын вакыт үтә. Сөргендәге иптәшләре аның каберенә таш кую өчен акча җыялар. Бер чакны Ляховский бу хакта Ленинга хат яза. Ә жандармнар шул хатның квитанциясен эләктереп алалар. Ленин квартирасында тентү үткәрү өчен бик яхшы сәбәп табыла. Тентү 1899 елның 2 маенда була. Ленин жандармга урындык бирә. Жандарм урындыкка басып китап шкафының өске шүрлеген карарга тотына. Аска төшеп җиткәнче арый һәм иң астагы шүрлекне бөтенләй тикшереп тә тормый. Ә Ленинның патша охранкасы кызыксына торган хатлары нәкъ әнә шул аскы шүрлектә була. Шулай итеп, Ленинның алдан күрүчәнлеге аларны Шушенскоеда озаграк яшәүдән коткарып кала, чөнки жандармнар ул хатларны тапсалар, сөрген вакытын, һичшиксез, тагын берничә елга арттырырлар иде.

Арткы бүлмәдә йорт хуҗасы Петрова яшәгән. Хәзер монда В. И. Ленинның Шушенскоедагы тормышын һәм революцион эшчәнлеген чагылдырган экспозиция. Шунда ук В. Солдатова-Лаврованың «Шушенскоеда Ленин квартирасында тентү» дигән картинасы эленеп тора.

Ленинга иптәшләреннән һәм дусларыннан, көрәштәшләреннән аерылып ерак сөргендә яшәү җиңел булмый, билгеле. Ул башта, күңелен күзгатмас өчен, кулына хәтта Европа картасын да алмый. Ләкин полиция күзәтүләре дә, көтелмәгән тентүләр һәм башка кыенлыклар да аның тимер ихтыярын, революциянең җиңүенә тирән ышанычын, бетмәс-төкәнмәс энергиясен, гадәттән тыш эшчәнлеген какшата алмый.

Яшь Ульяновның бу вакыттагы бөтен гомере Россиядә революцион марксистик партия оештыруга багышланган була. Ә моның өчен кыска гына вакыт эчендә күп кенә теоретик проблемаларны эшләргә, рус революцион хәрәкәтен яңа тарихи шартларда көрәш методлары белән коралландырырга кирәк була. Бу көрәш ике юнәлештә — теориядә һәм практикада эшләнә.

Ленин Шушенскоеда «Рус социал-демократларының бурычлары», «Россиядә капитализмның үсеше», «Безнең программа», «Россия социал-демократларының бурычлары» кебек зур хезмәтләрен, барлыгы 30 дан артык әсәрен яза.

Шушында ук Ленин яшерен газета оештыру, аны чит илдә чыгару турында уйлый башлый. Соңыннан ул газета «Искра» була.

Ленин белән Крупскаяның көннәре эш белән үтә. Алар икәүләп чит ил китапларын

тәрҗемә итәләр, бергәләп Ленинның китапларын күчереп язалар. Надежда Константиновна монда үзенең «Хатын-кыз эшче» дигән беренче брошюрасын яза.

Ленин Россиядәге һәм чит илдәге социал-демократ оешмалары, күп кенә пролетар революционерлар белән ныклы элемтә урнаштыра. Аңа бөтен җирдән, Урта-Колымадан башлап Женевалардан хатлар агыла. Шунлыктан ул дөнья хәлләре белән һәрвакыт танышып бара. Шуның өстенә ул күп кенә газета һәм журналлар алдыра.

Ленин сөргендәге көрәштәшләре белән дә ныклы элемтәдә тора, еш кына күрешә, сөйләшә, я алар үзләре Шушенскоега җыелалар, я Ленин үзе алар янына барып чыга. Аның иптәшләре арасында А. А. Ванеев, В. К. Курнатовский, Г. М. Кржижановский, Ф. В. Ленгник, З. П. Невзорова-Кржижановская, П. Н. Лепешинский, О. Б. Лепешинская, Н. Н. Панин, А. С. Шаповалов шикелле күренекле революционерлар да була.

1899 елда немец социал-демократы Э. Бернштейнның социал-демократларның бурычлары турындагы китабы басылып чыга. Ул анда пролетариат диктатурасыннан, эшчеләр классының революцион көрәшеннән баш тартырга чакыра. Рус «экономистлары», мәсәлән, Булгаков, Туган-Барановский, Кускова ишеләр шул ук карашны алга сөрәләр. Ленин моңа каршы «Россия социал-демократларының протесты»н яза, «Экономист»ларга марксизмнан чигенүләре өчен җимергеч удар ясый.

1899 елның җәендә протестны тикшерү өчен Ермаковское авылында сөргендәге социал-демократларның киңәшмәсе җыела. Аңа 17 кеше, киңәшмәгә катнашучыларның һәммәсе дә, кул куя. Ул «Сөргендәге 17 социал-демократның протесты» исеме белән, кул кую өчен башка политик сөргендәгеләргә дә җибәрелә, аннан Г. В. Плеханов җыентыгында басылып чыга, марксистик оешмаларга таратыла һәм, «экономистлар»га каршы көрәштә, Россиядә марксистик фикернең үсешендә, эшчеләрнең революцион партиясен әзерләүдә зур роль уйный...

Ленин, күп эшләве белән бергәттән, файдалы ял да итә белә. Ул җәяү йөрүне ярата. Балык тота, конькида шуа, шахмат уйный, ауга йөри. Хәтта Н. К. Крупская килгәндә дә ул ауда була.

Авыл хуҗалыгы техникумы янындагы нарат урманында Комлы тау, авылдан дүрт чакрым җирдә Торналар тавы бар. Ленин аларда еш булган, ерак-еракларга, Саян тауларына карап уйланып утырырга яраткан. Торналар тавыннан киткәч, Каурыйлы (Перово) күле янында, аучылар шалашы бар. Бу шалашта ауга йөргән чакларында Ленин кунып та калгалаган.

Хәзер бу урыннарда 600 гектар җирне биләп торган заповедник. Шалаш музейның бер экспонаты булып хисаплана. Шушенское музеена килгән экскурсантлар күлгә һәм шалашка бармый калмыйлар.

Сөргендә яшәгән чагында Ленин Минусинскида һәм Минусинск өязенең берничә авылында була. Шушенскоедан 45 чакрымда Ермаково авылы бар. Ленин анда беренче мәртәбә 1899 елның җәендә «Протест»ны тикшерү киңәшмәсенә, икенче тапкыр шул ук елның 8 сентябрендә туберкулездан үлгән Ванеевны җирләргә бара. Ванеев кабере янында Ленин соңгы сүз сөйли һәм озакламый аның каберенә «Анатолий Александрович Ванеев. Политик тоткын. 1899 елның 8 сентябрендә үлде. 27 яшендә. Туфрагың җиңел булсын иптәш» дип язылган чуен такта эшләтеп куя.

Шушенскоедан 25 чакрым ераклыгында Ивановка авылындагы шикәр заводында инженер-химик булып эшләүче Виктор Константинович Курнаковский янына 1898 елның октябрендә Ленин Крупская белән бергәләп бара.

Шушенскоедан 70 чакрым ераклыгындагы Тесь авылында Ленинның «Көрәш союзы» буенча иптәшләре Г. М. Кржижановский белән В. В. Старков яши. Ленин 1897 елның 29 сентябрендә шунда биш кич кунып кайта. 1899 елның җәендә Ленин, шундагы бер тауда геологик күзәтүләр алып бару хәйләсе белән рөхсәт сорап, Крупская белән бергә бара һәм анда алар өч көн торалар.

Үзе «шәһәр-авыл» дип аталган Минусинск шәһәрендә Ильич берничә мәртәбә була. Политик тоткыннар белән очраша, край музееи оештыручы Н. М. Мартьянов белән таныша, аның китапханәсенә йөри. Хәзер ул йорт Н. М. Мартьянов исемендәге музей. Биредә Ленин эшләгән китапханә бүлмәсе мемориаль итеп саклана.

Сөрген срогы ахырына якынлашкан саен, Владимир Ильич түземсезләнә бара. Аның йокысы кача, ябыга. Йокысыз төннәрдә киләчәккә планнар кора, эшкә атлыга. Моның өстенә, сөрген вакытын озынайтмасалар ярар иде, дигән борчылу да өстәлә.

1899 елның 16 декабренда полиция департаменты В. И. Ленинга сөргеннән соң 3 ел буе Петербургта, Мәскәүдә, университетлы һәм промышленность алга киткән шәһәрләрдә (барлыгы 60 шәһәр) яшәүне тыя. Ленин үзенең яшәү урыны итеп Петербургка якын булган Псковны сайлый. Ә Надежда Константиновнага сөргеннең калган срогын Псковта ире янында үткәрергә рөхсәт итмиләр, шунлыктан ул аны Уфада тутыруны сорап үтенеч бирә.

1900 елның 19 январенда Н. К. Крупская Владимир Ильичның әнисенә түбәндәге хатны яза:

«Кадерле Мария Александровна! Ниһаять, мәсьәлә ачыкланды: Россиягә китәргә мөмкин, срокны арттырмаслар шикелле. Әйберләрне 28 ендә җибәрәбез, ә 29 ында үзебез кузгалабыз... Хәзер безнең бөтен сүз юл турында гына. Китапларны ящикка тутырдык һәм үлчәдек, 15 потлап була. Китапларны һәм әйберләрнең бер өлешен



Каурый күле.
К. Т. Луканин рәсеме

транспорт белән җибәрәбез, хәер, безнең әйберләр, мөгаен, бик күп булмас шикелле... 29 ына кадәр вакыт тизрәк үтсен иде, китәргә булгач китәргә...» (В. И. Ленин, 55 том, 180—181 битләр.)

1900 елның 29 январенда, нәкъ сөрген срогы беткән көнне, Ленин, Крупская һәм аның әнисе Елизавета Васильевна атка утырып Минусинскига чыгып китәләр. Озатырга сөргендәге иптәшләре, крестьяннар җыела.

Ульяновлар семьясы шул ук көнне Минусинскига килеп җитә. Анда аларга В. В. Старков белән О. А. Сильвина кушыла. Шактый көчле салкыннарга да карамыйча, 300 чакрым юлны көне-төне баралар һәм Ачинскига җитеп поездга утыралар.

Ленинның һәм Крупскаяның Себер тормышы шулай тәмам була...

Бу көннәрдән соң 70 ел узды.

1938 елда КПСС Үзәк Комитетының карары белән Шушенскоеда Ленин яшәгән йортларда Ленинның музей-йорты ачылды. Бүгенгә кадәр анда 2 миллион кеше булды. Музейга килүчеләр үзләренең тойгыларын махсус кенәгәләргә язып китәләр. Андый кенәгәләр хәзер 20 том җыелган.

Менә алар — ике калын альбом. Берсенең тышына «Сез Ильичка нәрсә әйтер идегез» дип язылган. Мин андагы язулар белән таныша башладым. Кемерово шәһәрендәге 1 номерлы мәктәпнең 3 «А» класс укучысы Ленин бабасына болай дип яза:

«Кадерле Ильич!

Безнең бәхетле балалыгыбыз өчен сиңа рәхмәт! Тиздән мине пионерга алачаклар. Яхшы укырга вәгъдә бирәм».

Менә Шушенскоедагы ГПТУ-44 тәге 8 группа укучыларының язуы:

«Безнең кадерле Владимир Ильичыбыз! Безнең матур тормышыбыз өчен сезгә зур рәхмәт! Без сезнең сөргендә яшәгән урыныгызны гүзәл истәлек-шәһәргә әйләндерергә вәгъдә бирәбез.

Булачак төзүчеләр».

Петрозаводск шәһәренең 7 нче урта мәктәп укучылары музейда 4 январь көнне булганнар һәм мондый язу калдырганнар:

«Дөньяда бөек юлбашчы яшәгән шикелле яшәргә һәм Ватаныбызга Ленин хезмәт иткән шикелле хезмәт итәргә ант итәбез!»

Тагын бер вәгъдә:

«Кадерле Владимир Ильич!

Үземнең укучыларымны коммунизм төзүчеләре итеп тәрбияләячәкмен. Мин ышанам — алар сезнең барлык хыялларыгызны тормышка ашырачаклар.

Запорожье шәһәре, УССР, 3 нче мәктәпнең физика укытучысы Хухашвили П. В.».

Ә берәү исем-фамилиясен дә күрсәтмичә:

«Ленинны яратабыз,

Ленинны истә тотабыз,

Һәрвакыт шулай булыр!» — дип куйган...

Кенәгәләрдә төрле алфавит белән бик күп телләрдә: русча, японча, корейча, хакассча, немецча, французча, инглизчә, украинча, грузинча, гарәпчә, һиндчә, казакъча һ. б., һ. б. рәхмәт хисләре, җылы фикерләр, дулкынландыргыч тойгылар язылган. Өстәл өстендә торган соңгы кенәгәдә мин саф татарча язылган сүзләргә дә юлыктым. Аны тулысынча күчереп алдым. Менә ул:

«Мин Татарстан республикасы (башкалабыз Казан) Тәтеш районы Бидәңгә авылыннан юлбашчыбызның сөргендә булган урынын карарга килдем. Экскурсовод бик яхшы итеп аның тарихын сөйләде. Мин дә, авылыбызга кайткач, үз күзләрем белән күргәнне сөйләрмен. Миңа юлбашчының йөргән урыннарын күрү зур бәхет. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап альбом ясаячакмын.

32 ел укытучы булып эшләүче Фахрутдинова Рокыя Шакировна. Бидәңгә авылы, Тәтеш районы. 27. VI. 1968 ел».

Ерак Себернең Саян таулары итәгендәге ерак бер авылында бу юлларны укыгач, якташымны очраткан шикелле булдым. Рокыя апага яшь буынны Ленин идеяләренә тугрылыклы чын көрәшчеләр итеп тәрбияләүдә уңышлар, сәламәтлек телибез!

«Якташымны очраткан шикелле булдым» дигән сүзләргә өстәп тагын шуны әйтәсем килә: тегә фикерләр, тәкъдимнәр кенәгәсендә мин тагын Казаннан килгән укытучы-туристлар калдырган язманы да укыдым. Аңа группа җитәкчесе Ершов С. Н. кул куйган.

Татарстанны, Казан, Уфаны мин һәрвакыт үз янымда шикелле тоеп тордым. Гүя беркая да чыгып китмәгәнмен, һаман Татарстанда йөрим. Красноярскиның А. С. Пушкин исемендәге театрында Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» исемле трагедиясе бара икән. 18 апрельдә дә куелды. Шәһәрдәге тумбаларның күбесенә бу хакта афишалар ябыштырылган иде.

Икенче көнне Красноярскиның үз радио челтәре Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы буенча эшләнгән радиопостановка тапшырды.

Шушенскоеның җәйге кино-театрында «Верения» картинасы алдыннан «Ленин Казанда» исемле киножурнал күрсәттеләр. Ә шул ук кино-театрның фойесында, иң яхшы картиналарның афишалары рәтеннән, «Моабит дәфтәре» картинасының афишасы эленгән. Кергән кешеләргә күзләрен тутырып Муса Җәлил карап тора...

Мин элекке кухня бүлмәсендә кенәгәләрне карыйм. Аларны, язу өчен, әледән-әле миннән алып торалар. Чөнки музейга килүчеләр бик күп, экскурсияләр шактый. Алар төркем-төркем, 20 шәр, 30 ар кеше ишек алдында, урамда чират көтәләр. Экскурсоводларга эш күп, алар бакча ишегеннән бер төркемне чыгарып җибәрүгә бу ишектән баскыч тулып торган икенче төркемне килеп алалар. «Җанлы конвейер» көн озын өзлексез әйләнә дә әйләнә, музей кич булып кояш баегач кына тына.

Шулай ике экскурсия арасында минем каршыга шушы музейда инде 27 ел буена экскурсовод булып эшләүче Никулина килеп утырды.

— Уф! — диде.— Ленин көннәрендә һәрчак шулай. Бүген музейда 370 укучы пионерга алынды, 1400 экскурсант булды инде.

— Кайлардан килгәннәр, Прасковья Павловна? — дип сорадым мин.

— Үзебезнең Себернекеләр бик күп. Сахалиннан, Куриль утрауларыннан, Карпаттан, Кемерово елкәсеннән, Мәскәүдән, Казаннан берәү — аңысы сез буласыз.

Никулина әйткәндәй, Ленин көннәрендә монда чыннан да «урак өсте» башлана. Элекке ярминкәләргә җыелган шикелле халык җыела, Шушенское урамнары сабан туйларына охшап кала. Өзлексез быргы, барабан тавышлары яңгырый. Кызыл флаглардан, галстуклардан, кызларның матур киемнәреннән, иртә чәчәклардән күзләр камаша. Бу тантаналы, язгы бөек бәйрәмнән берәү дә, бер оешма да читтә калырга теләми. Мәсәлән, крайның физкультура һәм спорт комитеты, җиңел атлетиканың край федерациясе ел саен бу көннәрдә Шушенскоеда традицион йөгерү ярышлары үткәрә. Быелгы ярышта Барнаул, Томск, Кемерово, Ачинск, Абакан, Канск, Норильск, Красноярск, Боготол һәм башка шәһәрләрнең җыелма командалары катнашты. Сәгать 11 дә үзәк мәйданда старт булды, 60 спортсмен заповедникка — Ильич шалашы ягына ыргылдылар. 20 чакрымлык дистанция авыр иде, ләкин Новокузнецк спортчысы Владимир Александрович Щербаков, бу араны 1 сәгать 1 минут 27,5 секундта үтеп, ярыш чемпионы исемен алды. Икенче булып Томск спортчысы В. А. Огулло килде, өченче урынга Красноярск егете В. П. Киреев чыкты.

Субботино авылында Шушенское художнигы Луканинның шәхси күргәзмәсе ачылды. Аны тиз арада 1700 кеше карады.

Норильск коллекционеры Иван Варламович Рехлов В. И. Ленин турындагы картиналарны җыя икән. Шушенскоега күчеп килергә исәбе бар. РСФСР художниклар союзының күргәзмәләр дирекциясе, урындагы оешмалар белән бергәләп, культура йортында ул җыйган картиналардан «Владимир Ильич Ленин графикада» исемле күргәзмә оештырды. Күргәзмәгә 33 художникның 80 картинасы куелган иде. Монда да культура йортының ишекләре ябылып тормады.

Ленин туган көнне Шушенскоега пионерлар, октябрятлар һәм комсомоллар килеп тулды. Шушенское пионерлары «Ленин эзләре буйлап» дигән Бөтенроссия эстафетасын үзләрендә кабул иттеләр. Үзәк мәйданда аларның тантаналы линейкалары булды. Иртән генә Ленин музей-йортында пионердан комсомолга алынган укучылар, рәт-рәт булып тезелгән сафлардан йөгереп чыктылар да, муеннарыннан ал галстукларын салдылар һәм аларны әле генә пионерга кабул ителгән энеләренең һәм сеңелләренең муеннарына бәйләделәр. Моннан соң пионерлар музей-йорт алдындагы Ленин һәйкәле каршыннан тантаналы йөреш белән үттеләр, чәчәкләр куйдылар һәм Ерак Көнчыгыштан килгән чик саклаучы абыйлары белән янәшә басып почетлы каравылда тордылар.

Музей ишек алды куе бакча. Алмагачлар, өрәңге, сәрбиләр үсә, ишек янында, мәңгелек каравылга баскан сакчыдай, ялгыз чыршы уйланып утыра. Кояш якты. Өздереп сыерчыклар сайрый.

Шушь елгасы аша Ленин аугa йөрергә яраткан утрауга корыч арканнар белән асылмалы күпер салынган. Кешеләр үткәндә ул дулкындагы көймә шикелле чайкала, бала-чагалар, аның рәшәткәсенә тотынып, куанышып чыркылдаша.

Күпергә керер алдыннан яр башында кызыл йолдызлы ак таш тора. Ташка:

«Монда ак гвардиячеләр тарафыннан каты газаплар күргән кызыл партизан Парщиков Гаврил Петровичның (1895 елгы) гәүдәсе күмелгән. 1935 елның 16 ноябрендә вафат булды. Коллективлашу чорында 1928 елның 19 декабрендә Шушенскоеда кулаклар тарафыннан үтерелгән комсомолецлар Козик Кузьма Федорович (1905 елгы) һәм 1930 елда Солбе авылында кулаклар тарафыннан үтерелгән Воронецкий Михаил Федоровичның (1907 елгы) гәүдәләре күмелгән»,— дип язылган.

Күпердән үткән кешеләр, бу каберләр янына туктап, уйланып үтәләр.

Козиклар һәм Воронецкийлар шушы кырыс Себердә колхоз төзү, ярлы-ябагайларны бәхетле мул тормышка чыгару турында хыялланганнар, шуның өчен көрәшкәннәр һәм газиз җаннарын биргәннәр. Хәзер аларның иптәшләре, уллары, кызлары, оныклары, бу 5 еллыкта дәүләткә 198 мең центнер икмәк, 70 елда 533 центнер йон, 10.857 тонна сөт, 13 миллион 500 мең күкәй, 3.132 тонна ит, 3.660 тонна яшелчә тапшырырга, дип сүз бирде, һәм без сүзебездә торачакбыз, диләр.

Әйе, юкка таммаган комсомолецларның кайнар каннары. Ул каннарның кайнарлыгыннан Себер җылынган, җир җылынган. Караңгы төннәрдә алар хыялланган якты көн килгән. Шушенское хәзер шул якты көннәрдә яши, һаман яктыра, яктыра бара!

Актарылып аккан Шушь елгасы ярына баскан бронза Ленин да, күзләрен кыса төшеп, бу яктылыкка карый, тирә-яктагы яңа герелтене, яңа тавышларны тыңлый.

Элек Шушенскоеда, Себернең һәр җирендәге шикелле үк, керосин кыйммәт торган. Шуңа күрә аны бик кадерләп, саклап тотканнар. Кечкенә лампаларны тәмам караңгы төшкәч кабызганнар. Тәрәзәләрдән тоныклык кына соры яктылык төшеп торган. Ә Петровалар өендә яшел абажурлы зур утыртма лампаны иртә кабызганнар. Ул керосинны күп «ашаган», ләкин яктылыкны да мул биргән. Надежда Константиновна бүләк итеп алып килгән бу лампаны Владимир Ильич бик яраткан. Аның йомшак һәм тигез нуры Ленинны эшләргә илһамландырып торган. Өйдәгеләр йокларга яткач, Ильич лампаны конторкасының сул почмагына куя торган булган. Аның яктысы, кечкенә маяк нуры шикелле, урамга сузылган. Соңарган юлчылар «сөрген кешесенең» тәрәзәсеннән төшкән шушы бәләкәй нурга карап юл тапканнар.

Ул лампаны музей хезмәткәрләре кичләрен хәзер дә яндыралар. Ләкин хәзер Советлар иле өстендә балкып янган миллионнарча «Ильич лампалары» нурында бу лампа яктысын аеру кыенрак.

Шушенскоега электр энергиясе Себернең иң зур җылылык станциясе Назаровск ГРЭСыннан килә. Ә авылдан 60 кына чакрым ераклыкта — Енисейда хәзерге масштаблар белән чагыштырганда да искитмәле зур Саян-Шушенское ГЭСы төзелә. Буаның биеклеге 240 метр, куәте 6.400.000 киловатт!

Моңа тиң электр станциясенең әле бер җирдә дә төзелгәне юк!

Ильич Ватаныбызны тоташ электрлаштыру хакында хыялланган иде.

Быелгы кышның җилекләргә үтә торган суык шимбәсендә бер төркем яшьләр спорт мастеры Виктор Ведунко җитәкчелегендә ГЭС котлаваны өстендәге Кантегир кыясына күтәрелделәр һәм анда «Ильич хыялы тормышка ашачак» дигән сүзләр беркетеп төштеләр.

Ул сүзләр бик ераклардан күренеп тора.

Шушенское ярына баскан бронза Ильич бәлки шул юлларга карап куанып торадыр!..

Бәлки ул үзе яшәгән чорда тоташы белән укый-яза белмәүче надан крестьяннар яшәгән, Россиянең сөрген урыны булган «җәһәннәм тишегендәге» караңгы бер авылның яңаруын, төзелүен, кояшка, яктыга омтылуын күреп куана торгандыр!..

Шушенскоены яңа шәһәр итеп кору өчен хөкүмәт илле миллионлап акча бирде.

Хәзер «Шушьспецстрой» трестында 2.000 төзүче эшли. Аларның күбесе яшьләр. Комсомол путевкасы белән илебезнең төрле җиреннән Ильичка мәңгелек һәйкәл — шәһәр салырга килгәннәр. Менә 19 яшьлек Людмила Никандрова. Ул — Башкортстан кызы, монда штукатур булып эшли.

— Шушенское — минем өчен иң кадерле, иң якын җир,— ди ул.— Без аны 20 ел буена төзиячәкбез һәм дөньядагы иң матур шәһәрләрнең берсе итәчәкбез.

Галя Пушкова Мәскәү өлкәсеннән килгән, ул ташчы да, бетончы да, штукатур да, маляр да. Братск ГЭСын, Дивногорскины төзегән.

Төзүчеләр күп монда. Урамда очраган һәр өч кешенең икесе төзүче. Алар һаман иртә торалар, кила торалар, ләкин һаман да җитмиләр. Чөнки эшлисе эшләр дә искиткеч бит. Хәзер Фрунзе, Совет, Пушкин урамнары ягыннан — болын читеннән иске авылга бишәр катлы, 100 әр фатирлы кирпеч өйләрдән төзелгән яңа шәһәр якынаеп килә, 8 катлы гостиница, икмәк, сыра заводы, мунча-кер юу комбинаты салынып ята. Генераль план буенча бу 5 еллыкта гына да 60 мең квадрат метр торак урыны, ике мәктәп, өч балалар бакчасы, пионерлар йорты, ике кафе, магазиннар, спорт корылмалары, елга вокзалы, турист базалары, яңа күпер салыначак.

Киләчәктә Шушенское бөтенләе белән зур шәһәргә әйләнәчәк. Урамнарны асфальт каплаячак, өйләргә су керәчәк, фәнни-тикшеренү институтлары булачак.

Гомумән, Шушенское тагын бер мәртәбә үзенең яшьлеген, яшәрү чорын күрәчәк, төзелеш язын башыннан кичерәчәк.

Ләкин ни гаҗәп: шәһәр үзе яңара бара, яшәрә, ә аның бер урыны — ике музей

территориясе күзгә күренеп картая, искерә. Ул озакламый XIX гасыр ахырындагы яшь Ленин яшәгән чордагы вакытына кире кайтыр.

Бу — истәлекле зона. 33 крестьян йорты ишек алды корылмалары, әчке җиһазлары белән нәкъ шул чорларны күз алдында тотып кире эшләнә. Өяз управасы, төрмә (элек аны крестьяннар каталажка, яки салкын урын дип йөрткәннәр), кабак салына. Хәзер зонада кызу эш кайный. Балта, пычкы, ышкы тавышлары белән бу җирләр зур өмәне хәтерләтеп тора. Чыннан да өмә бу — бөтен ил өмәсе. Аны төзүдә күп оешмалар, галимнәр, төзүчеләр, Шушенскоеның... картлары-карчыклары катнаша. Соңгылары шул чордагы өйләрнең, җиһазларның ничек булуын, ничек торуын исләренә төшерәләр, иске әйберләр җыялар, галимнәргә кулларыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтәләр.

Урамнардан асфальт куптарыла, электр фонарьлары, чәчәк түтәлләре, хәзерге коймалар алына. Петрова йортында да «искерү булачак». Штукатурка, пар җылыткычлары, электр бетә, ишек алдындагы бакча киселә, анда элекке сарайлар, хуҗалык корылмалары төзелә.

«Ленинның Себер сөргене» мемориаль зонасын «Шушьспецстрой» трестының 3 участогы аякка бастыра. Эшләр 70 елның март аенда тәгәлләнергә тиеш. Архитектор-реставраторлар Новгородтан, Костромадан, Псковтан, Горькийдан һәм башка шәһәрләрдән килгән, ә төзүчеләр — бөтен илдән.

Шушенское төзелеше — Бөтенсоюз комсомол-яшьләрнең удар төзелеше. Ульяновск һәйкәл-шәһәрен төзүчеләр Шушенскоены салучылар белән ярыш башладылар. Ульяновск төзүчеләренең вәкилләре Шушенскоега килделәр. Очрашуда Ульяновскиның иң әйбәт ташчысы Геннадий Шувалов белән әйбәт штукатур Лидия Миронова үзләренең йөкләмәләре турында сөйләделәр, Ульяновск мәрмәрен һәм кельма бүләк иттеләр.

«Без төзүчеләр намусына тап төшермәбез, һәйкәл-шәһәрне һәм мемориаль заповедникны вакытында төзеп бетерербез»,— Шушенское ВЛКСМ райкомы секретаре Феликс Поздняк кунакларга әнә шулай диде.

Төзүчеләр белән беррәттән, музей канцеляриясендә дә киеренке эш бара. Сотрудниклар өйләрне, каралты-кураларны «тутыру» өчен фонд — элек хуҗалыкта кирәк булган, файдаланылган әйберләр җыялар, халык бу эштә бик зур ярдәм күрсәтә. Мәсәлән, Контырев авылында яшәүче Вера Александровна Полежаева, өлкән яшенә дә карамастан, Шушенскоега үзе килде, киндер сугу станы, бүтән әйберләр бирде. Иптәшләреннән алып 1 бизмән, пачач тарагы, өч борынгы ашъяулык китерде. Зыряновлар өен элеккечә үзгәртеп корганда аның улы Ф. А. Зырянов бик күп «вак-төякләр» искә төшерде, өстәл-урындыклар, савыт-сабалар табып бирде.

Хәзер фондта халыктан җыелган 1.700 ләп әйбер бар. Ләкин шунысы кызык: әле бер генә агач сука да табылганы юк, керосин лампалары, агач чүлмәкләр, икона һәм лампадкалар да бик кирәк.

Төзүчеләр мемориаль заповедникны «үткән гасырга тәрәзә» дип атыйлар. Хәзер бу тәрәзә көннән-көн зурая, актыра бара...

Мин шунда чакта музейга әнисе белән Лена исемле өч яшьлек кечкенә кыз керде. Ул, әйдә, әни, бер нәлсә күрсәтәм, дип, тып-тып басып бүлмәләргә үтте. Кроватьны барып тотты. Менә Ленинның кровате, диде. Мичне тотты, менә Ленинның мичө, диде. Китап шкафларына килде, менә Ленинның китаплалы, диде. Ә аның китаплары СССР халыкларының 64 телендә 320.438.200 экземпляр чыккан, 30 чит ил теленә тәрҗемә ителгән.

Лена, китапларны карагач, бүлмәләрне урап чыкты да, күзәтүләренә нәтиҗә ясады:

— Монда бөтен нәлсә дә Ленинныкы', диде.

— Ә Ленин бабаң үзе кайда соң, кызым? — дип сорады әнисе.

— Ул Мәскәүдә тола,— диде Лена.— Аның әле эше күп. Эшен бетелә дә кайта. Әллә шуны да белмисеңме?!

Дөрес әйтәсең, бәләкәй кызчык, дип уйладым мин, аның эше күп, бик күп. Без аның балалары Ленин бабайның бөек, изге һәм мәңгелек эшен ахырына кадәр эшләп бетерербез. Аның уйларын, хыялларын тормышка ашырырбыз...

Аяз Гыйләҗев

# УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН

РОМАН

1



Кешеләрне аңлау өчен нәрсә кирәк?.. Акылмы, тәҗрибәме, сизгерлекме?.. Әллә башкаларны аңлый алу сәләте аерым, югары затларга гына хасмы?.. Югыйсә без кешеләрне өстән-өстән генә аңлыйбыз ич... Дөрес, һәркем үзенең башкаларны танып белүе, читләр күңеленә үтеп керә алу маһирлыгы белән эченнән генә канәгать булып юанып йөри. Асылда исә без күз күргән, үзебез азмы-күпме өйрәнгән кешеләрнең йөз сызыкларын, чалымнарын, гадәт-кыланышларын үзләштерәбез дә үзгәрмәс стандарт, өлге итеп шуларны алабыз... Һәм кайчакта ансат кына шул сыйфатлардан чыгып бөтен кешеләргә «менә бу — яман адәм!» яки «бусы — ару егет!» дип тамга салып яши бирәбез. Дусларны да, хәтта сөйгән ярларны да шул стандарт өлгеләр белән сайлаучылар азмы әллә?.. Кеше дигәнең азга да риза, ул юаныч табып яшәргә, тынычланырга тели... Бәхетеме бу аның, бәхетсезлегеме, алла үзе белсен!..

Әйтик, менә Әхәт... Моңарчы мин аны шактый һавалы, тәкәббер һәм берникадәр җилкуар кеше дип йөри идем, тормыш дигәнең тиешле вакытын сайлап кына бөтенләй үзгәлеген раслады түгелме?!. Ипле генә егет икән ләбаса!.. Диләгә путевка табышты, хәтта озатырга да төшеп җиткән...

Мең тугыз йөз алтмыш җиденче елның беренче июнендә Казан вокзалында Мәскәүгә китүче «Татарстан» поездын озатырга төшкән йөзәрләгән халык арасында алар аерым утрау булып басып торалар иде. Бу өчесе өчен дә гайре табигый хәл булганга, Идрис гадәттәгедән дә җитдирәк уйлар белән мәшгуль, Әхәт, сизелеп торган җайсыз киеренкелекне киметергә тырышып, төрле озату анекдотлары сиптерә, Диләисә тирә-яктагы үзенчәлекле шау-гөрдән, ыгы-зыгыдан алҗып югалып калган иде.

Поезд кузгалырга унҗиде минут вакыт бар.

Әхәт, тәмләп сөйли башлаган мәзәген ярты юлда бүлеп:

— Пижоннар! — дип кычкырды.— Бәхетсез атаның балалары!.. Кешене юлга шулай озаталармы? Ә шампанское?.. Мин хәзер...

Ул ашыгып китеп барды. Идрис аны-моны кирэксенмичэ таркау гына тирэ-якны күзэтэ иде, яннарыннан Әхәт киткәч, җинеләеп калган Дилә аны җитәкләп алды.

Әхәт озатырга төшәр дип Дилә башына да китермәгән иде, монда кадәр аларның гаиләсенә әллә ни якынлык сиздермәгән ялгызак ярым ят кешенең шома шукланулары, оста җорланулары бер җәһәттән күңелне күтәрсәләр дә, аның бу кыланышларында ул үзе дә, Идрис тә абайламаган хәйлә качынадыр кебек тоелды.

Алар, арлы-бирле кабаланган кешеләрне чак-чак кына аралап, җитәкләшеп перрон буйлап йөреп килделәр. Кич җылы, зәңгәрсу һаваны телем-телем кискәләп вокзал өстендә карлыгачлар оча.

Алдагы вагоннар ягыннан дөбердәгән көчле тавыш килде, вагоннар күңелләрне кымырҗытып кузгалыштылар, Идрис сәгатенә карап алды.

— Тепловоз тактылар,— диде Дилә, артына борылып.

— Дөресрәге, вагоннарны тепловозга тактылар.

— Миңа дөрес сөйләмәсәм дә ярый,— диде Дилә, башын балалар кебек алга ия-ия.— Галиҗәнапләре кебек әдәбият факультетында да укымаган, редакциядә дә эшләмим.

— Алайса, оста барда телең тый,— диде Идрис, аның кебек кыланыбрак.

Гади шуклыктан икесе дә кызык ясадылар, көлештеләр, гадәти халәтләре кайтты, арадагы киеренкелек кимеде. Дилә туктальш Идриснең күлмәк якасын кайтарып карады:

— Күлмәкләреңне «Ланой» белән юарсың... Аннары шул, иртән дә әйтермен дигән идем... Ничек булса да минем янга килеп китәргә тырыш. Ике айга түзәр күк тимим... Бер атнага киләсеңме, күбрәккәме, үзең чамаларсың тагын. Мин, әлбәттә, озаккарак килүеңне телим. Булектә Әхәтең кала бит. Өйләнмәгән буйдак кеше, аңа кайчан ял алса да барыбердер ич? Сүз тыңлый торганга охшый үзе.

— Моңарчы күргәндә бер дә яратмый идең, озатырга төшеп җанынны эретте дәме? — диде чак кына көнләшеп Идрис.

— Нигә, дөрес түгелмени?

Идрис сүзсез генә ым какты.

— Ике атнага ычкына алсаң, гаҗәп шәп булыр!.. Ямансулармын дип бик куркам... Ике айга бит!

— Ул кадәрегә җибәрмәсләр, ике атнага булмас, өметләнмә. Аннары акча ягы да кабырганы кашыр...

Ул читенсенеп кенә нидер аңлатырга керешкән иде, икесе дә вокзал ягыннан килүче Әхәтне күреп алдылар. Аның авызы ерылган, иртәрәк юкарган саргылт чәчләре җилбердәп бер якка авышкан, ул ике кулы белән дә күкрәгенә шешәләр кыскан иде.

— Во! — дип кычкырды ул кемнәрнедер як-ягына этә-этә.— Ресторанны ябарга маташалар. Идән себерергә диме шунда... Дилә ханым, мондый кичермәслек олы гөнаһны бары сезнең аркада гына эшләдем... Ходай хәерле итсен!.. Тик шампанское юк, буфетчы хатын таныш, ялынып-ялварып сорадым, юк ди... Ит югында җылы шулпа, рәхәтләнеп сыра эчсәк тә тантана кимемәс бит?

Әхәт тегеләрдән ризалык алып тормады, арлы-бирле карангач, юллар өстеннән аркылы салынган тимер күпернең бетон баскычы почмагына шешәнең башын сызып җибәрде. Сырлы калай бөке ялтырап барып төште, күбекләрен атып саргылт сыра тышка омтылды.

— Дилә ханым, сез — китүче!.. Тотыгыз! — диде Әхәт житди тантана белән.

Шешәне алырга туры килде, әчмим-фәлән дип тәкәллефләнергә вакыт санаулы калган. Идрис тә, гомуми җанлылыкны көчәйтергә теләп, каян таптың мондый кадерле нәрсәне? — дия-дия шешәләрнең берсен

алып бик хәтәр генә кыланып бөкесен Әхәтчә төшермәкче иде, үткен кырлы бетонга сыдырып бармагын канатты да, канны күрсәтмичә, шешәне сузды:

— Яле, артист, күрсәт тагын!

Әхәт ялт кына ике шешәнең бөкесен очырды, дүртенчесен Диләгә сузды:

— Сусынны басарга дигәндә — бәлзәм!.. Юлда артмас, алып куегыз,— диде.

Күпер баганаларына сыенып шешә авызыннан гына сыра чөмерделәр. Җып-җылы сыра эрем суыдай әче иде.

— Фу,— диде Дилә, борынын җыерып.— Күгәрек тәме килә.

— Сезнең тимер ашап караган бар, ахрысы? — дип шаяртты Әхәт.— Берәр заман капкынга эләгеп ихтыярсыздан җәяләрен кимердегезме әллә?

— Сусаганга ярыйсы икән! — дигән булды Идрис.

Өч-дүрт кеше бер-бер артлы:

— Сыра каян бәчтердегез? — дип ялманып үттеләр.

Әхәт бер дә иренмичә вәкарь белән генә:

— Анда бетте инде,— дип анлатып калды.

Кешеләр шулай аһ итеп торгач, сыраның дәрәҗәсе бермә-бер күтәрелде, аны чырай сыта-сыта йоткалап тордылар, тирә-якта халык мыжылдады, арада таныш йөзләр берән-сәрән чагылып китте, әмма бу минутларда алар үз кайгыларын гына кайгырталар иде. Әхәт моны сизенеп учларын бер-берсенә ышкып алды:

— Менә баш! Сезнең аны-моны сөйләшәсе бардыр ич?

Дилә уңайсызланып башын аска иде. Идрис:

— Әһе, әһе,— дип йөткеренде.

Әхәт кемнедер күргән булып аңа кычкырды, эшлекле кыяфәт белән китеп барды, алар сынагандай көрсенеп бер-берсенә караштылар.

— Тагын җиде минут,— диде Идрис.

— Мәктәптә математикадан гел бишле генә алгансыңдыр син.

— Нигә?

— Ачу китерерлек төгәл саныйсың.

— Сәгать саный... Сәгать — явыз!.. Бу минутларны тизрәк үткәреп җибәрсен әйдә!..

Дилә шаяруларны куеп торырга кирәклеген аңлады.

— Идрис,— диде ул, назлап кына,— хатынын ике айга дәваланырга җибәргән дип мыскыллаучылар да очрар... Сезнең халыкка сәбәбен генә тап, сәдәбен маңгаеңа тагарлар, иеме?

— Савыгып кайт, Дилә.

— Савыгырга иде дә, Идрис...

— Туплардан атып, сөрәнчеләр чыгарып шәһәргә хәбәр таратсалар да, төкерәм анысына!.. Гайбәтченең авызын тегеп булмас, савыгып кына кайт.

Дилә кайнар учы белән аның беләген кысты...

— Савыгырмын...

— Акчаң җитмәсә язарсың, аның ояты юк... Үз-үзеңнән җәлләмә. Мин күбрәк эшләргә тырышырмын.

Ул ак сумкасын ачып карады: — Билет онытылмаганмы?..

— Әйдә, Идрис... Әйләнгәлик...

— Әйдә.

— Шулай, дөнья туктаусыз болгана.

— Син Израильне әйтәсеңме?

— Аларны да...

— Син борчылып кына хәл кылына торган мәсьәлә түгел... Дөрес, заманы шундый, битараф булырга ярамый... Иң гади кешенең язмышы юлында да дөньянын бөтен меридианнары кисешә хәзер. Кешеләр шу-

ны никадәр тизрәк аңласалар, шулкадәр шәбрәк булачак!.. Ләкин сиңа савыгырга кирәк... Уйлама әллә нәрсә!..

Төркем-төркем чайкалып торган халыкны тагын да тузгытып проводницалар аваз салдылар:

— Китүчеләр, утырышыгыз.

— Озатучылар, чыгарга вакыт!.. Җыеныгыз!..

Бу чакырулар тирә-яктагы буталышны көчәйтте, мунчадан чыккандай алланган кемнәрдер мышный-мышный авыр чемоданнар сөйрәп үттеләр, берәү ап-ачык итеп сүгенеп җибәрде... Кулларын артка яшергән Әхәт тә килеп җитте. Ишеккә тоташ ябырылган халык арасына кысылган Диләне аны күргәч кире борылды. Әхәт, фокусник кебек, ялт иттереп хатынның кулына бер бәйләм сирень чәчәкләре сонды. Диләне ах итте.

— Миңамы болар? Чынмы?

— Королева Елизаветага түгел, сезгә, Диләне ханым.

— Каян әлдердең? — дип сорады Идрис, көнләшеп.

— Төшә маллар егет кулына! — диде Әхәт һәм бер дә исе китмичә чут итеп Диләнең алсуланган яңагыннан үбеп алды. Чит кешеләр белән мондый мөгамәләне күрмәгән Идрис тә, Диләне дә аптыраштa калдылар. Диләне кыяр-кыймас кына Әхәткә кулын бирде һәм, ярым шаяртып:

— Миннән башка монда бик азынасы булмагыз, малайлар,— дип кычкырды. Әхәт сиздермичә генә Идриснең касыгына төртте дә көлә-көлә:

— Кая ди ул, Идрис — Матбугат йортындагы бердәнбер әүлия,— диде.

— Диләне, кер, кер,— диде Идрис, кыбырсып.— Кузгала!

Янә бер кат хушлаштылар, Идрис Диләнең колак яның үпте, яшь хатын, яшьле күзләрен сөртеп, кешеләр арасына кереп кысылды, керде, бер тынга югалып торды, аннары өченче купеның ачык тәрәзәсендә күренде:

— Мин монда, малайлар.

Аның күңеле сүрәнләнгән, кара күзләрендә моң иде.

Шау-шу арасында тавышы чак ишетелде. Җегәрен барлагандай, тепловоз тартылып алды, апельсин кабыгы төсле флаглар тоткан проводницалар тимер баскычларга сикерештеләр, хыянәтче тәгәрмәчләр шыпырт кына кузгалды, халык ташкыны вагоннардан бер читкә тайпылды.

Идриснең моңарчы ирлеге тыйлыктырып торган хисләре уянды, ул һушсыз калып беравык Диләне белән янәшә йөгереп барды, вагоннар мактанышып такылдаша-такылдаша берәм-берәм аны узарга тотындылар. Аның сыны катты, бугазыннан җан авазы атылып чыкты:

— Хуш, Ди-лә!..

Диләне аны ишетмәде, тик Идриснең өметсезлек сагышы өретелгән кара-кучкыл йөзен күреп калды, нидер әйтергә ымсынып тәрәзәгә башын тыкты, ул күренмәде, егерме жиденче номерлы Казан-Мәскәү поезды дөбердәп Бишбалта дамбасына кереп бара иде инде...

Аның сабый бала төсле сөмсерен коеп шактый озак басып торуын бары көлке генә иткән Әхәт ашыктыра башлады.

— Я инде, я, киттекме?.. Алай өзелерлек булгач, җибәрмиләр аны.— Үзе үк сүзләренең шыксызлыгын аңлап, гафу үтенергә тотынды.— Шаяртам гына, күрмисеңмени?.. Аңлыйм, Диләгә санаторийга барырга кирәк... Бик кирәк...

— Дүрт елга беренче тапкыр аерылышабыз... Үзем дә көтмәгән идем!

Халык ташкыны сирәкләнгән, шау-шу сизелерлек кимегән, алар да вокзал алдындагы мәйданга чыктылар. Көн ңык кына кичкә авышса

да, барыбер эссе, вокзалга сыймаган пассажирлар умарта күче булып бакча күләгәләрен сарганнар. Комлы сукмакларда бала-чага мәш килә, ярым ялангач балалар йөгерешәләр. Троллейбус тукталышында бик кыска күлмәкле, озын сыйраклы өч кыз иреннәрен кызыктыргыч ялый-ялый эскимо сосалар.

— Күрәсеңме? — диде Әхәт, баягы кебек үк аның янтыгына төртеп.

— Танышларыңмы?

— Танышу озакмы?..

Әхәтнең соры күзләрендә шуклык уйный иде, Идрис шактый кискен итеп аны бүлдерде:

— Озатырга төшүең өчен рәхмәт... Һәм барысы өчен дә рәхмәт!

— Кая олагырга җыенасың? — диде Әхәт, аптырап. Ул күзләрен майландырып һаман кызларны сөзә иде.

— Курс — өйгә!

— Синең эшләр җайлы хәзер. Бер башыңа бер квартира!.. Мажаралар сезоны башлана.

Әхәт эчке мәгънә биреп хихылдап көлде.

— Квартирам тар дип синең дә лаф органың ишетелми.

Теге истә-оста югында ата-анасыннан зарланырга кереште.

— Картлар белән гомер итүнең җәза икәнлеген Европада әллә кайчан аңлаганнар... Чыннан да җир өстендә җәһәннәм!.. Заманында күңелле генә кешеләр иде, картайгач акыллары бетәште. Үзгәрешләрне кабул итмиләр, яшьләрне аңламыйлар...

Әхәт Казан егете булып, әти-әнисе белән Киров районында үз йортларында тора иде.

Озын аяклы кызларны троллейбус утыртып китте, зыңгырдап беренче номерлы трамвай килде.

— Кадрларны ычкындырдык,— диде Әхәт, уфтанып. Идрис, трамвайны күрсәтеп:

— Синең экипаж, пижон,— диде.

— Әйдә аэропорттан урыйбыз.

— Юк.

— Француз коньягы бар. «Камю»... Кичә белеш малайлар кергәннәр. Бүгенгә калгандыр әле.

— Кайтырга булыр.... Кәеф тә кыеш-мыеш.

— Рәтлибез аны!.. Кайгыны вакытында тарат, дигәннәр изгеләр. Әйдә, кәеф мастерскоена чакырам!

Аның икеләнүен күреп Әхәт тыкырдата ук башлады:

— Хатыныңны назлап, куенында тотып дүрт ел яшәгәнсең, бер тын алсаң да язык булмас!.. Югыйсә мүкләнерсең. Өч айлык пауза, берүзеңә квартир!.. Бәхет яуса явар икән!..

Аның соңгы сүзләре Идриска шактый каты бәрелде:

— Нигә бик бәхетле булып чыктым соң әле мин?.. Төшендер, зинһар... Хатыным чирлегә бәхетлеме?.. Әллә әтиемнең Германиядә үлеп калуы зур бәхетме?.. Әниемне үз яныма чакырта алмавыма көнләшәсеңме?.. Бер бүлмәдә берүзең калу — ирекле баштан тоткын булу ул, беләсең килсә...

Әхәт дәшмичә генә аны бер кырыйгарак әйдәп китерде, уңайсызланып кына:

— Уйнап кына әйттем,— диде.— Шунысы да бар, хәзерге заманда һәрбер унган ир затының «буйдаклар фатиры» булырга тиеш имеш, диләр.

— Нәрсәгә ул?

— Кети-кети уйнаргадыр инде, әй, бала!.. Әйдә, коньяк белән сыйлыйм үзеңне, аннан «буйдаклар фатиры»ның кодрәтен сөйләрмен.

— Юмартлыгың өчен рәхмәт, тик ресторанга бармыйм.

— Ярар. Чыннан да барма,— диде кинәт Әхәт, бик үз итеп.— Аерылышу сине шулай тетрәтер дип уйламаган идем.

Идрис ихлас күңелдән:

— Үзем дә! — диде.

— Кайт, ял ит, йокла. Тәмле төшләр керсен.

— Син... барасыңмы?

— Бүгенге эшне иртәгә калдырма. Темп заманы!..

Ул троллейбуска сикереп менде. Идрис, саубуллашкан кебек, троллейбус кузгалганчы тәрәзәгә текәлеп торса да, Әхәт борылмады, тәгәрмәчләр астында асфальт чожтырдагач кына Идрис үзенең япа-ялгыз калуын аңлады.

Кем генә булмасын, аның холкы-гадәтләре белән килешәсеңме-юкмы, Әхәт бу кичтә Идрисне гадәти тормышы, эше, уйлары, хәтта киләчәге белән дә бәйләп торучы кеше иде. Ул троллейбус артыннан тартылып алды, хәтта көтмәгәндә:

— Әй, Әхәт! — дип кычкырып та җибәрде.

Хәзер ул файдасызга үкенә, тирә-ягында чайкалып, әле көлеп, әле уйчанланып тыз-быз йөренгән мең кеше арасында ялгыз калу рәхәт түгел иде. Әллә троллейбусның янадан килгәнен көтеп Әхәтне бастырып куа китәргәме?

Идрис кесәсеннән биш тиенлек капшап эзләнеп торды да кайтырга булды...

Тугызынчы трамвайга чират... Тыгыз, эссе вагонда кешеләр акрын гына кысылыша баралар. Казанкада су коенырга төшеп калып була иде, әллә нигә күңеле тартмады. Пляж тукталышында байтак кеше коелды. Алар урынына юеш чәчле, чуен төсле каралып өлгергән үсмерләр, яшь кызлар кереп тулды. Кызларның әрсез генә төртеп торган тере, яшь күкрәкләре, серле пышылдаулары, малайлар белән төрткәләшеп, дусларча ара-тирә көлешеп алулары Идрискә рәхәтлек, тынычлану китерде. Шактый озак шулар белән юанып, аларны күзәтеп кайтты. Кызларның йөзләренә, күзләренә яшертен генә караштырып, аларның характерларын, кем булырга мөмкинлекләрен фараз кылды. Кызлар таза, саф, сылу иделәр, алар хакында начар уйлыйсы да, киләчәкләрен ямьсез итеп күрәсе дә килми иде...

Шиксез, аларның бала чаклары, яшьлеге күңелле рәхәтлектә, туклыкта, муллыкта һәм тәрбиядә үтәр... Алар арасында Дилә кебек бик яшьли нужа чигеп гомерлек чир алучылар булмас...

Кинәт аның сулъяк күкрәгендә нидер чәнчешеп алды, ул йөзе белән тузанлы тонык тәрәзәгә борылды һәм кызларга әйләнеп тә карамады...

Өйдә дә ялгыз.

Шәфкатьсез ялгызлыкны онытып торыр өчен күңелгә хуш бирәр шөгыль эзләп табарга кирәк иде.

Табарга, табарга, беренче кичтә үк бирешергә, җебеп төшәргә һич тә ярамый...

Ул кәстрүлләрдә җылыта-җылыта ваннага су тутырды, кереп ятты. Озак кына иркәләнде, хәтта йокымсырады. Сөякләре мәмрәп, гәүдәсен талгын бер көчсезлек биләгәч кенә судан чыкты. Идәнгә чәчрәгән су тамчыларын берәмтекләп сөртте, бер тотынгач, дымлы чүпрәге белән бөтен квартираны тузаннан арындырып, почмакларны, диван асларын сыпырып чыкты. Аннан ут яндырмыйча гына диванга ятып торды. Почта ящигын карап менде. «Нейс Дойчланд» газетасының берьюлы ике саны килгән иде, кырын ятып аларны караштырды, торып утырып карады...

Тынычлык килмәде. Киресенчә, газеталар аның хәвефле шөбһәләрен арттырдылар гына... Якын Көнчыгышта менә-менә кабынам дип

пыскыган сугыш куркынычы бермә-бер көчәйде... Шунда, Сүәеш тирәсендә кабынган ялкын бөтендөнья сугышын — олы, дәһшәтле янгынны дөрләтеп җибәрсә?.. Кем белсен... Израиль иң хәтәр капиталистик илләрнең Якын Көнчыгыштагы коралланган ялчысы гына...

Дилә дә йокларга яткандыр... Ни уйлый икән?..

Кинәт ул тынычсызлыгының сәбәбе Дилә түгел, Әхәт икәнлеген төшенде. Дилә өчен ул тыныч! Ил имин булсын да савыгып кайтсын!.. Җүләр хатын түгел Дилә, дүрт ел эчендә дүрт пот тоз ашамасалар да, кайгы-шатлыкны байтак татыдылар. Квартирасыз интегүләр, акча житкерә алмыйча җәфаланулар, икеләнүләр, борчылулар барысы да уртак булды. Яшәү урынының юклыгы кеше рухын изә, аны шәхес буларак кыса, кечерәйтә... Чит кешеләрдә яшәп ятканда гаугаланып, кашык-аяк шалтыраткан минутлар да булмады түгел...

Квартира алганда әлеге дә баягы Әхәтнең ярдәме тиде. Редактор янына тәкъдим белән керде, аны ышандырды, үтенеп шәһәр башкармасына барды. Сөйләшә ала, үзен куя белә, дәлилләре төпле. Казан егете шул...

Әллә шул яхшылыкларының барысын да үзенең вак, яшерен максатлары хакына гына эшләдеме ул?

Әнә шул пычрак «буйдаклар фатиры» ачкычына темиен сузып кына путевка артыннан чаптымы? Диләнең авыруында, Идриснең кайгылы хафасында һич гаме юк идеме аның?

Идрис, Әхәт белән бергә эшли башлаган көненнән алып бүгенге тынгысыз кичкә кадәр эзлекле рәвештә уйлый-уйлый килсә дә, үзенең бүлек мөдирен турыдан-туры эт авызына салырлык гаеп-кыек тапмады.

Шулай булса да аны исемсез үкенеч кимерде.

Ресторанга бармавы өчен дә, үз тормышының тулысы белән иптәшләре күз алдында узуы өчен дә кыйналды.

Әхәт барын да белә диярлек: Диләнең авыруы, Идриснең шуна чамасыз борчылуы да аңа мәгълүм. Үз хатынына путевканы да үзе генә юллап җибәрә алмады бит ичмасам!..

Ул барын да белә...

Идрис Әхәтне беләме соң?

Психоаналитик анализлар ясап, кешенең үз эчәк-бавырларыннан чыгып кына киң дөньяга бәя биреп йөрүчеләрне яратмаса да, Идрис хәзерге минутта үзе өчен шактый кызыксыз нәтиҗәгә килде.

Яшькә Әхәттән олырак булса да, редакциядә бер бүлмәдә утырып эшләсә дә, ул кеше күңеленә җентекләп үтеп керә алмый икән. Юк андый үткенлеге Идриснең!.. Ул үзенә зарарлы дәрәҗәдә беркатлы, гади зат. Бер күзәнәкле. Эчендәгесе тышында.

Яхшыгамы бу, ямангамы?

Кешенең эчке дөньясына тирәнтен үтеп керә белмәгәч — яхшы белән яманны аера алмыйсың дигән сүз. Дус белән дошман синең тирәдә бердәй иркенлек белән урын алып торалар... Син — сукыр... Син — томана...

Эштә ялгышуларны, юлда адашуларны кеше үз башыннан кичерә дә оныта, үз иптәше, үз якыны турында ялгышканда тойган әрнеткеч, ачы хисне исә кеше гомер буена саклый.

Ул чын күңеленнән гарьләнә иде.

Иренеп кенә җәйге төн инде... Тып-тын... Әллә кайда гына этәч кычкырды.

Идрис һаман Диләдән бигрәк үзе турында, Әхәт турында, ике килми торган гомер турында, эше турында, аннан тагын Әхәт турында өзлексез уйлар чуалышында интегеп йокысыз ята иде...

Ул редакциягә бар кешедән дә алданрак килә. Бу гадәт Яңа Бистәдәге Күл урамында Зәкия карчыкның ярым караңгы, ярым чүмәшкән дымлы тәбәшәк өенең песи учы хәтле генә бүлмәчегендә яшәгәннән бирле калды. Шул чакта ук Идрис редакция бүлмәләре аулак вакытта иртүк килә дә язасын язып, укыйсын укып, кирәген хәстәрләп куя иде. Яңа квартира алгач та өйрәнелгән гадәтен ташламады.

Матбугат йортына каршы гына кафеда борчак боткасы салынган бифштекс ашап, бер стакан кефир белән хушлангач, ул ашыга-ашыга өченче каттагы бүлмәсенә күтәрелде. Иң әүвәл, баш саф чакта дип, чираттагы санга ике мәкаләне редакцияләде, уйланып кына, Сәйдәш көйләренә сызгыра-сызгыра берничә хатка җавап язды. Татарстаннан читтә яшәүчеләргә җаваплары гадәттәгедән озынрак, тәфсилләрәк һәм ягымлырак барып чыкты. Шушы зарур эшләрне тәмамлагач, тәрәзә каршысына басып, инде шактый җанлана башлаган Бауман урамына карап торды. Кешеләрне кеше арасында сынарга яратса да, ул шәһәр урамнарын, зиннәтле йортларны кешесез, аулак чакта күзәтә. Бүген эш белән мавыгып вакыт үткәне сизелмәгән, урам шактый тыгызланган, халык тротуарларга сыймыйча арлы-бирле агыла...

Борылып урынына килде, өстәл тартмасыннан Һейненың немецча җыентыгын алды, сүзлеген җайлап кул астына куйды, кычкырып ашыкмыйча гына укыды. Туктап шигырьне күңелдән кабатлады, Дилә хәтергә төште... «Мәскәүгә якынлашып киләләр!»

Бүлмәгә бер кыз килеп керде. Сөрмә тарткан зуп-зур күзле, сусыл иренле, житен сүседәй йоп-йомшак аксыл чәчле гаҗәп дәрәҗәдә мөлаем бу кыз редакциягә элек тә кергәли иде. Пединститутта чит телләр факультетының инглиз теле бүлегендә укучы бу кызны Идрис Әхәт янына килеп-китеп йөрүче байтак кызлардан аерып куя. Бигрәк тә кече күңелле, саф һәм итагатьле булып күренә иде ул аңа!

Моңарчы гел Әхәт барында гына кергәнгәме, кыз, кыюсызланып, ишек катында тукталды, аның шулай иртә килеп керүенә гаҗәпсенгән Идрис тә кызарынды.

— Хәерле иртә, Идрис абый,— диде кыз, юаш кына.

— Саумы, Лида. Узыгыз, уз.

Аларның моңарчы кара-каршы сөйләшкәннәре дә, исемнәрен аташканнары да юк иде сыман?.. Әллә сез дияргә инде, әллә син?.. Ул кызга кабат урын тәкъдим итеп караса да, Лида узмады, чыгып та китмәде, башын чак кына боргалап Идрискә томырылып тик басып тора бирде. Ниһаять, үзе ап-ачык күреп торса да:

— Әхәт килеп житмәдемени? — дип сорады.

Идрис, аягүрә басып, урындыкны аңа таба этәрде:

— Көтәргә вакытыгыз бармы?.. Килеп житәргә тиеш.

Кыз урындыкның бер читенә генә утырды, түгәрәк, матур тез башларын капларга тырышып, үтә кыска күлмәгенең итәкләрен тарткалап карады, ахыр, озын керфекләрен төшереп, күзләрен генә яшерде. Кызның күзләре саф зәңгәр иде.

— Сылу кызлар да минем өстәл тирәсендә утырсыннар әле,— диде Идрис, шукланып.— Югыйсә кергәне бере туп-туры Әхәт янына уза да китә. Минем өлешкә йомыш белән керүчеләрнең бик әзе генә сөзелеп кала.

— Әхәт янына шулай күп керәләрме, Идрис абый?

Ул, артыгын ычкындырганын чамалап, сүзне төзәтергә ашыкты:

— Йомыш белән дип ачыклаган идем, Лида!

Кыз яшертен генә көлеп алды.

— Иртә таңнан кызлар турында сөйли башладыгыз, Идрис абый. Мин сезне бер изге җан дип йөрсәм...

— Сәбәбе бар, сылу Лида.

Кыз күзләрен тагын да зуррак ачып аңа текәлде:

— Әхәт сезне дөнья йөзендәге иң тыйнак кеше дип мактаган була тагын!

— Хатынны санаторийга озаттым да буйдак егет булып калдым Ничек, шукланырлык сәбәп түгелмени?

Лида бу кадәресен бик яхшы белә иде. Кичә аэропорт ресторанынннан Әхәт туры аларга кайтты һәм Идриснең Диләсен ничек-ничек озатуын нык кына гаҗәпләнеп, чак-чак арттырып бизәп сөйләп бирде. (Күз яше үк чыгармаган иде Идрис чыгаруын!) Шуңа күрә кыз, Әхәт килмәгәнен белә торып, Идрисне — хатынын озатканда елый ала торган яшь-яшь ирне, карарга кергән иде. Әхәткә ышанып бетмәгән иде кичә Лида, Идриснең тиктомалдан шукланып сөйләргә ябышуы кызның күңелен кайтарды. Кызны ни беләндер рәнҗетүен аңышып алган Идрис шундук башка юнәлеш алды:

— Имтиханнарны ярасызмы? — дип сорады.

— Үзебез ярылмасак ярый ла... Әле белгән юк, Идрис абый, берсекөнгә беренчесе.

— Шүрлисезме?

Лида матур муенын боргалап сүзсез генә ияген какты.

— Эшкә кая җибәрәләр?

— Тәтешкә диләр.

Идриснең Тәтештә булганы бар. Ул Идел буйларын, биек-биек ярларны, йөрәгеңнең ныклыгын сыный торган текә баскычларны, яр астындагы сап-салкын чишмәләрне, шәһәр ягасындагы юкәлекләрне мактарга тотынды.

Кызның искитмичә генә тыңлап утыруын күргәч:

— Нәрсә, ышанмыйсыңмы әллә? — дип сорады.

— Күңел ачарга бармыйм ич мин анда, Идрис абый... Эше ничек булыр бит... Коллектив, квартира, мәктәп...

— Китәсе килмиме?

— Сез Казанны Тәтешкә ансат кына алыштырыр идегезме соң? Казан Казан инде... Башкала! Без бит әни белән икәү генә торабыз. Яхшымы-яманмы — үз йортыбыз.

— Сез олы кешеләр сымак сөйләп җибәрдегез.

Көлгән чакта Лиданың мул күкрәкләре тирбәлеп тордылар:

— О, Идрис абый!.. Миңа уналты яшь түгел ич!

Менә нәрсә өчен кергән икән бу кыз дип уйланды Идрис... Ул иртә таңнан Әхәтне эзли, мөгаен генә шәһәрдә калу мөмкинлеген юллаштырып йөридер...

Алай дисәң, нигә Әхәт килер чакта гына капылт чыгып китте?.. Җитмәсә: «Мин кергәнне Әхәткә әйтмәгез, Идрис абый», дип тә үтенде...

Редакция хезмәттәшләре килә башладылар, ишек бер ачылды, бер ябылды, хәл белештеләр, коридордан бөркелеп тәмәке төтене керде. Әхәт күренмәде, бүген ул нык ук соңга кала иде. Идрис аларның өйләренә шалтыратты. Өйдән Әхәтнең әтисе карлыккан нәзек тавыш белән:

— Үз вакытында чыгып китте, берәр яры кагылдымы әллә? — дип хафаланып җавап бирде.

— «Чаян»нан эш алган иде, шуның артыннан йөридер алайса,— диде Идрис, аны тынычландырып.

Хезмәттәшләрнең аяк тавышлары тынуга, Әхәтне сорап авыл агае керде. Ябык кына, тәбәнәк кенә, ак яңаклы, бәләкәй күзле бу агай йомышын әйтмәде, Нуруллин кирәк ие, диде дә фуражкасын учында изеп, түшәм санап таптанды.

— Кибетләргә дә керәсе бар иде, яңадан бер урармын әле алайса, якынның Бәдретдин абыең керде ие дип әйтерсең,— дип чыгып китте.

Редактор да Әхәтне эзләтте.

Кулына озынча бер әйбер тотып Әхәт унберенче яртыда гына килеп керде. Икенче кулы да буш түгел икән, анысында ак марляга ураган йомры төен. Һәрвакыт көяз егетнең бүген кырынмаган булуы бердән күзгә ташланды. Күз төпләре тирәнәеп калган, кыяфәтендә талчыгу, йончу сизелә. Үзе керде дә Идрис өстәле янында тукталып, төеннәрне берәм-берәм аның каршысына куйды.

— Күрәсеңме боларны?

— Күрәм.

— Нәрсә бу?

— Кыз булсаң, «ябышып чыгарга җыенганның өшәнчекләре» дияр идем. Ә болай аермыйм, нык төргәнсең,— диде Идрис, төеннең озынчасын капшап.

— Абайладыңмы?

— Балык дисәм инде.

— Комагайның борыны сизә тагын.

— Чират тордыңмы?

Әхәт төксе генә кашын җыерды да урындыкка лып итеп утырып тәмәке кабызды:

— Чиратта тинтәк торсын!

— Бу түгәрәге нәрсә?

— Анысы... кара икра.

— Каян каптырдың син боларны?

Әхәтнең кашлары тагын да яман җыерылдылар, ул тонык бер тавыш белән:

— Ришвәт. Взятка. Мине сатып алырга маташалар,— диде.

Идрис, көләсе килмәсә дә, һе-һе-һе дип көлде, тик тегенең шаярырга исәбе юк иде.

— «Чаян»нан шәһәр хладокомбинатын тикшерергә биргәннәр иде. Вәлиәхмәтов дигән бер бәндәне эшеннән куганнар. Күргәнсеңдер ич, тәбәнәк кенә, юаш кына!.. Республикада балык институтын бетергән бердәнбер белгеч. Уникум! Шуны эшеннән алганнар. Тотындым тикшерергә... Баш житмәслек чәбәләнгән йомгак... Эш ачыклана, тиешле эзенә керә дип йөргәндә генә, исән-сау торасыңмы, кодагый?!. Төнәген шул кеше мин югында өйгә кергән дә: «Мин Әхәтнең якын дусты... Менә Әчтерханнан посылка алдым, аңа шушы бүләкләрне тапшырсагыз кана» дип шушы ике төргәкне калдырып чыккан.

Идрис кабаланып кечкенә төенне чиште, аннан ялтырап торган бизәкле калай банка килеп чыкты.

— Оһо, килодан артык монда.

— Балыгы да экстра!.. Кызыл балык, майлары тамып тора... Шул яна дустымны эзләп вакыт үткәрдем... Адресын табып өенә бардым, бикле. Әллә мин киләсен белеп эчтән бикләнеп ятты инде, сволочь!

Банка капкачын ачып иснәп карагач, Идрис кычкырып ук жибәрде:

— Исе лә исе! Авыз суын китерә!..

Әхәт, ул-бу булмагае дигән сыман, төенчекләрне бергә төрештерде дә жирәнеп кенә үз өстәл тартмасына ыргытты:

— Туры килмәде, чыраена сылый идем.

— Нигә куганнар соң аны? Хаксызгамы?

— Шулайрак... Фактларның күбесе аның яклы иде. Комбинатта бер иш халык төйнәлгән, шомалар, каһәр! Сазаган чуртаннар. Ашаганнар Вәлиәхмәтовның башын! Ну моннан соң! — Әхәт йодрыгы белән өстәлгә сукты.— Сагайдым! Нәрсәнедер исәпкә алып бетермәгәнмендер кебек.

— Әгәр чын күңелдән китергән булса?

— Ришвәтне чын күңелдән китерәләрме? Тикшерү бетмәгән, эзләнү дәвам итә. Ул минем нинләр чокып чыгаруымны да, ни уйлавымны да белми. Үзе утырган ботакны үзе кисте, җүләр. Пычрак җан эше. Хәзер керәм дә чаянчыларга сөйләп бирәм.

— Сине редактор чакырган иде.

— Хәзер, хәзер...

— Бер уңайдан өеңә дә шалтырат әле, борчылып тормасыннар.

Вәлиәхмәтов турында читтән берәрсе сөйләсә, Идрис ышанмас иде. Тәбәнәк кенә, соңгы мода белән киенгән пөхтә бу кешенең елмаеп кына Әхәт янына кергәләвен ул да күрде. Төпле, эшлекле кеше дигән тәэсир калдырган Вәлиәхмәтов, баксаң, гап-гади ришвәтче икән!

Көтелмәгән бу яңалык кичә йокысыз яткандагы уйларны тагын өерләп күңелгә китерде... Никадәр икеләнсә дә, аның бу хәбәргә ышанасы килми, хак булган тәкъдирдә дә, Идрис Вәлиәхмәтовның бу ишарәсенең нигезендә эчкерсезлек, юмартлык, яхшылык адымы гына эзли иде... Нахакка рәнҗетелеп эшеннән куылган белгеч... Аның язмышын моңа кадәр байтак оешмалар, халык контроле, хәтта үзәк газеталар да тикшергән инде. Ләкин алар берсе дә Әхәт юнәлгән сукмактан китмәгәннәр, ул ачарга тырышканны тапмаганнар, Вәлиәхмәтов Әхәтнең хак юлга төшүен күреп торган, үзенең җиңеп чыгачагын сизенгән... Күңеле йомшармасмыни кешенең?.. Урлаган балык түгел, дусларыннан килгән бүләк!..

Тукта! Әгәр шушындый ришвәтне Әхәткә түгел, ә Идриснең үзенә китерсәләр?!

Әхәт чаянчылар янына төшеп менде, редактор янына кереп чыкты, үз урынына утырып газеталар актарырга тотынды. Идрис аңа сынап карап-карап торды да:

— Син, егет, нигә Лидага өйләнмисең? — дип сорады.

Әхәт кадап кына аңа карап алды.

— Яучы итеп җибәрдеме?

— Осталыгым юк.

— Хәйләң барып чыкмады, колагың кызарды. Алдаша белмисең, Идрис. Әйт, күпмегә сатылдың?

— Мине дә, Лиданы да шул кадәрегә барып житәрлек хөрт кешеләр дисеңме? Әйбәт кыз ич!

— Каян беләсең син аны?

— Күргәнем бар.

— Күреп кенә кешене белеп буламы?

— Карап, сынап торганым бар... Аннары, кешеләр турында начар уйларга өйрәнмәгән.

— Матур сөйләмә, дустым Аркадий!.. Өйләнмим, өйләнергә уйлаганым да юк... Киңәшең өчен рәхмәт. Сизәм, кыз активлыгын көчәйткән. Синең янга кереп энҗе яшьләрен түккәндер әле?

Идрис Әхәткә бу турыда сорау бирүенә үкенде. Шул гына житмәгән иде, Вәлиәхмәтов турында сөйләп һушын алды, хәзер Лида хакында да яман сүз әйтсә, бөтенләй аяктан егар. Сукыр син, Идрис, дияр... Томана син, Идрис, дияр...

— Нигә мине өйләндерергә ашкынасың? — диде Әхәт, сүзне үзе куәтләп.— Туйда барыбер эчмисең инде...

— Әйбәт кыз, тыйнак,— диде Идрис икеләнеп кенә.

— Тыйнак? — Идриснең котын алып Әхәт аскы иренен тешләде.— Әйбәтен дә әйбәт, тик минә кем чарлагыннан караганда әйбәт кыз?.. Безгә бер белгеч кергәләп йөри... Мәкаләләрен дә бастык. Яшь кенә. Кара гына...

— Тәүфыйкмы?

— Өстенә бастың... Исемен дә белеп такканнар иблиснең!.. Кызларны чүки генә инде шул Тәүфыйк!.. Өйләнмәгән. Менә дигән квартирасы... Казанка буенда дачасы... Төскә-биткә дисәң — киноартист. Тел бистәсе! Кыюлык дигәндә, тау актара... Лида шул мутның сөяркәсе булып өч ел йөргән.

Идриснең эче салкынаеп китте:

— Гомердә дә ышанмыйм.

— Өч җәй шуның дачасында куна-төнә ятты. Син аны кура җиләге җыеп, хризантемаларга су сибеп кенә йөргәндер дисәң, күзле сукыр... Беләсең килсә, шул Тәүфыйк аткарды да аны миңа.

— Ничек? Нигә?

— Туйган. Җиләгән. Ялыккан. Көн саен күркә ите дә туйдыра.

Әле ярый телефон шалтырады. Дилә шалтырата икән. Мәскәүдән. Идрис калтыранган куллары белән трубканы алды.

«Идрис! Исән-сау гына килеп җиттем».

— Котлыйм. Кәеф-хәтирәләр кайсы баскычта?

«Рәхмәт. Әйбәт. Билетны компосировать иттем. Поезд көндезге өчтә китә».

— Хәерле юл, Дилә.

«Тавышың бик зәгыйфь чыга».

Ул астан гына Әхәткә күз салды. Әхәт аның янына ук килеп басып бөеренә таянган, тайчынмыйча тыңлап тора иде.

— Телефон начар эшлидер.

Ул трубкага өрә башлады.

«Кичә нишләдең?»

— Минме?.. Берни дә.

«Ничек алай берни дә?.. Эч пошудан үләрсең алайса... Авырма! Кафеда ашадыңмы? Акчаңны кызганма... Мин чирләгән дә бик житкән... Киногa кер, ял ит... Башкорт театрының гастрольләре. Мактыйлар, аларны кара. Әтиләрдән хәбәр-хәтер юкмы?.. Китапка кадалып кына ятма. Җәй матур... Вагон тәрәзәсеннән сандугачлар тавышын ишетеп киллем».

— Тырышырмын.

«Сез анда ничәү?»

— Гадәттәгечә.

«Әхәткә сәлам әйт. Чәчәкләрен шиндермичә алып киллем».

Әллә барын да ишетеп торган инде, Әхәт сораусыз-нисез генә трубканы алды да ягымлы, шат тавыш белән Диләгә эндәште:

— Бу мин әле, Дилә ханым... Сәлам! Бар бит бәхетле кешеләр... Мәскәү нишли, гөрлиме?.. Мин сездән бик-бик көнләшәм!

Дилә Идрисне көнләштереп көлде:

«Артыгын көнләшеп куймагыз тагын».

Аларның рәхәт итеп, тәмләп сөйләшүләренә Идриснең ачуы чыгып торды. Әхәт юктан да кызык ясап көлде, Диләне көлдерде, менә кем бәхетле ул! Тәм табып яши, дошманнары юк, үз күңелен үзе күрә, кешеләргә яхшылык китерә!..

Икәүләшеп Диләгә хәерле сәфәр, савыгып кайту теләделәр. Бүлмә эче тынып калды. Идрис шактый утыргач кына:

— Нигә Вәлиәхмәтовның бөтен этлеген язып чыкмыйсың? — диде.

Әхәт башын калкытмыйча гына:

— Егылганны нигә тибәргә? — диде.— Болай да эшеннән сөрғәнәр. Житкән.

Шактый буазланган капчыгын җилкәсенә салып, ямьшәйгән картузлы баягы агай керде. Капчыгын иплап кенә идәнгә куйды, ике кулын сузып Әхәткә таба китте:

— Ару гына эшләп ятасызмы, Әхәт туганай? Менә без дә килеп чыктык.

— Саумысыз, агай. Утырыгыз, сөйләп җибәрегез.
— Менә килеп чыктык әле,— дип кабаглады агай, бәләкәй күзләрен челт-челт йомгалап.— Хәтәр олы йортта эшлисең икән, менә-менә җыгын чыгар.
Ул арада Әхәтне макет карап чыгарга секретарь бүлмәсенә дәштеләр.
Әхәт тиз-тиз кәгазьләрен барлады, үзен йотардай булып комарланып карап торган агайны Идрискә күрсәтеп:
— Син бик һәйбәтләп кенә агайны тыңла инде,— дип кереп китте.
— Менә, абзый,— диде Идрис, эшен куеп,— серегезне барыбер миңа чишәргә туры килә.
— Сиңа сөйләмим.
— Алар тиз генә бушамаслар... Хәер, ихтыярыгыз бәрәңге...
— Ничегрәккә китә соң мондаен сансызлык? — диде агай, кинәт гөжләп.— Бездә булды, җиңгәсе, ягъни минем җәмәгать, тавык суйды, аны йомшак түшәгебездә йоклатты... Юл төшеп Казанга килә каласың икән, онытма, шулай-шулай, әбәзәтельне кереп чык, диде... Керсәм, вәт сиңа, кәҗә тоягы күрсәтә... Без бит аңа тавык суйган, тамагына таш булып утырыгры...
— Гозерегез нәрсәдә соң сезнең? — диде Идрис, көлүдән чак тыелып.
— Сала кешесен санламас дип әйткән иде аны хатын... Кара, әгыйбди диме?.. Тавык ботын кимергәндә яман туганлашкан иде, хәзер танымаганга салыша, каһәр... Борын чөенке егетнең, борчакның эресен яра!.. Йомышны сиңа сөйләдем, ди, тот капчыгыңны. Аңа да сөйләмим. Бәдретдин төшеп калганнардан түгел, барыбер юлын табар, үзенекен итәр!.. Казанда начальство бер ул гына түгелдер әле. Тавык ашаганда ал да гөл...
Әхәт секретариаттан чыккач, Идрис аңа Бәдретдиннең зар-каргышларын сөйләп бирде.
— Председатель өстеннән йөри, юньсез,— дип көлде Әхәт.— Син аңа өч тәңкә бирерләр. Тавыгы шуннан да кыйбат тормагандыр. Җулик! Завхозлыктан төшергәннәр аны, шуңа үчегеп йөри.
Зарыктырып кына төшке аш вакыты җитте. Бер иш халык, су кереп кайтырга дип, редакция машинасына төялеп Казанкага китте, Әхәт белән Идрис капкалап алырга икенче кат буфетына төштеләр.

### 3

Өчпочмакларны типография ашханәсеннән яңа гына кертКәннәр икән, әнә алар, авыздан су китереп, пар атып, куна өстендә тезелешеп яталар.
— Ничәшәрне алабыз? — дип сорады Әхәт.
— Икешәр житәр. Берәр йомырка ал. Тавык ите дә ару гына күренә түгелме?
— Ну ашыйсың да инде.
— Синең якын дустың Бәдретдин аппетитны кузгатты.
Өстәл бушаганны көттеләр. Урыннары тәрәзә янына туры килде. Ишек алдында машиналардан зур-зур рулоннарны тәгәрәтеп газета кәгазе бушаталар.
— Синең югары як ничек? — дип сорады Идрис.
— Җүләр. «Камю»дан баш авыртамы? Шулай да үзебезнең әрмән, молдаван коньяклары шәбрәк.
— Патриотизм! — диде Идрис, өчпочмакны нык кына умырып.
Әхәт исә вак-вак кабып, тиз-тиз чәйнәп ашый иде.
— Ресторанга эчәр өчен генә йөрмим, бел, үтә кызык кешеләр очрый анда.

— Кичә дә очрадымы?

— Тешеңне ыржайтма, картлач. Синең андый кеше белән төшеңдә дә очрашканың юк. Тормышы җиде легендага җитәрлек.

— Нинди асыл сөяк инде ул?

Утыра торгач, Идрис Әхәткә һияреп ашыгыбрак ашый башлый иде.

— Кабаланма! Иң элек бер сорауга җавап бир: кеше үзе турында берни дә яшермичә кайда сөйли ала? Я, я! — дип тыкырдатты Әхәт.

Идрис ашаудан туктап уйланды.

— Юлда, вагонда.

— Һәй, юл анекдотларына ышана башласаң!.. Юлда мин Мисыр короле Фарукның кияве булып йөрим.

— Суд эскәмиясендә,— дип, күрше өстәлдән кемдер ярдәмгә килде.

— Сай йөзәсез,— дип башын селкеде Әхәт.— Кеше үзе турында фронтта, төрмә камерасында һәм ресторанда гына сөйли. Беренчесендә ул үлем белән, икенче очракта коллык белән, өченчесендә үзе белән үзе очраша!.. Барып җиттеме?

Тавык ите чыннан да тәмле иде. Артык симез дә түгел, ите сөяктән аерылып тора, хуш исле. Якын өстәлдәгеләр авызларын чапылдатмаска тырышып аларның сөйләшүләрен тыңлыйлар. Әхәтнең һәрвакыт кызыктыргыч нәрсәләр сөйләвен барысы да диярлек беләләр...

— Кичә очраган кошың да мәс иде алайса?

— Бик эчә... Шул сәбәпле хатыны ташлаган тегене, бала-чагалары сәлам дә бирмиләр, эшеннән куганнар. Миллион километр очкан летчик. Миллионер!

— Исерекләрнең мәгънәсез мактанышуын яратмыйм,— диде Идрис, кистереп.

— Ата казың кукәй саламы?.. Мин дә кочаклашып утырмадым... Ләкин беләсем килде: нигә эчә башлаган ул? Бөтен нәрсәсе бар, житеш: белеме, һөнәре, дәрәҗәсе, даны, семья бәхете, акчасы, иптәшләре... Бер селтәнүдә башны кыеп төшермә әле син, Идрис-хөкемдар!

Ләззәтле ит белән мавыгып чәй суынды, салкын чәйне голт-голт итеп кенә йоттылар.

— Тагын бер тавык, биш өчпочмак ашарлык хәл бар әле миндә,— диде Идрис.

— Гуж бине Гонык Икенче!

Коридорда бөркү һәм бугазларны кымырҗытып буяу исе аңкый. Аргы башта, «Чаян»чылар турысында, пумалалар тоткан, акшарлы кием кигән буяучылар күзгә чалынды.

— Тагын ремонт. Ел саен кайнаштыралар,— диде Идрис.

— Ленин районында Галимҗан Ибраһимов проспектында яңа өйләнешкәннәр скверы ясадылар, алмагачлар утырттылар, кайнар речьләр сөйләделәр... Язып та чыккан идек, хәтереңдәме?.. Алмагачларны йолкып ыргытып каеннар китереп тезделәр... Инде быел яз бакчаны тамырыннан корытып, проспектка асфальт җәеп маташалар...

Идрис, кеше-мазар юкмы дип, артына борылып карады.

— Су коенып килгәндә дә хөрт булмас иде,— диде ул.

— Безгә иртәрәк китәргә кирәк,— диде Әхәт, өзеп.

— Кая?

— Әллә футболдан да кыйракламакчы була инде? Кичәге кебек, миннән качмассыңдыр бит?

— Кичә син киткәч үкенеп маташтым...

Бүлмәгә кергәч, Әхәт диванга җәелеп утырды, ашык-пошык кына иске журналларны актаргалады, тәмәке кабызып, баягы фикерен дәвам иттерде.

— Әгәр мәсьәлә син әйткәнчә җиңел генә хәл ителә торган булса, ай-һай ансат ул!.. Булган эчкечеләрне юк дип уйлыйсың да күз йомып

яши бирәсең... Әмма мин соңгы вакытларда эчкечеләргә төбәбрәк карый башладым. Күп теттем мин аларны газетада,— дип сүзен сөйли бирде.— Хәзер язмыйм, алынмыйм... Аңлап бетермим, үз дәлилләремә ышанычым кимеде. Бер күңел йомшаклыгы, ихтыяр көче булмау белән генә шундый олы социаль күренешне аңлатырга ярамый... Былтыр көз Салехардта гостиницада бер кооператор белән бүлмәдәш булдык. Сөйләмәдемме икән сиңа?

— Юк шикелле,— диде Идрис, кызыксынып.

— Шул сөйләде. Кайдадыр җәһәннәмдә, Салехардтан да төньяктарак, Обь култыгында тәэминат бүлегендә эшлим, ди. Июнь башларында навигация ачылгач, баржа белән аракы китерәләр икән. Җан башына күпме икәнен дә әйткән иде, онытканмын. Баржа килгәч, ун көн эш бөтенләйгә туктала, ди.

— Нәтиҗә?

— Өч айда еллык норманы тамчысына хәтле чөмереп бетерәләр... Менә сиңа нәтиҗә... Тормыш шартлары кинәт үзгәрә. Муллык, туклык килә. Кешеләр җитәрлек акча алалар, вакытлары да күп кала. Ә алар вакыт белән акчаны ничек тотарга өйрәнмәгәннәр, әзер түгелләр!.. Ары-бире сугылалар да хәмергә ташланалар. Культура дәрәҗәбез күтәрелгәч, аракыдан җирәнә башларбыз.

— Юаттың!.. Тормыш күренешләрен бик ансатлаштырып аңлатасың.

Чәкәләшеп туймадылар, кешеләр кереп бүлдерде. Алар чыгып киткәч, Идрис һейнены актаргалады. Әхәтнең сүзе бетмәгән икән.

— Берәүләр эчә, икенчеләр кирәге булмаса да тел өйрәнә... Хобби заманы. Бер анекдот сөйлимме?

— Барыбер онытам мин аны,— диде Идрис, китабыннан аерылырга теләмичә.

— Ташлап торчы китабыңны!.. Юлда-мазарда төтен җибәрергә үзем дә үлеп яратам. Кызлар хәтәр кабалар шул чит тел дигән кармакка. Валлаһи!.. Тик былтыр троллейбуста бер кыз авызны пешерде... Күргә күреп алдым тегене: эксцентричный зат! Күзләре миндаль чикләвеге кебек... Минем дә сынатасым килми. Тиздә журнал, шәбәеп кенә утырып барам, малай, теге кызга карашгырып алам, шунда инглизчә ярырга тотынмасынмы?.. Чандыр гына татар кызы, тәки халык алдында кызартты. Шуннан бирле сагаям... Август башларында Казанга абитуриент кызлар, сары чебешләр килеп тулганда шәп була иде!.. Ә сиңа нәрсәгә тел?.. Европага җыенмыйсың, кызларга күзең төшми.

Идрис җыентыкны өстәл тартмасына салды:

— Немецлар минем әтине үтергәннәр.

— Һейне үтергәнме синең әтиеңне? Синең әтиеңә аткан немец Һейненны төшендә дә күрмәгән.

Әхәт сизелерлек кыза башлады. Ул, гомумән, бүлек мөдире буларак, Идрис белән сүз көрәштерергә ярата, һәрчак җиңүче булып, соңгы сүзне үзе әйтеп калырга омтыла иде. Тик Идрис газета-журналларны күбрәк, нигезлерәк укый, хәтере дә шәбрәк, ул мөдирен көч түкмичә дә җиңә, бирелергә яратмаган Әхәт еш кына кыдрачлана, кызып китә иде.

Әмма Идрис бүген баш бирмәде:

— Немец телен үз телем кебек белгәнче тырышачакмын,— дип үзенекен сукалады.

— Максат?

— Немецларны фашизм белән бәйләнештә генә түгел, халык буларак та беләсем килә.

— Тагын сугышырга туры килер дисеңме?

— Белә торуның зыяны булмас. Тел сугыш коралыннан бигрәк аралашу чарасы да бит ул. Үз халкыңны белер өчен дә өйрәнергә ки-

рәк. Дөнья бер, без гомер-гомердән йомылып кына яшәмәгәнбез, йомыларга уйламыйбыз да.

Идриснең сабырлыгы Әхәтне тагын да ярсыта торган иде, бүген сүз шушы урында өзелде, аны редактор янына чакырдылар.

Иртәдән бирле Казанны читләтеп кенә әле Арча ягыннан, әле Ослан тауларына тия-тия узынган болытлар, ниһаять, шәһәр өстендә куердылар. Урам шау-шуын күмеп күк күкрәде, Әхәт, редактор яныннан чыгып:

— Тәрәзәне яп! — дип кычкырды.

— Куркасыңмы?

— Анысы минем эш.

Ул яшен сугудан, тимер юл аркылы чыгудан, судан, гомумән, очраклы үлемнән курка иде.

— Барып та чыкты, бәреп тә екты.

— Нәрсә мыгырдыйсың син анда? — диде Әхәт, тәрәзә ябып маташкан Идристән шигәеп.

— Футболны изде бу, әйеме? Уенны кичектерерләр бит?

— Янгыр түгел, таш яусын,— диде Әхәт, шүрли-шүрли генә тәрәзәгә якынаеп.— Хәлләр яман яманын, чиләкләп коярга җыена!

— Казан уенчыларының ныклыгын сынап карыйлармы?.. Шулай, Ильяс пигамбәр кем яклы икән?.. Ике система очраша бит!

Янгыр бер-ике тапкыр тып-тып итеп тәрәзәләргә сызып-сызып сыланды да ишеп яварга кереште, бүлмә эче шунда ук караңгыланды. Әхәт ишек тирәсендә кул кушырып торды, аптырагач телефоннан шалтыратты:

— Ну, бәрә!.. Бәхет юк икән!..

Трубкасын куйгач, Идрискә кычкырды:

— Әй, Идрис! Австрияклар немецчә сөйләшәләрме?

— Юк. Аларның үз шивәләре. Гәрчә, бер-берсен ансат аңлашалар.

Әхәтнең сүрән йөзе яктырды.

— Әйдә, футболчылар белән очрашып сөйләшәбез? Мин интервью алам, син тәрҗемә итәсең. Интегүләреңнең файдасын күреп куаныйк. Әнә, шеф-мөхәррир яңа идеяләр белән аз керәсез дип шелтәли. Хәзер үзең үгетлим.

Редактор яныннан ул кара коелып чыкты.

— Яңалыкны аңламыйсыз... Спортның эчке мәгънәсен белмисез... Берегез дә аның тәмен, халыклар дуслыгын ныгытудагы ролен бәяләмисез.

— Нәрсә диде?

— Официаль материаллардан башка бер юл өстәмәгез, ди. Димәк, килделәр — гутен таг. Киттеләр — ауффедерзайн.

— Немецчәне син үзең дә каты ыжлатасын икән!

— Ипилек-тозлык.

— Сиңа кызлар сөярлек өйрәнәсе иде,— диде Идрис, аның күңелен күтәрергә теләп.

— Кызларны мин телсез дә сөя алам. Кул, күз исән булсын!.. Идрис, әйдә үзебез барып сөйләшәбез. Башка берәр җиргә, я радиога төртербез, килере булыр.

— Кирәкми.

— Нигә инде, кире таз?

— Футболны аңламыйм, яратмыйм.

— Син сөйләшмәссең, тәрҗемә итеп кенә торырсың.

— Коя ич.

— Син әле бөтенләй бармыйк дип үгетләрсең... Миннән яшертен берәр сәфәрең юктыр ла?

Идрис өстәлендәге тарау кәгазьләрне берәмтекләп җыештырды, папкаларын ыктымат бәйләде.

— Кешеләргә ышанычын югалткан бәхетсез бәндә син! — диде.— Кайчаннан җуйдың ул ышанычыңны?

— Авызыма резин имезлек кергән минутта...

— Футболчылар янына керик дип кытакламассың.

— Куркак! Халыкара скандалдан шүрлисеңме?..

Бер сүзгә җиде җавап табып тик көлеп тора бу Әхәтең! Идрис тә көлемсерәп:

— Безнең белән очрашырга атлыгып тормыйлардыр,— диде.

— Килештек. Калган стратегик мәсьәләләрне урында хәл итәрбез... Ну, көҗәлә дә кеше инде үзең! Вак... Кәҗә шомырты төсле... Синең белән торган хатын чирләмичә нишләсен? Я, я, картлач, авызыңны турсайтма!..

Идрис, яңгыр туктамасын дип, бик теләп утырды. Ике-өч сәгать юеш эскәмия саклаганчы, монда рәхәтләнеп китап-журнал актарынып утырасы килде аның... Егерме биш мең кеше арасында азапланганчы, монда япа-ялгызы ял итәр иде... Әхәт сөлек шул, бер ябышса, ычкындырыр димә...

«Япа-ялгызы гына?»

Уйланды да куркынып китте. Хата яшәмиме? Яшь кеше, егерменче гасыр кешесе. Үзе халыкларның якынаюын күзәтеп, сизеп, шул арадашлыкка өндәп килә. Әнә Әхәт ничек шатлана. Кемгәдер шалтырата, куана, футболчыларның килүе уртак сөенеч, уртак мавыгу. Футбол карарга килүче егерме биш мең кеше арасында Һейненны укыганнары ничәү икән?.. Һейненны, Штраусны белмәгәннәре дә Австрия командасы «Рапид»ның төп һөҗүмчесе Зигфридны әллә ничә кат ишеткәндер... Бәлки әнә шул ун-унбиш егет, аларча, бер шагыйрьдән зуррак, үтемлерәк эш башкаралардыр?..

Икеләнү узды, барырга кирәк, йөрергә, күрергә, аралашырга, шатланырга, кайгыртырга... Барысы да бергә...

Көндезге дүрттә уен башлана.

Матбугат йортыннан берән-сәрән генә чыктылар. Портлар юеш, күк соп-соры, асфальт өстеннән пычрак күбекләрен чәчә-чәчә кара гөрләвекләр ташый.

— Шауламагыз, җәмәгать, бал ява, бал! Июнь башында яуган яңгырның һәр тамчысы алмаз бөртегенә тиң, хас шулай! — диде кемдер, сокланып туя алмыйча.

— Кырда яумый шул ул, шәһәр ташына гына коя,— диде Идрис.

— Яңгыр яңгырны чакырыр!

Әхәтнең эш көйле, плащны киде дә куйды.

— Син плащ алмагансың икән, Идрис.

— Плащы кибеттә, акчасы банкыда.

Пиджакның көтек якасын күтәргән арада, яңгыр тамчылары сискәндереп җилкә чокырына тәгәрәделәр.

Җәяү атладылар, троллейбусларга якын килерлек түгел, стадионга якынайгач, кеше ишәйде, төркемләнеп бергә кушылдылар.

Килеп кергән бере үз урынын эзләүдән битәр футбол кырына карап тел шартлата иде:

— Бетергән икән!

— Хә-хә-хә!..

— Менә сиңа әкәми...

Футбол кырының яшел келәмен яп-якты су каплаган иде.

— Бәлки уен булмас та? — диде Идрис, һаман өметләнеп.

— Була, була!

— Син кәкрәерсең болай, картлач,— диде Әхәт,— әйдә, плащның бер почмагын арендага бирәм. Бәясен үзең чамала...

— Хак ярым хак җитәме?

Лычма юеш утыргычка чирканып кына ике-өч кат газета җәйделәр. Әхәт плащы астына посып, тәнгә-тән тиеп утыргач, Идрискә җылы йөгерде, ул кызыксынып ук футбол кырын, җыелган халыкны күзәтергә кереште.

Ниһаять, утыргычларны газеталар, плащлар, зонтлар, пиджаклар, тагын әллә нинди чуар-чабырлар каплап бетерде. Менә астан — Идрисләр секторының сул ягыннан — кардай ак майкалар, саргылт трусиклар кигән таза-таза җирән егетләр җитез генә йөгерешеп чыкты.

— Австрияклар, австрияклар! — дип шаулашты халык.

— Зигфрид кайсысы?

— Әнә, әнә, тугызынчы номер!

— Итальяннар капкасына өч туп кертте...

Футболчылар көлешә-көлешә кырга сибелгән чуар туплар артыннан куышып чабарга тотындылар. Бала чакларын хәтерләтеп су чәчрәтеп уйныйлар идеме, әллә тән язалармы, аңлап булмый башлады. Аларның су чәчрәтеп шуклануларына карап халык та гөрли, хуплап кул чаба иде. Идрис белән Әхәт плащка сыя алмыйча көлештеләр.

— Күрденме, Һейне? — дип куйды Әхәт.

Туп тәгәрәми! Гер тибәләрмени!

Әхәт, иңбашы белән Идрисне сөзә-сөзә:

— Безнекеләр җиңелер инде, тәгәрәми,— дип уфтанды.

— Ике як өчен дә тәгәрәми инде ул,— диде Идрис.

Аның сүзен ишетеп куршеләрдән берәү сүгенде:

— Шыбырдашмагыз! Безнекеләр чыга!

РСФСР җыелма командасыннан берничә уенчы белән ныгытылган Казан футболчылары «сезон»га хасрак киенгәннәр: трусиклары кара, майкалары җете кызыл. Алар кул болгап тамашачыларны сәламләделәр дә, кышкы кысан араннардан иркенлеккә ычкынган яшь тайлар кебек сикергәләп, су өстенә таралыштылар. Аяк-кулларын язарга тотынган уенчылар турында трибуналарда сүз куерды.

Судьялар чыкты, сыбызгы сызгырды, уен башланды!

Футболчылар көлә-көлә туп артыннан чабалар, таеп егылалар, бишәр метр шуып китәләр, чулт итеп күлләвекләргә чумалар, тамашачылар өзлексез шаркылдый, сызгыра, ихахайлый...

Үз стадионнарының шушындый бәләкәй, трибуналарның тәбәнәк, футбол кырының сулы булуына Идриснең эче поша башлады. Әгәр бу австрияклар яңадан бер тапкыр Казанга килеп чыга алмасалар, шәһәр аларның хәтерләрендә шундый юеш, дымсу, футбол кыры уңмаган килен тәбикмәге төсле лычкылдаган ләчтә булып хәтерләрендә сакланыр. Казан турында Европада сүз чыкса: «Ә-ә, теге, футбол кыры Венециягә охшаган шәһәрме?» дип усал шаяртырлар...

Сынатмаска иде...

Әле ярый, язгы боз күк өелешеп тамашачылар-болельщиклар килгән. Буш урыннар бөтенләй күренми. Суда чыланган, мәлҗерәгән туп артыннан кем ныграк йөгерсә дә, тамашачылар битараф калмыйлар, дәртләндереп гөрләшәләр, кул чабалар, сызгыралар. Бер-ике минуттан кемнең кайсы командадан икәнлеген аерып булмаслык күренеш туды, трусик-майкалар үтәли яшькелт үлән төсенә манылдылар. Уенның күбрәк казанлылар капкасы төбендә баруыннан гына каршы якның ныкышып һөҗүм итүен чамаларга була иде.

Идрис эченнән генә түгел, кычкырып ук Австрия командасының җиңүен тели башлады. Ул «Рапид! Рапид!» дип ай-һайлап аларны дәртләндерә, немецчә сүзләр дә кыстыргалый, үзе һаман: «Ичмасам җиңсеннәр, күңелләре төшмәсен, юанып китсеннәр» дип уйлый иде. Әхәткә бу бер дә ошамады, ул плащны бер тартты, бер күтәрде, терсәге белән дә Идриснең янтыгында уйнаштыргалады.

Бераздан стадионга ике яктан икешәр-икешәр дүрт янгын машинасы килеп керде. Аларны ур-ра кычкырып каршыладылар.

— Казан командасын коткарырга!

— Яналар иде югыйсә.

— Бетте «Рапид», шабаш!

Янгынчылар, футболчылар белән житез генә ярышкан сыман, машиналарыннан шыбырдашып коелдылар да озын эчәкләрен сүтә-сүтә кыр яны судьяларына комачаулап хикмәтли башладылар.

Янгыр вак иләктән коеп тора, уен кызганнан-кыза, тәмам ярсыган тамашачылар үкерәләр, янгынчылар бу көнелле спектакльгә кәмит, кызык өстәделәр. Ярым шәрә футболчылар янында аларның кыска аяклары, озын, чамасыз киң балаклы брезент чалбарлары, киң каеш белән буылган кыптыр-коптыр курткалары, елык-елык жиз каскалары, әүнәп-тәүнәп килеп биюче аю сыман кайнашулары үзе бер гажәеп тамаша иде. Янгынчыларга шундук исемнәр табып өлгерделәр: һәйбәт кенә купшы мыек жибәргән, аерыта киң балаклы берәү «центр форвард» булды.

— Пижон, стиляга! — дип үкерде стадион ул чулт итеп барып егылгач.

Ул ике машина арасында йөгергәләп кенә йөри иде. Башкалар «сакчы», «ярымсакчы» дәрәжәләренә лаек булдылар. Карсак гәүдәле, түшен киереп кенә кыбырсыганы «пешмәгән судья» исемен алды...

«Пешмәгән судья» кычкырып команда бирә торды, «центр форвард» киндер станындагы соса кебек ары-бире буталды, машиналар дүртесе дүрт урыннан гүелдәп эшкә керештеләр, насослар ыжлады, тик футбол мәйданы өстендә әледән-әле дулкынланып торган күлләвекләр тамчы да кимемәде. Машиналар бердәм гүли, тамашачылар янгынчыларны да, уенчыларны да дәртләндереп, көч биреп акырышалар, сызгыралар, стадион ду килеп тора иде. Янгынчылар, азапланып-азапланып та эш чыкмаслыгына ышангач, озын эчәгеләрен тотып «Пешмәгән судья» тирәсенә жыйналдылар.

Кинәт бөтен стадион ах итте, тамашачылар өстеннән суык жил узды, юеш, жебеп мескенләнгән туп казанлылар капкасына кереп, жәтмә арасына уралып тырпылдавыннан туктады. Бичара тупка озак хәл жыярга ирек бирмәделәр, артына тибеп тагын уртага чыгардылар.

Идрис плащын каерып ыргытып сикереп торды, кул чәбәкләде:

— Ур-ра! — дип кычкырды. Немецча да өстәде.— Булдырдыгыз!

Ике-өч кеше кырт кына аңа борылдылар:

— Ни ди ул?

— Шпиондыр бәлки?

— Ташлагыз,— диде Әхәт эре генә.— Ул чит ил министрлыгында эшли, дипломат. Бездә кунакта.

Тегеләр туп кергәнгә үртәлеп шашынганнар, тынсалар да Идрискә яман-яман карап алалар иде.

— Нигә шулчаклы кикрикләрен кызарталар? — дип пышылдады Идрис.— Әйтерсең лә, үзебезнең капкага тупны мин керткән?!.

Тәнәфескә шул күңелсез исәп белән чыктылар.

Рәтләр буйлап тонык су тутырылган кәгазь стаканнар йөреп китте...

Икенче тайм башланганда, тамашачыларның кызуы бераз сүрелгән, алар игътибарны су суыртырга азапланып та бер эш тә кыра алмаган янгынчыларга күчерделәр.

Менә уен башланды, янгынчылар, барып чыкмаган эшләрен ташлап, үзләрен чакыруларына канәгать икәнлекләрен яшермичә, футбол мәйданы тирәсенә чүмәштеләр.

— Акча да бара, футбол да карыйлар,— диде арадан берәү.

— Пижоннар, шаярган булып кына ун атмосфера белән Зигфридка берне бәрәсе иде!

— Тупка диген син, тупка!..

— Голны санарлар идеме икән?

Казанлылар исәпне тигезләргә теләп, тырыша-тырыша тупны каршы як капкасына алып килгәләделәр, тамашачылар аларга дәрт өстәп тамаклары карлыкканчы кычкырдылар, әмма кунаклар елмаешып мәйдан буйлап суны житезрәк ералар, тупны эләктереп алсалар, тиз генә ычкындырмыйлар, исәп әлегә алар файдасына булса да, туктаусыз һөҗүм итәләр иде. Тырышлык нәтиҗәсез булмады — казанлылар капкасына икенче туп керде. Зигфрид, шул ук аяусыз Зигфрид! Бөтерчек кебек бөтерелә-бөтерелә, әллә нинди баш әйләндергеч финтлар ясап ярымсакчыларны узды, сакчыларны артта калдырды һәм капкачы белән күзгә-күз килеп, тупны нәкъ югары почмакка җибәрде. Туп сызгырып үтеп киткәч, капкачы да сикергән булды, юеш пирчаткәләре белән һаваны сөзде, аннан, тотрыксыз яшь бозау сыман, лач итеп лайга барып сенде... Тамашачылар сикерешеп тордылар.

— Туң кәбестә күчәннәре!

— Туп тибәргә түгел, чүп көрәргә җибәрергә кирәк аларны!

Кемдер нәп-нәзек зәңгәр тавыш белән:

— Судьяны сабын казанына! — дип чыелдады.

Әхәт Идрискә шыпырт кына:

— Эмоцияләреңне яшер, халык кызды, тукмап ташламагайлары,— диде.

Уенның темпы сүрелде, карау кызыгы бетте, казанлылар өчен янып-көеп, йодрык төеп утырган тамашачылар Австрия командасын дәррәү мактарга күчтеләр...

— Егерме биш мең кешенең кәефен кырдылар, сыбызгылар,— диде Әхәт, манма су плащын кия-кия.— Хәзер тиз генә тынычланырмын димә...

— Матур уйныйлар. Бердәм коллектив. Бөтен линияләрдә көчләр тигез.

— Академик! — диде Идрисне мыскыллап Әхәт.— Бер мәртәбә футболга килеп теоретик ачышлар ясый.

— Мондый уенда гап-гади журналист күзе дә җиткән.

— Хәзер кая барабыз? — диде Әхәт сынап кына.

— Ныгытып ашарга,— диде Идрис, салкын, вак яңгырдан чирканып.— Көндез аппетит булмады... Менә син, комагай, ашыйсың икән!.. Бәдретдин килеп сереңне ачты... Әй, Әхәт, булган бер җиреңнән яман көчек сыман кунак өндәп кайтма!

Халык ташкыны аларны Болак буена ияртеп чыкты. Шул вакыт арттан кемдер:

— Җизни, җизни! Идрис җизни! — дип эндәште.

— Чукынды марҗа кыярга! — диде Әхәт, артына борылып.

## 4

Өй эчендәгеләрдән бүген иң элек Мөзәкир уянды.

Абыйсы Мөнир белән алар чолан идәнендә йоклыйлар иде.

Уянды да үзе ябынган иске толыпның итәген кайтарып абыйсына карады.

Йоклый. Тын алганы да ишетелми. Таң йокысы...

Кыймылдарга уңайсызланып шактый әвәләнде малай. Тавышсыз гына өй ишеге ачылды. Аяк адымнарын таный Мөзәкир: әнисе чыкты. Саклык белән генә өй алдындагы чапчак капкачын күтәрде. Шыпырт кына самоварга су салды, күмер тутырды. Мөзәкирнең борынына янган чыра исе килеп житте, ул җиңел сулап куйды...

Көн әйбәт икән!

Көн жилле-мазар булганда, әнисе самоварны өйгә гөлбәчкә куя. Тын, матур көннәрдә жиз самовар шунда болдыр янындагы таш ялгаш өстендә кукыраеп утыра. Ишек алдында кайнаган чәй тәмлерәк була, ди этиләре...

Әтисе дә сак: самовар гөжли башлауга уянып чыкты. Нык итеп киерелде дә:

— Шөкер, һавалар әйбәт тора икән! — дип пошкыра-пошкыра юынырга тотынды. Әнисе су салып торды. Бер комган гына житми этисенә, тагын өстәделәр. Чәлдер-чөлдер нидер сөйләштеләр, тик лапаскура ягыннан сузләре чоланга ук килеп житмәде.

Ул арада әнисе өйгә кереп Нәгыймне уята башлады:

— Тор, бәбкәм, уян, куяным... Тор, әнә кояш та чыгарга итенә...

Бигрәк иртә уянган Мөзәкир!..

Энесе Нәгыйм Мөзәкирдән көчсезрәк, гәүдәгә дә күп кайтыш, шулай да икенче ел инде этисе белән колхоз сыерларын көтә. Шушы эшне яратты малай. Яз житеп, сыерчыклар сайрый башлауга, чыбыркы ишәргә тотына. Гәрчә, күп еллар колхоз терлекләрен көткән Хәлил агай чыбыркы алып чыктырмый, хайваннарга үзе бер чакта да сукмый, иң кире, качкын малларга да яхшы сүзе, тәмле теле житәрлек аның.

Әтисе күз алдына килде Мөзәкирнең...

Кешеләр белән аз аралашканга сирәк-мирәк кенә сөйләшә торган, бер карауга кырыс бу кеше мал-туар янында бөтенләй үзгәрә. Күп санлы жыерчыклар уртасында калган япь-яшь күзләреннән елмаю китми. Кытыршы, бирчәйгән куллары белән сыерларның жып-жылы, йоп-йомшак муеннарын көнләштерерлек рәхәт итеп сөя, кашый, иркәли. Сыерлар да муеннарын сузып, күзләрен йомып, авызларындагы ризыкларын кушәргә тотынып мәрткә китеп торалар...

Нәгыйм дә этисенә охшаган, ахры, мал-туарны яратты. Әллә сул күзе кылый булганга, авылның телчән малайларыннан гарьләнеп урамсукмаклардан читтәрәк эшне сайладымы?..

Күренүгә:

— Кылый, кылый кылган, ыштан төбен жырткан! — дип үртиләр үзен... («Ул Сәхәби малаен бер ярасы булыр, такмакны шул чыгарды, тәкәрлек!»)

Әтисе белән Нәгыйм атна-ун көн куна-төнә жәйләүдә ятканнар иде. Малайлар Казанга барасы булгач, алар да озатышырга кайттылар. Кичә мунчалар керенеп, жыйнаулашып, шулпалы бәлеш ашадылар, кар базыннан чыккан салкын карлыган вареньесы белән ике самовар чәй эчтеләр...

Мөзәкир абыйсын тырылдата башлады:

— Мөнир, Мөнир!

Стена ярыгыннан идәнгә нур кылычы сузылды...

— Мөнир!

Тегесе уянмый да, селкенми дә.

Мөзәкир ярсып пышылдарга тотынды:

— Бел, малай... Әни әллә кайчан торды... Чәй кайнап чыкканга биш былтыр... Мөнир дим, Мөнир! Йокы базы. Соңга калдырсаң күрерсең, жыларсың.

Иртәнге биштә колхоз машинасы станциягә бара, алар шуңа эләгергә тиешләр. Станциядән поездлар уза, алар шуларның берсенә утырып Казанга китәләр...

Мөзәкир тезләнде дә йөзтүбән яткан абыйсын чалкан әйләндерде, Мөнир тәмле итеп иреннәрен чапылдатты, йокы аралаш елмайды.

— Калсаң кал, тотам да үзем китәм.

Жырлап кына чолан ишеге ачылды, әнисе керде, өзгәләнеп карап торган улының башыннан сыйпады:

— Иртә купкансың әле, балакаем... Уятма абыеңны, йокласын... Үзең дә рәхәтләнеп йокла, кинән.

— Сонга калдыра бит.

— Өлгерәсез, балам, өлгерәсез! Эшчеләргә тамак ялгатыйм да сезгә самовар яңартырмын.

— Мин чәйне этиләр белән эчәм.

Әнисе бераз бөкрәебрәк чолан ишеген каплап тора. Ачык өйалды ишегеннән кырлый-кырлый тавыклар килеп керде. Әнисенең кулыннан сөт исе, үлән исләре килде, Гөлбикә апа Мөзәкирнең каты, кара чәчләреннән сыйпый-сыйпый һаман иркәләде:

— Көйрәк шул син, улым!.. Үземә охшагансың... Абыең йокласын, тимә, үзең уянгансың икән, әйдә тор, әвәләнмә. Сансыз кеше сынсыз була диләр, тор...

Мөнир тәки кымшанмады, мышнап калды. Әнисе учларын сак кына шапылдатып тавык-чебешләрне өркетеп төшерде:

— Кө-өш, рәхмәт яугырлары!.. Иң элек эшчеләрне ашатырга кирәк, аннан сезгә дә жим сибәрмен, нәнекәчләр...

Мөзәкир юынып кергәндә, әтисе белән Нәгыйм изгән бәрәңге ашап чәй эчеп утыралар иде. Чожылдаган самовар янында түгәрәк җамаяк белән ак май тора, калай тәлинкәгә теп-тере су тамчылары җемелдәшкән яшел суган кыяклары тезелешкән. Кызыл ашъяулыкка төрелгән дәү, түгәрәк ипинең кибән башыннан соң калын гына җиде-сигез телем теленгән иде.

Әнисе чуклы-чәчәкле манпасый савытына тутырылган балны Нәгыймгә таба шудырды:

— Нытытып аша, бәбкәчем... Син дә, Мөзәкир. Юлга чыгасың... Яшь чагында нытып, көчәеп калыгыз... Әнә, Дилә апагыз... Мескенкәйне сабыйлыгында кирәгенчә тәрбияли алмадык шул... Мәктәбенә чыгып киткәндә, күз яшемнең тәгәрәп төшмәгән көне булмады... Каян килсен ул саулык, каян килсен кайгы-хәсрәтне җиңәрдәй көч?..

Әтисе кабаланмыйча гына Мөзәкиргә сөтле чәй ясады, әниләре утырмады, кече як ишегенә сөялеп алъяпкыч итәге белән ара-тирә күз тирәләрен сөртеп, ир-атның ашаганын күзәтеп рәхәтләнеп торды. Нәрсә кара кирәк булса, ул иренең күз карашыннан аңлый, ә дигәнче кар базына төшеп менә, чоланга йөгерә, соралган нәрсәне ялгышусыз китереп бирә. Тәмләп, озаклап чәй эчтеләр. Бераздан Мөнир дә торып киерелә-сузыла өстәл кырыена килеп утырды.

Тамак туйдыргач, Хәлил агай сүз әйтергә тиешен тапты.

— Улым,— диде ул, Мөзәкиргә төбәп.— Тиктомалга килде-китте сораулар бирә торган гадәтең дә баррак... Я, я, борылма читкә, үпкәләмә... Мин синең атаң, мин әйтмәсәм, сиңа кем әйтер? Кем яшәргә өйрәтер?!. Атаң белән шушылай өстәл артында утырып чәй эчү үзе бер бәхет, кадерен бел...

— Атаң әйткәнне тыңла, улым,— диде Гөлбикә апа.

— Җизнәң безнең иш түгел, олы урындагы кеше,— дип дәвам итте Хәлил агай, авызын чиста тастымал белән сөртеп.— Ырдый-бырдый сүз белән берүк аны борчыма. Әйбәт торабыз диген, бетте-китте... Болай да әле җизнәгезгә...

Әнисе күз төбен ешрак сөртергә тотынды:

— Апагыз да яшьли сырхап торгач, җизнәгезнең җанын кыйнамагыз ди атаң...

Мөзәкир капылт кына ашаудан туктады, кашыгын өстәлгә куеп тәрәзәгә текәлде. Читән казыгында сөттән бушаган чүлмәк кибә, чүлмәк өстен мәйдан ясаган ике чыпчык чырк-чарк мактанышалар...

— Яңа фатирларына күчкәч бара алмадык, үпкәләмәсеннәр, житешкәч бер күрербез... Моны тутагызга аерып әйтегез. Өй котламый калмабыз, анысына гына мәнебез житәр. Бусын, Мөнир, үзең жайлап әйтерсең.

Әтисе Мөзәкиргә ышанмый, «килде-китте сүз сөйләмә» ди... Малайның кәефе кырылды...

Аның көтүдән бизүе сәер генә булды. Моннан ике-өч ел элек әтисе белән көтүдән кайтты да әнисен мич арасына чакырып кертеп, кызарынып-бүртенеп:

— Моннан болай көтүгә чыкмыйм, әни,— диде.

— Нигә алай дисең, балам? Чирләп-мазар киттеңме әллә? — дип борсаланды Гөлбикә апа.

— Кая кушсагыз шунда барам, көтүгә чыкмыйм.

Кичке ашка кадәр бу хәбәр әтисенә мәгълүм булса да, Хәлил агай төпченеп, кабатлатып тормады. Иртән дә бу турыда сүз яңартмадылар, көтүгә Мөзәкир урынына беренче тапкыр Нәгыйм чыкты. Өй аулак калгач, Гөлбикә апа әле юмалап, әле ялынып малайның сөрен алды.

— Кыя тау өстендә утлатып йөрибез, машинасына утырып Степанов абый килеп чыкты... Әтине эттән алып эткә сала, көтүгә чыкканыгызга кайчан, терлекләр мәктәп кабинетындагы скелет кебек ябык, ди... Әти кыш буе уаланып чыкты: житенкерәми хайванкайларга, комбикорм кайтармыйлар, бардага бармыйлар, печән-мазар да мыскаллап бирелә, анысы да такы-токы быел, диде... Шуларны белә, председатель янында авыз йомып, тик тора... Степанов белән бәләкәй чакта дус булдык, бергә уйнадык дип мактанган иде югыйсә...

Ана малайның хәлен аңлап, аның үртәлүчән-гарьчеллеген белгәнгә, аңлатып, төшендереп карады:

— Бәләкәй чакта бөтен кеше белән дус буласың... Юллары аерылгач, нихәлләр кылмак кирәк?.. Атаң шундый инде ул, аны бер бүген генә үзгәртмәссең... Адәм баласы сандалдагы тимер булмас... Артыгын эндәшмәс, карыша белмәс, аларының кирәге дә юк. Сүккән-сүккән дә беткән, әтиеңнең укасы коелмаган. Иелгән башны кылыч кисмәс... Председательнең эше җиңелме әллә? Аның үзенә дә атлаган саен әр ишеттерәләрдер... Холыклырак булса, ни әйтер идең кана, Степанов дәдәң корырак шул... Әтиеңне бүген сүксәләр, иртәгә мактарлар! Эш кешесенә барысы да житәрлек әлегә...

Кишер, чөгендер утау, аны сирәкләү, жир йомшарту ялыктыргыч, вак эш булса да, Мөзәкир сүзендә торды, әнисе белән яшелчәдә изаланса изаланды, көтүгә якын да бармады. Яшелчәгә исә председатель сирәгрәк кагыла иде...

Быел да Мөзәкир яшелчәгә йөрергә булды.

Укулар беткәч, эшкә ныклап тотынганчы, Казанга апаларына барып кайтырга жыендылар. Беренчедән, быел жизнәләре яңа квартира алды, малайларның аны күрәселәре килде, икенчедән, Дилә апалары «ике айга дәваланырга җибәрәләр, якын араларда путевка өметләнеп йөрим» дип язган иде. Китканче аны күреп калырга кирәк, былтыр да кайта алмадылар... Олы апаларын малайлар бөтенесе дә үлеп яраталар...

Әниләре берәм-берәм һәркайсын аерым кәгазьгә төреп олы чемоданга кукәй тутырды.

— Биш дистәсен жизнәңнәргә күчтәнәч итәрсез, калганнарын сатарсыз. Якын-тирәдә берәр базар бардыр әле,— диде Гөлбикә апа.

Мөнир хәтәр көдрәеп:

— Әнә Мөзәкир эше ул— дип куйды.

«Базар» дигәнен ишеткәч, Мөзәкир аяк терәп каршы килде: «Бармыйм дигәч бармыйм базарга... Сатмыйм дигәч сатмыйм... Мин базар-

чы түгел!» дип кабатлады... Этисенең шырдый-бырдый сүз дигәне шул түгел иде микән?..

Чәй янында кинәнеп утырган этиләре кабалана башлады, кыршылган иске кожанын беләгенә салып, малайлар белән күреште:

— Әйбәт йөрерсез дип ышанам. Жизнәгезнең дә, апагызның да жаеннан гына торыгыз. Шулай яшәгәндә, барыңа да күңелле була. Ямегез?

Нәгыйм чак кына чалыш күзләрен мөлдерәтеп абыйларына кызыгып карап торды. Ул үкчәләре кыршылып беткән кирза итек кигән, өстендә Мөнирдән дә, Мөзәкирдән дә калган иске пиджак.

— Миңа пәке алып кайт, Мөнир абый, яме,— диде ул,— дүрт жәплесен, бораулы, безле булсын.

— Ярар. Күкәй сатылса, акча калса алырбыз,— диде Мөнир, аңа карамыйча гына.

Этиләре бусага яныннан тагын борылды:

— Пәкегә генә акча житкерерсез, туганыгызның үтенечен жиргә салмагыз,— диде. Нәгыйм сөенеп этисе артыннан теркелдәде...

Борынына ис керә башлаган үсмер егет булганга, Мөнирнең киемнәре затлырак. Ул ак күлмәген, көрән лавсан чалбарын үтүкләп кичтән үк урындык сыртына элеп куйган иде. Берочтан әнисе Мөзәкирнең тезләре чак кына куыкланып алга чыккан буй-буй кара чалбарын да үтүкләгән икән. Монарчы мондый нык сырлы чалбар кигәне булмаганга, Мөзәкир оялып чоланга чыгып китте һәм чалбарының сыры тигезләнгәнче тез турыларын сыпыргалады.

Күкәй тутырган авыр чемоданны Мөнир үзе алды, жизнәләренә бүләккә дигән нейлон күлмәк белән авылның аш-су остасы Миңзифа карчык ун күкәйдән пешергән таудай чәкчәкне Мөзәкиргә тоттырдылар. Түбән очка идарә янына барып житкәндә, машина кузгалырга тора иде. Гөлбикә апа уларын машинага кадәр озата килде.

— Апагызга да, жизнәгезгә дә сәлам әйтегез! — дип кычкырып калды.

Авыл урамын чыкканчы малайлар бераз шәбәеп, як-якларына борылгалап, башны күтәреп бардылар, бөтерелеп-бөтерелеп әржәгә үрмәләгән вак, соры тузанга игътибар итмәделәр. Авылны чыккач, әйберкаралары үз кырларына куеп, әржәгә чумәштеләр.

Бераз баргач та унда, елга аръягында тау тезмәләре башланды. Тау тезмәләренең патшасы булып сызылып кына текә сырт менә. Шушы инде Кыя тау!.. Итәгенә сыер көтүе таралган... Аклы-каралы чуар сыерлар... Әнә, качкын мүкләк иң алда... Мөртәт сыер, күпме жык күрде Мөзәкир шушы хайван аркасында... Жәйләү артындагы урманны ничә әйләнде шуны эзләп!..

Көн эссе булса да, кожанын кигән этиләре сын кебек кымшанмыйча аларны озатып калды. Нәгыйм өстән йөгереп төште, шатланып кычкыра-кычкыра таягын болгады.

Станциягә хәзер бик әйбәт юл бара, былтыр гына комлы вак таш жәеп, авыр кәтүкләр тәгәрәтеп тигезләделәр, коры чакта асфальтның бер якта торсын.

Мөзәкир, бераз баргач эче пошып, абыйсыннан сорап куйды:

— Нигә эти жизнәгезне борчымагыз ди ул?

— Берәүне дә борчырга ярамый,— диде Мөнир, белдекле төс белән. Үзен борчыган өчен малайны шелтәләргә әзер торуы ап-ачык булса да, Мөзәкир һаман тыелмады:

— Аны борчырга без борчалар түгел бит,— диде ул, юри дорфа итеп.

Балалар янында калганда кинәт шәбәя торган Мөнир бу юлы да борынны югары тотты:

— Килде-китте сүз сөйләшмәскә кушылганмы сиңа?.. Тын! — диде.

Малай тынмады.
— Килде-китте сүз ни төсле була соң ул? — дип сорады.
— Әйтик, ничек яшисез? дип сорасалар, әйбәт диген дә май кап.
— Әгәр өстәлләрендә май булмаса?
— Ул чагында чәнти бармагыңны нык кына тешлә.

Машина җиле аларның сүзләрен урлый, алар кычкырып-кычкырып сөйләшәләр. Мөнир, абый кеше буларак, энесенең чытлыклануына чик куярга булды:

— Үз хәлләре хәлдер, чүп кенә башыннан олылар эшенә, зурлар сүзенә тыгылып, сыек шулпаны куертып йөрмә, ишетсен колагың!
— Мин кайчан олы булам?
— Үз тамагыңны үзең туйдыра башлагач.
— Менә солдатлар үз тамакларын үзләре туйдырмый,— диде малай, киреләнеп.— Аларны хөкүмәт ашата. Олымы алар, кечеме?

Телләшеп барганда Мөнир, чәкчәк тактасының бераз артка шуышуын күреп, энесенә карчыгадай ташланды:

— Чәкчәкне боз тагын, чүп базы! Изсәң апа кирәгенне бирер, үзем дә өстәрмен, күп сорамам... Тел чарлап барган була бит, каткан кайрак...

Ул үзе такта чемоданны тезе белән кузов кырына терәп селкетми алып бара иде, Мөзәкир чүгәләде, чәкчәкне тезләре өстенә куйды, сул кулы белән чытырдатып тактага ябышты. Очалар гына, юл тигез. Каршыга килгән машиналар гөжт-гөжт итеп узалар. Ят авыллар, урманнар, күперләр, күпер буйларында казлар — барысы да кызык... Бер малай ыштанын күтәрә-күтәрә нәкъ машина алдыннан гына урамны йөгереп чыкты. Шофер кабина тәрәзәсеннән башын тыгып кычкырган иде, малай тукталды, борылып шоферга нәни йодрыгын күрсәтте.

— Менә үләт! — диде Мөнир һәм ни өчендер чәнчеп Мөзәкиргә карады.

«Җизни белән сөйләшәсе сүзләр бар... Күп...» дип уйлап барды Мөзәкир... «Мөнир гел бергә йөрмәс... Агылый-тагылый түгел... Җизни белән, апа белән калган чаклар булыр...»

Станцияләре кечкенә аларның, җыйнак. Акка буялган алты почмаклы бүрәнә йорт. Йорт тирәли тигез кыркылган сәрви куаклары. Җил. Гел җил. Ничә килде инде Мөзәкир монда, гел җил. Әллә станция тау башында, калкуда утырганга инде?.. Машинада килгәндә үк көн болытлап, сирәк-мирәк яңгыр төшкәли башлаган иде, хәзер гел яварга итенә... Иртән нинди аяз иде, кара, күкне нинди ямьсез болытлар сарып алды... Дәү үрмәкүчләр кебек болытлар кояшны урладылар...

Кеше күп түгел иде, поездга җиңел утырдылар.

Келтер-келтер күңелле генә бардылар. Өлкән юлаучылар аларның кая, кемгә барулары белән кызыксындылар. Мөнир:
— Казанга барабыз, апаларга кунакка,— диде.
Мөзәкир масаеп:
— Безнең җизни редакциядә эшли,— дип өстәде.

Аның сүзгә кушылуын Мөнир тагын өнәмәде... Малайлар ашап алдылар, берәм-берәм чиратлап вагон буйлап аргы башка барып килделәр. Казанга җитәрәк Мөзәкир пошына башлады:
— Җизниләрнең өен ничек табарбыз икән?
— Иң элек эшенә барабыз. Хәзер алар икесе дә эштә.
— Башта Дилә апаны табыйк без.
— Дилә апа Арча кырында ук эшли. Җизнинең эше вокзалдан ерак та түгел, кергән бар минем...

Беләм, беләм дип бик кәперенсә дә, Мөнир Матбугат йортының кайдалыгын оныткан икән. Сорашырга туры килде, ничек-ничек ба-

рырга иконлеген ачыклагач, малайлар жәяүләп кенә сыпыртырга булдылар.

Үз якларында саран гына сибәләгән яңгыр монда ару гына шәбәрткән, асфальтта гөрләвекләр тәгәри, асфальтта машиналар йөзә, чибәр-чибәр генә апалар туфлиләрен кулларына тотып чәп-чәп йөгерәләр. И-и, кызык! Тик Мөнир Мөзәкиргә озак тамаша кылырга ирек бирмәде, тамак төбе белән бер генә кычкырды. Чемоданын кулдан-кулга күчереп ул йөгерә, чәкчәген пиджак итәге белән томаларга тырышып, аның артыннан Мөзәкир чаба. Урам чатларында куркыныч: машиналар ыжламый да нәкъ кеше өстенә киләләр. Багана башларында кызыллы-яшелле утлар бии...

Мышкылдап, җеп бөртекләре калмыйча редакциягә барып керсәләр — җизнәләре анда юк икән.

Чәчләрен егетләрнеке шикелле кыска кистергән, юан тәмәке капкан бәләкәй битле сары хатын, малайларның кемлеген катлый-катлый сораштыргач, Дилә апаларының өченче көн дәваланырга китүен, җизнәләренең хәзерге минутта эштән качып Үзәк стадионда футбол карап утыруын әйтте.

Күшеккән малайлар тәмам аптырап телсез калдылар. Сары апа әрләп:

— Акча җәлләмәскә иде, телеграмма сугарлар менә! — дип куйды.

Яңгыр шыбырдаган ят урамга чыгасы килми. Ярым караңгы коридорда аз-маз киңәшкәч, малайлар күчтәнәч-төенчекләрен редакциядә калдырып, стадионга барырга булдылар. Җизнәләре энә түгел, ничек тә табарлар!

Арык хатын кая барасыз, фәлән дип төпченеп тормады, малайларны ияртеп Идрисләр бүлмәсен ачып керде, чемодан белән чәкчәкне почмактагы урындыкка куярга кушты, үзе якын килеп әйберләрне кармап, капшап карады.

— Каклаган каз да бармы?

— Каз юк... Уңмады казлар былтыр.

— Бусы чәкчәк... Әһә...

Борылып чыгышлый хатын Әхәтнең өстәл астына да күз салды:

— Монда да күчтәнәчләр ята шикелле?.. Әһә, бусы балыкмы?.. Икра?..

Малайлар аны өстәл янында калдырып урамга чыктылар. Як-якларына карана-карана, курка-шүрли стадионны барып таптылар. Тик аларны эчкә кертмәделәр. Билетлары юк иде, аңлатырлык итеп сөйләргә тел дә житенкерәмәде. Мөнир, олырак булганга, энесен стадион каршысындагы шәрап сата торган ларекның шыгына бастырды:

— Аң бул, шушыннан купма. Җизнине эзләп карыйм. Тапсам-тапмасам, сине алмага килермен,— диде. Үзе тагын биек-биек капка баганаларына таба китте.

Мөзәкир кырыннан гына трамвай узды...

Шушы икән инде Казан... Кремль кайда соң?.. Ул стадион капкасына борылып карый-карый Болак буена ук барып житте. Әнә ич алтын йолдыз!..

Аның янына шалама кыяфәтле берәү килде:

— Суалчан бар. Апарш,— диде ул. Малай куркынып ларек янына чапты. Яңгыр һаман сибәли. Коймалар артыннан вакыт-вакыт гөрләшеп кычкырган авазлар ишетелә, менә бервакыт шау-шу көчәйде, ишле халык кул чапкан кебек булды, тавышлар бераз басылгач, капка тирәсенә төрле яктан кешеләр чабышып килә башладылар. Аралыклардан бүселеп урамга да чыктылар. Кара болыт кебек агылган кешеләрне күргәч, Мөзәкирнең күзе шакмакланды, кайда ди ул монда җизнине эзләп табу! Мөнир үз башын югалтмыйча алып килә алса яратырсың... Ул шыкланып торган ларек алдына чират килеп тезелде,

Кызарынган кешеләр кулларын бутый-бутый ярсып кычкырышалар иде. Плащларга төренгән, мынгыланган газеталар ябынган бу халык арасыннан Мөнирнең үзен ничек табарга?..

Җизнәләрен очратмасалар, апалары өйдә юк, кайда кунарлар? Мөзәкир өметсезлектән жыларга житеште.

Болак буенда Идрисне куып житкәндә, Мөнир аптырап энесе янына кире кайтырга тора иде. Бәхете бар икән, ул бик очраклы гына жизнәсен күреп алды, шатлыгыннан кычкырып жибәрде.

5

— Исәнме, жизни!..

— Саумы, кайнеш... Мөнир, син бит?.. Үсеп беткәнсең, танырлык түгел.

— Без икәү әле. Мөзәкир дә монда ие.

— Кайда соң ул? Ничек монда киләсе иттегез?

— Тегендә ышыкланып тора... Эшеңә барган идек, монда диделәр. Син торып тор, хәзер юрттырып алып киләм...

Идрис Мөнирне тотарга өлгермәде, тегесе томылып чапты, Әхәт янгырдан качырып кына папирос кабызды һәм бер дә яратмыйча:

— Өйләнергә коткылап маташасың!.. Кайнеш!.. Агайне!.. Туган-тумача!.. Жизни-жизни, күңелем синнән бизми!.. Бе-е-без!.. Син дә шулар колына әйләнгәнсең икән! — дип Идрисне үчекләргә, черки булып безелдәргә кереште.

— Диләнең энеләре.

Аның тавышы кайнешләрен яратып калтырап чыкты.

— Лоторейда бер сум откан кебек шатланасын.

— Күңелле егетләр алар, менә танышырсыз.

— Куандырдың!.. Уналты-унжиде яшьлек балдызың килсә икән!.. Кияүдән кайткан каенанаң да ярап торыр иде... Планнар янды,— диде ярым шаярткан булып Әхәт.— Агрессор кайнешләр!.. Юлбасар кодачалар... Өйдә дә туйган мин шул сортлардан.

Идрис борчылып малайларны көтә иде.

— Планнарны яндырмыйк,— диде ул, Әхәткә карап.— Болай итәбез. Хәзер бер шешәне кыстырып миңа барыйк. Бәрәнге бар, ит тә житәрлек. Тегесе-монысы кирәксә, ярдәмчеләр янда, кайнешләрне чаптырабыз.

— Ит? Бәрәнге? — Әхәтнең мангае жыерылды.— Син мине Гаргантюа дип белдеңме?.. Миңа ашау түгел, миңа мохит кирәк, шау-шу, ритм... Ә син мине монах хөжрәсенә өндисең.

— Уңайсыз хәлгә куйма мине, Әхәт. Мөзәкиргә ундүрт яшь, аны ресторанга алып кереп булмый.

— Уф! Футболда жиңелдек, кайгыны уртаклашыр кеше юк.

— Чакырып торам түгелме?

— Һә!

Әхәтнең соң чиктә генә әйтә торган «һә»сы күп нәрсә аңлатырга мөмкин иде, артык үгетләүнең өмете калмады.

— Ярый ул чагында. Эчең пошса, адресны беләсең. Шкафта ярты сине көтәр.

— Ачкычыңны малайларга бир дә ычкыныйк.

— Ярамас... Кешелексезлек булыр ул, әй.

— Кайгыдан эчүгә сабышып унбиш тәүлеккә эләксәм, передача китерерсең. Колбаса — киевская, сыр — голландский, аракы — чистайский.

Әхәт плащына тагын да ныграк бөркәнеп китеп барды. Идрис аңа:

— Кара, көтәм! — дип кычкырды.

Оялудан кызарынган Мөзәкирне ияртеп Мөнир килде. Малайның куллары боз кебек салкын иде. Идрис Мөзәкирне аркасыннан сөйде дә:

— Манма су булгансыз, малайлар! Әйдәгез, ятерәк трамвайга чаптык! — диде. Җитәкләшеп тукталышка килделәр. Кешеләрнең күбесе әле булып узган тамашаның дәрт, ярсуыннан арынмаган, кул сугып бәхәсләшәләр, үткәндәге уеннарны искә төшерәләр, сугышка кадәрге футболчыларны сагыналар.

Шушы кадәр халыкның бердәм ыгы-зыгысына хәйран калган Мөзәкирнең елмаясы, көләсе килде.

— Кем белән кем уйнады? — дип сорады Мөнир.

— Әнә бит, афишаларга язылган,— диде Мөзәкир.

Мөнир энесенә күз дә төшермәде.

— Австриядән кунаклар кабул иттек. «Рапид» командасын.

— Безнекеләр җиңелдеме?

— Күрәзәлегең бармы әллә, Мөзәкир малай?

— Безнекеләр футболны уйный алмыйлар. Телевизордан бер уенны да калдырмыйм... Йөгерә алмыйлар безнең уенчылар. Вәт хоккейда яралар инде.

Трамвай һаман күренмәде.

— Үзегез футбол уйныйсызмы?

Мөзәкирне бүлдереп Мөнир җавап бирде:

— Уйныйбыз, уйныйбыз!

— Кайсы команданы яратасыз инде?

— Мәскәү «Спартаг»ын...

Мөнирнең җай чыккан саен энесен үчекләп, чокчып алырга яратуын Идрис сизенеп тә өлгерде. Бу юлы да:

— Ярата! — диде мыскыллап Мөнир.— Белеп дисеңме син аны? Галимҗан Хөсәенов уйнаганга гына инде.

— Бу бәлеш төсле йорт нәрсә була? — дип сорады Мөзәкир.

— Бусы — цирк. Бәйрәмгә өлгертергә дип ашыгалар. Әнә тегесе — Спорт сарае.

Алар карап торганда, Спорт сарае яныннан трамвай борылды. Аның ишекләренә генә түгел, тышкы яктан тәрәзәләренә дә чикләвек кәшәнкәләре кебек ир-ат, яшь-җилкенчәк сарылган иде. Трамвай юл таләп итеп ачулы зыңгылдый-зыңгылдый сәлам бирде дә тукталмады, узды... Халык, буа артыннан төшкән су кебек, аның артыннан ябырылды.

— Әллә тотып туктатырга итәләр инде? — диде Мөзәкир, куркынып.

Тагын өч трамвай үткәрделәр, стадион алдында кунаклаган автобуслар, мотоцикллар, җинел машиналар аллы-артлы тәгәрәп таралыштылар. Рәттән биш трамвай узгач кына, мең газап белән эчкә үтә алдылар. Кузгалып киткәч каяндыр, юеш, дәү абыйларның дымлы култык асларыннан Мөзәкирнең зәгыйфь тавышы ишетелде.

— Мөнир, чәкчәк тегендә калды бит.

Вагонда татарлар байтак икән, гөрләп көлештеләр.

— Үзеңнән фарш ясамасыннар, малай.

— Вәт тәмле тамак...

— Чәкчәкне чак-чак кына ашарга дигән.

Яңа квартирны күргәч, малайлар ах иттеләр. Әле кухняга кереп әйләнделәр, туалет ишеген ачтылар, краннарны борып җибәрделәр. Берсеннән гөжләп су килде, икенче кран яман ырылдады, улады, тавышлана торгач, күгәрек авызыннан берничә яшькелт тамчы тамды.

— Монысында су анасы утыра,— дип аңлатты Идрис.— Көзгә шуны җиңә алсак, кайнар су булачак, имеш.

Мөнир авызын җыя алмый иде:

— Прәме шәп булган бу, жизни... Искитмәле... Дилә апага су дип чыгып йөрисе юк икән... Шушындый квартирада торасы иде безгә дә!

Идрис ризалыгын җәлләмичә иягән кагып торды:

— Әйе, әйе, Яңа Бистәдән соң монда оҗмах. Тегендә тавык кетәге иде, монда тартма... Гомумән, уңай квартира! Түшәм белән идән арасын гына карагыз. Кулны күтәрәм, түшәм ерак та калмый. Өйгә кергәндә исә үзеңне Алып батыр кук сизәсең... Туалет белән ванна да бергә. Кешегә һәр яктан җиңеллек өчен уйлап эшләнгән, йомышыңны үтисең дә чулт суга...

Мөнир ярыла-ярыла көлде, Мөзәкир сагайды: аңламассың бу жизнине, әллә чын сөйли, әллә шаяртып малайларны сыный?.. Бу Мөнирнең әйтер идем, шүрәле кытыклыймы әллә, хихылдаудан туктамый... Ишекләрне әйбәт утырткаННармы дигән булып карап йөргән була, эшем юкса...

Ниһаять, кухнядан куанычлы тавыш килде: чәйнек капкачы парга чыдый алмыйча үрле-кырлы сикерә иде.

— Бие, бие, Әпипәгә бие,— диде Идрис, калай савыттан чәй чеметеп.— Егетләрне бер сыйлыйк әле. Колбаса ашыйсызмы?

— Ашыйбыз, ашыйбыз.

— Эремчек?

— Ашыйбыз.

— Май, күмәч, сыр?

— Булсын гына!

Өстәл тирәсенә тезелешеп утырдылар, аз-маз тамак ялгагач, Идрис учы белән иягенә таянды.

— Я, хәзер түкми-чәчми сөйләгез, авылда ниләр бар?

Яңаклары кабартмадай бүлтәйгән Мөнир көч-хәл белән:

— Әйбәт, әйбәт! — диде.

Идрис белән Дилә икесе бер районнан булып, авыллары да берберсеннән ерак түгел иде. Байтактан шәһәрдә яшәсә дә, ул үз районнарының хәле белән гел кызыксынып тора, район газетасын алдырып укый, кайсы тамыры беләндер һаман җирдән аерыла алмый иде.

— Игеннәр ничек күренә?

— Әйбәт, әйбәт!

— Яңгырлар?

— Безнең арттан явып калды.

— Әби, бабай таза йөриләрме?

Малайларның җавапларны кирпеч суккан кебек кенә калыплап утыруларыннан Идрис боларның карыннары бик нык ачып, сөйләшерлек чамалары калмаган дип уйлады. Менә эремчек тә бетте, колбаса, сыр телемнәре дә алмаш-тилмәш ике авызга кереп киттеләр, май савыты бушады, ипи телемнәреннән өелгән кибән юк булды, малайларның сүзчәнлеге артмады. Мөнир һаман бер төрле җавапларга пичәт сугып утырды, Мөзәкир рәхмәт әйтеп табыннан купты да почмактагы китап шкафы янына ешынды.

Мөнирнең хыяллары да гап-гади ап-ачык иде:

— Шул инде, жизни... Авылда да шул. Эшлиләр, ашыйлар... Илле еллыкка күрше Марида зур клуб өлгерә... Колхозны шунда үзәкләштерергә уйлыйлар. Председатель дә шунда күчте... Гараж салдылар... Әти белән Нәгыйм көтүдә... Әни яшелчәдә... Үзем яңа гаражга керергә дип торам... Булдырып булса, унынчыдан соң машинада!

— Ә армиягә?

— Армиядә дә машинага өйрәтәләр диләр бит.

— Әби авырмыймы?

— Бик тазалар әлегә.

— Хәйдәров абыегыз ничек?

— Йөри!.. Яшьләр белән концертларга катнаша. Бии, җырлый. Кин балакларын җилфердәтеп тыпырдап китә...

Малайлар икесе дә бер үк күренешне хәтерләп елмаештылар.

Ирек Хәйдәров белән Идрис бергә институтта укыды. Авылдашлар булгач, Ирек Идрисне Дилә белән таныштырды... Ирек — аның студентлык елларының дусты — институтны тәмамлагач бер-ике ел гына укытып йөрде дә аны авыл советына председатель итеп сайладылар...

Укыткан чакта хатлар алышкан, кайткан-киткәндә чакырышып, бер-берсенең туйларында мәж килеп йөргән иптәшләр соңгы вакытларда нигәдер читләштеләр.

— Колхоз председателегез һаман шулмы?

Монысына китаптан аерылып Мөзәкир җавап бирде:

— Шул, шул, Степанов абый.

Тагын әллә ниләр белешәсе килсә дә, Идрис тукталды, бары Мөзәкирдән:

— Син көтүне нигә ташладың соң? — дип сорады.

Аның өчен Мөнир җавап бирде:

— Һәй, ул кирене!.. Йөри шунда трай тибеп, эт куып...

Өйдә, аларның түрләрендә, кай яклары беләндер Диләгә бик-бик охшаган ике үсмер утыра. Идристән ничә яшькә генә кечерәк алар, чордашлар диярлек, әмма җәелеп сөйләшерлек уртаклык табылмады.

Аларның үз тормышлары, хыяллары... Серләре...

Мөнир кызлар караштыра башлагандыр...

Мөзәкирнең күзләре теп-тере, төбәп, төпченеп карый...

Ә нигә дәшми? Ник сөйләшми?

Арадашлык иткән нибарысы Дилә генәме?

Сирәк күрешкәнгә, шәһәр кешесе санап, малайлар аннан ятсыналармы?..

Биш-алты елдан шушы үсмерләр дөнья мәшәкатьләре белән капма-каршы очрашачаклар. Ничек яшәрләр алар? Кем булырлар?.. Идрис өчен чишелмәгән сер, җавабы табылмаган табышмак булып калырлармы?..

Малайларга урын идәнгә җәелде, алар яту белән шундук сендeләр. Идрис өстәлне җыештырды, су җылытып табак-савытларны юды. Яткач, көндәгечә, узган егерме дүрт сәгатьне күз алдыннан уздырды.

Казан зур шәһәр шул хәзер!..

Кемнәр генә кунак булып килми аңа?!

Австриядән футболчылар... Күрше Мари республикасыннан Мөзәкирләр, Мөнирләр...

Зур шәһәр — меңәрләгән кешеләрнең күрешү, аралашу, аңлашу урыны...

Зур шәһәр — кеше гомерендә бер баскыч...

Баскычтан менеп тә, төшеп тә була...

Менүгә караганда төшү ансатрак, әлбәттә...

Иртәгә Диләгә хат язарга...

Малайларны кайларга алып барырга, ниләр күрсәтергә?

Кайдадыр әтәч кычкырды... Шул серле якларны урап кайтасы иде... Шул әтәчләрне күрәсе иде... Шәһәр урамнары артында гына тавык фермасы бармы әллә?.. Авылмы?..

Шактый соң ятылса да, Идрис иртә уянды. Көн кояшлы, бүлмә япьякты, кичәге болытларның әсәре дә калмаган. Диваннан торып, малайларга басмыйча гына сагаеп үтим дисә, Мөзәкир күзләрен ачып аңа текәлеп ята икән.

— Нигә йокламыйсың? — диде ул шыпырт кына.

— Белмим.

Малай торды, мыштым гына аңа ияреп кухняга керде.

— Урын үзгәлисеңмени?

— Белмим.

— Ярар, хәзер чәй куеп җибәрәм... Кибетләр ачылуга, син вак-төяккә барып кайтырсың. Курыкмыйсыңмы?

— Кемнән куркырга?

Идрис көлде.

— Бәрәңге кыздырсам ашарсызмы?

— Кыздыр, җизни... Үзем әрчимме?

— Булыш.

Икәү әрчергә керештеләр, Мөзәкирнең бәрәңге кабыклары алкаланып-алкаланып чиләк эченә мәтәлеп тордылар. Идрис соклануын яшереп тормады. Мактаудан кызарынган малай:

— Җизни, син миңа инженерлар чыга торган институтны күрсәтерсең әле,— диде.

— Институтның кайсысы кирәк соң сиңа? Инженерлар алар бик күп төрле.

— Миңа самолетлар, ракеталар ясый торган булсын...

— Күрсәтермен... Син шуны сайларга ниятлисеңме?

— Әһе... Тик син аны сораганны Мөниргә әйтмә, җизни.

— Ярамыймы?

— Көлә.

— Көлмәс!.. Кирәгенчә әйтербез... Үзең, кемнән куркырга дисең, үзең Мөнирдән шүрлисең...

— Мыскыллаган, көлгән кешедән куркыла шул...

Идрис бәрәңге тутырган ак эмаль табакка шаулатып су агызды:

— Үзең уйлаганга ышанасың икән, яшереп торма. Курыкма да. Нык бул, теләгеңнән кайтма.

Ул малайның ышанмыйчарак карап торуын аңлады.

Өлкән, акыллы кеше булып киңәш бирү ничек ансат икән!.. Әле ярый, чамасын белеп тыелып калды...

Бу малайлар янында үткер булырга кирәк... Юкка-барга акыл сатып аларны ышандырырмын димә... Чынлыкны, хакыйкатьне дә ничә кат тимер иләкләр аша уздырырга яраткан үсмер чак ялганны һәрвакытта диярлек тоя, тотып ала һәм көрәшергә керешә...

Бүген шимбә... Ике көн рәттән ял... Малайлар бик уңай вакытта килеп төштеләр. Музейга барырлар, университетны карарлар, коенырга Иделгә төшәрләр. Мөзәкир көймәдә йөрик дип бик тыкырдата, өлгерә алсалар, анысы да кызык булачак, Идриснең үзенең ике ел су өстен күргәне юк...

Якшәмбе көн кич кенә Идрис җитешеп Диләгә хат язды.

«Малайлар зур юаныч булды... Мөнир шактый хәйләкәр... Ә Мөзәкир бик үскән, акыл кергән... Уйлана, укырга киләм, ди... Бусы белән нык куандырды... Аның яшендә максатның зурысын куя алу егетлек галәмәте түгелмени?.. Укымаган кешенең безнең заманда кадере бетеп килә, ә алар вакытында ничек булачак?.. Синең хакта сорашырга уңайсызландылар, ләкин бел: алар сине бик сагыналар!.. Без барыбыз да өзелеп сине сагынабыз...»

Иртәнге җыючы ала китсен дип ул хатны ящикка салырга чыкты...

Июнь төннәре якты, аяз була иде, бүген исә караңгы... Урам тып-тын, шомлы... Җил чыккан. Ямьсез болытларны айкап-чайкап йөрткән җил күлмәкчән генә йөгереп чыккан Идрисне өшетте. Ул хатны салды, куырылып тиз-тиз өйгә чапты. Подъездга кергәч, күтәрелмичә, беравык тынын җыеп торды.

Малайлар тигез генә, рәхәт кенә мышныйлар... Күкнең болытлы, төннең шыксыз, күләгәләрнең куркыныч булуында аларның гамьнәре юк. Бәхетле сабый чаклар!..

Идриснең күнелендә хәвеф, күкрәгендә сызлану иде...

Ул монын аерылу сызлануы икәнен аңлап бетермәде, утны сүндерде һәм җәелеп диванга капланды...

## 6

Бүген әле бише генәме?..

Шартла, үртәл, ярыл, Дилә киткәнгә әле биш кенә көн узган...

Ә аннан аерылганга ел узды кебек... Түзмәс Идрис, ай ахырына кадәр дә чыдары җитмәс, килешә алсалар, ял сорар да Дилә янына китәр... Бергә чакта бергәлекнең кадерен белмисең... Көн турында, ел турында, гомер турында шушы кадәр авырттырып уйланмыйсың...

Дүшәмбе...

Нибарысы биш көн аерым яшәлгән. Аерылуның хисне үртәп котырта торган иң аяусыз көннәрендә әле дә ярый Мөнир белән Мөзәкир килеп чыктылар...

Бүген алар китәләр... Көндезге ун сәгать кырык минутта — кунакларын Йошкар-Ола поездына утырткач кына Идрис эшкә барырга тиеш. Алдан шулай сөйләшенсә дә, ул кичә малайлардан тагын бераз торуларын үтенде. Әтиләре шөрепләрен ныгытып борып җибәргәнгәме, малайларны үгетләп җиңеп булмады. «Гаражда көтәләр булыр, шулай килешенгән идек»,— диде Мөнир. Мөзәкир сүзсез генә аны җупләде.

Иркенләбрәк йокларга да була бүген! Поезд бик уңайлы вакытта кузгала, ашап-эчеп, сөйләшеп туйганнан соң да тугызынчы трамвай ялындырмый-нитми генә үз вакытында илтеп җиткерәчәк.

Шулай да урын өстендә озак аунап булмады, ул шыпырт кына торды, гантельләрен кухняга алып кереп, гимнастика ясады. Радионы тоташтырырга уйлаган иде, малайларга шау-шу булыр дип, уеннан кире кайтты.

Төндә шик-шөбһәләр тудырган һава бүген бөтенләй үзгәргән, аз гына янгыр сибәләп үткән җир дә, күк тә сафланып калганнар. Тәбәнәк, яшь ябалдашлы юкәләрнең үтә яшел нәфис яфракларында баллы чык җемелди. Ул кухня тәрәзәсен киереп ачты да чәй куйды. Пәкесен алып кереп шунда кырына башлады.

Малайлар эрегәннәр. Кичә байтак җир йөрелде, Идриснең үзенең дә тез буыннары сәфәрнең озын булуын сиздереп-сиздереп ала...

Тиз китүләре кызганыч, планнар ярты юлда сүтелеп калды. Көймәдә чыгарга өлгермәделәр, Горький музей-йорты карамаган килеш калды... Йөргән кадәресе дә файдасыз булмады, малайлар шәһәр күреп, бераз ачылып китәләр... Идрис үскән чакларда зур шәһәрләрнең берәрсендә шушындый якын туганы булсын иде әле... Институтка гариза бирергә килгәч, якшәмбе көн иде, вокзал каршысындагы бакчада куны чыктылар...

«Харьков» электропәкесе күңелле генә жуылдый, ике түгәрәк пәке, әле колак янына менеп, әле ияк очына кунып, куерып шыткан кара төкләрне жыештыралар, битне иркәлиләр. Пуф-пуф килеп чәй дә кайнап чыкты. Ул бәләкәй ак чәйнеккә мул гына чәй салды да тастымал белән төреп мендәр астына яшерде.

Ишек алдында күгәрченнәр йөри. Йортның әле бу, әле теге ишегеннән кешеләр чыгып эшкә ашыгалар... Эшкә барасы булмаганда да әйбәт икән!

Ул диванга ятып тагын бераз аунады. Аннары, сәгатькә карап, малайларны уятты:

— Подъем!

Мөнир дә, Мөзәкир дә берьюлы диярлек сикерешеп тордылар, әсәренеп, каушап жизниләренә карап тордылар.

— Ут-мазармы әллә?
— Торыгыз, ябалаклар!
Ул шукланып малайларның икесен ике яктан җилтерәтеп алды, башларын култык астына кыстырды, өчәүләшеп әүмәкләшеп идәнгә тәгәрәделәр.
— Әле син алаймыни, җизни?
— Әһә!
Малайлар көч белән тырпылдашып ике яктан җизнәләре астыннан чыктылар да анын үзен аска салырга көчәнә башладылар. Урын-җир буталды, тузан купты, ах-ух килеп шактый көрмәкләшсәләр дә, Идрисне идәнгә бөгә алмадылар.
— Булды, булды, малайлар,— диде ул, мыш-мыш килеп.— Берәм-берәм юынырга, марш!
Мөнир кундәм генә юынырга кереп китте, алар Мөзәкир белән урын-җирләрне җыештырдылар.
— Бу паласны урамда кагып керимме, җизни?
— Ярыйдан башка сүз юк.
Мөзәкир, чүбен коймас өчен, паласны пөхтә генә урады да күкрәгенә кысып ишек алдына чыгып китте. Элгән ап-ак керләргә тузан очмасын дип бөтенләй бер читкә барып, җилбер-җилбер китереп паласны какты.
Мөнир майкасын салып ташлап (җизнәсеннән күрмәкче) чәпчәп юынды да, кызарынып күкрәкне киереп чыкты.
— Теге салам сыйрак кайда?
— Ишек алдында.
— Тәлинкә ялаштырамы?.. Палас кагарга чыккан, имеш.
— Нигә тынышмыйсың син анын белән, Мөнир?
— Кушканны эшләми... Янәсе, үзенең башы бар.
— Моның өчен мактарга кирәкмиме икән аны, ничек уйлыйсың?
— Һе, мактасаң-мактамасаң бер инде... Өйдә дә җык күрәбез.
Мөнирнең җизнәсе алдында олы, эшлекле һәм бик акыллы буласы килә иде.
Мөзәкир керде дә паласны әйбәтләп урынына, ишек катына җәйде.
— Җизни,— диде ул сокланудан тыела алмыйча.— Шәһәрнең читендә сез икән... Монда урамнар бетә икән ич?.. Ә аннан ары кырлар башланамы? Менә бусы кызыктыр, ә?.. Трактор белән шәһәр кырында гына җир сөрәсең... Бер атладыңмы — асфальт...
— Барып караган юк шуны, Мөзәкир.
— Нигә бармыйсың, җизни?
— Вакыт тими.
— Җизни... Дилә апа кайткач озаккарак килимме?
Мөнир башын чайкады:
— Паласны да хәйлә белән кага бит!
— Җитәр сина, Мөнир,— диде Идрис, шелтәләп.— Кил, Мөзәкир!.. Бергәләп көймәдә йөрербез.
— Шәһәр читенә дә барырбызмы, җизни?.. Менә кызыктыр ул... Шәһәрне кырдан карап торасың!..
Агач саплы габада күкәй куырдылар. Ак күмәчкә май яктылар, күкәй тәбәсен, малайлар йокыдан гына торсалар да, нык суктылар, аларга ияреп Идрис тә шәп кенә ашады.
Малайлар, тел белән әйтмәсәләр дә, шәһәргә килүләреннән гаять канәгать иделәр. Нәгыймгә дигән дүрт җәпле пәкене җизниләре үзе бүләк итте. Хәтта кайчысы да бар! Икесенә дә ак репс күлмәк, Мөзәкиргә дәреслекләр сатып алдылар.
Чәй урынын әйбәтләп җыештыргач, әйберләрне тагын бер кат күздән кичереп, барлап чыккач, күтәренеп трамвай тукталышына киттеләр. Тугызынчы трамвай ялыктырмыйча гына аларны вокзалга илтеп тә куйды.

Өйдә күнегеп, шаярышып торган малайлар трамвайда, үзләренең «сала кабартмалары» икәнлекләрен хәтерләп, посыбрак, тын гына бардылар. Вокзал, андагы бетмәс ыгы-зыгы Идрискә тагын бер кат Диләне, күптән түгел генә узган вакыйгаларны хәтерләтеп, каны саркып торган яраны авырттырып алды...

Ул малайларны вагонга кертеп әйбәтләп утыртты.

— Я, хуш булыгыз, кайнешләр. Тагын килегез.

— Сау бул, жизни.

Унбердә ул редакциядә булырга тиеш... Тәтеш районыннан гыйбрәтле генә бер хат килде... Тәтешкә, Тәтешкә... Эшкә... Эшкә!.. Каян килде бу сәер рифмалау?.. Ә-ә, Тәтешкә эшкә җибәрәләр дигән иде бит... Лидасы ни пычагыма хәтергә килеп тора тагын?..

Әхәт көтәдер инде. Идриснең соңга калуы гадәттән тыш хәл булганга, азрак каны кайныйдыр... Бүген дә көн эссе булырга чамалый. Әнә бит кешеләрнең сөмсерләре ничек коелган!.. Шул инде, шәһәрдә олайган саен кешеләр аулак яшеллекне, тын тугайларны, кешесез җәйләүләрне ныграк юксыналар. Калалар зурайган, шәбәйгән саен, аны төзегән кешеләр дачаларга, бакчаларга теләбрәк качалар... Төзүчеләр белән шәһәрләр арасында яшертен көрәш бара... Табигый хәл!.. Тик Идриснең быел койрыгы каткан, ул беркая да кача алмый. Җае чыкса, берәр атнага Диләя янына барыр инде... Диләя янына... Диләя... Тәтешкә эшкә... Тәтешкә эшкә... Тфү! Каян килде соң бу җәфа-рифма?..

Матбугат йорты.

Биш катлы умарта оясы... Эшчән тырыш кортлар да, арада соры кортсымаклары да бар аның тартма-тартма бүлмәләрендә...

Беренче кат — танышлар, баш селкеп сәламләшүләр.

Икенче кат — танышлар ишәя. Баш изәп кенә котылып булмый, туктапып кул да сузгалыйсың: «Әхвәлләр, бала-чагалар ничегрәк, тәкъсир?»

Өченче кат...

Тезләрен тезгә куеп диванда Әхәт утыра. Әвене янган егетнең авызында тәмәке. Ботинкалары аксыл-көрән, очлы башлы, калын үкчәле.

— Төтәткәнсең!.. Берәрсен ыслап сихерләргә ниятлисеңме?..

Ул сәламне коры гына алды:

— Саумы?

Идрис тәрәзәне ачты.

— Агрессор кайнешләр сыздымы?

— Озаттым.

— Бөлдереп киттеләрме?

— Ансыз булмас инде.

Идрис кәгазьләрне таратып ташлап Тәтештән килгән хатны алды, юлдагы рифмасы хәтергә төшеп көлеп җибәрде. Әхәт балтасы суга төшкән утынчы күк утырсын әйдә, вакыты җиткәч, кәефен нәрсә кыруын үзе сөйләп бирер әле!.. Нигә шулай озак эндәшми ул?

— Югары як ничек? — диде ул, башын күтәреп.

— Мин, Идрис, китәргә уйлыйм...

— Кая? — диде ул, тагын көлеп.— Тәтешкә эшкәме?

— Тиле күке шикелле шыр-шыр утырма әле,— диде Әхәт, нык кына кызып.— Җылар чакта авызын җыя алмый. Җылый алмыйсың икән, дәшмә.

— Шеф-мөхәррир белән әләгештегезме?.. Әллә Ниса апа гына...

Әхәткә шунда гына Идриснең берни аңламавы барып житте.

— Туган-тумача арасына чумып, тәмам обывательгә әйләнгән син,— диде ул тагын да тузыныбрак.— Радио тыңламыйсың, дөньяның йөрәк тибешендә гамең юк.

— Бүген тыңлаган юк шул,— дип дөресен әйтеп бирде Идрис.

— Тумас борын картайган җан.
— Сүгенмә әле син.
— Сугыш! — диде Әхәт ике йодрыгын берьюлы һавага күтәреп.
— Кайда сугыш? — диде Идрис, агарынып.
— Менә монда,— диде Әхәт, йөрәген күрсәтеп.— Израиль Мисырга басып кергән. Синай ярымутравында Өченче бөтендөнья сугышы башлана!
— Син азрак арттырмыйсыңмы?
— Джонсонның үз кызына әйткән сүзләрен онытлыңмы? «Синең әтиең Өченче бөтендөнья сугышын башлаучы булып тарихка керер!» дигән.
— Герострат!
— Алай гынамы... Герострат дөньяның җиде могҗизасыннан берсен яндырып кына тарихта кара күләгә булып калган... Ә бу туксан тугыз могҗизаны харап итәчәк!.. Израиль агрессиясе уен түгел... Артында кемнәр торуын абайла!.. Сүәешне кичерә алмыйлар, кабахәтләр. Израиль — пешка. Ләкин оста җәнҗалчылар кулындагы пешка...
— Менә эшләр кая киткән икән...
Эш тә, Тәтеш тә онытылды. Редакциянең башка бүлмәләрендә дә ыгы-зыгы. Наборга төшерелгән газетаны кире алып менделәр. Кемдер, телетайп бүлмәсенә барып, соңгы хәбәрләрне белешеп килде. Хәбәрләр җанны шатландырырлык түгел иде. Израиль һава көчләре Берләшкән Гарәб республикасының аэродромнарын, шәһәрләрен бомбага тота, зур танк берләшмәләре бөтен Синай ярымутравында һөҗүм җәелдергәннәр иде. Фашистлар методы — блицкриг!..
Идрисләр бүлмәсендә моңарчы инвентарь номеры сугылганга гына газета подшивкалары янында бутафория булып утырган тузанлы радиоалгыч ходка китте, аның индикаторының яшькелт күзе хәвеф барын сөйләп мелт-мелт итә. Гарәб гаскәрләре бөтен фронт буйлап чигенәләр, Мисыр халкы тәшвишкә төшкән иде...
Бүлмәдә Идрис белән генә калгач, Әхәт тагын бер тапкыр фәлсәфәгә бирелеп алды:
— Вьетнамда бер партизанны үтерү Америка Кушма Штатларына йөз егерме ике мең долларга төшә... Әгәр шушы кадәр акчаны фәкыйрь крестьян файдасына тотсаң... Акылга сыймаслык вәхшилек!..
— Каядыр китәргә җыенасың, ахры?
— Мисырга барам... Күңелем сизә, иманым камил: бездән башка анда эш чыкмас... Без монда йомшаклык та, икеләнү дә күрсәтергә тиеш түгел. Икеләнү — хата, йомшаклык — җинаять!.. Бөтен дөнья империализмы әле яңа гына укмашып ныгый башлаган ярлы илгә ташлана икән, авыз күтәреп речь сөйләп утыру ярамый!.. Сизәсеңме, әле бер яктан, әле икенче яктан алар дөнья картасын тешләп-тешләп карыйлар. Ныкмы, янәсе... Без шул чакта аларның тешләрен сындырырга, аппетитларын бозарга тиеш. Юашны басалар аны, Идрис!
— Әгәр чыннан да бөтендөнья сугышы башланып китсә?
— Шуны уйлыйм да баш очымда бомбалар ярылганны көтәсем килми... Я янам, я калам! Доброволецлар язалар икән, бүген китәм...
Барлык хезмәттәшләрне редактор бүлмәсенә чакырдылар. Рәкыйпнең кырыслыгы, хезмәттәшләрнең сүзсезлеге аларның юк-бар өчен генә җыелмавын раслап торды. Завод-фабрикаларда Гарәб илләренә телләктәшлек митинглары башланган... Идрис резин-техник әйберләр заводына, Әхәт вертолет заводына киттеләр.
Күңелдә ачу шулкадәр ташыган иде, Идрис түзмәде, эшчеләр алдында үзе дә чыгып сөйләде...

# 7

Ниһаять, Идриснең киче буш. Ул күптәнге хыялын тормышка ашырырга, урамнарны узып, шәһәр кырында нәрсәләр барын карап кайтырга ниятләп куйган иде. Почта тартмасына күз салса, Диләдән озын хат килгән! Юлдан язылган хат... Ул хатны озаклап, ижекләп диярлек укыды, язылмаган уйлар, әйтелмәгән сүзләр эзләп Диләнең чын кәефен, сәламәтлеген белергә теләде.

Утырып үзе дә язды...

Хатны салырга чыкканда, шактый соңарган, караңгы төшкән, җәйге төн иңгән иде. Бер чыккач, ул өйгә кереп тормады, акрын гына атлап шәһәр читенә таба юнәлде...

Урамда парлылар йөриләр.

Яшьләр...

Әллә бар аларга дөнья, әллә юк. (Шулай дип уйларга була!)

Парлылар кара-каршы очрашканда кызлар, әллә оялып, әллә тыйнаклык күрсәтеп, керфекләрен түбән төшерәләр, егетләре исә ерактан ук тасраешып киләләр дә ашардай булып бер-берсенең кызларын күзлиләр. (Минекеннән дә матурны эләктермәгәнме?)

Шәһәр шушында бетә. Биш катлы, тәбәнәк тәрәзәле, тар коридорлы тартма-тартма йортлар ике яктан тезелеп, бер-берсенә кысылышып киләләр дә кинәт такыр кыр башлана...

Төзелеш шушында кадәр ашыгып килгән дә, үзе артыннан таш игезәкләр дөньясы калдырып кире борылган, шәһәрнең муртайган кара бүрәнәле бер катлы агач йортларын ялмарга, ашарга керешкән...

Идрис җәйге эңгер белән өретелгән такыр кырга барып шактый гына юанып торды. Бу очта караңгы, урамнарга яктылык уздырып өлгермәгәннәр, парлыларга шул гына кирәк тә! Алар читенсенмичә-нитмичә урам уртасыннан барган шәпкә тын гына үбешәләр...

Парлыларны берәм-берәм күздән үткәреп җибәреп, Идрис кырга таба чыкты. Шәһәр урамында яктыда күренмәгән йолдызлар күктә кабынды.

Бераз баргач, аңа куаклар очраштыргалады. Кара-кучкыл ботакларның ешлыгы артыннан хәрәкәт, ыгы-зыгы һәм йомшак кына көлгән хатын-кыз тавышы ишетелде.

— Ул кадәр үк каты үпмә... Иренне кара яндырасың!..

Ят кешеләрнең серен ишетү аны сискәндерде...

Күнегелмәгән җир, каралҗым шәл бөркәнгән куаклар, качып утырган җан ияләренең барлыгы аны шигәйтте, ул кырт борылып шәһәр ягына кайта башлады. Иң кырый йорт янынннан үткәндә аңа кемдер кычкырган кебек булды.

— Абый!

Ул як-ягына каранды. Тәрәзәләрдән төшкән яктылык тасмаларын кисеп урамда парлылар гына йөриләр. Нигез тәрәзәчегеннән ике мәче атылып чыктылар да койрыкларын уктай күтәреп чабарга тотындылар...

Шәһәр шушында бетә икән... Моннан ары такыр кыр башлана, куаклар, әрәмәләр артында гына авыл булырга тиеш. Әгәч тавышлары мөгаен шуннан килеп ишетелә торгандыр...

Тапталган вак чирәмнәргә чык йөгергән, аның табаны юкарган җәйге ботинкалары моны гиз сизделәр, ул учы белән авызын томалап ике-өч тапкыр гына төчкерде.

— Абый!

Бу юлы тавыш якында гына ап-ачык ишетелде.

Идрис әсәренеп боргаланды, өскә күтәрелеп карады. Икенче кат балконында тимер рәшәткәләргә куллары белән ябышып бер малай утыра иде.

— Син миңа эндәшәсеңме, бәләкәй тоткын? — дип сорады ул.
— Сиңа, абый.
Тавышына караганда малай бөтенләй сабый булырга тиеш.
— Нигә бәй-бәй итмисең, ускәнем? — диде Идрис, үзенең «бәләкәй тоткын»ын йомшартырга теләп.
— Кур-к-ам,— дип сузды малай, калтыранып.— Карават астында нидер кыштырдый.
Аның тешләре тешкә тия иде. Идрис, булдыра алган хәтле шыпырт итеп:
— Әниеңне уят,— дип киңәш бирде.
— Өйдә ю-ук...
— Кем өйдә юк, әниеңме?
— Икесе дә. Әти дә, әни дә...
Идрис аптырашта калды.
— Син берүзең генә мени? Кайда соң алар? Эштәме?
Малай борынын мышкылдатты да куркып кына:
— Берүзем,— диде.
— Ничә яшь соң сиңа?
— Алты.
— Ә, алайса, өй сакларлык егет булгансың икән! Исемең ничек?
— Минемме? — Малай беравык тынып торды.— Айдар.
— Менә шулай, Айдар дус,— диде Идрис, татарчалап.— Әйбәт кенә кер дә төренеп ят. Карават астында бернәрсә дә булмый.
Айдар аңламагач, ул сүзләрен русча кабатлады.
Малай үпкәләде, рәшәткәләрне ычкындырып арткарак шуышты.
— Булмас сиңа,— дип мыгырданды ул,— олылар гел ялганлыйлар.
— Ишетәсеңме син? — дип кычкырды Идрис балкон астында таптана-таптана.— Карават асты джунгли түгел, анда синдәй егет куркырлык кем дә булмый!
Малай ләм-мим димәде, кымшанып урыныннан кучте, чиләкме, мискиме шылтырады, тимер рәшәткәләр арасыннан ике ялан тәпи килеп чыкты.
— Айдар, син салкын бетонда утырмыйсыңмы? Кер өеңә, кер,— диде ул, хафаланып.— Әтиеннәр дә хәзер кайтыр.
Кыштырдаган тавыш ишетелде, малай аягына басты, иягең балкон култыксасына куйды. Күзе ялтырап китте.
— Син минем әтине беләсеңмени?
— Белмим... Озакламый заводларда смена бетәр, шуннан чыгып чамалыйм.
— Белмәгәч, нигә алдашасың?.. Кайтмыйлар, кайтмыйлар.— Ул үҗәтләнеп ияге белән агач аратаны кыйный иде.— Башта киногa керәләр, аннары гөмбә астына утырып мороженое ашыйлар. Минем әни эскимо ярата... Аннан бакчага танцыга керәләр. Гел шулай.
— Кыш көне дә бакчага танцыга йөриләрме? — диде Идрис шаярыбрак.
Малай чиксез дәрәҗәдә җитди иде, ул шаяртуны кабул итмичә аңлатып бирде:
— Фе, кыш көне мин бакчада булам! Атналык детсадта... Хәзер анда ремонт!.. Әтиләр мине йоклаталар да чыгып китәләр. Тиз йокыга китмәсәм, ачуланалар. Мин йокламыйм, күземне кысып-кысып йомам да шым ятам!.. Ишекне шалт! Тыштан бикләүләре була, күзләремне ачам... Алар кайтканчы йокламыйм... Бүген карават астында нидер кыштырдый...
— Ишегеңне ач, Айдар,— диде Идрис,— мин синең яныңа кереп утырам.
— Син бандит түгелме, абый?
— Түгел.

— Ачмыйм. Әни ачулана... Ишекне алар тышкы яктан биклиләр.
— Өегездә бүтән ачкыч юкмыни?
— Әни яшерә... Буфетны да, шкафны да бикли,— диде малай, беренче тапкыр җыламсырап,— эзләдем инде... табалмадым... Шунда дару шешәсен ваттым, бармагым киселде.
— Ут яндырырга иде,— диде Идрис җан теләктәшлеге белән.
— Куркыныч!.. Карават астында кыштыр-кыштыр йөриләр...
Идрис гаҗиз булып як-ягына каранды, ары сугылды, бире килде, кемгәдер ачуы чыкты, үз көчсезлегенә кыенсынды, аннан чалбар каешын чишеп малайга ыргытты.
— Тот!
Айдар каешны оста гына эләктереп алды.
— Булдымы?.. Хәзер каешны аелы аша чыгарып рәшәткәнең иң түбән ягына бәйлә... Бәйләдеңме? Хәзер әйбәтләп тыңлап тор: култыкса аша чык. Чык, чык, егылмыйсың... Ныкябыш! Чыктыңмы?.. Егет икәнсең. Курыкма, аска карама! Рәшәткәләргә чытырдап ябыш. Хәзер иплəп кенә каешка тотын да аягыңны ычкындыр.
Малай чожт иттереп аска шуып та төште. Идрис ике куллап аны кочып алды. Җиту чәчле арык кына малай боз кебек салкын иде.
— Әһә, үр куяны!.. Калак сөякләрең шылтырый... Җитмәсә үзең ялан тәпи... Аягыңа берәр нәрсә элдерәсең калган.
— Туңмыйм мин,— диде Айдар, җиңелчә генә калтырап.
— Мәле, минем җылы пиджакны киеп җибәр!.. Өстең юка.
Идрис үзенең тәҗрибәсезлегеннән оялды... Айдарның дәү пиджакка уралуын сөенеп карап торгач, ул ботинкаларын чишенеп ташлап оекбашларын малайга сузды:
— Боларны да ки... Бәләкәйрәк булырлар да...
— Туңмыйм,— диде малай, үзе оекбашларын ялт кына киде.— Каеш калды бит.
— Чалбарны тотып йөрермен!..— дип көлде Идрис.— Тора бирсен! Шул ук маршрут белән сиңа өскә сәфәр ясарга кирәк ич.
— Әни күрсә, үзем бәйләп төштем диярмен.
— Килештек!
Айдарны өйгә алып кайтып китәргәме әллә дип уйланды Идрис, яхшысынмады... Ата-анасы нинди кешеләрдер, фаш булып тавыш-гаугага куптарырлар, бәладән баш-аяк, яшәсеннәр, әйдә үз дигәнчә!..
Алар кыр ягына таба атладылар. Малайның оекбашлары сыдырылып түбән төшеп йөдәтте, бәйләп куярга җеп-мазар юк иде.
— Син бөтен кешегә дә шулай кычкырып каласыңмы?
— Юк.
— Алайса нигә миңа эндәштең?
— Син дә ялгызың бит... Парлыларга мин таш ыргытып калам!
— Оһо!.. Ыргытасың да качасың инде? — Идрис тукталып Айдарны җитәкләде.— Бармагың сызлыймы?
— Печтек тә авыртмый.
— Туктыйк шушында,— диде Идрис бераз баргач.— Анда юеш. Чык төшкән. Чыкны беләсеңме?.. Бәбиләр, нәни кызчыклар, малайлар бәй-бәй итәргә яткач, үләннәргә вак-вак көмеш тамчылар төшеп куна... Матур, әмма аякны чылата чык!.. Минем ботинкам балык тота торган җәтмә төсле. Син дә яланаяк.
— Мин беләм... Моннан болыннар башлана.
— Әйе,— диде Идрис, аңа карап.
— Әни миңа монда килергә кушмый... Бу якта караклар, бандитлар, әшәке малайлар йөри, ди... Олылар гел алдашалар!
— Нигә син парлыларга таш атып каласың?
— Иөрмәсеннәр! — диде малай һәм яман ачы сүгенде.
Урам теленең күтәрелмәгән зәһәреннән Идрис исәнкерәп калды.

— Бер әйбер күрсәтәм дә, борылабыз.— диде Айдар, Идриснең җиңеннән тартып.— Әйдә, әйдә, курыкма. Чирләмим мин. Чирләсәм дә, кызганма, үз улың түгел бит.

Сүгенгәне өчен кыздырырга торганда, Айдар соңгы сүзләре белән Идриснең күңелен йомшартып җибәрде, ул юеш үләннәрне чирканып ера-ера малай артыннан иярде. Урамны чыгып сулга ике йөз метрлар баргач, коры үзән башланды. Шул үзән уртасында тәбәнәк кенә бер корылма шәйләнде.

— Кара,— диде малай, Идрискә башы белән орынып.

— Нәрсә бу, мунчамы?

— Алачык,— дип пышылдады малай, куркынып.— Монда бер бабай килеп йөри. Аның аягы агач. Ул малай чагында хулиган булган.

— Кем әйтте?

— Бөтен агач аяклы кешеләр бәләкәй чакта бандит булганнар! Аларның аякларын усал кешеләр кискән... Ә мин андыйларга тоттырмыйм... Ул карт хәзер сихерче... Әни әйтте, үзем дә белдем. Әнидән качып килдем дә ярыктан карап тордым. Сихерче карт ярыкларны кәгазь белән томалады... Тимер чыбык белән выжт иттереп тиштем! Анда бер велик бар. Өр-яңа! Во велик! Ике тәгәрмәчле. Сихерче аны стенага элеп куйды. Ачкыч ятатып чәлдерәм мин аны.

— Китик моннан,— диде Идрис катгый гына.

— Йозакны гына күрсәтәм.

Мондый дәү, дугалы авыр йозакны Идриснең күргәне юк иде. Малайның кыюлыгына, зирәклегенә исе китү белән бергә, аның күңелендә мондый йозакның хуҗасы чыннан да гади адәм түгелдер, сихермихер иясеңдер дигән шик килде.

— Капкын төсле йозак,— дип тәтелдәде малай.— Кадак тыгып боргалап караган идем, ачылмый.

— Ничек буең җитте?

— Ә мин кафе янынннан тартма сугып килдем.

— Каян беләсең син капкынны?

— Күршеләргә телевизор карарга йөрим... Үскәч мин аучы булам, сәяхәтче. Африкага барам. Үзем белән киноаппарат алам. Казанныкы түгел, безнен шәһәрдә юньле нәрсә чыгармыйлар, ди әти... Японныкын алам! Во! Арсланнарны, филләрне карточкага төшереп йөрим... Синең иң яраткан фильмың кайсы?

Малайның соравына уйнап кына җавап биреп котылып булмый иде.

— Минемме?.. Яхшы фильмнар күп... Иң ятратканым швед режиссеры Бергманның «Җир җиләге аланы» картинасы.

— Караганым юк,— диде малай, җитди итеп.— Ә мин «Язмыш барабаннары»н яратам.

— Әйбәт картина,— дип хуплады Идрис.

— Өч карадым, өчесендә дә жыладым...

— Дөрес иткәнсең. Хәзер кайтыйк инде, син туңасың.

— Синең Африкага барганың бармы? — диде малай алачыктан ерагайгач.

— Африкага юк, Себергә барганым бар. Иртыш буена.

— Анда филләр юк.

— Булмас. Иртыш буенда мамонт сөякләре күп. Анда елга ярында мамонтларның каберлеге.

— Тере мамонтлар кайда йөри?

— Тереләре калмаган.

— Алайса нигә бардың соң син?

— Студент чакта эшкә җибәргәннәр иде.

Яшел-кызыл борт утларын җемелдәтеп самолет узды.

— Абый,— диде Айдар, аның җиңеннән тартып,— самолет күккә тиеп, ышкылып барамы?

— Нигә?

— Күккә ышкылып бармаса, ничек эзе калсын аның?

Ул физика законнарын гади тел белән үзе белгән кадәр малайга аңлатып караса да, Айдар ышанмады.

— Син белмисең икән,— диде ул ышаныч белән,— ышкылып бара! Күк бик каты, зәңгәр боз төсле, самолетлар аны тишә алмый, шуңа күрә ракеталарны очлы-очлы ясыйлар.

Урамга кергәч, малайны очкылык тота башлады.

— Тукта, әйт! — диде Идрис, Айдарны эләктереп.— Бүген нәрсә урлап ашадың?

— Абый, куркытма инде,— дип ялынды малай.

— Урлагансың, урлагансың. Әйт!

— Куркытмасана, абый,— диде Айдар.— Очкылык гел килә миңа. Күрше Вил абый куркытып карый, очкылыгым барыбер бетми.

Идрис көлде. Алар балкон астына килеп җиттеләр, каеш җилдә атынып малайны көтә иде.

— Син иртәгә киләсеңме?

— Иртәгә эшкә... Кичкә кадәр ерак...

— Кил, яме.

— Безгә әнә теге йорттан квартира бирделәр.

— Теге сихерче дә шул йортта тора! — дип кычкырды малай.

— Шулаймыни?

— Синең малаең бармы?

— Юк,— диде Идрис, аның чәчен учлап.

— Булса син аны ияртеп йөрер идеңме?

— Әлбәттә.

— Әни миңа малайларны больницадан биреп җибәрәләр, ди... Син әшәкене ник алып кайттык икән, ди... Ә мин беләм, малайлар әниләренең эчләрендә үсәләр... Бер әйбер сөйлимме? Беркемгә дә әйтмисеңме?

— Сөйләмәм,— диде Идрис, кызыксынып.

— Җаным, каным чыкса да сөйләмәм диген.

— Сөйләмәм!

— Мин тәмәке тартып карадым инде. Тәмсез. Соңыннан башны авырттырды.

— Менәсеңме инде? — диде Идрис, каешка үрелеп.

— Курыкма,— диде малай,— кайтмыйлар алар. Мин сине озата барам.

— Әйдә. Аннан мин сине күккә озатырмын.

Идрис кузгалмаска теләгән иде, Айдар кыптыр-кыптыр алдан китте. Алар кафе янына узып баралар. Малай яктыга кергән саен танып-белеп калырга теләгәндәй күтәрелеп-күтәрелеп аңа карый. Идрис моны үзенчә аңлады.

— Синең карын ачтыр, мөгаен.

— Юк,— диде малай ныклык белән.

— Чак кына көт... Минем берәүне күрәсем бар!

Ул малайны бер кырыйгарак бастырып кафега кереп китте. Ишек катында идән сөртеп азапланган ябык, киез чәчле хатын күтәрелеп аңа каршы төште.

— Кафе ябыла.

— Буфетка гына! Шырпым беткән!

Идрис учындагы вак акчаларын шылтыратты.

Әйләнеп чыкканда кафе тирәсендә Айдар юк иде. Зур пыяла ишекләр янында өч-дүрт егет җыештыручы хатынга ялынып бөялгәннәр.

— Айдар!

Ары карады Идрис, бире йөгерде, малай юк кына бит!..

— Айдар!

Караңгыдан, кафе артыннан малайның тавышы ишетелде:

— Монда мин, монда!

Идрис аңа каршы китте, җилтерәтеп Айдарны яктыга чыгарды. Малайның ике кулында да буш шешә иде.

— Каян алдың боларны?

— Кирәк алар миңа... Иртәгә тапшырам...

— Хәзер үк ыргыт.

— Нигә? — диде малай, гаҗәпләнеп.— Кирәк алар миңа.

— Мин сине сыйламакчы булам, син каракланып йөрисең!

Итле дөге сумсалары күрер күзгә бик яңалардан булмасалар да, малай, бер-ике тапкыр каерып капкач:

— Во! — дип баш бармагын күрсәтте.

Кәгазь стаканга ул чиксез куанды. Идрис, туңарсың, азрак эч, дип үгетләп торса да, өч стакан лимонадны чүмереп бетерде. Чүп савытына салырга дигәндә, Айдар бушаган шешәне тартып алды, йөгереп караңгыга кереп югалды. Әйләнеп чыкканда, кулларында әйбер-кара юк иде.

— Яшереп куйдым! — диде ул, мактанып.— Дөге сумсасын үлеп яратам!

— Аша алайса.

— Тик син алдадың,— диде ул кулын Идриснен пиджак итәгенә сөртә-сөртә.— Беркемне эзләмәдең, туп-туры буфетка элдердең.

— Мин эзләгән кеше чыгып киткән,— дигән булды Идрис.

— Зурлар гел-гел ялганлыйлар. Шуңа күрә минем үсәсем килми. Ул тозлап-борычлап ачы итеп сүгенде.

Идрис малайны җилтерәтеп каршысына китерде:

— Каян оттың мондый кабахәт сүзләрне?

— Олылардан!

Кинәт аларның баш очыннан гына гамьсез гүелдәп самолет узды, малай тынычсызлана башлады, ул Идрисне йолыккаларга, тарткаларга тотынды:

— Тизрәк, тизрәк! Кайталар, кайталар,— диде ул, тотлыгып.

Юртып барып та життеләр, Идрис малайдан пиджагын салдырып алды, куркудан калтырап торган курач, җиңел гәүдәне култык асларыннан эләктереп каешка буй җитәрлек итеп күтәрде.

— Бас иң өстенә! — Малайның аяклары юеш-юеш һәм сап-салкын иде.— Каешка тотын. Эләктерденме? Үзеңне цирк артисты дип уйла! Алло, күтәрел, күтәрел! Шүрләмә, ычкындырма, каешны урап тот. Үрмәлә, бер-ике!

Малай тимер рәшәткәләргә чытырдап ябышты, үрмәләде, түше белән култыксага ятты, эчкә сикерде. Каешны чишеп, оекбашларын салып аска ыргытты.

— Оекларың тишелгән, абый.

Идрис оекбашларын газета кисәгенә төреп кесәсенә салды.

— Ямыйбыз аларны! Ә син кер, иплән кенә урыныңа ят. Мин монда булырмын.

— Исән бул, абый,— диде малай, кинәт борылып.

Балкон ишеге шапылдап ябылды, өй эчендә тавыш-тын ишетелмәде. Идрис беравык тыңланып көтте дә кайтыр якка атлады.

Урамда аңа өч-дүрт парлы очрады. Алар төннең матурлыгына, күкнең ямьлелегенә сокланып рәхәт итеп көлә-көлә ашыкмыйча гына урам буйлап баралар иде.

Ул кабалана башлады: соңгы хәбәрләрне тыңларга өлгерергә кирәк!

Тагын Дилә искә төште, тагын күкрәкнең сул ягында нидер чәнечте...

Кеше үз йөрәгенә ыгы-зыгы, өстәмә борчулар эзләп өенә, радио дулкыннары янына ашыга иде...

8

Идрис белән Диләнең өйләнешкәннәренә дүрт ел узса да, аларның бәбәйләре булмады. Баштарак яшьлекләре сәбәпле үзаралай сүз кузгатырга кыенсынып йөрделәр. Ниһаять, кеше табигатенә мең-миллион еллар береккән ата-ана булу теләге омтылышы оятны җиңде, җир тишегенә керердәй читенсенеп врачка каралырга бардылар...

Идрис ансат котылды, аңа:

— Сау-сәламәт! — диделәр.

Диләгә җиткәч, врачлар уйга калдылар. Анализлар ясалды, бүлек мөдиренә күрсәттеләр...

— Сез яшь чагыгызда күп тапкырлар ангина белән авыргансыз... Шушы салкын тиюләрдән байтак органнарыгыз җәфаланган, сез бәбәй таба алмыйсыз,— диделәр аңа.— Бәби теләсәгез дә, теләмәсәгез дә дәваланыгыз.

Дилә бу аяусыз хөкем белән килешергә теләмәде, түләүле поликлиникага барды, атаклы гинеколог-профессорга каралды. Анда да яшь хатын өчен куркыныч, җан өшеткеч сүзләрне кабатладылар:

— Дәваланырга, яшь ханым, дәваланырга! Өметне өзмәгез, нык булыгыз... Теләгән табар дигәннәр!.. Көньякка барып файдалы ләм ванналары алыгыз. Мөмкинлегегез сыйдырса, ләмнән соң берәр ай көньякта, үзегез дәваланган климатта ял итәргә тырышыгыз...

Үзеннән бигрәк ире өчен борчылды Дилә.

Соңгы бер елда аерата түземсезлек, хәтта таләпчәнлек, ныклы карар белән өзмәс-төтмәс бала көтте Идрис... Профессор янына өмет белән мөлдерәмә тулы күзләрен текәп озатып калды... «Чыккач та шалтырат!» диде... Хәзер иптәшләр, ата булудан гомергә мәхрүм икәнлеген белгәч, ни әйтер? Ярый ла дәваланып рәт чыкса?..

Авыру аналардан гарип-гораба балалар гына туа икән дип тә сөйлиләр бит!..

Өзгәләнде Дилә, нык өзгәләнде...

Менә хәзер кайтып керер дә яратып кавышкан, сөеп кияүгә чыккан кешесеннән нинди хөкем ишетер?.. Бәбисез гаиләләрнең нәкъ шул нигездә талашуларын, ир белән хатынның бер-берсен бикәргә гаепләүләрен, соңра бөтенләй пычакка-пычак килеп аерылышуларын актыккы көннәрдә аңа еш кына ишеттерәләр иде. Кайгылы колакка хәсрәт сүзе күбрәк керә, кулыңны кая сузсаң да, канаган бармак бәрелә...

Тип-тигез җирдә, ап-аек баштан тәгәрә дә егыл инде!..

Көтелмәгән уйлар... Күнегелмәгән врачлар... Ят терминнар... Болар өметсезлектә тәкатьсезләнгән хатынны буынсыз калдыралар... Икесе дә бала дип өзелеп китәләр, иртә-кичен телләрендә шул гына иде...

Диләнең кыяфәтен күрүгә, Идрис барын да аңлады. Ирлеге җитте, ак димәде, кара димәде, зарсыз ризалашты: ике айга түгел, ярты елга җибәрергә әзер!.. Иөр генә, күрен, тикшерт, дәвалан!..

— Хәзерге заман медицинасының көченә ышанам,— диде Идрис һәм бу ышаныч тәмам какшаган Диләгә дә йокты...

Бәләкәй тоткын Айдар белән очрашу аңа нык тәэсир итте. Ул бу дөньяны тискәре яктан, моңарчы бер чакта да күтәрелеп карамаган яңа ракурста күрде.

Бала теләү — борынгыдан, күзәнәкләрдә геналар күчереп килгән саңгырау бер инстинкт кына икән. Кешенең күзәнәкләреннән күңелгә

өн ага, жан белән кан берләшеп мигә тукыйлар: нәсел-ыруыңның дәвамы кирәк! Җирдә тереклек яралганнан бирле бу шулай килә, уйлан!

Бала тугач башлана икән анын мәрәкәсе! Бала тугач, үзенә игътибар, кадер-хөрмәт, урын, тәрбия, вакыт сорый икән!..

Әгәр аның улы нәкъ Айдар төсле сүгенеп җибәрсә?

Кафе артындагы тартмалардан буш шешә чәлдереп чыкса?

Тотылса?

Трамвай тәрәзәсенә таш атып калса?

Ул очракта да балага булган мәхәббәт өстенлек алырмы, әллә моңарчы ул татымаган акыл, көч, ниһаять, ата кеше абруе ярдәмгә килерме?

Бусы Айдар...

Монысы яшел, дәү яфраклы әрекмән... Дәү, сусыл яфракларын җилфердәтеп җирдә утыра. Ана юньле-башлы берәү дә дикъкать итми: әрекмән тек әрекмән! Азмы алар болында!.. Файдасы да юк, зарары да тими... Бер заман шул әрекмән сабакка котыра, тигәнәкләрен өлгертә, якын килеп кара, кием-салымыңа әрсезләнеп ябыша, тотына... Инде хәзер барысы да аны әйләнеп, читләтеп узалар, куркалар.

Айдар да шул ук әрекмән түгелмени?..

Радиода хәвефле хәбәрләр. Сүрия, Гыйрак, Ливан Израильгә каршы сугыш игълан иттеләр... Сүәеш каналында пароходлар йөреше туктады... Ә Израиль гаскәрләре Синай ярымутравын биләгәннән-биләп баралар...

Идриснең күз алдына гарәп илләренең хәрби парадлары килде. Дөяләргә менеп атланган ак башлыклы укчылар, киң япанчаларын иңгә салган фәкыйрь, җайдак бәдәвиләр... Дин белән үтәли сөремләнгән, «пигамбәребез дә фәкыйрь булган әле» дип хәерчелекләрен акларга тырышучы фанатиклар...

Америка, Англия заводларында эшләнеп, төрле илләрнең кырболыннарында канлы көрәшләрдә сыналган танкларга, француз самолетларына каршы сез нибарысы батырлык, бердәмлекне генә каршы куя аласыз...

Бердәмме сез?.. Батырмы сез?..

Нигә йөз миллионлы гарәп халкын бәләкәй генә Израиль дерелдәтеп тота! Нигә чигенәсез сез?!.

Әхәт хаклы, мең тапкыр хаклы: дөнья халкы бердәм булып, берберсен аңлашканда гына сугыш чукмарларын айнытырга җай табылачак! Кешенеке кештәктә дип битараф булып яшеренеп калырмын димә хәзер... Җир шарында кеше яшеренерлек почмак юк... Һәр кителмәгән хәлне кителгән төсле итеп кабул итәргә өйрәнергә вакыт...

Уйланып ята торгач, сигезенче яртЫ китте. Ул торды, аерата бирелеп гимнастика ясады, тир бәреп чыккач салкын душта коенды, кофе эчте. Салкын су аны борчулардан арындырды, тиз эри торган Бразилия кофесы «Касике» көч бирде.

Трамвай тукталышында шактый борчылырга туры килде. Троллейбуслар йөрмәгәнгә, пассажирлар адашкан бәбкәләр шикелле урам тутырып бәрелеп сугылалар, утырып китәргә җай эзлиләр. Таксины соң чиктә генә ала Идрис. Дилә кайгысы белән квартирсызлык нужалары аны акча белән сак эш итәргә өйрәттеләр...

Соңга калырга да ярамый... Сиңа кирәктә таксие табыламы?

Тәки соңгарып килде, Әхәт инде байтактан килгән, кәгазьләрен өстәл тутырып юри тутырып ташлаган, күрми дә, ишетми дә, эшкә йотылып утырган була...

— Әхәт, сәлам! — диде Идрис.

— Салют, картлач! Ярдалдыңмы?.. Баш чатный, авызның тәме юк, кәеф губернаторныкыннан яман!.. Күзгә ак-кара күренми. Шулаймы?

Анын соңга калуын Әхәт мәзәк итте.
Нигә һәм нидән авыртсын икән?
Әхәт, май чүлмәге янында ешынган мут песи сыман анын тирәсендә әйләнгәләп, бармак бөкли-бөкли санарга кереште:
— Борын кызарган... Күздә дә шик бар!.. Өс-баш та таушалган... Кыҗыр-быҗырлар башландымы?
— Кыҗырдамый торсын әле! Чупрәсен салмадың ич.
— Көртлек кебек, башыңны яшерсәң дә, артын күренеп тора! Ачармын серенне, картлач, анлык кына кодрәт бар абзаңда! Үзең сөйләп котыласыңмы, әллә мин тезеп салыйммы?
— Урамга күз төшер: троллейбуслар йөриме?
— Фи-и, редакциядә ничә чалбар туздырып шуннан да остарак алдарга көчең юкмы?.. Эчәгене үземә юлларга кала...
— Әйдә, тырыш.
— Кайда себерелдең төнге унбердә? Звоногыңны өзеп төшерә яздым.
— Төнге унбердә үзең дә изге ният белән йөрмәгәнсеңдер, шәт?
— Ә, танасыңмы?.. Без икәү идек.
— Шаһитсез килмәдем дисең инде?.. Звонок тавышын ишетмәдем, йокыга киткән чагым булгандыр.
Әхәт күзен акайтты:
— Нәрсә? Өйдә идем дип шыттырасыңмы?
— Интекмә, сәфәрдә идем... Мин дә бер гаҗәп кеше очраттым.
— Димәк, син ресторанда утыргансың!
— Ногыт борчагын сөрсегән, күрәзәлегең бер тиенгә тормый!.. Ул кеше икенче кат балконында иде,— диде Идрис, үз сүзенең эффектыннан үзе канәгатьләнеп.
Әхәт җыланга баскандай сикереп алды:
— Атакай гынам!.. Ул оялчан гына кыз балконда басып тора... Чәчләре җилдә тузгыган, муены шәп-шәрә... Син җирдә... Кулыңда гитара... Серенада җырлыйсың. «Тып итеп балконга чык иркәм, көтәм сине кичләрен һәм иртән!» Поэзия... Әй, күктән җиргә төштегезме соң?
— Булды инде, булды,— диде мутланып Идрис.
Сызгырып ук җибәрде Әхәт.
— Ярар, котылдың... Юкса ни тикле өйрәтеп, синнән рәт чыкмады дип кыйналам. Рәхмәт, шәкертем, йөрәгемә сары май тамыздың... Сине лаеклы укучыбыз санап теге исемлеккә дә кертербез.
— Шундый хикмәтле исемлек тә бармыни?
— Иң өстендәге фәрештәләр шыгырдатып гөнаһ дәфтәренә язып куйдылар!
Икесе дә көлешеп туйгач, эшкә тотындылар. Бераздан Әхәт башын күтәреп Идрискә карады:
— Соңгы сводкаларны тыңладыңмы?
— Юанырлык нәрсәләр аз, гарәпләр пыр тузып чигенәләр.
— Ничек алай?.. Бөтенләй аңлашылмый... Шунлык та корал, көч юкмыни аларда?.. Сугыш буласын белеп тордылар, аз булса да сагаймадылар микәнни?..
Идрис уйлап кына җавап бирде:
— Кайвакытта корал гына хәл итми, халыкның рухы, хөкүмәтнең рухы, гаскәр башлыкларының рухы да зур роль уйный.
— Стратег! — диде усал елмаеп Әхәт.— Үзем дә беләм! Тик барыбер аңламыйм.
Курьер Җәүһәр апа кочагына төяп көндәлек почтаны алып кайтты, аны күреп барысы да хатлар бүлегенә керделәр. Әхәт, газеталарны бөтен кешедән алда карарга яратканга, шуларга ташланды.

Идрис иң элек хатларны күздән кичерә. Бүлек мөдире Ниса Чәймилова, илле яшьләрдәге кырыс хатын, хатларны курьер кулыннан үзе ала, саный, адресларына карап сортлап чыга, шунарчы берәүгә дә тоттырмый. Аның күрә-карау күзе белән борын эченнән мыңгырдап укуын тыңлап торып Идриснең калак сөякләре сызлый...

Ничә тапкыр хатлар бүлегенә кермәм дип ант итте инде, барыбер керә, җәфалана, җәзалана...

Гомердә булмаганны ул бүген Чәймилованы ашыктырды:

— Тизрәк карагызчы, Ниса апа,— диде.

Чәймилова, аягүрә басып, бармак төртә-төртә хат өемнәрен күздән кичерде дә:

— Редактор исеменә бүген өч хат,— диде.

Әхәт аның күзенә кирәрлек якынаеп сөйләп китте:

— Шеф исеменә, гадәттә, матбугатны үз мәнфәгатьләре өчен дә файдаланырга мөмкин икәнен үзләштергән, дәүләттән һәм җәмгыятьтән ныграк каерырга омтылган, патентлы, шомарган дәгъвәчеләр еш яза.

— Ай-һай, күпне беләсең, Әхәт Исмәгыйлович. Ничек башың авыртмый? Күпне белгән башта бөлгән, аннары үлгән, диләрме әле? Аз бел, сүзгә саран бул, озаграк яшәрсең!

Чәймилованың саргайган бармаклары арасыннан сигарет төшми дә диярлек, суыра да өстәл астына өрә.

— Әнә, Идристә Гали пакесе бар, Ниса апа,— диде Әхәт, газеталарны өеме белән аның алдына ташлап.— Минем телне кисегез,ә аның үзен...

Идрис аңа ачу белән карады.

— ...бер уңайдан теге исемлеккә кертегез.

— Әкият сөйләмә.

— Кичә төнлә бер шаһит алып үзем барып тикшердем. Өендә юк иде. Кайда йөргән ул? Нишләгән?.. Егерменче гасырның алтмыш җиденче елында ялгыз калган ир вакытын ничек үткәргән?

— Кешегә бәла такма син,— диде Идрис, борчылып... Бу Әхәтнең логикасына төшенеп бетмәссең, кая сукалап керепп китте.

— Нинди исемлек уйлап чыгардың? — диде Ниса.

— Донос исемлеге,— диде Әхәт, көлеп кенә.

Сүзнең уеннан ашканын шунда гына аңладылар. Нисаның бәләкәч йөзе саргайган кыяр кебек җыерылды, ул чәрелдәвек аваз белән:

— Сөйләшә белеп сөйләшегез! — дип выжылдады.

Идриснең гаҗәпсенүенә Әхәт бер җөмлә белән җавап бирде:

— Ниса апаң редактор исеменә жалоба язган: взятка алып ята диган.

— Үзең кайтып сөйләдең ич син аны! — диде Идрис, шаккатып.— Өйләреңдә калдырып китканнәр.

— Взятканың үз аягы белән йөргәнен кайчан күргәнең бар? — диде Ниса, исе китмичә.— Балык, икра кемгә килгән, шунысы мөһим!

Әхәт үз бүлмәләренә чыкканчы рәхәтләнеп көлде.

— Ничәмә-ничә яшь журналистны кан жылатып редакциядән кудырды бит... Мине дә шулай тожырмакчы. Гатеми торсын! Чокчына, жинаять эзли, көтеп, посып тора... Тәнге унбердә шалтыратып һәр көнне өйдәлегемне тикшерә. Шалтырата, эндәшми... Сизәм, ул!

— Алайса син мине саттың.

— Шүрәлеләр янында синең ниндилегеңне тикшерәсем килде,— диде Әхәт, ваемсыз гына.— Уңмаган килен бәлеше төсле ишеләсеңме, әллә унган бодайныкы кебек кылчыгың тырпаямы?.. Сиңа да аның тырнакларын татып карарга туры килер. Үз хәлемне дә алданрак сизеп торасым килә: бата башласам, кул сузарсыңмы, әллә муенга таш тагарсыңмы? Икесе ике нәрсә. Мин дусларымның кемлеген ачык белеп

яшәргә телим... Баррикадалар артына басканда терсәккә терсәкне тerәрлек булсын.

Әллә ниләр уйлап чыгара бу Әхәт дип уйлады Идрис... Үзенчә сынап каравымы? Идриснең нәрсәсен сыныйсың? Әчендәгесе тышында... Күңелендәге телендә... Кичә соңга калып кайткан икән, монда бер дә баш китәрлек мажаралар юк...

Тик ул кичәгеләрне Әхәткә сөйләмәде...

Бераз тынычлангач, Әхәт үзе яңалык әйтте:

— Вәлиәхмәтовны чаянчылар янына чакыртып бүләкләрен кире кайтардым. Тәгәрәп жылый малаең... Бар әле, Идрис, егерменче гасырның уртасында, Октябрьның илленче елында да төрле бөжәкләр яши. Маяковский кандаласы бер генә түгел... Без дә начар энтомологлар булмыйк!..

Идриснең бик якыннан белә торган, даими язучы берничә хәбәрчесе бар. Бүген шуларның икесеннән аңа атап язылган хатлар килгән иде. Ул аларны Нисадан яздырып алды да укырга тотынды. Хәбәрче егетләр бик ышанычлы: алардан килгән материаллар махсус тикшерү дә сорамыйлар, бусы инде кат-кат сыналган. Идрис үзе дә аларга соң дәрәжәдә игътибарлы, егетләр дә аның ышанычын жуймаска тырышалар.

Хәбәрчеләрнең берсе авыл яшьләре турында, аларның авылдан китәргә омтылулары турында яза.

Колхозларында эшләүчеләрнең уртача яше кырык алты икән... Кызык... Әллә гыйбрәтлеме? Әнә, Ангарск, Солнечногорск, Дивногорск кебек яңа шәһәрләрдә торучыларның уртача яшьләре егерме дүрт — егерме алты... Гомумән, яңа калалар авыл яшьләрен үзләренә магнитлыйлар. Ә 1926 елдан 1966 елга кадәр, ягъни кырык елда безнең илдә сигез йөз кырык дүрт яңа шәһәр туып-үскән. Яңа шәһәрләр үзләренең перспективалары, мавыктыргыч профессияләре белән яшьләрне үзләренә тарталар, берләштерәләр.

«Игенче профессиясе картаямы әллә?» дип сорый хәбәрче. Әллә хәзерге заман игенчесен без элекке кырчы белән тиңләп, аны бәяли белмибезме?..

Егет бу сорауларга жавап тапмаган, аларга жавапны Идрис үзе дә белми, әмма бу проблемалар тирәсендә еш уйлана иде. Шуның өчен шундук хатны шатланып эшкәртергә тотынды, редакцияләде.

— Тыныч заман хатлары болар, Идрис...— диде Әхәт, урыныннан торып.

Бераздан аңа Лида шалтыратты.

— Әхәт, минем белеш малайларны хәрби комиссариатка чакырганнар! Ул телефон трубкасын кысып вата язды:

— Нәрсә дигәннәр, тизрәк бул, я? — дип кат-кат кычкырды.

— Берни дә әйтмәгәннәр.

— Һем,— диде күңелсезләнеп Әхәт,— тагын берәр көн көтәм дә гариза язып үзем барам...

— Син чыннан да китәргә уйлыйсыңмы? — диде Идрис, алар сөйләшеп бетергәч.

— Сөйләшеп кенә калырга мин Батыргали агай Шалканов түгел!

Унберләрдә Идрисне редактор чакырып алды.

Кайчандыр зәңгәр яшьлегендә үзе дә шигырьләр, балладалар белән женләнеп йөргән, әдәбиятка, газетага мәхәббәтле бу кешене Идрис хөрмәт итә иде. Яшькә үзләреннән әллә ни ерак китмәсә дә, житәкче эшләргә иртә катнашкан, тулы гәүдәле, олысымак йөрешле шеф-мөхәррир һаман эш сөюдән туктамый, нәтижәдә үз хезмәттәшләреннән дә шуны ук таләп итәргә көченнән килә иде. Башка редакторлар белән эшләп караганы юк Идриснең, татып караганнар Рәкыйп Шәкүровны «әйбәт хужа» дип йөртәләр.

Сүзгә сабыр, эреләнмәс, тик бер йомшак ягы бар, үзен оста, үткен журналист дип уйлый. Хәтта үзенә атап язылган хатларга аерым бер табыну белән карый иде.

Идрис кергәндә шеф-мөхәррир корректура битләрен карап утыра иде.

— Нихәл, картлач? — диде ул, кул биреп.

— Әлеккечә, Рәкыйп абый.

Әхәт Идристән бер яшькә кече булса да Рәкыйпкә исеме белән дәшә, Идрис редакторны олылап «абый» дип йөри.

— Диләдән хәбәр-мазар юктыр?

— Бар, бар! Юлдан озын хат язып җибәргән.

— Яхшы, яхшы,— дип Рәкыйп тамак кырды.— Терелсен инде! Яшь чагында килгән чир китәргә тиеш... Син дә язгала, онытма, хатын-кыз шундый моментларда аерата нечкә күңелле була.

— Язарга кирәк булыр...

— Кичәге репортажың әзерме?

— Шуның белән утырам.

— Монда бер хат бар...— диде Рәкыйп, Идрисне сискәндереп. Командировкага чыгасы килми иде.— Ата-аналар минем исемгә язганнар!

— Мөһим хәбәрме? — диде, аз гына елмаеп.

— Балаларны детсадтан җәйге дачаларга шәһәр читенә чыгарырга тиешле булганнар, врач гаепләме шунда, райбашкармамы, чыгармаганнар. Гаеплесе анык түгел, хәтта эмоцияләр күп, фактлар томанлырак... «Хәзер балаларны кая куйыйк?!» дип сөрән салалар.

— Үз балаларыннан туйганнар икән,— диде Идрис тик торганда.

— Э-э, картлач, болай ярамый, батмый!.. Зар җылыйлар икән, сәбәпсез түгел, унбишләп имза гына бар. Тема отышлы, минемчә.

— Хат Казаннанмы, Рәкыйп абый?

— Казаннан, Казаннан! Районы да синеке...

Идрис хатны алып, адрестан бигрәк имзаларны карады. Сыздинбыздин имзаларның берсе адәм танырлык, калганнары борынгы руник язмаларны хәтерләттеләр. Хатны бер генә кеше язган да имзаларның барын да үзе сырлаганга охшый. Аз булдымы инде андый рәссамнар!

— Безнең районда абстракционистлар ишәйгән икән.

— Уйлыйк: балаларны кая куярга диләр...— Рәкыйп өстәл тартмасыннан чуар-чабыр биш-алты кап алды да, сайлагач, берсеннән чиртеп папирос чыгарды, кабаланмыйча кабызды.— Нәни генә фактта тормышның трагедиясе чагылмыймы?

— Салават күпере бер тамчы суда да була... Ләкин күктәге эффект түгел инде, Рәкыйп абый,— диде ни өчендер хатны алырга теләмичә.

— Баланы телиләр, көтәләр, борчылалар. Өмет баглыйлар!.. Ә тугач: «Кая куярга? Нишләргә? Ничек үстерергә?».. Уйлыйк, бу уен түгел!.. Син тыңлыйсыңмы мине?

— Тыңлыйм,— диде Идрис, хатны куеп.

— Графология белән соңрак мавыгырсың. Уйлыйк, әһәмиятле нәрсә килеп чыкмыймы?.. Алынасыңмы?

— Уйларга ярый,— дип килеште ул.

— Менә яхшы,— диде Рәкыйп, блокнотына билге куйды.— Газетага бармаса, хат авторларына аңлатып җавап язарсың... Сиңа бернн кадәр бу тема якын тора, шуңа бирүем... Я, хәерле эш, картлач.

Идрисне озаткач, Рәкыйп Әхәтне чакырып кертте.

— Синдә ни хәлләр?

— Тырышып яткан көн,— диде Әхәт, ялтыр чәчләрен туздырып.

— Идрисне артыграк җикмисеңме? Җөгәнеп киткәнгә охшый... Диләне уйлап йомыкыйланган.

— Начар йоклаган.
— Син аңа рухи ял оештыр.
— Үтәлер.
— Үтәлер дигәнең шешә орбитасында төнге сәяхәтләргә кайтып каламы?
Әхәтнең елмаюы каядыр качты.
— Картлач, син дә шул аксак чикерткә Чәймилова сүзенә ышана башладыңмы?
— Өстеңнән жалоба артыннан жалоба язалар. Нишләргә тиеш мин?
— Жыланның угын суырып ал. Башкалар әләкченең кәнтәйлеген күрсеннәр. Жылап борылырлык итмә.
Рәкыйп көлемсерәп маңгай пеләшен кашып куйды.
— Ансат... Синең белән мин туганчы ук редакциядә эшли башлаган кешене ничек куасың?
— Төрмәдә цензор булып утырган бит ул, газета чыгармаган.
— Профсоюз, суд бар... Барыбер кире кайтачак.
— Асрыйк алайса арабызда шундыйны... Тере табигать, терек булмаган табигать, ионосфера, микромир... Анда жылан да, маймыл да, хәтта черки дә янәшә тыныч яшәргә тиеш... Шулаймы?
— Ә син черки булма! Комачаулама кешеләргә, яман телләргә азык та бирмә.
— Мин шундый, миңа үзгәрү кирәкми.
— Син аның чал чәчләрен ихтирам ит.
— Итәм. Хөсетлеген, жаһиллыгын сөймим.
— Анысы үз эшең... Идрис турында әйткәннәрне онытма...
— Идрисме?.. Артык тын яшәгәнгә мукләнеп киткән егет ул! Бер уяныр әле...— Әхәт, ишек төбенә житкәч, борылып күзләрен ялтыратты.— Ә үзең, Рәкыйп, Ниса турында әйткәннәрне хәтер тартмаңа сал. Үзең утырган ботакны кисмисеңме? Сиңа да ябышыр ул, сагай.
Әхәт, бүлмәләренә чыккач, тузынганын Идрискә сиздермәс өчен, беравык тәрәзәдән Бауман урамына карап торды. Аннары гына:
— Агрессорлар азыналар, Идрис,— диде.
— Син Израиль турындамы?
— Бер анда гынамы ул жыланнар?
Идрис эндәшмәде, ул кичәге митинг турындагы репортажын бетереп килә иде.
— Тәмам?
— Әйе.
— Шеф сиңа яңа эш йөкләгән икән. Ашыкмыйча, иркенләп тикшер.
— Каян исте әле мондый шәфкать жиле?
— Югарыдан... Аннары, көннәр эссе, тартмасында ми кайный. Сәламәтлегең турында да онытма. Сакланганны гына саклармын дигән ходай хәзрәтләре... Мин алай-болай китеп барсам, бүлектә син каласың.
Гел шулай Әхәт, шаяртып башлый, уен-көлке белән дәвам итә, житди итеп очлый, я киресенчә. Ә мәгънәсен бар очракта да тыңлаучы үзе төшенсен. Идрис исә авыр күтәрелә, ул һәр сүзне үлчәү тактасына салырга, уйланырга тиеш...
Редактор биргән хатны үз исеменә яздырырга ул Ниса янына керде.
— Утырып тор, апаем,— диде Ниса, аумакайлачып.
— Хатны гына...
— Янмый, кабаланма...
— Тикшерүне Рәкыйп абый миңа тапшырды.
— Менә нәрсә искәртмәкче булам... Син, Идрис туган, Әхәткә жентекләбрәк кара!.. Аннан гына түгел, андыйлардан читтәрәк йөр. Бар

андыйлар, бар. Нигилист! Белеп туган, җүләр булып үләчәк. Эчкән кешедән яхшылык көтмә, гаделлеккә өметләнмә.

— Исерек чагын күргәнем юк.

— Ашыкма, күрсәтер. Тик соң булмасын... Абайладыңмы? Нихәтле хатын-кыз аның янына килеп йөри... Кем җепкә тезгән ул Мюнхаузен үрдәкләрен?

— Миңа аның артыннан күзәтергә кушуыгыз булдымы, Ниса апа?

— Күзәтүнең ни ояты бар? Иптәшне ялгыш юлга кертеп җибәрикме?

— Ниса апа,— диде сабырсызланып Идрис,— барасы җиргә китәргә вакыт. Детсадка.

— Нинди бакча ул тагын?

— Менә хатта күрсәтелгән. Унҗиденче детсад.

Ниса Чәймилова юри кат-кат укып егетне җәфалап бетерде, озак итеп катыргы тышлы кенәгәгә теркәде.

— Кешенең мөхитын күзәтәм мин. Әхәт синең эше юаш эшчәннәрне суган-борычсыз кабып йотачак.

— Нигә йотар икән? Мин аның көндәше түгел, эштә дә аның урынына үрмәләргә җыенмыйм.

— Кызык өчен йотар! Бүре егерме сарыкны ашар өчен буып ыргытамы? Ашыймы ул аларны?.. Дошманы — кеше исе килгәне өчен ботарлый.

— Киңәшегез өчен рәхмәт, Ниса апа.

— Кергәлә.

— Үз тирәмдәге бүреләрдән үземнең арынасым килә.

Идрис башкача катырак җавап тапмады. Студент чакта ук шушы Чәймилова янына килеп, беренче заданиеләрне шуннан алып йөргәнгәме, шул чактагы мөнәсәбәтләр хәзергәчә калды... Шушы өч тотам буйлы тәмәкече хатын алдында Идрис имтиханга кергән яшел студент сыман каушап төшә. Теге вакытта да өркеп кенә йөри иде, хәзер дә шүрли. Уф...

Эш көне тәмамланырга вакыт байтак иде, ул Әхәттән китәргә рөхсәт сорады.

— Кая?.. Кичәге балкон каршысында романслар җырларгамы, ак чырайлы баһадир?

— Детсадка.

— Бүген үкме?

— Темп заманы!

— Бүген берәр яры барыйк. Эч поша... Бакчага иртәгә керерсең.

— Синдә нинди планнар бар?

— Спорт сараенда Югославия эстрадасы артистлары. Шуңа әләгәсе иде.

«Биш тәңкә!» дип уйлады Идрис. Теле:

— Табарсың көнендә билет,— диде.

— Үтәрбез.

— Басып торыргамы?

— Галиҗанап сәнгать алдында үрә катып торсаң да ярый,— диде Әхәт, астыртын гына көлемсерәп.— Син Чәймилова каршысында уклау йотып торганга охшыйсың.

— Нигә?

— Күзләреңне сүндереп чыгарган... Яратмыйм шундый күселәрне! Бердәнбер мактанычлары чал чәч... Акыл, тәҗрибә, дөньяны аңлау ике инфаркттан соң гына килә дип адым саен раслап йөрү...

— Синеңчә «Илла рәхәт булыр иде, үлеп бетсә карчыклармы?»

— Чәймилова туганда ук шундый булган.

— Алайса нигә үзгәрмәгән? — Алар тагын кызыша башладылар.—

Тәрбия кайда, җәмәгатьчелек нигә карамаган? Ахыр килеп яшәешнең объектив законнары аңа кагылмаганмы?..

— Ярар, бар алайса! — дип кул селкеде Әхәт.— Алдап китсәң, тереләй тотып ашармын.

— Ниса да шулай ди, тотып ашар ул сине, ди.

Әхәт шаркылдап урыныннан купты:

— Китче! Иң кирәген әйтми торасың, әкәми!

— Куанма шул хәтле.

— Җүләр... Димәк, ул минем тешләрдән курка... Ниса кебекләрне куркытырга, брат ты мой, шактый нәрсә кирәк... Утта батмас, суда янмас гайбәтченең теле... Шулай диме, ашар диме?.. Ха-ха-ха!.. Яшибез дөньяда, картлач!

## 9

Күз күнеккән Бауман урамы...

Аннары унда-сулда дамбалар. Казанка өстендә акчарлаклар оча. Сирәк күренәләр алар. Кеше күпкәдер, мөгаен. Кара инде, Казанка ярларындагы комда Кырым пляжындагы тыгызлык...

Кондукторлар да таныш.

Бу тукталышка күз ияләшеп беткән. Иртән дә, кичен дә Идрис аны үтеп китә. Игезәк урамнар, бертуган йортлар. Зур гына ишек алдында аңа кирәкле детсад, агач атлар, нәни корабль, бүген алары барысы да буш. Монсу. Йорт әйләнә сукмаклар, бала беләге юанлыгы гына ап-ак каеннар. Юка ябалдашлы юкәләр тернәкләнеп киләләр. Урамнан керүгә монда салкынча. Тып-тын.

Шәр ачык ишек төбендә ике буш мичкә. Чыпта каплар, измә тартмасы авылның иң ялкау киленчәгенең ипи күәсе кебек касмаклана-касмаклана каткан. Өч-дүрт буй идән тактасы кырыйда ауный.

Кая карама — тараулык...

Идрис ала-кола акшарланган стеналарны читли-читли эчкә үтте. Каерылып ташланган идән, сай гына базда гөберле бака сикерде... Идәнне, мөгаен, кысарга җыеналардыр... Акшары кубарылган стеналар... Җылыту батареялары да кузгатылган. Алар ял итәргә яткан арык атлар кебек почмакта өелешеп торалар. Кабырга араларында ак брезент бияләйләр кысылган.

Сулда «Мөдир» дигән язу кадакланган ишек. Ул бикле. Идрис өч-дүрт ишеккә тәртеп-тәртеп карады. Тузан исе бөркеп үтәли җил исте.

Бүлмәләрдә җан иясе юк иде.

Чыкканда ишек катында аны йөнтәс кашлы, тәбәнәк кенә карт каршы алды. Ул сораулы күзләре белән аннан туктарга үтенеп юлына аркылы төште.

— Тере кеше дә бар икән дөньяларда! Исәнмесез...

— Үзем дә мәгарәгә кергәндәй булам,— диде карт сәламне алып.— Сез яңа прорабмы дисәм?..

— Түгел, редакциядән мин.

— Алай икән, эшләр шуңа киттемени? — диде карт, күтәрелеп.— Яңа прораб килеп карар дигәннәр иде.

— Эшчеләр кайда?

— Эшчеләр? — Картның күзләрендә хәйләкәр очкыннар кабынды.— Эшчеләр юк. Килмәделәр.

— Нигә килмәгәннәр, белмисезме?

— Материал юк. Мәнә сүтеп ташладылар да җыя алмыйлар. Сүткәндә ата-аналар да булышты, җыярга материал кирәк.

— Ә сез кем буласыз?

— Мондагы патшалыкта иң олы кеше — каравылчы. Каршыда яшим. Әнә теге йортта... Минем балконда ул чәчәкләр! Шәп дими

кара! Карчыгым белән икәү генә дә, нишлисең, төнлә икебез бер бүлмәгә сыймыйбыз. Гырлыйсың ди явыз... Төнгә монда булам... Анда да арттан бастырып керә. «Гырлаганың өйгә ишетелә, борылып ят» дигән була... Көнләшә, явыз!.. Тикшереп йөри...

Калын гына тавышлы бу картның сафлыгы югалмаган күзләрендә акыл сирпелеп тора иде. Идриснең аннан болай коры гына аерыласы килмәде. Бу кешедән моңарчы үзе белмәгән, әмма бик кирәкле нәрсәне ишетер кебек тоелды. Сүз куешкандай икесе дә агачлыктагы эскәмиягә атладылар. Эскәмия тәбәнәк, утырып өчен җайсыз иде.

— Сез биредә күптән эшлисезме?

— Елдан артты. Пенсиядә мин. Элек мехкомбинатта идем.

— Мөдирне күрергә иде.

Мөдирне күрү зарур булмаса да, болай, сүз ялгар өчен генә әйтте Идрис.

Карт аптырап аңа карады:

— Мөдир гаепләме монда? Ул үзе кыл тозакка эләккән бичара песнәк сыман! Ата-аналар тетмәсен тетәләр, югарыдан кыздыралар... Ә сабыйларны дачага чыгармадылар, менә кайда ул кәҗәнең мөгезе!.. Тырыш хатын безнең мөдир, чиксез унган. Ләкин ни майтарсын?

— Фамилиясе ничек дисез?

— Гринберг, Фаина Наумовна.

— Бу бакчада балалар атна буе булалармыни?

Карт баягыдан да җанланыбрак китте:

— Төрле сорттан бар. Андыйлар да күп. Мин уралам инде алары белән... Кызык та, кызганыч та. Дүшәмбе көн китереп ташлыйлар да шимбәдә генә килеп алалар. Алмаган чаклары да җитәрлек. Якшәмбедә пешекче белән няня гына кала. Тәрбиячеләр ял итә. Балаларны мин карыйм... Карчыкның тынычлыгы бетә якшәмбедә!.. Пешекчедән көнләшә үләт... Бастырып артымнан кереп җитә.. Бер малайны өйгә алып чыга башлады, үзе карый.

Идриснең күңелендә усаллык кабынды: менә шундый ваемсыз ата-аналарны газетада тетәсе иде, ә бу — башланган да ташланган ремонт — бүген бар, иртәгә юк мәсьәлә.

Ул мөдирне күрергә булды.

— Гринберг иртән килә дисезме?

— Өтәләнеп килә.

— Телефон бармы сездә?

— Әй, ул нәмәрсәкәй нечкә сыйраклы кызлар белән тәтә-тәтә килергә генә ярый лабаса. Эш хәл итеп буламы аның аша? Известьны да, буяуны да чыбык аша тоттырмыйлар.

Картның сүзләре акыллы иде.

— Балаларны нигә дачага чыгармадылар, белмисезме?

— Анысы безгә мәгълүм түгел. Санэпидстанциядән бер хатын дулаган... Хатын-кызны беләсез бит, дуласа дулый. Сыер дуласа аттан яман!..

— Ни өчен каршы килгәнен белмисездер инде.

— Тигез җирдә түмгәк табып тибә торган быжгактыр бер...

— Ремонтны кем башлады?

— РСУ.

Таныш оешма, таныш хәлләр. Мең кат яздылар инде газеталар РСУны. Татарстан нефте газеталарда РСУ кадәр язылмый торгандыр. Шүрәле каргаган оешма!.. Авыз тәмен бетереп тикшереп маташасы юк, мөдире дә кирәкми, шалтыратып вак-төякләрне ачыкларга да үз балаларыннан ялыккан ата-аналарга шоп-шома гына хат язарга булыр... Эшне тикшерергә коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрерләр, ватсыннар әйдә баш!

Шулай уйлап Идрис урыныннан купкан иде, капка янына көл төсле такси килеп туктады. Аннан бер ир кеше төште. Туп-туры монда таба атлады, каравылчы белән таныш иде ул, ахрысы, баш кагып исәнләште, Идрискә дә сәлам бирде.

Кардай ак нейлон күлмәгенең җиңнәрен ыктымат итеп сызганган, таза беләкләре кап-кара йон белән капланган җитез хәрәкәтле, сыгылма атламлы бу кеше үтә шадра иде.

Яшь шадра кеше сәер хәзер.

Әллә бик үк яшь түгелме? Югары билле, кесәләре алга уелган соры ләвсан чалбары яшәртәме?.. Биек үкчәле, гаять очлы фырт туфлялары яшь кыяфәт бирәме? Күзләре дә үз итеп, ягымлы, дустанә карыйлар. Шадралыгы йөзен бозса да, бу ир чибәр, күркәм кеше. Өс-башы булсын, тотышта булсын, манераларда Идрис бу ирнең үзеннән өстенлеген сизде. Барган бер җирендә хуҗа булып, үз дәрәҗәсен саклап шушының сыман шифырт-мифырт кына йөри белми Идрис!

— Фаина Наумовна мондамы? — диде ир.

— Бер каравылчы да бик житкән.

— Тегеләр тагын килмәдеме, Мироныч?

— Күрәсең.

— Адәм актыклары! РСУга ике шалтыраттым, управляющийның үзе белән сөйләштек. Эшчеләр җибәрәбез дип ант эчтеләр.

— Кайчан икәнен әйтмәгәннәрдер? — Мироныч сукмакка чырт итеп төкерде.— Менә бу иптәш редакциядән килде.

Моңарчы ир Идрискә өстәннәнрәк карый иде, редакциядән дигәч, аның карашы жылынды, ул кулын сузып:

— Шәп. «Чаян»нан түгелме? — диде.

Аның «Чаян»ны гына санларга әзер икәнлеге сизелде.

— Түгел... Яшьләр газетасыннан.

— Ренат Кәримов булам мин... Казанның иң матур егете! Сезнең газетада мәкалә бастырганым да бар... «Белем» җәмгыятендә лектор мин. Язгыз әле шуларны, теләсәгез минем имза белән чыгарыгыз...

— Бу хәлләргә кем сәбәпче инде?

— Барысы да сәбәпче,— дип кычкырды Кәримов.— Эшчеләр ялкау, житәкчеләре булдыксыз. Житмәсә санэпидстанциядә шундый килбәтсез убыр утыра, гомергә бала күрмәгән кысыр хаста!

Тагын нидер әйтмәкче иде Кәримов, беләгендәге алтын сәгатенә күзе төшеп кинәт тыпырчынды, авызын зур ачып хихылдады, йөгереп барып такси ишегенә ябышты.

— Шалтыратырмын әле! Фамилиягез ничек?..

Ишек шапылдап ябылды, машина кузгалды.

Идрис каравылчыдан:

— Бу иптәшнең ремонтка ни катнашы бар? — дип сорады.

— Йөри шунда, баламут,— диде Мироныч, төкереп,— малае монда аның.

— Малае?

— Атналык группада. Тере малай, шук... Айдар исемле.

— Айдар?!

Идрис ирексездән капкага таба талпынды ул арада машинадан җилләр искән иде.

## 10

Ленин районына кайтканда ук таксидагы бензин исе күңелен болгаткан иде, бу юлы Ренат арткы урынга керде. Бая эссе көндә үз-үзен белештермичә алга, мотор янына утырган бит. Өр-яңа машинадан бензин исе аңкый, Ренат шоферның шактый уңган җәлпәк беретына, төк баскан яңакларына чыраен сытып карады.

Юлы унмады Ренатның, Мироныч янында уралган теге редакция корты аның планын сүтте... Детсадка ремонт эшләренең башланмавын, эшчеләрнең бүген анда булмауларын аңа РСУдан телефон аша ап-ачык әйттеләр. «Балалар дачада булырга тиеш, алар кайтуга ал да гөл итәрбез» диделәр. «Кулыгыздан килмәгәч, нигә чишендердегез?» дигән сорауга көлеп җавап бирделәр: «Анысы безнең хата, алны-артны уйлап бетермәгәнбез».

Бакча белешергә бармаган иде Ренат, чәнчелеп китсен, редакциягә дә ул язмады, юк-бар материал астында Кәримов фамилиясе чыкмый торсын... Бетмәгән әтрәк-әләмнәр...

Китүен ашыгыбрак китте, ахрысы, теге редакция кешесе кунарга калмас иде әле... Соңардың дип өйдә барыбер тавыш-гауга кубачак... Җиде язынкка бер җәза булыр иде... Алай да ярап булмый хатынга, болай да, тузынпачак Луиза!..

Хәер, хәзер ул ирекле баштан үзе көл төсле машинаны хәтәр җилләр, усал давыллар арасына куа. Беткән баш беткән...

Бүген алар беркая да бармаслар. Ренат Луизаны шуңа ризалаштырыр. Югославия эстрадасы артистлары ел саен киләләр, быел булмаса, яренгә барырлар.

Бүгенге концертка моннан ун көн элек билет алганда алар Айдар җәйге дачада булыр дип исәпләгәннәр иде. Барып чыкмады. Малайны кая куярга хәзер? Кем белән калдырырга? Күрше-күләнгә йөз суы түгүдән файда аз, Луиза тирә-күрше хатын-кызлары белән дипломатияне күптән өзгән. Бар өмет Мироныч иде. Барышлый Айдарны шуларга кертеп калдырырбыз дип уйлашканнар иде. Редакция кешесе алдында чишелеп китәргә базмады, базмады гына түгел, курыкты Ренат (дөнья ул!). Мироныч та әллә ничек читләтеп карады...

Арткы урында киерелеп барган Ренат шоферга бер генә сүз әйтте:

— Монда.

Шоферның сдача санаганын ул комсызланып күзәтте, бер тиен дә чәйлек бирмәде, хатын янда чакта акчаны унга-сулга чәчәргә яраткан Ренат ялгыз йөргәндә бер тиен өчен канга-кан килә иде.

Яртылаш киенгән-ясанган Луиза бизәкле эчке күлмәктән генә балконга чыгып аны көтеп тора иде. Ул чыелтырап чыккан тавышы белән:

— Нәкъ унҗиде минутка соңардың, җанкисәк,— диде.

Ренат күзен күтәреп аңа кул болгады да кабаланып подъезд ягына чыкты. Ишек алдындагы кара-каршы эскәмияләргә тезелешкән карчык-корчыклар ул күренүгә шым булдылар, биргән сәламен дә алмадылар, Ренат алар яныннан йөгереп узды. «Кайчан моннан күчәрбез дә шушы убырлар күз алдымнан югалырлар!»

Шап-шап өскә менә башлады, почта тартмасыннан атналык кинопрограмма белән «Модалар» журналын алды. Луиза ишекне ярым ачып аны сагалап тора иде. Ишек ярыгыннан аның тыгыз, мул күкрәкләре аллачып күренде.

— Син «алмаларыңны» бераз җыештыра төш,— диде Ренат, ишекне ябып. Луиза йомшак беләкләре белән аңа килеп сарылды, иркәләп суырып үпте.

— Барысын да мин үтенгәнчә эшләгәнсеңдер инде, җанкисәк?

Ренат аның хуш ис килеп торган яңагыннан сыйпады да бүлмәгә керде.

— Айдар кайда?

— Әллә хәзер үк илтмәкче буласыңмы? Мәшәкатьләнмә, барышлый кертеп чыгарбыз.

— Кайда соң ул?

— Син шуны әйт әле, җанкисәк... Анда тагын сугыш башлаганнармы? Радиодан колагыма чалынып калды. Гарәпләр сугыша диме... Вьетнам турында сөйләп колакны тондырганнар иде, хәзер тагын...

— Әй, аларның сугышларын әйт... Гарәпләр сугышсыз торамы? Бик каты бәрелешләр булды дип язалар да сводка теркиләр: ике кеше үлде, өч кеше яраланды...

— Алай булса ярый. Сугышлар күбәйсә чит илләргә туристларны чыгармаслар дим...

— Айдарны берәр яры җибәрмәгәнсеңдер ич?

Хатын, «үлеп баручы аккош кебек» канатын җилпеп, караңгы бүлмәгә ишарәләде.

— Карцерда.

— Ул хөрмәтне ни хезмәте өчен алды инде?

Луиза күзләрен дәү ачып, кашларын бер төшереп, бер меңгереп, бар эшен куеп сөйләргә кереште:

— Безнең начальникны беләсең бит, кот очарлык коры бәндә!.. Бүген көч-хәл белән иртәрәк җибәрде... «Луиза Шәмсиевна, җәй житте исә сезне эштә тотар хәл юк» ди... Кайткач кафега ашарга барырга җыендым... Малайны да алыйм дим... Чакырам — юк. Эзлим — юк. Бөтен ишек алдын карап бетердем. Җитмәсә, ишек төбен дә теге җен карчыклары сарган. Әй, әллә ниләр сөйләшкән булалар... Ренатик, кайчан моннан китеп үз ишләребез арасыннан квартира алабыз инде?

Ренат түземсез генә аны бүлдерде:

— Айдар турында сөйли башлаган идең...

— Шуны эзләп аш вакытым узды инде,— диде Луиза, иреннәрен матур турсайтып.— Барсам, кафены төшлеккә япканнар. Әй ачуым килде, өйгә кайтып киләм, карасам, теге шакшы чокырлар ягыннан ул йөгерә.

Ренат караңгы бүлмә ишегенә терәткән урындыкны сабыр гына бер якка алып куйды.

— Нишләгән ул анда?

— Сорадым, әйтми. Бүре баласы кебек тик карап тора.

Ренат кардай ак күлмәген салып пөхтәләп кенә элде.

— Бөркү... Душта коенмыйча ярамас. Култык асларым су гына.

Туалетка керер алдыннан ул ясалма җитдиләнеп караңгы бүлмә ишеген ачты:

— Чык.

Малай аякларын бөкләп буш посылка тартмалары өстенә менеп утырган, җыламый да, эндәшми дә, караңгыда күзләре генә елтырый иде.

— Чыкмыйм.

— Чык диләр сиңа, кире.

— Сез концертка киткәч чыгам.

— Без китмәсәк төнне шунда кунарсыңмы? — Ренатның тавышы чак кына йомшарды.— Чык, Айдар.

Малай теләр-теләмәс кенә чыкты, ике куллап ишек тоткасына ябышып асылынды.

— Уйнама ишек белән.

Ренат аның башыннан сыйпамакчы иде, малай читкә тартылды. Авызына аллы-гөлле япон шпилькалары капкан, чәчләрен күперткән Луиза көзге каршысында боргалана иде.

— Айдар,— диде ул.— Сине Миронычлар кунакка чакырган. Барасыңмы?

— Юк. Мин Миронычларга бармыйм.

— Тагын нәрсә?.. Синнән сорап торганнар иде ди...

— Варвара түти каеш белән яра.

— Кемне?

— Миронычка да эләгә, миңа да.

— Ай аллам, сүз тыңламыйсыңдыр. Кире малайларны каеш белән генә түгел, сыек чыбык белән пешерәләр.

— Ярар,— диде Ренат, арага кереп.— Мироныч алып кала алмыйм, диде. Кунаклар көтә. Мәскәүдән әллә кемнәре кайткан икән.

Луиза ышанмадымы, төшенмәдеме, авызындагы шпилькаларын тырпайтып чәтердәп кычкыра башлады:

— Без житешкәч шулай булмыймы соң? Бөтен шәһәр караган, без генә дөмегеп ятабыз... Төшке ашта пляжга барган идем, торган бер кешенең авызында шул... Мин торам кагаеп... Кешеләр чит илгә чыгалар, Европа тирәли сәяхәттә йөриләр... Без үзебезгә килгән концертны да карый алмыйбыз.

Ренат менә шушы сүз һөҗүменнән курка иде, шулай да ул ирлеген саклап хатынының ташкынын буды:

— Безнең балабыз бар.

Луизаның турсайган иреннәре бәлшәйде, шпилькалары елка уенчыклары кебек ялтырап идәнгә чәчелделәр, ул аяклары белән шабырдатып аларны чәчеп җибәрде.

— Баламы? Богау, зынҗыр диген!

Айдар башын кыйгайтып, күзләрен челт-челт йомып аларның әле берсенә, әле икенчесенә карый иде.

— Сез барыгыз, бар,— диде ул кинәт.

— Син җәфаны кайда калдырырбыз?

— Берүзем ятам да йоклыйм.

Луиза өметләнеп Ренатка карады.

— Нәрсә? Олы малай ич Айдар... Аның яшендәге малайлар фашистларга каршы сугышып йөргәннәр.

Ниһаять, бер тапкыр булса да Ренат кызды:

— Синең мисалың белән килешсәм, концерттан кайтканда такси табалмагач, «синең яшендәгеләр президент, академик булып беттеләр!» дип әйтәчәксең бит.

Луизаның җылагы бетте, ул кулларын җәеп Ренатка ташланды, көлә-көлә аны ут атып тора торган күкрәкләренә кысты.

— Кичә чыгып киттегез бит,— диде Айдар.

— Ах, оятсыз,— диде Луиза, иренең кочагыннан ычкынып.— Тыңланып ята икән. Шпион!

— Мин шпион түгел, диде Айдар. Аның күз керфекләре чыландылар, менә тамам, менә тамам дип торган яшьләрен ул тузанлы йодрыгы белән сыпырды.— Мин шпион түгел!

— Әйтәм ич, йокламый, юри алдалап ята дидем...

— Кайтуыгызны да ишеттем,— диде малай, үҗәтләнеп.— Әни әйтте: «Гулянын авызы кыек, ә син ана карап елмаясың», диде.

Ренат малайны төрткәләп балконга алып чыкты:

— Артыгын беләсең икән, җиллән азрак! Йокламый ята икән тагын!

— Мин... курыктым...

Ул атасының сыйпарга үрелгән кулыннан тагын тайчанды, читкә карады.

— Торып тор шушында...

Балкон ишеген япкач, Ренат форточканы да тартып куйды. Луиза инде күңелле генә мырлый-мырлый сөрмә тартып маташа иде.

Ул хатынын арт яктан килеп кочты:

— Шулай да мина оят,— диде.

— Кем өчен яшисең син? — диде Луиза, Ренатның йөзен көзгедән эзләп табып.— Шул нәләт суккан гайбәтче күршеләр хакынамы, әллә үз көнең көнме?

— Бала бит, сабый... Синең белән минем ул яшьтә булып караганыбыз юкмы? Без дә фашистларга каршы сугышып йөрмәдек.

— Һәм яхшы иттек.

— Төне буе куркып ятса?

— Ә хатын? Шушы бер бүлмәдә, шәһәр читендә хатынны йозакта тоту оят түгелме?.. Өйләнгәндә син башкачарак идең, Ренат. Өрмәгән җиргә дә утыртмам диден.

— Урыныц шәп анысы,— дип көлде Ренат һәм учы белән хатынының артына сукты.— Бала табып ялгыштың.

Луиза ашыгып-ашыгып сөрмәсен мамык белән сөртә башлады:

— Ялгыштырдың... Бала дигәндә үзең гаепле. Хатын-кыз биология законнары белән исәпләшергә тиешле дип кем үгетләде. Бәбине әни карар диден.

— Әни белән шулай тиз ызгышырсыз дип кем уйлаган?

— Кем аңа шулай тиз чирләргә кушкан?..

Айдар тугач та алар тиз-тиз авылдан Ренатның әнисен алып килгәннәр иде. Җиде бала үстереп шуларның бишесен сугышта югалткан ана төпчеге Ренат янына коштай очып килгән иде... Әмма картлык чире бик тиз аяктан екты. Ул чирләп егылуга, Луиза аны чоланга күчерде. Мескен ананың пешереп ашарга хәле юк, күршеләре кергәч: «Ашап чыгып китсәләр, шулпалары калмадымы икән дип кухняга чыккалыйм, калдырмыйлар шул», дип зарлана икән... Күршеләре хәбәр иткәч, карчыкны колхоздан тулы бер делегация килеп, бер көн тотмый алып кайтып киттеләр... Ренатларның мажаралары чак кына халыкка фаш булмады. (Шул чагында газетачылардан сагаеп калды да Ренат!)

Хәзер дә аның күңеле нигәдер шомланып, күңелсезләнеп торды. Ләкин ул күптәннән инде Луизага үзенең ни уйлавын, чын настроениесен әйтми, чөнки ачыктан-ачык сөйләшүләр байтактан чатнаган гаиләгә татулык урынына кискенләштерү генә алып килә иде. Шуңа күрә ул бүген дә уйлаганын ачып бетермәде, тынды, хатынының Мәскәүдәге «Лейпциг» кибетеннән махсус кайтартылган бизәнү әйберләре белән каш-күзен үзгәртүен күзәтте. Аның күндәм генә дәшми торуына Луиза бик канәгать иде. Бераздан Ренат Айдарны исенә төшерде, балконга чыкты һәм шыпырт кына:

— Луиза, Луиза! — дип кычкырды.

Малай балконда юк иде.

Әнә буш чиләк ята, әнә аягы сынган ат ауный, Айдар бер җирдә дә юк. Тәне эсселе-суыклы булып китте. Ренат коты чыгып аска карады, асфальтта да буш шырпы каплары гына ауный.

— Луиза!

Тимер рәшәткәгә бәйләнгән бау асылынып тора. Луизаның гамагыннан киселгән бау, таный аны Ренат.

Хатын көттереп кенә балконга чыкты:

— Ник кычкырасың, җанкисәк?

— Айдар качкан!

Ренат Луизага бауны күрсәтте. Хатын фырт кына артын борып кереп китте, кулындагы әйберләрен идәнгә атты, креслога егылып улап җыларга тотынды.

— Учлап-учлап каныма тоз саласыз!

(Бу сүзне әйткәне юк иде Луизаның, әнкәсе репертуарыннан сакладымы икән?)

— Җитәр, Луиза!..

Хатынның күзеннән чәчрәгән очкыннар күз төбенә җыелган яшь тамчыларын салават күпере төсле җемелдәтәләр иде:

— Бу өйдә рәт бетте! Икегезне дә ташлап китәм. Сиңа хатын түгел, хезмәтче кирәк, шадра феодал! Ал әнә урамда киез итек киеп асфальт җәюче берәр йолкышны... Синең сасы авызлы анаңа шундый килен генә төс!.. Бала да табар, ыштаныңны да юар... Син ата була белмәгәнгә малаең хулиган!

Бу инде тырнакларын ышереп өстәл янында мырлап йөргән Луиза түгел, гаилә дип атала торган сугыш кырында әле мондый канонаданың ишетелгәне юк иде. Ренат та кызды һәм хатынын әрләп ташлады:

— Баласы югалганда үзе турында уйлаган ананың кем икәнлеген аңлыйсыңмы?

Аннары чабып урамга чыкты.

Кая олагыр бу бишкисәр? Ну тотса, ну тотса... Луиза сүзендә дә дөреслек бар: карангыда биклән кенә яткырырлык аны!..

Майкачан йөгереп йөрү яхшы түгел, әнә ач ишек төбендә гайбәт саклаган чүп каргалары ничек акаештылар. Айдарның качканын да күргәннәрдер әле?!.

Ул өйгә кереп җәһәт кенә өс-башын алыштырды. Аягында кыска кунычлы кедалар, өстендә рижский кара спорт костюмы. Корсакны бөлдерә дип байтактан бу киемне кигәне юк иде... Луиза креслода авызын бәлшәйтеп утырып калды.

Ну тотса, ну тотса...

Бала-чага йорт тирәләрендә кайнаша. Ренат текәлеп карап балаларны араласа да, Айдар анда күренмәде. Күрше ишек алдында гөрләп футбол тибәләр, ул шунда ашыкты. Кытай стенасы булып эленгән аклы-зәңгәрле керләр арасыннан башын тыгып уенчыларны карады. Юк. Ренат үз подъездларындагы малайларны бик чамалы гына төсмерли. Шулай да берсен таныды:

— Безнең Айдар күренмәдеме? — дип сорады.

— Юк,— диде малай, туп-туры карап.

Малайларның икенчесе, олимпийский картуз кигән олырагы:

— Болын ягына сыпырткандыр, шуннан эзләгез,— дип киңәш бирде.

Каһәр төшкән урын! Шәһәр читендәге шул бушлыкка кыш буе машина-машина кар ташыдылар. Бөтен шәһәрнең чүп-чарын шунда өйделәр. Ни карап шул шакшы малай анда урала диген. Башкалар рәтендә ишек алдында туп типсә...

Кара халык — кара сарык нәселеннән дип табаларга тагын Луизага җай...

(Футбол типкәндә Луизаның «Аяк киеме төткәзер хәл юк, яңадан туп тирәсендә күзем күрмәсен!» дип дөбердәтеп алып кайтканын Ренат онытып та өлгергән!»)

Ул йортларны узып такыр кырга чыкты. Үзәнгә житте. Монда иске генә сарай бар икән. Аның ачык ишеге янында җыелма урындыкта бер карт сөякләрен кояшта җылытып утыра иде.

— Әй, картлач! — дип эндәште ул.— Бу тирәдә берәр малай күренмәдеме?

— Монда малайлар житәрлек,— диде карт, йомык күз кабакларын чак кыймылдатып.— Кәҗәләр дә бар.

Үзәннең ары башында бәйдә ике-өч шалама кәҗә үлән чемчеп йөриләр икән, бу карт шуларның көтүчесеме әллә?

— Син монда еш ураласыңмы?

— Булгалыйм.

— Айдар исемле малай. Алты яшендә.

Карт күзләрен ныгытып ачты, кесәсеннән челем чыгарды, тәмәке төйде.

— Сез аның әтисеме?

— Әйе. Беләсеңме син аны?

Карт урыныннан торды, аяк протезы шыгырдап куйды, ул авыр гына атлап сарайга керде, аннан челемен кабызып чыкты.

— Күренмәде.

«Карт күсәк!» дип сүгенде эченнән Ренат, «буш сүз өчен күпме вакытны алды!»

Айдарны никадәрле озак эзләсә, Луизаның давылы шул хәтле озаккарак тартылачак. Игә китереп булмас кеше белән ямьле җәйдә атналар буе ызгышып ятарсыңмыни?!

Элек ичмасам шәп булган, унар бүлмәле квартираларда торганнар, бик сагынганда гына хатыныңның бүлмәсенең ишеген шакыгансың. Хәзер бит дәрәҗәңә, тормыш таләпләренә карап түгел, эте-бете күрше булып яшәп ята... Ә квартиралар... Атлаган саен хатыныңның маңгаена бәреләсең. Сагынырлык вакыт табылмый!

Кая олагыр бу бала?

Ренат бу тормышта хәзер барыннан да бигрәк яшь хатынның зәһәр тавышыннан курка. Миналар сызгырган кебек, радиодан «Һава тревогасы игълан ителә!» дигән сыман ишетелә Луизаның тавышы...

Өйләнгәч алар ару гына тордылар. Шушы җен ташы Айдар туып аның ирлегенә, ирегенә, горурлыгына ясин укыды. Элек җәмгыять, тормыш турында сөйләгәндә ул ясләләр, детсадлар, интернатлар, пионер лагерьлары бар, алар барысы да хезмәт ияләренең карамагында дип бик күпләрне юата ала иде. Башмак кысканда дөньяның киңлегеннән ни файда? Тиле исәр сыман шалама кәҗәләр, тузанлы әрекмәннәр арасында малаеңны эзләп тыр-тыр теркелдә, имеш!

Ну тапса, ну тапса!

Менә агачлар... Тал-туйралар... Ямь-яшел чирәмнәргә сукмаклар төшкән. Хәйран матур урыннар икән... Монда ук килмәс: куркыр, алты яшьлек сабый бит... Ул бугазын киереп:

— Айдар, Айдар! — дип кычкырды.

Әрәмә арасыннан йөгерә-тулгана шактый баргач, ул көтмәгәндә генә үз улының тавышын ишетте. Ишетте дә каккан казык кебек катып калды. Кыдрач, капризлы улының шулай тәмле итеп, иркәләп сөйләгәнен бер тапкыр да ишеткәне юк иде әтисенең. Кем белән шулай тәмле телләнә икән бу ачкүз!

— Шулай, шулай... Атла, караборын... Кыймылдарга кирәк сиңа. Йөргергә... Үсәсең, үсәсең!.. Әнкәгезгә ипи, сезгә сөт.... Ит юк бүген, тәтемәде... Бүген мине кафега алып бармадылар... Шешә тапшырырга киткән идем... Аның каравы бер кәгазь тартма сөт бар, тәмлеме?.. Әйдә, бәләкәч, атла, әйдә!.. Убырлы карчыклар, хулиган картлар сезне күрмәсеннәр!

— Айдар!

Атау булып куерып, бергә чорналып үскән тал куакларын аралап Ренат эчкә керде. Эт ырылдады. Бәләкәй генә аланчык уртасында аның улы утыра. Ике нәни көчекне күкрәгенә кыскан Айдар, куркуыннан телсез калып, әтисенә карап катты. Малай артында көчекләрнең әниләре — эче суырылып кергән ябык кына карт эт басып тора иде. Ренат шикләнеп битен куе яфраклы ботак белән каплады. Эт бер-ике талпынды да янтаеп егылды, аның арт аяклары имгәнгән, эт арт санын сөйрәп чак-чак кына хәрәкәтләнә икән. Балалары янына килгән рәхимсез кузле, ят ис килеп торган олы кешегә ул тешен ыржайтып тагын бер ырлады, гаярьләнеп тагын дүрт аякланды, күзләрен мөлдерәтеп Айдарга карады да тагын ауды. Айдар көчекләрне чирәмгә куеп этнең сирәгәйгән сырт йоннарын сыйпады. Эт озын, кызыл теле белән малайның алсу яңагын ялады. Көчекләр малай алдыннан төшкәч, аның тез арасында әүмәкләшә башладылар.

— Син нишлисең монда? — диде Ренат, исен җыеп.

— Уйныйм...

— Ташла шул шакшыларны!

Ренат ун бармагын да тырпайтып көчекләргә үрелә башлаган иде, эт ыржаеп тагын ыргылды, Айдар үрсәләнеп кычкырды:

— Әти, тимә!

Ярсыган ата ачуын эттэн, көчеклэрдэн алмак булып тибеп жибэрде, Айдар көчеклэрне каплап жиргэ ташланды, очлы ботинка дөп итеп аның янтыгына килеп бэрелде. Ул тыны бетеп ухылдады, шулай да көчеклэрне кочагыннан ычкындырмады:

— Тимэ, эти!

Ренат, торырга маташкан этка яман карап «Пшел!» дип жикеренде дэ кулыннан йолкып малайны торгызды, сөйри-сөйри агачлыктан алып чыкты. Айдар куш аяклап жиргэ терэлэ, этисенен кулларын тырный, тешли, үксеп-үксеп жылый иде. Агач арасында чыбык-чабыклардан, кабык, калай кисэклэреннэн этмэлэгэн эт оясы күренеп калды. Аларның каршысына авыр атлап, уфылдап баягы шөкэтсез карт килэ иде.

— Нигэ тиясез аңа? Нигэ баланы рэнжетэсез? — дип кычкырды ул.

Ренат тегеңэ бер генэ кычкырды:

— Ә синең ни катышың бар, чабата!..

Айдарны шартлатып биклэделэр...

Балкон ишеге дэ бикле...

Ул тышкы ишекнең салкын тактасына битен куеп торды-торды да, коридордагы аяк тавышлары тынгач, идэнгэ чүкте, мыштым гына жылап жибэрде...

*Дэвамы килэсе санда*

# ...КЕШЕЛӘР КИЛӘ ШАГЫЙРЬГӘ

*Мостай Кәримгә 50 яшь тулу уңае белән*

Әле монсу, әле борчулы, әле иркәли, әле шелтәли торган тавыш, әмма бер вакытта да дөнья ыгы-зыгысына битараф булмаган һәм кешеләргә дә тынычланырга, битараф калырга юл куймаучы ул ниткән тавыш, кем тавышы, кайдан килә торган өн дисезме?

Ул — шагыйрь Мостай Кәрим тавышы, гражданин һәм яралы солдат тавышы. Язылып торган төп урыны Өфе каласы булган һәм «Башкорт халык шагыйре» дигән дәрәҗәле исемне алган Мостай өчен, әйтергә мөмкин, сугышның да, яшьлекнең дә һәм яшьлек белән бәйләнешле барлык изге сыйфатларның — сөю-сәгадәтнең, дөньяны балаларча эчкерсез яратуның һәм, вакыты белән үзеннән-үзе оялып, чак кына тотлыгып калуның — берсенең дә, берсенең дә чиге булганы юк. Ул дөньяны тагын да матуррак итеп күрү өчен һаман сугыш кырында кала, шул ук вакытта, ярасы сызлаудан туктаып торган араларда, үзе алган калалардан бик үк канәгать тә булмагандай, һәрхәлдә, үзе алардан өстенрәк торып, үзеннән-үзе шаян гына көлеп куярга да көч вә куәт таба:

> **Сабантуйдан җаяу кайтып киләм...**
> **Көн эссесе инде басылган.**
> **Бөтен нәрсәм төгәл, тик нишләптер**
> **Кәпәч төшеп калган башымнан.**


Әнә шул кешегә, Агыйдел ярындагы моңлы сандугачка, күнел яраларын курыкмыйча әйтә белүче, ә күбесенчә аларны бер якка куеп, тешен кысып, тагын һәм тагын сугыш кырына ташланучы тәвәккәл солдатка, шагыйрь Мостай Кәримгә 50 яшь тулган, имеш. Ышанасы килми, шаярта гынадыр.

Ышанасы килми, шул ук вакытта, нәкъ шушы факт белән бәйләнештә, мин шагыйрьләр язмышы турында уйланам. Катлаулы язмыш кичерәләр алар, шагыйрьләр.

Аларның беришесен дус-ишләре, поэзия цехының бармак белән генә санарлык бәндәләре — бары тик шулар гына кабул итә, шулар гына кул өзгәндә чөеп йөртә. Кин халык язмышы, дөнья язмышы аларның жилкәсе артында кала.

Шагыйрьләрнең тагын икенчеләре бар: аларын, шул эшнең әһелләре белән берлектә, үз халкы таный, үз халкы хөрмәтли. Бәхетле язмышлылар болар. Мостай Кәримне без әнә шул бәхетлеләр арасында күрәбез.

Мондыйлардан башка тагын, дөресрәге, шулардан үсеп чыга торган өченчеләре — бик бәхетлеләр бар. Аларны, үз халыклары, шул эшнең үз осталары белән бергә үк, башка халыклар да үз баласы, үз жырчысы итеп, кочак җәеп каршы ала. Мостай Кәрим үзенең зур таланты белән әнә шул бик бәхетлеләр арасына да үтеп кергән шагыйрь. Мәшәкатьләр һәм сугышлар белән тулган безнең бу дөньябызда аның тавышы еракларга, бик еракларга яңгырап өлгерде инде.



Шагыйрь, драматург, ялкынлы публицист, актив җәмәгать эшлеклесе Мостай Кәрим турында күп кенә матур һәм гадел сүзләр әйтелде, киләчәктә әле тагын да әйтелер. Аның күпкырлы эшчәнлегенең һәрберсе үзенчә ялтырый торган һәр кыры турында аерым-аерым монография язсаң да хәләл булачак. Бу безнең кочак җитмәстәй Мостайны кочарга азаплануыбыз түгел, бу — бары тик талантлы коллегабызның, дустыбызның, юк-юкта безнең янга, әле кәпәчен югалтып, әле безнең арада юри югалтыр өчен килеп чыга торган кадерле кунагыбызның 50 еллык бәйрәме унае белән урынлы әйтелгән бер сүз генә.

Аннары тагы, форсаттан файдаланып, журналыбызның бу санында бирелә торган яңа шигырьләренә бер соклану. Әле юл арасында ялтырап китә торган шуклык — нәкъ Мостай шуклыгы, әле дөньяның катлаулылыгы турында тынып уйланып калулар, әле, гомернең үтә барганын сизеп, чын шагыйрьләрчә моңлану — сокланыр бизәкләр күп бу шигырьләрдә.

Илле яшь! Ләкин чын шагыйрьгә картаю юк. Тын күл буенда ялгы туктап, башкаларны уздырып җибәрү юк. Шагыйрь һәр даим кешеләр белән, кешеләр хәсрәте — аның хәсрәте, кешеләр шатлыгы — аның шатлыгы:

...Кешеләр килә шагыйрьгә
Мәшәкать, хәстәр белән,
Керфекләре очындагы
Тулышкан яшьләр белән...

Калдырып китәләр ана
Борчылу, әрнү, яра...
Шуна аның карашында
Моңсулык арта бара...

Шул ук вакытта дөнья — дөнья булып кала. Әрнү, яралар белән беррәттән, аның шатлыклары да, шуклыклары да, мәзәкләре дә бетәсе түгел һәм бу соңгылары шагыйрьне күзләрен икенче төрле ачып җибәрергә мәҗбүр итәләр.

Бер кич шагыйрь күзләреннән
Бөркелеп нурлар акты,
Гүя чулпан алдан калкып,
Чылтырап таңнар атты.

Шагыйрь өендә шундый бер
Тамаша булган икән:
Таянып килгән таягын
Бер карт онытып киткән...

Нигә соң ул тамаша шагыйрь өендә генә булырга тиеш тә, нигә бездә, гади кешеләр өендә булмаска тиеш икән? Өметсез шайтан, диләр. Юк, без өметне өзмибез әле. Киләчәктә Мостайның яңадан-яңа нәфис шигырьләрен уку, көчле сәхнә әсәрләрен күрү белән бергә,— белмәссең дөнья хәлләрен — бәлки, шагыйрьнең сабан туеннан кайтышлый, сәрхүш баштан төшереп калдырган кәпәчен дә табып куярбыз. Югалтырга ярыймы соң шундый талантлы башта йөргән кәпәчне!

Фатих ХӨСНИ

## Мостай Кәрим

# Сабантуйдан кайтып киләм

Сабантуйдан җәяү кайтып киләм...
Көн эссесе инде басылган.
Бөтен нәрсәм төгәл, тик нишләптер
Кәпәч төшеп калган башымнан.

Кәпәч нәрсә! Баш кына сау булсын.
(Җирдә тулып ята бәрәкәт).
И-һи! Күпме мәрәкәләр күрдем
Һәм үзем дә булдым мәрәкә.

Үрмәләгән булдым баганага...
Дәрман әйтте дәрткә: «Куй, энем!..»
«Барыняга» көчләп биеттеләр,
«Чабатага» үзем биедем.

Көч сынашты алыш мәйданында
Чаярагы исә ир-атның,
Мин — беркатлы, кеше көлдерәм дип,
Күзне бәйләп, чүлмәк кыйраттым.

Көн эчендә байтак гыйбрәт күрдем,
Һәркем тыңдәш үзе тиненә.
Тегеләр бал эчеп акыл туплый,
Болар әйран эчеп тилерә.

Сабантуйдан җәяү кайтып киләм.
Каршы очраганнар туктыйлар:
— Үткән бәйрәм белән!
— Узган белән!!! —
Кул кысалар —
Ягъни котлыйлар.

Яше-карты, зирәк-юләр заты
Бары да хуплый ихлас үй белән:
— Гөрләп үткән ямьле бәйрәм белән!
— Шаулап узган сабантуй белән!!!

Куегызчы... Әдәпкә көч килер.
Сыйпамагыз ялбыр ак баштан,
Юатмагыз узган рәхәт, бәхет,
Узган гомер белән, якташлар.

Кызыкмыек баткан кояшка без,
Мавыкмыек үткән эш белән,
Котлашыек киткән бәла белән,
Беткән чирләр, кипкән яшь белән.

Кайтып киләм. Башта кәпәчем юк.
Баш сау булса, кәпәч табылыр...
Аргымакка менеп, сабантуйга
Мин барырмын әле тагын бер!

## Әйләнә карусель...

Әйләнә карусель, әйләнә,
Карусель корылган хәйләгә.

Очканы, чапканы, йөзгәне
Һәм җирдә сөйрәлеп йөргәне —

Һәммәсе бер тигез җилдерә,
Җил үзе аларга юл бирә.

Беркатлы кешеләр шак ката:
— Боланнан калышмый ташбака!

— Куянны күрергә килегез:
Гәүдәгә фил белән бер тигез...

Әйләнә карусель, әйләнә,
Карусель корылган хәйләгә.

Ир бала атланган толпарга,
Кыз бала утырган шоңкарга.

Толпарын малай әй камчылай,
Камчылай... Шиге юк тамчыдай —

Җилдереп җитәчәк дусына,
Менә ул дусына кул сона.

Кыз бала әйләнеп артына,
(Ул бәхет талында талпына)
Елмаеп малайга тартыла.

Күзгә-күз, кулга-кул үрелә —
Үрелә ике гөл бөредә.

Бер адым ни бары аралар...
Тик шунда бер адым ара бар:

Бер адым арада — дәрьялар,
Күкләргә кадалган кыялар,

Кояштан җиргәчә юл ята,
«Мәңгелек» исемле ел ята,—

Әгәр син атлансаң толпарга,
Әгәр ул утырса шоңкарга.

Чөнки бит карусель әйләнә,
Карусель корылган хәйләгә...

Туктады карусель. Менә җир.
Әй, малай, кызыңа кулың бир!

Җибәрмә учларын учыңнан,
Адым да аерылма дусыңнан —

Чөнки бит җир шары әйләнә,
Җир шары корылган хәйләгә...

●

Ярсу Танып буйларында
Алсу таңнар яна иде,
Тирәктәге бер сандугач
Йөрәкләрне яра иде,
Сөюеннән, сагышыннан
Үзе дөрләп яна иде.

Әйт, кошчыгым, ярың кайда?
Табышырмын. Мин бит көчле —
Мин бит кеше. Үзем гашыйк,
Үзем янам, синең төсле.

Ике куллап ертыр идем
Зәңгәр ефәк пәрдәләрен,
Әгәр шунда күрер булсаң
Сөйгәнеңнең гәүдәләрен.

Башым белән ярыр идем
Күкнең алтын гөмбәзләрен,
Аръягында табар булсаң
Сөйгәнеңнең тик күзләрен.

Йөрәгемне атырмын да
Яндырырмын дингезләрен,
Төпләрендә калган булса
Сөйгәнеңнең тик эзләре.

Әйт, кошчыгым, ярың кайда?
Табышырмын. Мин бит көчле —
Мин бит кеше. Үзем гашыйк,
Үзем исәр, синең төсле.

## Шагыйрь шатлыгы

Шатлык сөйләргә шагыйрьгә
Килерме кем дә бирәү?
Шатлык канатлы заттан ул —
Кирәкми аңа терәү.

Кешеләр килә шагыйрьгә
Мәшәкать, хәстәр белән,
Керфекләре очындагы
Тулышкан яшьләр белән.

Бар галәмне юатырга
Шагыйрь дә алла түгел,
Телгәләп үк бирер иде —
Йөрәге алма түгел.

Калдырып китәләр аңа
Борчылу, әрнү, яра...
Шуңа аның карашында
Моңсулык арта бара.

Бер кич шагыйрь күзләреннән
Бөркелеп нурлар акты,

Гүя чулпан алдан калкып,
Чылтырап таңнар атты.

Шагыйрь өендә шундый бер
Тамаша булган икән:
Таянып килгән таягын
Бер карт онытып киткән.

●

Дау күтәрә җаным, кырау сугып,
Үлән кыяклары каралса,
Үкси җаным, атылып сүнгән йолдыз
Кабер туфрагына кадалса.
Шәфкать кайда? Шундый бәрәкәтсез
Табигатьнең барлык иккәне.
Килгән нигә китәр өчен килә,
Нигә кире кайтмый киткәне?
Дау күтәрә җаным... Нигә фани
Бу җиһанның барлык иккәне?

Гакылым тыныч. Бөтен нәрсә ачык —
Һич урын юк фараз итәргә.
Дөнья фани. Киткән кире кайтмый.
Ә килгәннәр килә китәргә.
Гакылым аяз. Хөкем күптән чыккан.
Соң инде, соң дәгъва итәргә.

●

*Хәсән Туфанга*

Сандугачка нигә буй-сын,
Нәрсәгә аңа бизәк?
Таңда бер сайрап җибәрсә,
Биш кат өзелә үзәк.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә аңа титул?
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул.

●

Котчыккыч төш күрдем бер төндә:
Бар йөк төшкән, имеш, өстемнән.

Бөтен дөньям тәмам көйләнгән,
Барлык бурычларым түләнгән,

Биргән вәгъдәләрем үтәлгән,
Данны өзеп алам түтәлдән,

Дус мактамый, дошман үчләшми,
Төшергәндә һич кем эндәшми.

Якынайган бөтен аралар,
Төзәлгәннәр бөтен яралар,

Кылыр изгелекләр кылынган,
Гөнаһларым барысы йолынган...

...Өн ишетәм: «Эшең беткәнме?
Беткән булса, күтәр үкчәне!»

## Галимҗан Латыйп

# КЫЗЫЛ ЯР

ПОЭМА[1]

Җәй ае. Ачык тәрәзә.
Ак челтәр пәрдәләре.
Сәхнәгә чыга осталар,
Алкышлар — әледән-әле.

Тракторист җырлый «Уел»ны,
Кранчы гармонь суза.
Агроном кызый биюдән
Өченче турга уза.

Зал көтә, тагын чакыра,
Үзенә ошаганны.
Чыга скрипкачы кыз,
Сихерли бөтен залны.

Уйный ул, оеп уйный ул,
Талпынып, очып уйный.
Күңелләр мондый вакытта
Әллә нәрсәләр уйлый.

Моң белән тула тирә-як,
Сандугач, кошлар җыры...
Кавалерия маршы...
Ишеттем кайда моны?!

Тып-тыныч, тыңлый бөтен зал
Берьюлы сихерләнеп,
Ишетелә колак төбендә
Тояклар сикергәне...

Алкышлар куба гөр килеп,
Дерелди пыялалар.
Җыр тыңлый күкләр,
йолдызлар,
Тын күлләр ояналар...

Зал тагын, тагын чакыра
Унсигез яшьлек кызны.
Ул чыгып башын иде дә
Гаҗәеп моңнар сызды.

Гап-гади татар кызында
Мондый көч каян икән?
Елмайса заллар яктыра,
Һәм бераз шаян икән.

Туктале, мин бит бу кызны
Кайдадыр күргән идем.
Кашлары кыйгач, күзләре
Кара карлыган инде

Толымнар... Әйе, толымнар,
Нәкъ Зөһрә толымнары.
Юллары җиңел түгелләр,
Юллары борылмалы!..

1

Уяна авыл таң белән,
Күзләргә йокы керми.
Ә кояш чыга да бата,
Әйтерсең, берни белми.

Кич ятса, иртә торса да
Авылның кайгысы бер:
Сугышлар кайчан тынар да,
Ил кайчан соң рәтләнер?

Әнә бит тагын хәбәр бар,
Корбан артыннан корбан.
Әхтәмнең бердәнбер улы
Вагыйз да һәлак булган.

Куллары дер-дер калтырый,
Хәбәре бигрәк авыр...
Әхтәмнәр белән бергәләп
Кайгыра бөтен авыл.

Кабатлый Әхтәм бер сүзне:
— Ай балам, газиз балам!
Бәләбәй янында дигән...
Янам мин, дөрләп янам!

[1] Кыскартылып басыла.

Ишеткән. Зөһрә дә кайтты,
Сулышын ала көчкә.
Нидер өзелеп төшкәндәй
Тоелды аңа эчтә.

Әйтә Әхтәм гел бер сүзне:
— Бәләбәй ерак түгел...
Сез теләсә нәрсә әйтегез,
Чыгам мин юлга бүген.

Ул яткан изге туфракны
Үз күзем белән күреп,
Әйләнеп кайтсам шул яктан
Җиңелрәк булыр кебек.

Зөһрә дә торды сикереп:
— Әти,— ди,— мин дә барам.
— Сабыр ит,— диде әнисе,—
Кирәкмәс, юк, юк, балам!

— Әткәйгә юлдаш булырмын,
Монда мин нигә кирәк?
Күңелсез миңа биредә,
Сызлана, сыза йөрәк.

...Күрделәр аның каберен,
Күрделәр иптәшләрен.
Әйттеләр, үләр алдыннан
Нәрсәләр сөйләшкәнен.

«Үлемне уйламады да,
Төзәлә ярам,— диде,—
Дошманны тар-мар итәргә
Мин тагын барам».— диде...

Чардуган кордырды Әхтәм,
Буятты яшел төскә.
Күңеле бераз утырды,
Һәм җылы керде эчкә.

Тик юлга чыгар алдыннан:
— Мин калам,— диде кызы.
Төзәлеп килгән күңелне
Бозды ул, тагын бозды.

— Бер файдам тияр минем дә,
Карармын, терелтермен.
Укырмын газет, китаплар,
Җаннарын эретермен.

Укытучы кайда булмасын —
Мәктәбе аның шунда...
Әхтәм карт атын җикте дә,
Бер үзе чыкты юлга.

Калды госпитальдә Зөһрә,
Муеныннан эшкә чумды.
Укытучы да, сестра да,
Җан җылысы да булды.

Бер көнне Зөһрәгә дәште
Вагыйзның дусы Самат:
Мин үзем күрәм Вагыйзның,
Сеңелкәш, сезгә карап.

Чамалый егетне Зөһрә,
Абыйсы хатларыннан.
Шул булса, булырга тиеш,
Минзәлә якларыннан...

«Ул аны үлем кулына
Бирмәгән, алган тартып.
Ул яткан җирдә дошманның
Гәүдәсе калган ятып...»

Зөһрәне бөтен госпиталь
Үз итте, якын итте.
Ә кызый, берсен шуларның
Ут итте, ялкын итте.

Төшендә күреп сөйләнде:
— Зөһрәкәй,— диеп Самат.
Иртәгесен елмаештылар:
— Егеткәй, эшең «харап»...

## 2

Сугыш тындымы аз гына:
Ял. Әзерлек. Төймә тагу.
Коралларны ялтырату,
Өс-башыңнан тузан кагу.

Ирену юк, ирегү юк.
Һәр минуты җиңү өчен.
Сыный сугыш күзгә карап
Ике якның удар көчен.

Ике фронт. Ике гаскәр.
Ак һәм Кызыл исемнәре.
Россия бит моңа кадәр
Мондый хәлне кичермәде.

Бер үк илнең кешеләре
Аерылдылар ике ярга.
Кемнең җаны кая тарта,
Ансы синең ихтыярда.

Әйтте Ленин: корал белән,
Көрәш белән юл ярырга.
Туган илне кирәк безгә
Камалудан коткарырга.

Күз ачылды солдатларның,
Уены белә,
Сулны белә.
Октябрь кабызган ялкын
Сугышчының күңелендә.

Ак алъяпкычларын салып,
Зөһрә кыз да шинель киде.
Үз эченә бөтереп алды
Аны кайнар сугыш җиле.

Күз өстендәге каш итеп,
Карый аңа сугышчылар.
Әйтерсең лә, алар бар да
Шушы кызга бурычлылар.

3

Бәләбәйнең урамнары
Киң дә түгел, тар да түгел,
Итек эзе, тояк эзе,
Ыгы-зыгы анда бүген.

Әйе, чират Бәләбәйгә,
Бозаулыкның бетте эше.
Генерал Ханжинның тагын
Суырылды азау теше.

Барлады ул коралларын,
Санап чыкты солдат башын.
Качты төнге йокылары,
Ашамады ашар ашын.

Ертылганны ямарга дип
Килде Каппель гаскәрләре.
Бәләбәйдә хәл итәргә
Кирәк, имеш, мәсьәләне.

Атлый аклар урам буйлап:
— Рас-два! Рас-два!
«Россияне коткарабыз»,
Запевала, әйдә җырла!..

Чыйныйлар сары трубалар,
Барабаннар аһ оралар.
Парадныйлардан кемнәрдер
«Браво» дип кычкыралар.

Олы чиркәү бар кечендә
Дыңгырдата кыңгыравын.
Аксак мәзин азан әйтә,
Хәтерләтеп эт улавын.

Янәсе, котелгән көннәр!
Шатланыгыз, җитте килеп.
Кайтты, димәк, бөтенләйгә
Безнең үзебезнең «ирек».

Ни генә юк бу дөньяда
Ак полковник тәре үпте...
Нигезенә мина төрткәч,
Цейхгауз тезен чүкте.

Тетрәде җир, тәрәзәдә
Пыялалар калтырады.
Менә сиңа, кызылларның —
Үкчәләре ялтыравы!

...Зөһрә дә чыккан урамга,
Өсте-башы менә дигән.
Ап-ак перчатка өстеннән
Бриллиант кашлы йөзек кигән.

Хатын-кызлар ир-ат кебек
Игътибарга алынмый, дип,
Үзе теләп килде Зөһрә,
Мондый эшкә ярыйм мин, дип.

Кайчак сизелер-сизелмәс
Сискәнеп тә куя үзе.
Ләкин көмеш кебек чыңлап
Чыга аның әйткән сүзе.

Ул «ролен» уйный белә,
— О господа! — шаулап көлә.
Кыз-кыркынның күңелләрен
Кирәк бераз күтәрергә.

Офицерлар елмаешып,
Каш сикертеп үтә аңа.
Бу шәһәрнең хатын-кызы
Лаек, имеш, игътибарга.

Белә Зөһрә эш бик җитди,
Утка баскан табаннары.
Дошман йөргән юллар хәтәр,
Алар кара баганалы.

Янәсе шундый шат Зөһрә,
«Мәхәббәттән исерә ул».
Хәтерен нык эшкә җигеп,
Барсын күздән кичерә ул.

Саный Зөһрә:
— Берәү, икәү...
Ун... егерме туп арбасы.
Штык саны өч мең диләр,
Атлылары мең чамасы.

Солдатларның кәеф төрле,
Ут эченә ашыкмыйлар.
Йортлар саен таралышып,
— Бир олырак кашык,—
диләр.

●

Учредилька бинасында
Бал булачак икән кичкә.
Эчемлекләр подваллардан
Тәгәрәде мичкә-мичкә.

Чакырдылар Зөһрәне дә,
Ничек калдырсыннар аны.
Гильдии купец «әтисенең»
Еракларга киткән даны.

Тынды урам төш алдыннан,
Киләселәр бетте килеп.

Штаб алдында ак флаг
Чайкалды гел җилеп-җилеп.

Эшләр шактый кызу, ахры,
Бераү кирә, бераү чыга,
Дезертир, дип, бер солдатны
Подпоручик сугып ега...

Үзәк урам. Бу тирәдә
«Балыкларның» эреләре.
Адъютанты белән үтә
Купшы Колчак генералы...

Эх, бу этне эләктереп,
Алып качсаң икән моннан.
Юашланып, мескен булып,
Калыр иде бит бу елан...

Шулай уйланып барганда
Каршы яктан патруль килә.
Кул очын козырекка терәп,
Хәрби сәлам бирә-бирә.

Ридикюлен ача Зөһрә,
Үзен эре тота ләкин.
Ашыкмыйча гына алып,
Күрсәтә ул документын.

Гафу үтенгән шикелле
Честь бирәләр Зөһрәгә.
Шундый кешенең баласын
Туктаттык, имеш, зерәгә.

●

Яна утлар җем-җем итеп,
Төшерелгән ак пәрдәләр.
Бары силуэтлар гына
Күренәләр тәрәзәдән.

Уйный хәрби музыкантлар,
Пыялалар зыр-зыр итә.
Шпорларын челтерәтеп,
Офицерлар биеп китә.

Кемдер әйтә: танго, танго!
Ярым исерек гәүдәләр
Инке-тинке бөтерелеп,
Пар-пар булып әйләнәләр.

Дәрәҗәсен белә Зөһрә,
Нәзакәтле тота үзен.
Подпоручик колагына
Пышлап кына әйтә сүзен.

Ә офицер шактый кызган,
Мактанасы килә аның:
— Фәрештәкәй, беләсезме,
Сезнең өчен фида җаным.

— Кадерлем минем,— ди
Зөһрә,—
Исерә күрмәгез тагын.
Укытырга кирәк тизрәк
Тегеләрнең сабакларын.

— Һи, аңарчы калмый берни,
Таң алдыннан гына һөҗүм.
Телисеңме, бер комиссар
Тотып бирәм сиңа үзем.

Ә кыз аңа, «браво» дип,
Комплимент әйтеп ала.
Тангодан соң краковъягы
Һәм полонез кабатлана.

Димәк, һөҗүм иртәгә үк,
Исерек тел ярап куйды.
Зөһрә туташ кыстый-кыстый
Бокалларга шәраб койды.

— Я, госпада, күтәрәбез!
Монсы, безнең җиңү өчен!
Курку белмәс баһадирлар
Дошманнардан алыр үчен.

Чәкәштерелде бокаллар,
Шактый кеше инке-тинке.
Зөһрә туташ җаен табып,
Үзенекен читкә сипте.

Мактадылар Зөһрәкәйне:
— Бардыр синең канатларың.
Фәрештәләр фәрештәсе,
Аңлыйсың син солдат җанын!..

...Канатланып кайтты Зөһрә,
Йөзе якты, күңеле шат.
Госпитальдән аны эзләп
Килеп төште бер сәлам хат.

Самат язган: «Мин тазардым,
Мена тагын басам сафка.
Беләсе иде, Зөһрә туташ,
Исәнме икән минем кашка?»

4

Дүрт көн, дүрт төн гел ут
чәчеп
Торды сугыш кораллары.
Һәм бер юлы тынып калды
Бәләбәйнең урамнары.

Кыйшайган туп арбалары,
Мылтык, кылыч ята аунап.
Коралларның ошаганын
Ал үз кулың белән сайлап.

Аннан Бөгелмә ычкынды,
Кулдан шуган балык кебек.
Барды безнең сугышчылар
Урталыкка ярып кереп.

Рәхмәт әйттеләр Зөһрәгә:
Синең ярдәм тиде,— диеп.
Чапай аның аркасыннан
Аталарча алды сөеп.

Хәзер, диде, безнең алда
Синең туган Уфаң тора.
Ишетелгән сезнең исем
Командарм Фрунзега.

Шәфәкъ төсле булды Зөһрә:
— Хезмәт итәм Ватаныма!
Чыннан да ул лаек иде
Телгә алып мактарга.

5

Тузанлы юл. Поход килеп
Арылган. Мөшкел иде хәл.
Атлылар һәм җәяүлеләр
Ял итәргә булды бер мәл.

Елга тып-тын җәелеп ята.
Аланы да бар кечкенә.
Кояш ут булып тәгәри,
Чыдар әмәл юк эссегә.

Үләнгә куштык атларны,
Иярләрен дә алмадык.
Су коену турында сүз
Кыймылдатты безнең халык.

Рөхсәт булды. Ә дигәнче,
Барыбыз да чумдык суга.
Атлы казаклар шул ара
Куаклыктан килеп чыга.

Безнең өскә яңгыр кебек
Пуля яудыра каһәрләр.
Чыелдап кешнәшә атлар,
Куркышып бар да әсәргән.

Бер читтәрәк иде Зөһрә,
Ялгызы ул ком өстендә.
— По коням! дигән команда
Аермачык ишетелә.

Кая киенү кайгысы,
Ә дигәнче корал алып,
Аны-моны карап тормый,
Атка менә безнең халык.

Атка менә. Каушап калмый,
Бәрелә кылычка кылыч.
Ярым шәрә гвардия
Сибә тегеләргә борыч.

Самат алдан ярып керә,
Унга селти, сулга селти.
Нишләргә белмиләр аклар,
Эшләр яман, эшләр хөрти.

Тәгәрәшеп кала башлар
Ат тоягы арасында.
Безне җеннәр кисәдер, дип,
Төшә дошман кара шомга.

Кинәт әче тавыш белән
Ак офицер разбой сала.
Кизәнелгән кылыч төшми,
Югарыда туктап кала.

— Чапма мине, чапма, зинһар!
Алла хакы өчен калдыр.
Сез хатын-кыз, шулай булгач,
Азмы-күпме шәфкать бардыр.

Теге вакыт Бәләбәйдә
Күргән иде бит ул аны.
Подпоручик әфәнденең
Бик кадерле икән җаны.

Кылыч тора баш өстендә
Соңгы минутларны санап.
— Мәхәббәтем сүнми, ди ул,
Кызыл булуыңа карап.

Үзен саклап калу өчен
Җай эзли ул, түбәнләнә.
Үчен ала алмаз кылыч,
— Башың белән җәһәннәмгә!..

Зөһрәнең чәч толымнарыннан
Бәреп чыкты салкын тирләр.
Ир исемен йөртсәләр дә,
Үлә белми кайбер ирләр.

Дошман ягы туздырылгач,
Кынына керде кылычлар.
Сугышчылар елмаешып,
Бер-берләренә елышкан.

Мунчасы шәп булды, диеп,
Бер сугышчы тел шартлата.
— Шәрә килеш сугышуы
Җиңел икән, куәт арта.

Дошман селтәгәнче селтәп
Өлгерденме! Булды, димәк.
Кара тиргә батасы юк,
Бөтен тәнең тора җилләп.

Көлешәләр сугышчылар:
— Яңача бу, яңача, дип.
Төшенә керер акларның,
Билләһи бу тамаша,— дип.

Су буена кире кайтып,
Сугышчылар киенделәр.
Ләкин өч иптәш юк иде,
Башлар түбән иелделәр.

Зөлкарнаев — башкорт ягы,
Икенчесе Казанныкы.
Өченчесе Гусев Иван,
Краснококшай — туган йорты.

Бер минутка тып-тын тордык
Баш киемен кулга алып.
Соңгы сәламебез булып,
Яңгырады безнең залп.

...Көтмәгән булганнар аклар
Болай килеп чыгар, диеп,
Кинәт һөҗүмгә кызыллар
Каршы торыр, чыдар, диеп.

6

Чишмәгә күченде штаб,
Уфаның ул капка яны.
Агыйдел ярлары буйлап
Тезелеп киткән аклар ягы.

Самат әйтә: — Нигә әле
Чишмә сидим?
Киттек әйдә, Уфа гулям!
Кемдер аңа каршы төшә:
Боерык юк, ди, Фрунзедан.

Ике ярда ике гаскәр,
Ныгып алган икесе дә.
Ачу белән, бүре кебек,
Карый алар бер-берсенә.

Ләкин озак ятып булмый,
Бер елганың суын эчеп.
Чыгасы бар теге ярга,
Агыйделнең иңен кичеп.

Безнекеләр тавыш-тынсыз
Тупландылар Кызыл Ярга.
Дошман ягы бу тирәне
Алмый әле игътибарга.

Сүтелә иске келәтләр,
Саллар ясап төшерелә.
Ярдәм итә авыл халкы
Аргы якка күченергә.

Кузгалды көймәләр алдан,
Аерылды саллар ярдан.
Тирбәлеп тора су өсте,
Эреле-ваклы дулкыннардан.

Тавыш та юк, атыш та юк,
Шыпылдый ишкәкләр генә.
Пулеметлар карап бара
Аргы як тау итәгенә.

Караңгының колагы сак,
Ләкин күзе сукыр аның.
Сизенде дошман, күрәсең,
Көймәләрнең кыштырдавын.

Яктырттылар елга өстен
Җитәр-җитмәс урталыкка.
Яр буеннан котырынып,
Аклар безне утка тота.

Ары шартлый, бире шартлый,
Пулеметлар тек-тек итә.
Снарядлар я җитмиләр,
Я аз гына узып китә.

Калтырана, куба елга
Төбе белән, иңе белән.
Балыклар да, кошлар кебек,
Югарыга күтәрелгән.

Сугышчылар йөзә бирә
Ут эченнән һаман алга.
Белер идек, диләр алар,
Аяк тиеп алса ярга.

Кемдер каты ыңгыраша,
Усал пуля чаккан аны.
Гимнастеркасын кызартып,
Бәреп чыга кайнар каны.

Әйтә Зөһрә: — Хәзер бәйлим,
Тешеңне кыс, чыда, туган!
Калтырана, туңа егет
Кан агудан, чыланудан.

Кызара Агыйдел суы,
Ләкин кичү дәвам итә.
Командармның приказы
Телдән-телгә килеп җитә:

— Яктырганчы — теге якка!
Ныгытырга елга ярын.
Бөтен көчне — бер йодрыкка,
Кирәк безгә плацдарм!

Баш көймәләр ярга барып
Төртелергә өлгермәде.
Күреп торды командарм
Сугышчылар бер-бер артлы
Су өстенә сикергәнне.

Яңа окоп. Балык исе,
Каршыбызда аклар ята.
Дошманнарга булган ачу
Нәфрәт тавы булып калка.

Кычкыралар безгә карап:
— Ягез, плен төшегез,— дип,
Җаныгызны да саклarбыз,
Әйбәт булыр эшегез,— дип.

Һәм Самат мондый мәкердән
Кулмәгенә сыймас булды.
Гранатасын кысып тотып,
Куршесенә тамак кырды:

— Ничә минут калды икән
Бу козгынның кычкырасы?
Башаягы белән бергә
Көлен күккә очырасы...

Окобыннан чыкты да ул
Алга таба үрмәләде.
— Күрсен әле бу мордар,—
дип,
Гомеренә күрмәгәнне,—

Селтәде ул үлем йөген
Ике тапкыр бер-бер артлы.
Үзе, берни булмагандай,
Ә дигәнче җиргә ятты.

Болай булгач, аңлашыла,
Ни булса да булды, димәк.
— Әй, молодец — диеште-
ләр,—
— Вәт ичмасам,
Батыр егет! Шулай кирәк!

...«Ур-ра!» тавышы яңгырады,
Әйе, алга! Еары алга!...
Кызыл, яшел ракеталар
Чөелделәр Кызыл Ярга.

Күтәрелде сугышчылар
Тузан, төтен арасыннан.
Ажгырып һәм бөтерелеп,
Давыл үзе бара сыман.

— Ах, нәләтен!..
Пулемет ич, тыкылдата.
Яралылар ыңгырашып,
Берәм-берәм җиргә ята.

Әй, бу разведка дигәнең,
Шәйләмәгән менә шуны!
— Тончыктырам ансын да,—
дип,
Самат тагын алга шуды.

— Самат җаным! Самат,
Самат!..
Агарынып китте Зөһрә:
— Күрәләтә, үз иркеннән
Ут астына барып керә...

Тын алу юк. Кузгалу юк.
Күзәтәбез: нәрсә булыр!
Куагы да берән-сәрән,
Көтү үткән такыр урын.

Ә пулемет дулый-дулый,
Котырынып, шашып ата.
Игътибарын кемдер аның
Сул канаттан уңга тарта.

Әйе уңга! Сулда Самат!
Ориентирны дөрес тота.
Мушкага эләксен өчен
Ачылырга тиеш нокта.

Бераз тын калып торды да
Тагын телгә килде теге.
Челт-челт йомылгалап алды
Зөһрәкәйнең күз керфеге:
— Димәк, Самат җитәлмәгән,
Уң булмаган аның юлы.
Җибәрегез, үзем барам,
Кирәк аңа ярдәм кулы.

...Кузгалак яфракларына
Самат каны тамып калган.
Үзе каты яраланган,
Ләкин һаман алга барган.

Җитәсе җиренә җиткән,
Берне аткан, икенчегә
Мылтыгын ул коралмаган,
Яткан җирдән торалмаган.

Бәйләде Зөһрә иңбашын,
Сыйпады бөдрә чәченнән.
Елмаерга теләде ул
Арыныр өчен күз яшеннән.

— Тыныч бул, Саматым,—
диде,
Үз дигәнем итәчәкмен.
Мин барыбер ул этләрнең
Башларына җитәчәкмен.

Елмайды егет Зөһрәгә,
Рәхмәт, җаным, дигән кебек.
Күкләр ачылгандай булды,
Китте күңел күтәрелеп.

Тагын шуды. Алга! Алга!
Бер омтылса барып җитә.
Каты шартлау. Тәгәрмәчләр,
Фуражкалар очып китә.

Тынды үлем сипкән урын,
Челпәрәмә килеп тынды.
«Ура» тавышы тирә-якта
Каплап алды бөтен кырны.

Кызыл яу булып безнең як
Күтәрелде Кызыл Ярдан.
Бетмәс яра, китмәс яра
Алды аклар кызыллардан.

Бәреп чыгарылды дошман,
Траншеялар бушап калды.
Тик бер хәбәр һәммәбезнең
Котын алды, өнен алды:
— Зөһрә үлгән! Һәлак
булган!..
Тәмәке янчыкларыбыз
Җиргә төште кинәт кулдан.

Ышанасы килмәсә дә,
Ышанмаска мөмкин түгел.
Сугыш шул бу, адым саен
Гел сагалап йөри үлем.

Кеше гомере, метеор кебек,
Ялтырый да тынып кала.
Батырлыгы, матурлыгы
Исәннәрдә кабатлана.

Кабатлана тергезелеп,
Аннан таудай булып үсә.
Гасырларны атлап чыгып,
Үлемсезлек ягына күчә.

Күтәрелде Кызыл яулар
Алга, диеп, Уфа өчен.
Бише белән кайтарырга
Дошманнардан Зөһрә үчен!..

Тынды сугыш. Күкрәү тынды.
Керә гаскәр зур калага.
Тәрәзләрдә нур уйнатып,
Кичке шәфәкъ алсулана.

«Уфа кайда, Уфа кайда?
Уфа биек тауларда шул,
Уфа биек тауларда.
Каршы торалмады дошман
Шанлы Кызыл яуларга шул,
Шанлы Кызыл яуларга».

Штык очында ал яулык
Җилфер-җилфер янып тора.
Гүяки аннан Зөһрәнең
Кайнар каны тамып тора.

Ал яулыкны сөйгән егете
Истәлеккә бүләк иткән.
Ә кыз аның почмагына
Саматның исемен чиккән.

Бу язуда чая кызның
Мәхәббәте, сагышлары.
Зөһрә исән дигән кебек
Агыйделнең камышлары...

Күз алдында тора Зөһрә,
Яп-яшь булып, матур булып.
Яши һаман безнең белән
Үлемсез бер батыр булып.

●

Сәхнәдә скрипкачы кыз,
Алкышлар ява гына.
Шәфәкъ нурлары кунганнар
Ике як яңагына.

Уйный ул Сәйдәш маршын,
Бетховен, Бахны уйный.
Ышанам, болай булса ул,
Бөтен дөньяны буйлый.

Туктале, мин бит бу кызны
Кайдадыр күргән идем.
Кашлары кыйгач, күзләре
Кара карлыган инде.

Толымнар, әйе, толымнар
Нәкъ Зөһрә толымнары.
Юллары җинел түгелләр,
Юллары борылмалы.

Карыйм да тирә-ягыма
Сискәнеп, айнып китәм.
Охшаган гына икән лә,
Юк, Зөһрә түгел икән.

Зөһрә ул скрипкада
Уйный белми иде бит.
Өстенә крепдишин түгел,
Гимнастерка киде бит.

Ул чакта мондый кичәләр
Хыялда гына әле.
Октябрь белән башланып
Китте дөньяның яме.

Алышына көннәр, гасырлар,
Җәй һәм кыш алышына.
Һичкем дә киртә куялмый
Дөньяның агышына.

## Әхсән Баянов

# ДЕКАБРЬНЫҢ УНӨЧЕНЧЕ КӨНЕ

ДҮРТ МОНОЛОГ

## БЕРЕНЧЕ МОНОЛОГ

Ул елларда безнең Базы елгасында зур тегермән буасы ясала һәм су Агыйдел хәтле җәелә торган иде. Яр буйларында зиреклекләр, таллыклар, шомырт, балан, карлыган куаклары — урманнар, әрәмәлекләр җәелеп китә. Ерганакларда, күлләрдә үрдәк, чөлди, кыр казы, сирәгрәк булса да торна кебек оялчан дусларыбыз яши. Юеш үләнлектәге баласын җуеп әллә, һавада тәкрарлек кычкыра. Озын көннәр буе нидер эзли дә эзли мескенең.

Җәйге матурлык эчендә мин кошлар, җәнлекләр хокукында — чын табигать баласы. Яшел ярда учак ягасың да бәрәңге юып-ярып һәм тоз салып, чәйнекне кайнарга куясың. Яр буена утырсаң, су астыннан күренгән уенчак балыкларга кызыгасың: нигә мин шушы балыкларның берсе түгел икән? Ах, шул балыкларның берсе булсам! Һич югында шушы ташбаш урынында! Ә? Аның хәле кыш көне дә, җәй көне дә бер төсле. Андый-мондый кечкенә шуклык, тынгысызлык күрсәткән өчен аны тиргәмиләр — җаны ни теләсә шуны эшли, рәхәтләнеп йөзеп тик йөри ул! Хәзер инде мин дә йөзә беләм белүен дә — тик балык шикелле рәхәтләнеп, озак итеп су астында тора алмыйм — күңел канәгатьләнми! Эх, балык булсаң икән!

Теге як ярда атлар чемченеп йөри. Тыңлаганыгыз бармы — шундый матур итеп кетердәтәләр алар үләнне?! Ә яшел печән яки салам турап салган башакны? Абзарда һәркайсына аерым арата бирелгән аларга — бөтенесенә шундый игътибар. Ә безнең кебек малай хакында кайда инде ул кайгырту! Бармы син, юкмы. Менә ат булсаң! Алар ничек шәп чабалар! Мин авылда иң каты йөгерүчеләрдән дә — барыбер атны узып булмый ул. Иң начар кырчын дигәне дә сине ун чакрымга калдыра. Ах, ат булсаң икән ул!

Без сыерлар, сарыклар көтәбез. Шуңадырмы — сыер да, сарык та буласым килми. Акрынрак, салсызрак хәрәкәтләнсәң, сыер дип мыскыл итәләр. Берәр эшне аңламый эшләсәң, сарык диләр.

Юк, сарык та, сыер да булмыйм мин.

Ә теге чөлдиләр? Торналар? Ах, мин менә кош булырга теләр идем! Нишләп шул кошларның берсе мин түгел икән? Теләсә кая оча алалар. Көннәр салкыная башладымы, китеп баручы җәй артыннан очалар да куып җитәләр. Безнең кебек нәрсә кияргә икән дип, салкыннан калтырап өйдә утырмыйлар. Күпме ил, күпме җир күрәләр, сәяхәт итәләр. Ә минем шушы судан башканы күргәнем юк. Бу сулар, бу әрәмәләр дә матур, бик матур. Шулай да кошлар гына очып күтәрелгән биеклекләр, кошлар гына барып җиткән еракълыкларданиләр юктыр дисең! Әллә нинди әкиятләр сөйлиләр, шундый матур әкиятләр: күр дә тор, кошлар киткән илләрдәге хәлләрне сөйлиләрдер әле ул әкиятләрдә! Ах, шул кошларның берсе булсаң икән! Әкиятләр илен барып күрер идем мин!

Юк шул, мин бары беркемгә дә кирәкмәс, канатсыз малай гына. Илдархан абый килүгә ашарга әзерләп куйсам, аннан көтүне су буена төшереп туплашсам, кичлектә малларны ашата-ашата йөреп, кичкә берсен дә югалтмыйча хуҗаларына алып кайтышсам, минем өчен бик әйбәт инде. Тиргәүче булмый. Бүген дә шулай, иртәгә дә шулай, берсекөнгә дә... Шулай җәй узып та китә. Ә кыш көне... Әйе, адәм баласы булып туып ,бик үк дөрес эшләмәгәнмен, ахрысы мин. Минем кем булып туарга теләвемне сорамыйча бик зур ялгышлык эшләгән табигать. Бик зур ялгышлык!

Илдархан абый ниләр уйлый торгандыр, әйтә алмыйм. Ул минем белән андый нәрсәләр хакында сөйләшми бит. Хәзер бөтенләй аз сөйләшә, нәкъ олы кешеләр төсле. Хәер, ул зур кеше дә инде: унбиш яшь, эти үлгәч, аны алыштырган кеше... үз өстенә авыл көтүен алды. Ә мин, җиде яшьлек малай, ярдәмче генә.

Бер көнне төшкелектә мәзәгрәк бер нәмәрсә ясады. Юка гына дүрт чыраны дүрт почмаклап беркетте дә аңа бәрәңге белән кәгазь ябыштырды. Аннан соң тегәрҗептән яман да озын итеп койрык такты — бер чакрым бардыр, арттыра төшсәң. Шушы дүрт почмаклы нәмәрсә һавага күтәрелеп ак башлы еланга әйләнә дә әллә кая, күздән югалганчы очып китә, имеш. Әгәр җепне ычкындырсаң, бөтенләй кире кайтмыйча, шулай кош шикелле, илдән илгә, мәңге очып йөриячәк икән! Нәрсә уйлап, нинди теләк теләп ясагандыр ул очкычны, әйтә алмыйм. Биш-алты малай җыелып, тантаналы рәвештә (монысын хәзерге төслерәк әйтүем инде) очырып җибәрергә уйлаган идек, очмады, каһәр. Шуннан соң ике-өч көн буе Илдархан абый бөтенләй бер сүз эндәшми йөрде. Нигә шулай иткәндер инде...

Сирәк-мирәк булса да безнең янга Нәркәс апа килеп китকәли. Зәңгәрсу бизәкле күлмәге, кара алъяпкычы, тамчылы алкалары һаман күз алдымда тора. Нәркәс апа килсә, безнең күңелләр күтәрелә, бигрәк тә Илдархан абыйның. Әллә нинди чая, башкаларны да үз шаянлыгы белән мавыктыра белә торган чеп-чибәр бер апа инде ул!

Кайбер көннәрне мин кызыккан ат, куян, бүре, торналар, кыр казлары төшерелгән китаплар алып килә. Менә безгә бәйрәм андый көннәрдә!

Шунысы начар, ул килсә, Илдархан абый көтүне бер миңа ташлый да китә. Үзләре әллә нәрсәләр хакында сөйләшкән булып, олы кешеләрчә әкрен генә атлап, әллә кайлардан урап килгән булалар, сөйләшкән булалар. Шул гомер сөйләшүгә каян җитә диген сүзләре! Ә минем икеөч сүз әйткәч үк сүзем бетә дә куя, теләсәм дә сөйләшә алмыйм.

Нәркәс апа киткәч, Илдархан абый чыбыркы очын рәтләп ишкән булып, я бүтән шөгыль табып, сәгатьләр буе уйланып, елмаеп утыра да утыра. Тиле кеше шикелле. Нәрсә уйлый торгандыр....

Яңгырлы көннәрдә хәл мөшкелрәк.

Бервакыт, яшен яшенләп, күк күкрәп яңгыр яуганда, күзгә карап бүре килде дә бер сарыкны аркасына салып алып та тайды. Сыерларның

ничек котыруын, ничек бөтен көтүнең акырышуын күрсәгез! Без аларны җыярга, качырмаска тырышабыз, артларыннан чабабыз. Алар исә куган саен тизрәк кача. Бигрәк тә үзебезнең сыер. Мин аның артыннан чаба торгач чытырман таллык-каенлыкка барып чыктым. Шушы сазда ике-өч кенә көн элек (болай чабышулар шактый еш), үземне белештерми йөгереп барганда, елан өстенә басып узган идем. Әле дә йөрәк жу итеп китә: ничек өлгермәде икән ул чагарга?! Беткән иде бит баш! Валлаһи беткән иде!

Бу юлы да килеп чыгар дип куркам, ләкин һаман йөгерәм үзем...

Шулай, бер сарыкны алды да китте бүре. Таралды да бетте көтү. Караңгы төшкәч, безне юксынып авылдан кешеләр килделәр. Ник алып кайтмыйсыз көтүне? — диләр. Ә без аны һаман җыярга тырышабыз. Сыерларның кайберсе күптән инде өйдә икән, кайберсе бүтән авыл игененә кергән, аларын соңыннан штраф түләп алырга туры килде — зур гына утарга япканнар да куйганнар.

Кич кайткач Илдархан абый да, мин дә манма су күлмәкләрне сыгып яңадан кидек тә ашамый-нитми урынга яттык. Илдархан абый төн буе миңа йокы бирмичә, сулкылдап елап чыкты... Нәрсә уйлагандыр — анда да әйтмәде.

Көзен, билгеле, аның яшьтәшләре дә, минем яшьтәшләрем дә укырга — мәктәпләргә йөри. Ә без кышка чаклы кырда. Кыш көне Илдархан абый атлар карарга керде, мин урамга чыга алмас булдым, өйгә бикләндем: рәтле кием юк.

Шулай яши, эшли торгач, Илдархан абый үзенә әйбәт кенә кием юнәтте. Мин дә аз-маз кеше күзенә күренерлек хәлгә килдем — икенче көзне укырга кердем: икенче класска. Чөнки, өйдә ятсам да, беренче класслар укыган бөтен китапларны йөзәр кат укып, йөзәр кат күчереп язып, көн саен мәктәптә йөргән кешеләрдән яхшырак укый ала идем. Арифметикадан үземне бигрәк тә иркен сизәм. Тик язуның матурлыгы гына чамалы. Шушы көнгә чаклы почеркны матурлый алганым юк — кирәкми торган булса, бөтен кеше дә укымас иде ул беренче класста.

Дүртенче классны гына бетерсә дә, Илдархан абый укымышлы кешеләрдән хисапланып, аңа наданнарны укытырга куштылар. Абыебыз укытучы булып китте.

Икенче елны хисапчылар курсына җибәргәннәр иде, аңысын да гел отличнога бетереп, колхозда хисапчы булып китте һәм анда өч ел эшләде: егерме яшендә бөтенләй олы кешегә әйләнде.

Безнең өй моңарчы нәкъ искечә: түрдә — буйдан-буйга сәке, өстәлфәлән юк, шунда ашыйсың, шунда эчәсең. Ике генә бүлмә. Илдархан абый бу тәртипне үзгәртергә балта осталары җибәргән. Сәкеләрне кубарып ташладылар да өр-яңа тактадан аерым бүлмә ясап куйдылар, ишекләргә ялтырап торган тимер бикләр, тоткалар кактылар. Сәке урынында тимер карават, сәгать турысында менә дигән өстәл барлыкка килде. Һәм, озак та үтмичә... Илдархан абыйның бергә эшли торган дус егете килде дә әнигә әйтте:

— Зөлхәбирә җиңгәчәй, хәзер сезгә килен алып кайтабыз, каршыларга әзерләнегез.

Килен дигәнебез Нәркәс апа булып чыкты.

Илдархан абый белән алар ай чамасы гына бүлмәдә йокладылар. Аннары, Нәркәс апа укытучы булып (шул елны ул урта мәктәп бетергән) эшкә урнашкач, безгә кайтмас булдылар. Илдархан абый аның янына, күрше авылга йөри торган булды.

Ә көз җиткәч, аны армиягә алып киттеләр.

Нәркәс апа безгә кунакка килгәли, җәен күбрәк бездә яши. Илдархан абый кайтачак вакытны көнлекләп, сәгатьләп саный. Ләкин аларның язмышын кайдадыр уй да барып җитмәслек ерак илләрдә яшәүче власть ияләре хәл иткән булган инде.

Корбаннары, югалтулары белән, афәтнең чиге-чамасы күренмәве белән шомландырган иң коточкыч җәй — кырык бернең җәе килде.
Илдархан абыйның кайчан кайтасы, кайтамы-юкмы икәне бөтенләй билгеле түгел хәзер. Менә сиңа ил язмышы, менә сиңа кеше язмышы!
Кич.
Кара якта, мич алды ягында кечкенә өстәлгә утырып, чәй эчәбез. Ни өчендер ут та алмаганбыз — әз булса да керосин янга калсын диптер инде. Каршыбыздагы бакча як тәрәзәдән, төньяктан, йөз адым чамасы ераклыктагы шомырт куаклары шәүлә төсле булып күренә. Самоварның тыныч чыжылдавы, чәй һәм бәрәңге пары күңелгә әз булса да юаныч бирә шикелле.
Июль киче тын, карангы, төпсез. Бер-ике айдан Нәркәс апа укытырга киткәч, безгә тагын да караңгырак, ямансурак булачак.
— Үзебезнең авылда гына укытсаң! — ди әни,— кышны бергә-бергә чыгарыек. Иптәш булырыең, бер терәк.
— Үзем дә шулай димен дә бит шул. Мәктәп юк — авыл бик бәләкәй, ачмыйлар. Сорап та карадым.
Шулай әңгәмә корып утырганда, ишек ачылды да аннан таныш сын күренде.
— Исәнбәк абый!
Һәм тиз генә мин аның каршысына атылдым.
Исәнбәк абый минем аркадан каккалап, бәләкәй генә чемоданын ишек төбенә куйды да, бу якка чыгаргамы, чыкмаскамы дигән кебегрәк, аптырабрак калды. Нәркәс апа да аның карашыннан каушагандай башын иде һәм стенага йомылды.
Ярый әле, әни аптырамады — салмак кына торып Исәнбәк абыйны үзе кочаклап алды:
— Әй, Исәнбәккәем! Сагындырып кына! Әй, Исәнбәк! Менә сиңа!
— Я, ни хәлләрегез бар? — диде Исәнбәк абый, ниндидер тавыш калтыравын җиңәргә тырышып һәм шул сүздән соң елмаеп та куйды. Өй эче шул сүз белән, аның ягымлы елмаюы белән тиз арада яктырып киткәндәй тоелды — әни ут кабызганнан түгел, әйтерсең.
Яктыда Исәнбәк абый Нәркәс апага текәлеп, танырга тырышкандай тукталыбрак калгач, мин ярдәмгә килдем:
— Нәркәс апа ул безнең!
— Киленебез шушы инде, Исәнбәк,— диде әни дә.
— Ә! Шушымыни киленебез? Бик шәп! Я, күрешик инде! Мин менә бианаңның туганнан туган энесе булам. Сиңа — абый. Күрешикме соң?
— Күрешик соң,— диде Нәркәс апа, оялгандай һаман аска карап, һәм Исәнбәк абыйга кул сузды.
Күрешкәч, Исәнбәк абый юка яшел плащын тиз генә салып ишек янындагы чөйгә элде дә — инде бу юлы нык адымнар белән — тагы безнең якка чыкты:
— Я, Вәкил, юыныйк, су салып бир миңа.
Комганда су беткән икән — шатлыгым эчкә сыймыйча олы чүмеч белән су салдым һәм ул юынганчы әни тастымал алып миңа сузды:
— Яңарак сөлгегә сөртенсен,— диде.
— Менә бит, ә, ничек үсеп тә киткәнсең. Ничә яшь инде сиңа?
— Унике тулды, унөченче!
— Озакламый кызылармеец та булырсың, сугышчы булырсың!
— Ул армис булганчы ук барыр микәнни сугышлары? — диде әни куркуын яшермичә.
— Белеп булмый инде аны, түтәй! Сугыш бик каты бит. Тегеләр шактый тиз килә. Нихәтле күбрәк килсәләр, сугыш шулчаклы озаграк барачак.
— Бөтенләй басып китмәсләрме?

— Бөтенләй басып алсалар да, сугыш бетмәячәк — мондый зур илне барыбер буйсындыра алмаячаклар. Шул, озакка гына сузылуы бар.
— Без барыбер җиңәячәкбез бит, Исәнбәк абый, шулай бит?
— Шулай, әлбәттә, шулай.
— Ишеттеңме, әни? Мин сиңа нәрсә әйткән идем?
— Ходай гына кушсын. Әйбәт сүзеңә рәхмәт, Исәнбәк. Әйдә, булганынча авыз ит ризыктан. Кыстатма.
— Ярый, рәхмәт, кыстатмам,— дип чәйне үз алдынарак күчерде Исәнбәк абый һәм Нәркәс апага карады, — Нәркәс булам дисез икән!
— Мәзәгрәк исемме? Кушканнар инде...
— Начар исем түгел, миңа ошый, ифрат назлы, ифрат иркә яңгырый.
— Әйтмәгез инде.
Чәй эчкән арада әни Исәнбәк абыйның хәлләрен сорашты, без икәү тыңлап кына тордык, ара-тирә генә сүз кыстырып.
— Соңгы вакытта Свердловскида эшләдем, беләсез инде.
— Андый-мондый нәрсә юктыр бит? Кинәт кайтып төшүеңнән әйтәм. Алла сакласын, бу дөньяда...
— Зыянлы нәрсә юк.
— Отпускагамы?
— Бөтенләй.
— Бөтенләй?
Әни Исәнбәк абыйга гаҗәпләнеп карады, ә мин шатланып кычкырдым:
— Шәп! Китмә, Исәнбәк абый, бер дә китмә.
— Китәргә туры килә шул,— диде үзе чак кына моңайгандай һәм, без сүзсез калган арада, нык тавыш белән өстәде: — Кирәк!
— Хәзер кая китәсез инде? — диде Нәркәс апа да аның китүен теләмәгәндәй.
— Хәзер үк түгел, аз гына соңрак.
— Кая? — Бу сорауны тагын Нәркәс апа бирде.
— Фронтка.
Безнең өчен яңа бу сүзнең ничек шомлы яңгырашын үзегез беләсез инде: ул сүз ишетелүгә тагын озак вакыт тавыш-тынсыз калдык.
— Ярый, Исәнбәк, бик дөрес эшләгәнсең,— диде соңыннан әни, нәрсәнедер аңлагандай,— әңкәң урынына калган тутаңны күреп китүең бик тиеш. Рәхмәт. Үзем дә бик сагынганыем.
— Мин дә бик сагындым шул. Әмма кайтуым аның өчен генә түгел.
— Бүтән күрәсе кешеләрегез дә бардыр шул.
— Безнең заводтан фронтка җибәрмиләр. Бронь бирүләре ихтимал иде. Ә минем каласым килми.
— Нишләп? Күрәләтә сугышкамы? Дабрабуле?
— Үз теләгем белән. Я, бөтен таныш-белеш, ир-ат китеп беткәч, мин нишләп калыйм? Шушындый вакытта? Хатын-кызлар исәбендә?
— Бәй, забутта беләләрдер инде кемне җибәрергә икәнен.
— Менә шул, түтәй, мин таныш-белеш аркылы тиз генә эштән чыктым да сезнең белән соңгы кабат күрешергә дип...
— Авызыңнан җил алсын,— ди аны бүлдереп әни,— ни сөйлисең син!
— Ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк мондый чакта.
— Киткән бер кеше үләргә тиеш түгелдер бит! — диде Нәркәс апа дә йөзенә чыккан борчылуын яшермичә.
— Киткәнче шушы якын-тирә авылларның берсендә эшләп торырмын, бер-ике ай. Военкоматка заявление илтәм, иртәгә үк!
— Иртәгә үк!
Менә сиңа! Ә мин аның белән бергә елга буйларында йөрергә, су керергә, җиләк җыярга, шахматлы уйнарга дип хыялланып утырам. Ничек була инде бу?

* * *

Менә шулай: унбиш көн — бер ай чамасы Исәнбәк абый да, Нәркәс апа да безнең өйдә яшәделәр һәм бер-берсенә бик тиз ияләшеп тә киттеләр. Исәнбәк абый каяндыр велосипед сатып алган да район үзәгенә көн саен диярлек бара һәм алдына Нәркәс апаны утырта. Йомышлары нинди булгандыр — әйтә алмыйм. Күрше авылларга кибетләргә дә йөрделәр бугай. Хәтеремдә, бер көнне мандолина алып кайттылар.

— Менә тутәй, Нәркәскә бүләк алдым,— диде Исәнбәк һәм мандолинаны көйләргә кереште.

— Уйный беләме соң ул аны? — диде әни, бүләкне өнәмәгәндәй.

— Белмәсә, өйрәнер.

Бу вакыт Нәркәс апа үзе нидәндер уңайсызланып, тәрәзәдән тышка караган булып утырды.

Икенче көнне, велосипед белән чираттагы бер сәяхәттән соң, калын гына китап алып кайттылар. Китапка мин бик сөендем дә, әллә русчаны рәтләп аңламаганга, тырышып-тырышып карасам да укый алмадым, тик исеме генә хәтердә калды: «Записки Пиквикского клуба...»

Исәнбәк абый кебек тантаналы төстә игълан итмәсә дә, соңынтын беленде: китапны Исәнбәк абыйга Нәркәс апа бүләк иткән иде.

Матур беркөнне өчәүләп җиләккә бардык — Елан тавына. Нәркәс апа мандолина, Исәнбәк абый теге калын китабын алды. Минем кулда — зур гына бер тәлинкә һәм банка. Тау буенда үләнгә күмелеп утырдык. Нәркәс апа мандолинада өйрәнергә азаплана, без аңа ничек кая басарга икәнен күрсәтеп карыйбыз. Тик һаман барып чыкмый: Нәркәс апаның сәләт юк икән музыкага, чыкмый гына көй, үтерәсеңмени аны!

Шактый вакыт булашкач, җиләк җыярга килгәнебезне хәтерләп, мин Нәркәс апага тәлинкәне биргән идем, алмады:

— Ай, апаем, бик зур бит бу, ничек тутырырбыз?

— Сез икәүләп җыярсыз!

— Барыбер зур.

— Мәгез алайса банканы.

Мандолинаны тау буена калдырып (ерак китмибез бит), җиләк җыябыз. Алар икесе бергә йөри: сөйләшәләр — сүзләре бетми, шаяралар — хәлләре бетми. Инде кояш баерга таба борыла башлады, инде мин берүзем тегеләр алмаган икенче тәлинкәне тутырдым — ә болар икесенә бер ярты литрлы банка белән йөриләр. Әй, булдыксыз да инде бу олы кешеләр, кечкенәләрне яманлап, акыллы сөйләшергә генә булдыралар. Җиләкне хәзер ашап кына йөрим. Алай да куркыныч, «җиләк астына төшүен» бар. Бервакыт эссэдә шулай күп җиләк ашап, хур була язган идем бит: бөтен тәнне әллә нинди кып-кызыл таплар басты, әчетә, кычыта, яндыра, елыйсылар килә, үләм дип торам. Акылны шулайрак җыясың аны.

Ниһаять, килделәр минем янга.

— У! Тәки тутыргансың бит! — диде Нәркәс апа, көч-хәл белән елмаерга тырышып.— Ә без... Менә! — һәм ул тулып та җитмәгән банкысын күрсәтте.

— Тулмаган, һә-һә-һә! — Рәхәтләнеп көләм.

— Җә инде, шулчаклы мыскыл итмә инде,— дип ялына Нәркәс апа.

Исәнбәк абый исә кулына мандолинаны алды да телдән калды: мандолинаны чиртә, тегесе — кылтыр-кылтыр...

— Нишләгән ул? — дим куркып.

— Нәрсә? — ди Нәркәс апа.

— Мандолина... шартлаган.

— Мин аңа кагылмадым,— диярга ашыктым, мандолинаның буйдан-буйга ярылып чыгуын абайлап.

Исәнбәк абый медиатор белән мандолинаның кылларын тагын чиртеп карады — күптән түгел генә яңгыраган көйләрдән җилләр искән, зыр-зыр... тагын. Җанлы кеше шыңшыган шикелле — имгәтеп ташлаганнармыни!

— Өйрәнә алмый калдым,— диде Нәркәс апа.

— Кызганыч,— диде Исәнбәк абый, чын күңелдән кайгырып.

Ә кайгырыр нәрсә булган икән шул.

* * *

Бер-ике көн узгач, Нәркәс апа яңадан чырайланып китте. Исәнбәк абый белән тагын шаяра, көлешә башладылар. Бервакыт шулай уйнаганда, Исәнбәк абый аның кулыннан нәрсәнедер тартып алган иде (китапмы, ахрысы), Нәркәс апа үзенең озынча һәм нык кулы белән шулкадәр каты итеп сукты, аларга әни гаҗәпсенеп бик озак карап торды. Икенче көнне күрше хатынына зарланып сөйләгәнен ишеттем:

— Болар бигрәк мәзәк кылана башладылар инде. Егет белән кыз диярсең. Син Нәркәскә сиздер әле. Яшьлеге белән ул уйлап җиткерми бугай. Килешми ул алай диген.

— Килешүен дә килешми шул,— диде күрше хатын.— Чыбыксыз тилефун дигәндәй... чыш-пыш тарата — бөтен авылга.

— Әстәгъфирулла, тәүбә. Кит, сөйләмә язмаганны.

— Үзеңдәген кешедән сора, дигәндәй...

Әни Нәркәс апага шул хәбәрне җиткердеме, әллә бүтәнчәме — тик ул килештермәслек хәлләр, кәефне җибәрерлек бүтән иркенлекләр хәтердә калмаган. Киресенчә, алардан аерылу кыенлыгы йөрәкне кисепкисеп ала хәзер. Сентябрь җитәрәк икесе ике авылга укытучы булып киттеләр — Нәркәс апа якынрак бер авылга, тегесе еракка. Нәркәс апа ял саен диярлек кайтып йөрсә, Исәнбәк абый бөтенләй күздән югалды. Декабрь урталарында гына — бусы инде соңгы тапкыр — тагын кич, бу юлы төс-кыяфәтенә туры килми торганча — аркасына биштәрле капчык аскан хәлдә килеп керде. Армиягә китешли, рөхсәт сорап, бер кичкә, саубуллашырга гына кайткан иде ул.

Чишенгәч тә теге мандолина (могҗизага да ышанасы килә бит кайчак) төзәлмәгәнме дигәндәй уйнамакчы булып караган иде дә, юк шул — зың-зың һаман...

— Эх, Вәкил, Вәкил...

Әйтерсең, мин гаепле.

— Уйна әле, зинһар, баяныңны.

Һәм нәрсә хакындадыр уйланып, бик озак, бик озак мин уйнаганны тыңлап утырды.

...Соңыннан кемгәдер хат язды, бәрәңге белән ябыштыргач, адрес язды...

Кич, чәй эчкәч, идәнгә урын җәеп, бөтенебез тезелешеп шунда яттык та төн буе диярлек сөйләшеп чыктык. Без Исәнбәк абыйны кызганабыз, ә ул — безне. Язга кадәр җитәрлек тә ашлык юклыгын белгәч, бөтенләй тынычлыгын җуйды һәм йокыны бөтенләй качырырлык яман киңәшләр бирә башлады:

— Син, түтәй, нәрсә диярсең — әгәр мин шәһәргә Вәкилне ияртеп алып барсам?

— Ник анда?

— Баянны сатарга кирәк.

— Баянны? — Мин, аның бу сүзләрне әйтүенә ышанмыйча, сикереп үк тордым.

— Әйе.

— Әсләм абый аны миңа калдырды. Сакларга кушты.
— Ул ачуланмас, бер дә юкка сатмыйбыз. Сезнең өчен — исән калуыгыз өчен.
— Юк, Исәнбәк абый, саттырмыйм.
— Бик кирәк дисәгез, сугыштан соң тагын алырсыз. Я, язлыкта ни ашап яшәрсез?
— Үлән.
— Үлән чыкканчы?..
Аптыраштан эндәшмәвемне минем ризалык бирүем дип аңлагандырмы, эни йомшак кына әйтте:
— Булдыра алмас шул, бала тикле балага ничек баян тоттырып җибәрмәк кирәк.
— Әйтеп торам бит, үзем алып барам. Сатып ук бирәм. Акчасын куфайкасы эченә шапләп тегеп куйгач, җырлап кына кайта ул. Аның каравы, көзгә хәтле җитәрлек ашлык алып куярсыз, хәзердән үк, бәясе күтәрелгәнне көтмичә.
— Ирләр башы әйбәтрәк эшли шул,— диде эни, ризалашу гына түгел, аңа сокланып ук.
Мин нәрсә әйтергә белми ятам. «Сатмыйбыз» дип һаман бер сүзне тугласам да, алар, эшнең инде хәл ителгәнлеген белдереп, икенче нәрсәләр хакында ук сөйләшергә керештеләр. Ә минем башта — баян. «Юк, юк, барыбер бармыйм!» — дим эчтән генә.
Шул уй белән йоклап та кителгән. Күзләремне ачсам, инде Исәнбәк абый киенеп алган да мине уята:
— Әйдә, киттек, егет бул, әйдә, тиз.
Торасы килмәүдән бигрәк, барасым килмәвен беләсез инде. Елар чиккә җитеп, көч-хәл белән торып бастым:
— Нәрсә киярга? Минем аякка юк.
— Соң, инде... моңынчы ни киеп йөрдең?
— Чабата.
— Тагын ки шуны.
— Тишелгән.— Чабатаның тишек булуы — минем өчен иң зур бәхет икәнен сизенәсездер. Тик Исәнбәк абый тагын аптырап калмады.
— Әсләм абыеңның ботинкасы-фәләне калмаган идеме?
— Мин аларны туздырдым инде.
— Итекләре бар, тузмаган,— дип тиз генә әләктереп алды эни һәм чоланнан пар итек алып та керде,— сиңа ярый торгандыр инде ул, мә.
— Кара син, хром итек!
Сәбәпнең тәки табылмавыннан эрни-әрни аякларга чүпрәк-чапрак урадым да кидем. Итекләр коргаксыган, шыгырдап тора... бер җиерыгы бармак турысыннан эчкә баткан һәм шул төштән тишелгән дә... Итекләр аякны бик тиз суеп чыгарачак һәм... аннары кире авылга... Ә хәзер зурлар сүзенә карышмаган кыяфәт чыгарырга кирәк. Бәләкәй чанага яшел сандыгы-ние белән баянны салып бәйләдек тә киттек.
Чананы мин тартам. Ни өчендер турыга, ындыр артлап чыкмыйча (анда кар юлы салынмаган иде шикелле) урам буйлап барабыз. Урамны чыкканда ук инде мин сукранырга да керештем, итекләр аякларны ачыттыра да башлады. Мин уйлаганнан да тизрәк. Ипидер, чынлап монысы.
— Юк инде, походка чыктыңмы, егылганчы атларга тиешсең,— ди Исәнбәк абый.
— Миңа беркем дә кушмады.
— Миңа да кушмадылар — барам бит.
— Барма син дә. Кит заводыңа кире.
— Эх, энем, энем. Бәләкәй шул әле син, аңламыйсың. Кешедә вөҗдан дигән нәмәрсә бар, шул йөртә, шул куша! Шул!
Шулай дигәч, тагын атладык.

Авылны чыккач, аркасындагы капчыгын чанага салып бәйләде дә үзе чананың бер як җебеннән тартып бара башлады. Болай миңа җиңелрәк җиңелен, тик аяклар адым саен ныграк авырта, өши бара шул. Эндәшмичә генә сыкрануымны, сызлануымны сизептер, урманны узып ялан җир белән бераз ара үткәч тә үзе тукталды:

— Чынлап авыртамы?

— Чынлап булмаса...

— Барасың килми бит, сатасың килми баянны,— диде ул, минем аякларга караган хәлдә.

— Ансы да бар.

— Ачтан үләргә ризамы?

— Риза.— Ул сәерсенеп карагач, өстәдем: — Әни әйтә, ил белән булгач, бернишләр хәл юк, ди.

— Ай алла! Үлемгә әзерләнеп беткәннәр! Болай булгач... Әҗәлне көтеп кенә ятасы калган инде.

— Ә баянны барыбер сатмыйм мин. Үлсәм дә.

— Үзең юлга чыктың.

— Син кушканга.

Шактый вакыт сүзсез торгач, нидер уйлап, ул тагын кузгалды. Ялан белән ераграк киткән саен җил көчәя — муенның бүрек каплап житкермәгән ачык төшләреннән кереп, тәнне әчеттерә, күн итек аркылы чеметеп, бөтен гәүдәне калтырата. Туган авылдан ераклашкан саен көчәячәк икән бу җил, тагын да зәһәрләнәчәк икән бу салкын, ә тегендә, Исәнбәк абый барып җиткән төштә, давылга әйләнәчәк — карлы һәм канлы давылга! Ах! Туган җирдә, урман ышыгында ничек рәхәт булган икән, белмәгәнбез кадерен, белмәгәнбез!

Исәнбәк абый да шул аерманы сизеп, үзенең кая барасын уйлап, күз алдына китереп шомлана, мөгаен. Берсүзсез атлый да атлый.

— Карале, Вәкил,— диде ул бер мәлне кинәт тукталып,— мин бит хатымны онытканмын.

— Нинди хат?

— Кичә кич язган идем — Илдарханга.

— Алайса... мин үзем салырмын. Хәзер үк, кайтып китим!

Башка килгән фикердән үзем дә куанып, кычкырып җибәргәнмен икән: Исәнбәк абый сүзеннән аңладым. Чынлап та шатланмаслык түгел шул. Ай!

— Кычкырма шулчаклы, буранны котыртасың,— диде ул һәм көлеп куйды,— хәйләкәр!

Ә миндә бернинди хәйлә, усаллык юк, туп-турысын әйтәм.

Юлга чыкканнан бирле беренче кат күтәрелеп карасам,— күзләренкашларын кар сырган икән, бите юпь-юеш, бәйле бүрек бауларына чаклы боз каткан. Әле күпме барасы бар — юлның башы гына! Кичәсе юлларын күз алдына китерсәң, болай да өшегән җан тагын да ныграк әчетеп сулкылдый. Ах, ниләр күрмәс әле аның газиз башы! Ниләр генә күрмәс! Исәнбәк абый!

Мондый уйларны мин аның үзенә әйтә алмыйм, аларны сүзгә әйләндерү минем өчен ул чакта гомумән мөмкин түгел, мин тик сизенәм, барын да эчке бер авыр сизену белән сизенәм һәм башым тагын да түбәнрәк иелә. Буран ажгыруын киметә һәм жылыта төшеп, өстемә Исәнбәк абыйның ягымлы һәм ямансу тавышы, тыныч сүзләре сибелә — аркама, бүреккә бәрелгән кар бөртекләренә чак кына да охшамаган йомшак сүзләр:

— Мин ул хатны Илдарханның үзе өчен генә язган идем. Син кара инде, ялгыш бүтән кеше кулына эләкмәсен, яме.

— Мин аны бүген үк илтеп салырмын. Бүген өлгермәсәм, иртәгә.

— Шуны уйлап торам әле — салырга да ярамас.

— Ничек «ярамас?» Нишләтим соң алайса?

— Белмим шул.
— Үзең язгансың...
— Ялгыш аңлап, Илдарханның мине бик нык тиргәве бар.
— Нишләп ул сине тиргәсен ди?!
— Әйтеп булмый шул, булмый — ничек килеп чыгар бит.
Берни аңлый алмыйча, күзләренә карыйм. Дөресрәге, аңлыйм, ләкин ышана алмыйм. Сүз җәй көне, авылда йөреп узган теге «чыш-пыш» хакында бара. Исәнбәк абый һәм Нәркәс апа... тагын нидер... Тик бу хакта олы кеше миңа сөйләп торыр дип, үзенә шул хакта әйтсәң — җайсыз хәлдә калуыңны, хур булуыңны көт тә тор. Юктыр, бу хакта түгелдер... Ә Исәнбәк абый башын ия. Әйтерсең, гаепле...
— Алайса, үзе кайткач бирермен хатны.
— Аңласа икән, аңлый алса икән!..
Бу сүзләрне ул, билгеле, миңа түгел, үз-үзенә әйтә. Әйе, үзе әйткәнчә, бары тик кычкырып уйлый һәм нишләргә кирәклеген бары тик хәзер генә хәл итә... Мин аның бер карарга килә алмый интегүен күреп газапланам, кызганам.
— Ертып ташлыйк соң...
— Ертырга да ярамый. Кирәк булуы бар. Әгәр ул дөреслекне белмәсә, аның алдында мин әшәке бер кеше, үзен-үзе хөрмәт итә алмаслык куркак бер кеше булып калырга тиешмен.
Бу сүзләрне мин бөтенләй аңламыйм һәм, ни өчендер, аңларга да тырышмыйм, тик алар бүгенге көнгәчә аермачык булып күңелдә саклангannar һәм алардан бүген инде кайбер нәтиҗәләр ясарга тырышам... Тик булдыра алмыйм. Дөрес эшләдеме ул? Мин аңа бәлки ярдәм итәргә тиеш булганмындыр? Ничек итеп? Хәзер инде аны тиргәргә яки якларга гына мөмкин.
— Беләсеңме, нишләргә кирәк,— диде ул, ниһаять, нәрсәдер уйлап чыгарган тавыш белән,— сугыштагын белеп булмый, җибәрми тор син аңа. Әгәр үлсә...— минем йөрәк авыртудан кычкырып җибәрү мөмкинлеген абайлап, сүзен ачыкларга ашыгып, үзе кычкырды: — сугыш бит, үләләр бит, ай, энекәшем, үләләр, күпләр, бик күпләр, күпме генә кызгансак та, үләләр! Безгә бер генә юл кала, түзәргә, ирләрчә түзәргә. Син дә түз, түз!
— Ыһы...— Күзләргә тулган яшьне тыярга тырышам һәм бүтән сүз әйтә алмыйм.
— Менә шул, әгәр үлсә, тыныч үләрлек булсын, газапланмасын.
— Әйе.
— Синең белән зурларча сөйләшеп була икән, акыллы малай син, молодец. Хәл кылыйк шулай: исән кайтса да бик кирәге чыкса гына тапшырырсың хатны, үзең белеп.
— Ни өчен тагы, ник?
Ярамаган сүз ычкындыруын абайлагандай уңайсызланды абыем:
— Болай.... Шул... Бик нык газапланса гына бирерсең. Ярыймы? Эшли алырсыңмы шулай?
— Нәрсәсе бар аның?
— Алайса, тагын бер үтенечем — үзең укыма ул хатны, яме?
— Я...
— Көчең җитәрме шуңа?
— Нәрсәсе бар аның?
— Алай-болай үлсәм...
— Исәнбәк абый!
— Без бит шулай сөйләштек, дөреслектән курыкмаска.
— Курыкмыйм да бит...
— Шулай булгач... Ни әйтмәкче идем әле? Әйе, үлсәм, туфрагым рәнҗемәслек булсын, син мине гафу ит... Илдарханга да әйт ышануымны... сүземне үтә.

— Анысы... мин үтәрмен.

— Рәхмәт!

Исәнбәк абый мине җилкәмнән сөеп куйгач, үзенә соңгы тапкыр карап калыйм дип башымны күтәрсәм, аның күзләрендә яшь икән. Шушы зур кеше — акыллы, җитез, уенчак кеше елар дип кемнең башына килсен! Бүтәннәр сөйләсә, ышанмас идем. Исәнбәк абый! Ай, Исәнбәк абый! Ничек ярдәм итим соң мин сиңа? Ничек хәлеңне җиңеләйтим? Олылар үзләре булдыра алмаганны без ничек булдырыйк?

— Ярый, бар, хуш! Түтәйгә сәлам әйт.

— Әйтермен.

Ул да китәр юлга бер-ике адым атлады, мин дә... Тик тукталдым, аңа карамаска көчем җитмәде. Ул да борылган икән, мине күреп, үзе дә тын калды. Басып тик торабыз. Күпме торганбыздыр, ул ниндидер бер ашкынуын җиңә алмагандай икеләнеп кенә, миңа таба килә башлады, үзе бер сүз әйтми. Мин — аңа таба. Менә тагын очраштык. Тагын берсүзсез генә мине кочаклады. Кочаклады да тып-тын калды... Тагын бер сүз дә юк. Шулай мин буран тавышын, җил тарткалавын, абыемның шушы табигатьнең үзе төсле үк чиксез һәм тирән сагышын, ә ул минем кечкенә җанымның үрсәләнеп ашкынуын (әлбәттә, әлбәттә, ул моны сизгәндер!) тойган хәлдә күпме торганбыздыр, ул, ниһаять, тагын кузгалды:

— Я, хуш, бәхил бул!

Күзләрен яшереп тиз генә китеп тә барды...

Ап-ак киңлек уртасында, меңнәрчә чакрымнарга сузылган урманнар һәм далаларның, СССР дип исемләнгән чиксез илнең нәкъ уртасында аерылыша алмый газапланган ике кешенең ничек интегүен күрүче булса икән! Ай, елар да иде ул, үксеп-үксеп елар иде, нәкъ шушы күз ачкысыз ак буран шикелле ярсып елар иде! У-у-у-х!..

...Ак кар каплаган, буран күмгән шушы мескен җир шары өстендә яшел сандык бәйләп куелган бәләкәй чана янында уникé яшьлек малай тукталган да тып-тын басып тора да тора. Абыйсы — юл капчыгын аскан юлчы — атлый да атлый. Дөньяда бүген алар икәү генә. Юлчы шулай әкрен-әкрен ераклаша бара. Ераклашканнан-ераклаша бара. Аның төсе, киеме, юл капчыгы да күренми башлый, ул силуэтка, җансыз-тәнсез шәүләгә әйләнә һәм шул хәлдә күз алдына китерергә мөмкин булмаган мәңгелеккә кереп югала... Ул тик шул кыяфәттә малай хәтерендә гомерлеккә, гомерлеккә кала... Хәзер дә шул хәлдә — дөньяда ике кеше. Иксез-чиксез ак бушлык уртасында... ике кеше.

Ике кеше...

* * *

Китте Исәнбәк абый.

Китте дә югалды шулай — суга төшкән таш кебек.

Нәрсә уйларга, бүтәннәргә ничек аңлатырга да белмим. Аннан бер хат һәм бер рәсем генә калды. Чак кына кырыйгарак таралган чәчләре өстәрәк дулкынланып тора. Маңгаенда ике калын гына буразна — бөтен уе, бөтен узганы калдырган серле юл... Дөньяны һаман аңларга тырышкан акыллы күзләре, көләргә дә, көлмәскә дә белми аптырап тынган иреннәре... Берни әйтмиләр... Аннан калган хатны ачып укыйсы килә: шунда ул үзенең киләчәген язып калдыргандыр шикелле. Көненә өч тапкыр ачарга теләп, көненә өч тапкыр үземне җиңеп яшим.

Шулай да, ничек кенә булса да антны бозмаска, егет сүзен таптамаска, үземне җиңәргә, ничек кенә булса да җиңәргә сүз бирдем һәм җиңдем.

Хатны үземнән үзем ерак, ләкин җил-яңгыр тими торган ышанычлы җиргә яшердем һәм аны онытканлыгыма үземне үзем ышандырырга тырыштым һәм ышандырдым. Минем өчен хәзер ул юк. Илдархан абый исән кайтса гына, хәтергә төшәчәк.

* * *

Ә Илдархан абый сугыш беткәч озак та тормады, отпускыга кайтып килде.

Ниндидер йомыш белән (вак-төяк юнәткәләргә бугай) Уфага барган идем. Кайтышлый, пристаньда күрәм: ике кеше сөйләшеп утыра. Икесе дә хәрби киемнән. Яшьрәге — старшина, икенчесе, олырагы — сержант. Карыйм, икесе дә таныш. Яшьрәге — чиста, чибәр... Әсләм абыем бугай бит. Әйе, үзгәрмәгән диярлек. Ә тегесе — Илдархан абыйга охшаганрак. Ләкин олыгайган, шактый ямьсезләнгән... Таныйм. Икесен дә. Ләкин күрешергә, эндәшергә куркам: үз күзләремә ышанмыйча (бу бит артык зур һәм көтелмәгән бәхет — ничек ышанасың!), каршыларына бастым да акылсыз кеше шикелле карап тик торам. Ниһаять, алар да мине күрделәр.

— Вәкил, син бит бу! — диде Әсләм абыем.

— Нишләп эндәшмисең? — дип сорады Илдархан абый.

Шатлыктан, телсез калып, басып тик торам икән. Үзләре йөгереп килеп исәнләштеләр. Мин кул гына суздым. Шундый мәзәграк кеше инде мин. Ай, шундый оялчан малай инде мин, рәтсезең. Алай ярамаганын үзем дә беләм, тик икенче төрле була алмыйм. Таныгач ук ник икесенең дә кочагына асылынмаска, ник шашып ташланмаска инде, кычкырмаска, көлмәскә инде? Ник үз бәхетеңне үзең киметергә?

Хәтеремдә, ул көнне пароходка билет беткән иде. Икенче көнне пароход булмады. Шуңа күрә бер-ике көн шәһәрдә йөрдек, кәртечкәгә төштек — өч туганның күрешү истәлеге хәзер дә саклана.

Өч улы берьюлы кайтып төшкәч, әнинең ничек шатланганын, шулай ук көләргә дә, еларга да белмичә, кочакларга да, кочакламаска да белмичә каушап, диванага сабышкандай өйдә бөтерелеп йөрүен, я касыгын, я табагын, хәтта самоварын да таба алмыйча интегүен сез күз алдына китерә аласыз инде. Бер дә гаҗәпләнерлек түгел. Нәркәс апаның без кайтып ике-өч сәгать үткәч үк унбиш-егерме чакрымлык авылдан килеп җитүе генә гаҗәп тоелды миңа. Шул арада ничек ишетеп, ничек килеп өлгерергә мөмкин икән?! Шатлык — менә нинди ул!

Көянтә-чиләк белән чишмәдән кайтып килүче бер хатынның урам як тәрәзәдән:

— Нәркәс тә килә! — дип әйтүе булды, табын янынnan дәррәү кубып урамга ташландык — иң алда Илдархан абый!

Ул йөгерә, аның каршысына Нәркәс апа йөгерә. Инде кочаклашырга гына калгач, икесе дә шып туктадылар да, икесенә бер сүз әйтешергә онытып, беренче танышкандагыдай, тартынып ырак күрештеләр. Оялуларымы, каушауларымы йөзләренә үк чыккан — кызарганнар, күзләрен бер-берсеннән генә түгел, бездән дә яшерәләр, әйтерсең, мәхәббәт — гөнаһ, әйтерсең, сагынышу — начар хәл, әйтерсең, мәхәббәтнең, еллар буе тупланган сагышның берьюлы шартлавы, башкаларга күрсәтерлек дәрәҗәдә, тыелгысыз хәлдә, язгы буа, язгы су төсле җимерелеп ташуы — оят нәрсә. Бу кадәр сагына алудан гарьләнергә түгел, юк, юк, мең кабат юк — гарьләнергә түгел, бары тик горурланырга гына кирәк ләбаса! Мәхәббәттән тартынмаска, аның рәхәтен, бәхетен, ләззәтен, аерылыклардан соң килгән ләззәтен киметмәскә, җылы диңгезгә ташлангандай бәхет кочагына ташланырга кирәк иде ләбаса!

Менә алар Таһир белән Зөһрә, менә алар Ромео һәм Джульетта — тагын кемнәр... ни өчендер бу юлы үзләренең иң гүзәл, иң сокландыргыч сыйфатларын яшереп, сокланырга гына мөмкин булган көчләрен тыеп, безнең арага кереп, еллар буе бергә яшәгән кешеләрдән берни белән дә аерылмаган кыяфәттә атлап киттеләр. Нәркәс апаны мин җитәкләдем, ул Илдарxан абыйны.

* * *

Бәхетле өйдә йокы да тәмле.

Иртәгесен кояш та шундый күңелле кыяфәт белән каршылады. Сентябрь тирәсе булса да, көннәр җылы килгән иде ул елны.

Ихатага чыктым. Илдархан абый коймa тактасына сөялгән дә хәрәкәтсез калган. Мөгаен, ул иртәнге бакчада мең төрле төс күреп, шул төсләр, шул бакча рәвешендә үзенең киләчәген күз алдыңа китерә торгандыр, мең төрле планнар корадыр...

Янына килдем:

— Нәркәс апа кайда?

Илдархан абый җавап бирү түгел, башын да күтәрмәде. Әллә ишетмәде.

— Нәркәс апа кайда?

Җавап тагын юк. Янында бераз торгач, кояшка каршы, күтәрмәгә килеп утырдым. Алда мунчадан төтен чыга... Утар капкасыннан көянтә-чиләк тоткан Нәркәс апа чыгып килә. Күрәм, аның да чырае качкан.

Менә ул Илдархан абый турысына килеп җитте. Тукталып калды — сүз көтә. Тегесе борылып та карамый.

— Илдархан, нишләп син... шулхәтле... Я инде... Илдархан! Кеше алдында...

Торды-торды да чишмәгә китте. Илдархан абый яныннан ничә кабат узгандыр — һаман күзләрен ала алмыйча, кузгала, китә алмыйча интекте.

— Илдархан, кеше алдында хур итмә мине, җитәр!

Шул сүзне ишетүгә, ниһаять, Илдархан абый тураеп басты. Йөзе көл төсле агарган иде...

— Кем? Кем хур итте сине? Кем? Минмени?

— Илдархан! — Бу сүзне Нәркәс апа кычкырып та, елап та әйтмәде — ин кадерле исемне кадерләп, яратып, күкрәгеннән кысып кына чыгарды.

— Илдархан!

Ярату да, үкенү дә, гафу үтенү дә — барысы да шул сүзгә туплаган иде.

— Әле мин сине хур иттеммени, мине син түгелмени?

— Әйтәм бит...

Илдархан абый тагын коймага сөялде һәм тагын тынып калды.

— Нәркәс, бар кит, җинаятькә этәрмә мине,— диде.

Нәркәс апа көянтә-чиләгеннән бигрәк, кайгы авырлыгыннан сыгылып төште... Тик авыз ачып бер сүз дә әйтә алмады. Берсе коймага сөялеп кенә егылмыйча тора, икенчесе — көянтәгә. Арада — бушлык, күзгә күренми торган чәнечкеле койма... Араларыннан кемдер узган... Капкадан кап-кара күлмәкле хатын чыгып бара. Таныш хатын, күрше авылдан — Мәүлия исемле...

Ашыга-ашыга өйгә кердем дә каушый-каушый сандыкны ачтым. Китап-дәфтәрләрне бутый-бутый актарып, Исәнбәк абый хатын эзлим. Көчкә таптым. Югалган дип кот алынды. Берничә минуттан Илдархан абыйның чырае яктыра башлар. Хат! Бөтенесен төзәтәчәк хәзер — сихерле хат!

Чыктым.

Илдархан абый үзе генә — бакча эчендә утыра иде.

Шунда кердем:

— Исәнбәк абый сиңа хат калдырган иде.

— Хат? Нинди хат?

— Менә! Мә, укы! — Ул кулын сузмагач, аптырап өстәдем.— Сиңа!

Илдархан абый, «Нинди беркатлы кеше син!» дигәндәй, кимсетебрәк карады да кулын селтәде:

— Жирәнәм!

Каттым да калдым.

— Бар, алып кит! — дип җикерде ул миңа.

— Юк, мин китә алмыйм, син укырга тиеш — гафу итәргә...

— Хыянәт гафу ителми.

Җавап табалмыйча аптырап калам. Нинди сүз! Миңа хәзер унсигез яшь, аңлыйм — беләм, кайбер хисләр белән танышлыгым да бар... Бу сүзләрне әйткәндә, ул, солдат, артиллерист, бер атылган снарядны яңадан үз урынына кайтарырга мөмкин түгеллеген, киселгән кул яки аякның кире ябышмавын хәтеренә китергәндер. Ә йөрәк хакында... Йөрәк хакында әйтәсе дә юк. Аны үз урынына кую турында уйлау да куркыныч. Хәл шундый. Сизәм, ярдәм итәргә телим, тик көчем җитми — юк, җитми көчем. Шулай да, эскәмиядә озак вакыт утыргач әйтеп карыйм:

— Әйдә, онытыйк, әйтмик беркемгә.

Илдархан абый баягы кимсетүле карашы белән генә карап куйды.

— Һы!

— Исәнбәк абый әйтте, «Бездә бернинди гаеп юк», диде. Гайбәт ишетсә, ышанмаска кушты.

— Нинди гайбәт?!. Шулай гына булса! — Илдархан абый үрсәләнеп, төйнәлгән йодрыкларын баш өстендә уйнатып, аннары хәлсезләнгәндәй, тез башларына ябышты. Мин аны чак кына сүрелә төшкән дип ялгыштым һәм үзем дә сизмәстән дәвам иттем:

— Аңласаң, син гафу итәргә тиеш. Җинаять түгел бу. Һәлакәт! Һәлакәткә юлыккан өчен кешене тиргәмиләр.

— Кем сүзләрен сөйлисең син, ә?

— Миннән башка аның сүзләрен кем сөйләсен хәзер. Ул бит үзе сөйли алмый, аның өчен — мин...

— Пычрак эшкә тотынгансың...

— Үлгән кешене тиргәргә хакың юк!

Шушы сүзне ишетүгә, аптырап ул да тынды — мин дә. Мин үземне чынлап та Исәнбәк абый дип исәплим һәм коточкыч оялу хисе кичерәм...

Кузгалырга да, сүз әйтергә дә батырчылык итә алмыйча, зиһенне җыя алмыйча, күпме торганбыздыр, урам яктан әни күренде һәм безгә таба елмаеп килә башлады. Тик безнең чырайга карап, елмаюы әкренәкрен сүнә, сүрелә барды һәм борчылу, ярдәм итәргә теләү белән алышынды.

— Берәр хәл юктыр бит? Ник алай сез?..— диде әни якын ук килеп һәм нелә төшеп.— Ник болай? Ни булды? Ягез инде... Миңа кара сиңа...

— Юк, әнкәй, берни дә юк,— дим мин, Илдархан абыйның ярамаган сүз ычкындыруыннан курыккандай.

— Нәрсәдер бар ла, сизәм бит, сизәм.

Мин дә сизенәм. Кинәт Илдархан абый кузгалыр да коточкыч сүзләр әйтер, үзенең кичә генә, бүген генә, миңа шушы минутларга чаклы исән булган, сугышлардан, походлардан, кан, ут эченнән тәтен арасыннан, үлем авызыннан йолкып алган бәхетен, киләчәген бер селтәнүдә челпәрәмә китерер дип котым очып тора.

Илдархан абый, күтәрелеп карарга оялгандай, шактый озак сүзсез торды. Утырган җиреннән бер торып, бер утырып интекте. Бүтәннәр гонаһысы өчен үзен гаепле сизгән шикелле, урын тапмыйча, китәргә дә, китмәскә дә белмичә, кызарып иза чикте. Аның белән бергә мин дә.

— Кычкырыштыгызмы әллә? Язмаганны! Каян чыккан ди ул. Бала чакта сугышмаганны!

— Болай гына,— диде сыкрануыннан туктый алмаган Илдархан абый,— ялгыш бәрелде, яраланган төш...

— Яраланган төш!

— Синең ярың да бармыни? — дидем бу көнгә чаклы шушындый әһәмиятле нәрсәнең миңа билгеле булмавына гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча.

— Ботта минем яра, төзәлми диңкетте.

— Әйбәт! — дидем мин, Илдархан абыйның баягы серне яшерә, йота алуына куанып.

Сүзне әни үзенчә кабул итте:

— Яра әйбәт буламы инде...

— Тән ярасы төзәлер...

— Шулай шул... Күңел җәрәхәте генә төзәлми диләр бит, — диде әни кузгалып. — Әйдәгез, керегез инде, чәй әзер, — дип, өйгә кереп китте.

Илдархан абый күкрәге белән тагын бакча коймасына сөялде. Кесәләрен капшагандай итте дә тәмәке төрде һәм озаклап тәмәке тартты. Мин инде аны сүз белән, сораулар белән борчымаска булдым. Болай булгач, аңлашылды бугай: әнидән шергәч, ул гафу итәргә тырышачак, димәк. Чын ир икән Илдархан абый, җинде үзен, гарьлеген һәм... Көпәкөндез, ап-аяз көнне сугасы яшен чатнамый калды, гарасәтле яңгыр читләтеп узды. Шулай уйладым да тынычландым. Эчтәлеге миңа билгеле булмаган әлеге хәерсез хатны, җан өшетеп торган ниҗәмә еллык шомлы серне кулда тоткан хәлдә чишмә юлына киттем. Чишмәдән ерак та түгел ур [1] суы ага — хатны, ни өчендер, шунда ыргыттым. Исәнбәк абыйның соңгы өмете бөтерелә-бөтерелә агып китте... Һәм мин аны шул килеш оныттым. Дөресрәге, онытканлыгыма үземне ышандырырга тырыштым, ләкин ышандыра алмадым. Хәзер, дөресен әйтим, хатны ачып укымаганыма, суга агызып җибәрүемә үкенеп бетә алмыйм. Илдархан абыйга әйтәсе сүзләре генә түгел, бәлки Исәнбәк абыйның йөрәгеннән бары тик бер генә кат ургып чыккан «аһ!» дигәне шул хатта агып киткәндер?

Ә хәзер без юрарга гына тиеш...

* * *

Бер-ике көн чырайсыз йөргәннән соң, Илдархан абыйның әкренләп «тән җәрәхәте» төзәлде шикелле. Китәр чагы җиткәч исә, елмая ук башлады.

Соңгы кичтә генә, башына колмак әчелеге менгәч, елаумы, җырмы икәнлеген аера алмаслык тавыш белән көйләп куйды:

Җырлау түгел, жыларсың да,
Ятлар сөйсә ярыңны...

Нәркәс апа белән без аларны ике-өч чакрым җирдәге олы юлга чаклы озата килдек. Нефтебазага керосинга баручы очраклы машинага утыртып та җибәрдек.

Киттеләр. Икәү генә калдык. Әллә аерылу кайгысыннан, әллә тынгысыз уйдан башларыбыз иелгән. Тын гына атлыйбыз, җәйге басу буйлап өйгә кайтабыз.

— Исәнбәк абый нәрсә язган иде теге хатта? — диде Нәркәс апа борчылуын яшерергә теләмәгән тавыш белән.

— Нинди хат? — дидем мин аңламаганга сабышырга тырышып. Ә баштан ялтырап мәзәк сорау узды: «Кай арада күреп алдың соң әле син аны?»

— Я инде, яшермә инде миннән. Дуслар бит без синең белән. Теге көнне... иртән... икегез утырганда... Кем хаты иде ул? Исәнбәк абый хатымы?

[1] Ур — ясалма инеш.

— Илдархан абый аны укымады...

— Эх, Исәнбәк абый! — дип кабатлады Нәркәс апа әллә нәрсәдән бик каты кайгырган төсле. Әйтерсең, мин яраткан исем аның өчен яман бер нәрсә иде.

— Ул хат инде нигә кирәк соң? — дидем күпмедер җир атлагач. Әкуңелдән: «Исәнбәк абый белән дә һаман кызыксына» дигән уй узды.

— Әйе шул... кирәкми... Мин болай гына ..

Кайтып җиткәнче бүтән бер сүз дә булмады. Үз-үзен тотышында, чыраенда Нәркәс апаның ниндидер өметсезлеккә бирелүен, читсенүен, ятсынуын сизәргә мөмкин иде. Бу аның икенче кешегә әверелә башлавы иде бугай.

* * *

Нәркәс апа берничә ай буе күзгә күренмәде. Ничек, нинди уйлар белән яшәгәндер. Көзге айларның берсендә укыткан авылыннан бер апа белән кайтышлый бездә чәй эчеп, җылынып, үз авылларына киткән чакта икәү генә капка төбендә калган идек — бик ямансу кыяфәттә пышылдап әйтте:

— Илдархан абыеннан хат килде

— Кайчан кайта?

— Кайтмыйм дигән.

— Кайтмыйм дигән?

— Аның белән безнең ара өзек хәзер.

Берни аңламыйча тын калам.

— Көтмәскә кушкан. Иргә чыгарга кушкан.

Табигый, тагын сүз әйтә алмыйм — аптырадым да калдым.

— Ни дигән сүз инде ул?

— Менә шулай инде. Җимерелде...

— Мөмкин түгел!

— Их, апаем, белеп бетермисең шул син. Белеп бетермисең.

* * *

...Көннәр үтә, демобилизацияләнгән солдатлар бер-бер артлы кайта тора. Ә безнекеләр юк... Мин көтәм, миннән бигрәк әни көтә. Әллә нинди буталчык төшләр күрә-күрә көтә — иртә — таң аттымы, берсеннән-берсе яман төшләр сөйләп аптырата.

Язгы ташу вакытлары җитте.

Язның бер матур көнендә шундый коточкыч хәбәр килде: имеш, Агыйделне җәяү чыгып килүче бер солдат, бу ярга җитәрәк, боз кузгалган җиргә туры килгән дә — батып үлгән...

Яхшы хәбәр җәяүле кеше тизлеге белән йөрсә, начар хәбәр җил тизлеге белән оча... Бу хәбәр безнең якны аркылыга-буйга көнендә үк әйләнеп чыккандыр һәм ул, легендага әйләнеп, озак еллар телдән телгә күчеп йөриячәк. Сугышта баласын җуйган меңнәрчә ана, меңнәрчә ата, апа-сеңел, агай-эне, кайтып җиткәч суга төшеп югалган солдатның үз улы, үз энесе, үз абыйсы икәненә ышанып, күпме көннәр буе уйлана-уйлана, юрый-юрый, ышанмаска үзен мәҗбүр итәргә тырыша-тырыша һәм барыбер ышандыра алмыйча күпме яшь түккәндер!

Безнең әни дә шулай хыялыйга әйләнә язды. Күпме тынычландырырга теләмә, барыбер файдасы юк.

— Ул солдат, Илдархан булмаса, кайда соң минем Илдарханым? Бөтен исән кеше кайтып бетте, ул гына юк. Шулдыр. Илдархандыр, минем баламдыр, бүтән кеше булмас. Нинди олы сугыштан исән калгач, өенә кайтып җитте дигәндә, батып үлсен инде! Акылдан язмыйча ничек түзмәк кирәк моңа!

Айлар узган саен, әнинең кайгысы һаман тирәнәя барды — кая оныту! Акылдан язмасын дип чыннан да куркабыз. Үзебез дә ни әйтергә белми газапланабыз: суга төшкәндәй югалды Илдархан абый, чынлап та.

Җәй дә үтте, көз дә җитте.

Бу вакытларда мин үземнең нинди авырлыклар кичерүемне, үз-үземә урын таба алмыйча бәргәләнүләрем, эзләнүләремне язып тормыйм инде. Чөнки сүз бүтән хакта бара бит...

Көзге көннәрнең берсе «Нәркәс апа кияүгә чыккан» дигән хәбәр китерде. Өметен өзгән икән, бичара... Бөтенләй ялгыз калудан курыккандыр: ашыккан Нәркәс апа, бигрәк ашыккан! Кем белә, бәлки Илдархан абый исәндер дә әле, ниндидер исәп белән яки мөмкинлеге юктан, чарасыз кайтмый торгандыр. Алай дисәң, хат язар иде...

Нәрсә уйларга белми аптырашта калган кышкы көннәрнең берсендә хат та түгел, хәбәр дә түгел — Илдархман абый үзе — хәбәрсез-нисез һәм, турысын әйтсәк, көтмәгәндә һәм өмет инде өзелә язды дигәндә, кайтып төште.

Исән! Исән Илдархан абый!

Тик...

Ул инде элекке Илдархан абый түгел. Ничек үзгәргәнен тәгаен әйтә алмыйм, тик аның тышкы кабыгы гына кайткан иде, минемчә. Ә җанын, элекке якты күңелен, ягымлы рухын — чыраен кайдадыр калдырып, югалтып кайткан иде ул. Элекке кебек йомшак холыклы, матур кеше юк, ниндидер миңа таныш булмаган, кырыс, аз сүзле һәм... миңа охшап бетми торган бер кеше кайткан. Тышкы кыяфәте дә әйбәт хис тудырмый: әллә нинди формасыз, озынча тәпиле, бераз өскәрәк тә күтәрелеп торган очлы пималар... калын, сырган яшел чалбар һәм фуфайка...

— Шинелең юкмыни? —дип сорадым бер көнне.

— Авыррак хәлгә калгач, сатарга туры килде,— диде ул исе китмичә генә.

— Кайда йөрдең?

— Чарджоу ягында.

— Ник кайтмадың?

— Сиңа кирәкми анысы.

— Ә әнкәйне күпме яшь түктердең? Ул яшьне ничек түләрсең?

— Синең эш түгел, үзем карармын.

Гаҗәп инде, үз туганымда, үз әниемдә нишләп эшем юктыр минем! Башсыз! Кансыз! Ни ди бит!

— Нәркәс апага ник кияүгә чыгарга куштың?

Җавап юк.

Менә сиңа Илдархан абый — теләсәң ничек ышан һәм ярат. Юк, көчем җитмәс минем — элеккечә ярата да, кабул да итә алмам мин аны, мөгаен!

Ничек дидем? Кеше әллә яшь чагында гына әйбәт буламы, зурайгач, шушылай ямьсезләнәме? Ничек? Ник? Җиңел генә баш тартам түгелме? Аңларга тырыштыммы соң әле мин аны? Бөтенләй тырышып карамадым бугай бит әле. Әйе, түземлерәк булырга, аңларга, әлбәттә, аңларга кирәк.

* * *

Илдархан абый элекке эшенә — яңадан хисапчылыкка керешкәч, эчкә җылы кергәндәй тоелды. Бәлки шунда — яшь чакларындагы шикелле тормышның матурлыгын, мәгънәсен яңадан табар... Язмыштан узмыш юк дигәндәй, аптырарлык нәрсә түгелдер бу: тормышын өр-яңа-

дан корган кешеләр азмыни! Нәркәс апа кебек әйбәт кызлар да бетмәгәндер. Белмәссең...

Башта ук әйтик, өметебез акланмады безнең: өс-баш начар, шуны рәтләргә дип, күпмедер акча юнәтте дә, эшен, вакытлыча гына дип, миңа калдырды да ниндидер бер ерак шәһәргә китеп барды. Бер атнага киткән кеше унбиш көннән соң гына кайтып керде һәм үзе генә түгел: күрше авылдан Гадилә исемле бер кыз белән. Юлда табышканнар — өйләнергә план корганнар, имеш....

Мин хисапчы кеше түгел, үзегез беләсез, бу эшне рәтләп эшли дә белмим, холкым да андый түгел. Кире үзенә тапшырам икән дип сөенсәм, буш куаныч: Гадиләсе сәүдәгә остарган булып, өйләнешкәнче тормышларын бөтәйтергә чамалап, тагын сәфәргә китәләр икән. Өйдә булганнарын беркемгә дә әйтмәскә куштылар һәм китеп бардылар.

Тагын ярты ай чамасы вакыт узгач, «Илдарханнар кайткан» дигән хәбәр таралды. Күрше авылда — Гадиләләрдә ята икән... Янына бардым, өйгә чакырдым, әнинең елавын, кайгыруын әйтеп карадым — ярдәме тимәде, кайтмады...

— Чисти азаланган икән! — диде әни, мин кайтып хәлне сөйләгәч.— Ходаем, рәнҗермен дә рәнҗешем төшәр дип куркам. Бәхетсез итәрмен дип куркам. Ай, балакаем! Язды бит юлдан! Балакаем!

Күпмедер вакыттан соң законсыз сәүдә итүдә гаепләп, Гадиләсен дә, үзен дә төрмәгә яптылар. Судка безне шаһитлар сыйфатында чакырганнар иде.

Бу көннәрдәге хисләрне яңартасым килми... Хәтер курка, уй курка, тән чымырдый һәм вөҗдан чиркана... Безнең өйдә, безнең нәселдә (әни әйткәндәй) мондый да түбән төшүне моңарчы белми дә, күз алдына да китерә алмый идек без.

— Атагыз исән булса... болай булмас иде. Ятим үскәннең шул инде аның, шул, көчем җитмәде, тәрбияли белмәдем,— дип өзгәләнде әни.

Нинди тәрбия инде ул монда? Кеше үзе балигъ, үзе җаваплы бит хәзер! Үзенә җык та булмас (ачудан әйтүем), биш елын тутырыр да кайтыр. Әни бар бит, ул кызганыч!

Биш ел буе җәяүләп яки ни туры килде шуңа утырып, капчыкка май, эремчек, криндель тутырган хәлдә, җәйге чилләләрдә, көзге пычракларда, кышкы бураннарда кимсенеп һәм кимсетелеп, төрмә капкасы төбенә минем әни барачак бит инде хәзер... Минем әни! Безнең әни!

Илдархан абый, уйладыңмы син бу хакта? Уйладыңмы?

* * *

Биш елын тутыргач, Илдархан абый тагын авылга кайтты. (Мин, студент, аның кайтуын телеграмма белән котладым, куанычлы хезмәт, бәхет теләдем.)

Ел ярым чамасы авылда эшләде, өйләнә алмыйча (кемне генә димләп карамаганнар дисең — берсен дә яратмаган!) теләсә кая сугылып, төрле эштә йөргәннән соң тагын китеп барган.

Икенче юлы мин авылга каникулга кайткач, бергә туры килдек. Кунакка кайткан: Шура исемле, үзеннән ун яшькә өлкәнрәк хатынга өйләнеп.

Бер ай бергә булдык. Аек чагын бер-ике генә көн күрә алдым. Арлы-бирле сугылып йөри дә терсәкләре белән өстәлгә таянып, ике кулы белән ике як чигәсен тотып, таныш җырны шыңшый:

> Җырлау түгел еларсың да,
> Ятлар сөйсә ярыңны...

Бер аек көнендә — әле һаман да бүлмәдә эленеп торган мандолинаны кулына алып, көйләп карады, чиртеп карады — тавыш чыкмады —

зыр-зыр килеп, гыжылдап тик тора инструмент. Соңыннан ул аны утынлыкка алып килде дә утын кискәсенә җан ачуы белән китереп орды... Кемнеңдер аягыннан тотып, башы белән орган төсле...

Ике-өч елдан өйгә бер хат килгән иде.

Беренче хәбәр: Шурасы белән тора алмаган. Аерылышканнар.

Икенче хәбәр: йөрәгенә зәгыйфьлек килеп, абыебыз больницага кергән.

Өченче хәбәр: башка шәһәргә күчкән... Кайсы шәһәр икәне язылмаган.

Бүтән хат та, хәбәр дә юк.

Исәнме, түгелме — белмибез.

Югалды.

Шулай, күз алдыбызда диярлек, карап торган хәлдә диярлек бер кеше югалды...

Минемчә, сәбәп, теләсәк тә, теләмәсәк тә — Исәнбәк абый һәм Нәркәс апа...

Исәнбәк абый, бу — синең эш. Исәнбәк абый! Ник эндәшмисең?

Шулай шул, син күптән үлгән кеше бит. Ләкин бу аклану түгел. Кайбер гөнаһлардан үлем дә акламый... үлеп тә акланып булмый. Әйт, син шулхәтле гаеплеме? Ник эндәшмисең? Үлемнең шактый җитди нәрсә икәнен уйлап кына бераз сабыр итәм. Көтәм.

Ә син, Нәркәс апа? Син дә җаваплы.

Ни өчен эшләдегез сез бу эшне? Ник?

Сез җавап бирергә тиеш. Әйе.

## ИКЕНЧЕ МОНОЛОГ

Вәкил энем!

Әгәр кешегә ышансалар, ул акыллыга әверелә. Акыллы сүз әйтсен дисәң, син дә ышан миңа, Нәркәс апаңа.

Безнең Череккүл авылына ел саен килмисең син. Әллә ямен күрмисең инде. Базы буена иркенләп аяк сузган да ямь-яшел дөнья эчендә күмелеп утыра Череккүл. Кемнәр генә узмый бу авылдан. Теге заманнардан бирле кемнәр белән генә күрешелмәгән. Мин инде кешеләргә илтифатсызга әверелә башладым бугай. Үз турыбыздан узган-барганнарга күз дә салмыйм. Югыйсә бит шундый гадәт авылда, беләсеңдер, нинди дә булса ят кеше күзгә чалынса, безнең хатын-кыз тәрәзәгә каплана. Уңайсызланып та тормый. Күздән җуелганчы карап кала юлчыны. Мин алай түгел. Әмма да бер юлчыга игътибар иттем.

Ямь-яшел чирәм үсә безнең урамда. Урамның икенче ягындарак ят кеше тукталды — балалар белән сөйләшә. Каршысына сабый — кыз бала килеп басты:

— Кулыңны күрсәт әле, абый, нинди икән?

Юлчы кулларын ачып күрсәтте — уч төбен һәм кул аркасын. Бала җентекләп карап торды — әйтерсең чегән кызы.

— Син әйбәт кеше икән, абый.

— Ник?

— Начар кеше бармакларын җыеп күрсәтә, йодрык төсле итеп. Бәхәсләшмәделәр.

Ят кеше елмаеп үз юлына китте, балалар аны:

— Син кемгә киләсең, абый?

— Нигә безгә килмәдең? — дип озатып калдылар.

Аны туктаткан кыз бала — минем иң кече кызым Әлфия. Ә узып баручы? Мин аны сиңа охшаттым Вәкил энем. Син идең бит ул? Әйе, мөгаен син идең. Чирек гасырдан соң исеңә төшереп килүеңә, карап китүеңә рәхмәт. Ә шулай да ник кермәдең?

Бу авылда миннән башка беркем дә сине танымагандыр. Алар сине чынлап та белмиләр. Күргәннәре дә юк. Ә мин беләм. Ни өчен читтән генә булса да минем өйгә, минем тормышка күз салып узуыңны сизенәм. Хәтта нәрсә уйлаганыңны да чамалыйм. Бик тә, бик тә якыннар идек бит без синең белән.

Ә шулай да ник кермәден соң әле син минем янга? Сөйләшмичә, һич югында күзләремә карамыйча ничек узып китә алдың син, Вәкил энем?!

Бу өй беркемнекеннән дә әллә ни аерылып тормый. Өянкеләре белән дисәң, алар урам буйлап тезелгән. Шифер түбәсе, телевизор антенасы беләнме? Юк, андыйлар да хәтсез күренә хәзер — елдан-ел күбрәк күренә. Капка төбендә торган матай беләнме? Юк. Бернинди дә шаккатырырлык аерма юк. Ә ныклап уйлый китсәң, һәр өйнең үз сере бар!

Мич тирәсендә өй саен бер-берсенә су тамчылары кебек охшаган хатыннар әйләнгәли. Кояшта янган битләре, юантык билләре, алъяпкычлары, яулыклары — хәтта сөйләшүләре белән дә бер-берсеннән ерак китмәгәннәр алар. Менә син шуларның берсенә тукталыбрак карадың да уйланырга мәҗбүр булдың. Су кебек, үзе пешергән аш, икмәк кебек гади бер хатын. Кайчандыр чибәр, җилкенчәк кыз булган. Инде тугыз баласы... Героиня! Бер баласы вуз бетергән — үз тормышы, калганнары урта мәктәптә... Иң кечесе анә синең белән очрашты.

Безнең өй дә бүтәннәрнеке кебек үк. Бу өй, бу гаиләнең дә бүтәннәрнеке кебек үк үз бәхетләре, үз борчулары, үз шатлыклары бар... Һәм... бу өйнең дә — безнең өйнең дә сере бар. Ата — гаилә башлыгы белми, балалар башларына да китерә алмыйлар. Ә син, Вәкил, беләсең...

Мич һәм казан тирәсендәге мәшәкатьләр белән яшәүче хатын уйлыйдыр бәлки: мин генә шундый уйлар белән хыялланып йөрим, мин генә күңелдә сер саклыйм дип. Ләкин һәркемнең яшьлеге булган, мәхәббәтеме, мәхәббәткә якын хыялымы калган. Аны теләсә кемгә сөйләп йөрмиләр бит. Шулай, өйләрнең тәрәзәләреннән карасаң, барысы да бертөсле, ә күңелләренә карый алсаң, уф...

Һәркемнең күңелендә ай күмелгән.

Мин үземнең ямансу көннәремдә бер сәбәпсез күлә торган елларымны, болытсыз таңнарымны, көтеп алган кичләремне, үземә генә әйтелгән мактау сүзләрен (әйе, әйе, мактау сүзләрен, алар да кадерлегә әйләнде бит хәзер — теләсәң дә хәзер ишетә алмыйсың — көт син — кем әйтер аларны!), агачларның төнге шыбырдавын, болыннар, елгалар кичкән яланаяклы ике яшь кешене — мәхәббәт исеме катнашкан, тик үзебез генә белгән серләр кушылып яңгыраган, бөтен халыкка ялгыш кына бертөсле булып ишетелгән таныш җырларны сагынам. Дөньядагы барлык шау-шудан аерылгандай тыныч, ялгыз калган чакларымда мин хәзерге күңелле җырларны түгел, элекке ямансу һәм салмак көйләрне җырламакчы булам. Ләкин тавыш та элекке түгел — аңа кушылучы да юк. Ә элек бар иде. Икәү идек без. Икенчесе — Илдархан.

Хәзер аларны мин югалттым — икесен дә.

Ничек дисеңме?

Сугыш беткәч, Илдарханның отпускага кайтканын хәтерлисеңдер. Ул утырган машина күрше авыл кибете янында туктап торганда ук миңа телефон шалтыравы килеп җитте. Хәбәрне тиз генә директорга әйттем дә җәяүләп чаптым. Ашыгудан абынам да егылам, абынам да егылам. Ярый әле юлда бүтән беркем дә күренми — карап торучы булса, шаккатыр иде. Унҗиде чакрымның җидесен шулай үзгач, хәлдән таеп чирәмдә утыра идем, шәп кенә атлы тарантас күренде. Этәй

авылыннан колхоз председателе икән — очыртып дигәндәй алып кайтты. Аннан инде — чакрым ярым гына...

Кайтып та җиттем. Саз аркылы сузылган салам күпер буйлап килгәндә, тау башыннан сез күрендегез. Сезнең каршыга, бәхетем, Илдарханым каршына ашыгам, төркем арасыннан аны эзлим, күрмим тик. Сине шундук танадым. Ике кеше хәрби киемнән, берсе Илдархан булырга тиеш, чак кына охшаган да бугай... Тик кинәт туктаддым да калдым — Илдархан урынында бөтенләй бүтән кеше басып тора. Үзгәрсә дә үзгәрә икән кеше!

Минем Илдарханым чын мәгънәсендә чибәр, сирәк чибәр иде. Елмаю, бераз гына каушау, бер минутка да сүрелеп тормаган мәхәббәт белән караган, бераз гына сөрмәле зур коңгырт күзләр, чип-чиста түгәрәк йөз, шикәр төсле ап-ак тешләр... Ай шикелле балкып торган бәхетле егет иде минем Илдарханым. Шундый егет озатып, шул егетне көтә идем мин. Ә каршымда... Кем аны алмаштырган? Еллармы, сугышмы? Кайда минем үз Илдарханым? Бирегез аны миңа, үзем сезгә тапшырган кадерле, чибәр, гүзәл кешене!

Әйтерсең, чынлап та бөтенләй чит кеше кул бирде — хәтта елмаюы да икенче... Мин аңа сүз дә әйтә алмадым, тирә-якта кеше булганга, уңайсыз хәлдә калмас өчен генә бергә атладым.

Өйдә вак-төяк ыгы-зыгыдан соң табын оешты. Шуңарчы, Илдархан минем үзем белән генә калырга, еллар буе саклаган сүзләрен әйтергә җай эзләр дип, читтәрәк йөрсәм дә, ул, ни өчендер, мин эзләгән тынлыкны эзләми, шау-шуның нәкъ эчендә булуны артыграк күрә бугай. Әллә аны җибәрмәделәр, әллә чит кешеләрне калдырып торырга үзе кыенсынды...

Мәҗлес башланып, Бөре шәһәреннән кайта торган теге тәмсез көмешкә исен аңкытып, исән-сау кайтучылар хөрмәтенә бик тәмләп тост күтәрделәр. Илдархан да. Ә мин стаканның ирнәвенә генә кагылдым да «хәзер» дигән булып, иҗатага, аннары бакчага чыгып утырдым, Илдарханны көттем. Сәгатьләр буе көттем, чыкмады. Тәрәзәдән мәҗлес шаушуы, исерек җыр гына ишетелеп торды. «Мин яраткан Илдархан болай эшләмәс иде...»

Ниһаять, чыктылар. Ләкин һаман исерек сүз, миңа таныш булмаган истәлекләр. Илдархан бакча янына килде — мине эзләп түгел ләкин.

— Бә-әй, Нәркәс, нишләп син берүзең?

— Белмим шул...

— Как это так белмисең? Их, Нәркәс, Нәркәс!

Кулларымны тотты, юк, элекке кайнар, мәхәббәт дулкыны бәрелеп торган куллар белән түгел, каты һәм салкын куллар белән. «Юк, бу бөтенләй ят кеше, чит кеше!» Сүзләремне куәтләп, битләремә көмешкә һәм тәмәке исе бәрелде. Минем Илдарханым тартмый иде. Кочаклады — карышмадым, түздем. Ләкин сизәм, озак түзә алмаячакмын...

Шулай шул, ирләрнең кайберсе сугыштан тупасланып, ямьсезләнеп, бозылып кайтты... Җитмәсә, үзләренең күзгә кырып салырлык кына, аз, кадерле икәнлекләрен сизеп, һаваланып... Хатын-кыз, мескен, аларга ярарга тырыша, җайлаша, үзен-үзе кимсетә... Мин алай эшли алмаячакмын, үземә өстән карарга рөхсәт итмәячәкмен. Ирләр мине ихтирам итәргә тиеш, Исәнбәк абый кебек...

Гөнаһыбызга кермим, мәҗлестән соң сагынулар һәм көтүләр хакында сүзләр булды, ләкин аларда да элекке табигыйлек, сафлык сизмәдем мин. Гомумән матурлык, чын мәхәббәт ерак иде шикелле! Без хәзер, мөгаен, күңелне дулкынландырган бик күп гүзәл нәрсәләр, әйтик, Жан Кристофның нечкә күңеле, эзләнүләре, гүзәл әсәрләре, мәхәббәте, дуслары хакында, Пиквик клубы әфәнделәренең беркатлы маҗаралары хакында, аннары мәшһүр шагыйрьләр, артистлар хакында, ниһаять, киләчәккә булган өметләребез, хыялларыбыз, бәхет һәм мәхәббәт ха-

кында сөйләшергә тиеш идек. Жиде еллык аерылышудан соң күпме сүз җыйналган булырга тиеш иде!

Юк, мин артыграк таләп куям бугай, юлдан кайткан кеше бит Илдархан. Алай дисәң, мәҗлес өчен ник арымаган?

Инде яктыра да башлады. Торып утырдым. Өйалды стенасыннан иртәнге кояш яктылыгы үтеп күзне камаштыра. Ә без караңгыда. Тыныч йоклый Илдархан...

Әгәр ул элекке булса, мин уянганны сизәр, үзе дә уяныр һәм нидер сораштыра, иркәли башлар иде. Юатыр иде, Исәнбәк абый кебек...

Тукта, ничек дидем? Исәнбәк абый! Әйе, ул! Ул бит миңа мәхәббәтнең бөек хис икәнен, гүзәллек икәнен аңлатып китте! Күзләремне ул ачты. Аны очратмаган булсам, бәлки Илдарханның үзгәрүен дә сизмәс идем. Шушы икән бәхет, шушы икән ир дип, гомер буе тыныч яшәгән булыр идем. Хәзер минем чагыштыру берәмлеге бар: Исәнбәк абый! Уф! Сизәм, бик яхшы сизәм мин Исәнбәк абыйның чагыштыргысыз акыллы, игътибарлы, гүзәл икәнен, идеал икәнен... Шикәр татып карамаган кеше аның тәмен белмәгән кебек, аны очратмаган булсам... Әгәр очратмаган булсам! Мин моны уза торган бер кызыгу дип кенә уйлаган идем бит. Ә күңелдә — авыр йөк һәм мин аны күтәрә алмаячакмын, аннан йогып калган тынгысыз чирне, җавапсыз мәхәббәтне яшерә алмаячакмын. Илдархан белергә тиеш, аның алдында йөзем ак булырга тиеш, ул мине гафу итәргә тиеш...

Илдарханны армиягә озатканда беренче кат шәрап эчкәнемне хәтерлим. Дөнья кинәт җиңеләеп китә, гаҗәеп төсләр уйный күз алдында, аяклар үзләреннән-үзләре атлый. Гүя син — һава шары. Авырлык, каршылык, проблема дигән төшенчәләр бөтенләй юк нәрсә икән ул. Бер генә хис били күңелне: кемнедер яратасың, өзелеп-өзелеп яратасың. Бу хис үзе дә шәрап кебек, бераз ачы, бераз шикәрле. Ә айныгач... Айныгач, үзең дә шаккатасың: нишләп курыкмыйча кул суза алдым икән шул исерткеч тулы бокалга? Бокал тулы — яшьлек тилелеге, тыелгысыз дәрт...

Беренче күрешкәндә үк — хәзер инде шулай аңлатмакчы булам — Исәнбәк абый миңа әллә нинди ымсыну, курку, каушау, тагын нинди-дер бүтән, әйтеп аңлата алмаслык мәгънәле күзләр белән карады һәм шул каушау, кинәт миңа да күчеп, нindидер тынгысыз һәм ләззәтләрәк аптырау белән күңелне актарып ташлады. Ник бу болай, ник? Яшермим, күп ирләр карашын очратканым һәм сынаганым бар. Берсе яратып карый, икенчесе — кызыгып, өченчесе (монысы ешрак) сине күлмәксез итеп күз алдына китерә (гафу итегез, дөресе шул) — ә төбендә бөтенесе бер үк талпыну — табигать... Ә Исәнбәк абый бөтенләй бүтән күз, бүтән мәгънә, бүтән кичерешләр белән карады — ул карашта нindидер миңа таныш булмаган саф һәм төпсез тирәнлек бар иде. Мин аңа карарга батырчылык иттем һәм кинәт баш әйләнеп китте... Ах, белсәң иде, нинди илаһи мәгънәләр, нинди илаһи хисләр икән ул тирәнлектә?! Кешеләрнең генә түгел, дөньяның да нindидер бер почмагы күренмәгән икән миңа бу көнгә чаклы. Ә минем күрәсем килә.

Кулына кәгазь-карандаш туры килдеме, Исәнбәк абый нindидер сызыклар сыза, сурәт ясый. Сызыклар күп төрле, ә рәсем — бер генә: кош сурәте — ни өчендер, бер генә канатлы. Ник алай икәнен сораган идем:

— Бер канатын җуйганга күрә,— дип кенә куйды, бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Әмма да сурәтнең гади генә нәрсә түгеллеген чамаларга мөмкин иде. Икенче юлы үзе юкта күрдем: шул сурәт астына йөз кабаттыр: «Бәхетле булыгыз!» дип язган. Өстәлдә калган шул язудан йөрәккә тагын да авыррак тойгылар күчте. Димәк, ул...

Беркөнне иртән әле уянмаган дип торам — тып-тын ята, хәрәкәтсез. Ә күзләрендә... күзләрендә яшь! Ул мине күрми дә, каядыр еракка,

еракка караган. Ямансу, өметсез күзләр... Гомерлеккә калды күңелдә. Аңладым, коточкыч фаҗига яшерелгән бу күзләргә, ерак яшерелсә дә, артык олы булганлыктан, бер генә күңел сыйдыра алмый аны. Кемдер бүлешергә тиеш аны, уртаклашырга. Фаҗига... Нинди фаҗига?

Шунысы хак — мондый да бәхетсез кешене минем гомеремдә дә күргәнем юк һәм аны кызганмау, хәлен җиңеләйтергә тырышмау коточкыч кешелексезлек булыр иде. Ярдәм итәсем килә, ләкин ничек, нәрсә эшләргә икәнен белмичә йөдим, шуның аркасында үз йөрәгем сулкылдый...

Кирәк мәгълүматны бөртекләп җыям — беркөнне бер нәрсә, бер сүз, икенче көнне — икенчесе. Шул сүзләрне ишетер өчен яныннан да китмим диярлек. Сораштыруым, көннән-көн якынлашуым үзенә дә ошый, күңеле күтәрелгәндәй була, ләкин ялгызы гына калса, тагын боега, әлеге өметсез, сагышлы күзләре белән каршылый, һәм мин тагын сискәнеп китәм. Үзен генә калдырмаска тырышам. Кайбер нәрсәләр ачыклана барган саен, аның өчен курку, борчылу да арта бара. Ниһаять, фаҗиганең нәрсә икәнен ахырынача ачыкладым: кешеләргә кешеләр генә бирә ала торган җылылык, якынлыктан, үз итүдән килә торган бөек шатлыкны гомер буе татымаган ул һәм аннан өметен дә җуйган... Коточкыч бушлык, җансызлык... Шатлыклар, бәхетләр диңгез булып шауларга тиеш урын — кайнар комлык, чүл — коры диңгез...

Исәнбәк абый, ник һаман дөньядан ваз кичкән күзләр белән карыйсың син миңа? Ник? Сыңар канат белән, үз бәхетенне таба алмаган хәлдә җирдән китәчәгеңә ышандыңмы? Юк, үлемгә мин сине бу хәлеңдә җибәрә алмыйм, юк, җибәрә алмыйм... Нинди хис бу? Әллә яңа мәхәббәт килдеме? Әйтә алмыйм, юк, һич әйтә алмыйм. Ләкин, барыбер, ничек кенә булмасын, нәтиҗәсе бер — хисләремне айкап ташлады, мине икенче кешегә әйләндереп китте ул... Югыйсә, тыныч йоклап яткан Илдархан янында шушындый газаплы уйлар уйлап утырган булыр идеммени! Шундый уйлар белән аның янында... Әйе, мин гаепле... Алдакчы, вөҗдансыз!

— Илдархан, мин гаепле синең каршыда...

Шундый да тыныч йоклый дигән Илдарханым күзләрен ачты:

— Нәрсә дидең?

— Мин гаепле, Илдархан...

— Эш нәрсәдә? Чынлапмы?

Һәм мин сөйләп бирдем. Ахырдан болай өстәдем:

— Тик шунысын бел, теләсә нинди хәлдә дә мин сине ташларга җыенмадым. Ташламам да. Бу — хыянәт түгел.

— Нәрсә соң алайса? — диде Илдархан һәм, җавап ишетмәгәч, тизтиз киенеп, чыгып та китте.

Әйе, гафу итмәде ул һәм шуның белән мине дә, үзен дә гомерлек җәзага тартты. Мин яшьлектә сөйгән Илдархан, мөгаен, кичергән булыр иде, никадәр генә гаепле булсам да. Әйе, кайтмады, кайтмады минем сөекле кешем, Илдарханым сугыштан!

Җинаятьнең ике яклы икәнен беләм, аның икенче ягына «җәза» дип язылган. Тиешлесен кабул иттем: Илдархан белән хушлашкач, беренче көннәрдән үк балалар күзенә карарга курка башладым. Үзем дәрес бирәм, үзем алар күзеннән коточкыч мәгънәләр укыйм: бөтенесен белеп торалар, тик үземә әйтергә кыючылык итмиләрдер кебек. «Безне укытырга нинди вөҗдан белән киләсең син? Изге хисләр тәрбияли торган кеше үзе изге булырга тиеш». Көн саен класска килеп кергәч, шундый шелтәләр ишеткәндәй тоям. Сүзсез шелтәнең никадәр авыр икәнен сез башыгызга да китерә алмый торгансыздыр. Ичмаса, тел белән әйтсәләр икән, бәхәсләшер идем, җиңелгәч, туйганчы бер елар идем дә бәлки тынычланыр идем. Ә болай... Күпмегә түзәргә мөмкин икән бу хәтле җәзага?

Ронога гариза бирдем — җибәрми диңкеттеләр — газапны сузар өчен диярсең. Күп вакытлардан соң, укытыр өчен гомуми урта белем генә җитми башлагач, читтән торып укырга димләгәннәр иде, тагын мәктәптән китәргә гариза яздым: шаккатып карап торалар — бүтәннәр усәргә, укырга җай эзли, хәзер шул мөмкинлек туды, ә син, янәсе...

Кешеләрне тәрбия итәргә, бүтәннәр акылы белән җитәкчелек итәргә бирелгән хокуктан баш тартып һәм үземдә иң тыйнак хокук, кешеләргә хезмәт итү хокукын гына калдырып, фермага күчтем, теге вакытта, сыерлар күтәрәмгә калган чакта. Кешеләргә генә түгел, терлекләргә дә хезмәт иттем. Хәзер — семьяга гына... Әллә шул хокуктан да мәхрүм ителергә тиешме мин? Син дә, Вәкил, шулай уйлыйсыңмы?

Ник бу хәтле дә җайсыз хәл килеп чыкканын сорасалар, әйтә алмас идем. Чөнки һаман аңламыйм, үзем дә аңламыйм. Шул хакта синең белән киңәшермен дигән идем, Вәкил энем.

Ник кермәдең соң син минем янга?

Илаһи зур җиңүгә егерме ел тулган көнне бәйрәм иткән чакта... мин Исәнбәк абый тавышын ишеттем.

Телевизор аша шул сугыш картиналарын карап утыра идек — бөтен гаилә һәм кунаклар бергә җыелып. Балалар көлешә, зурлар я тын кала, я үз күргәннәрен өстәп, күңел җәрәхәтен яңарта... Ә экранда снарядлар, бомбалар ярыла: бөтенебез шушы яңа өй белән күккә очарбыз кебек. Үлем лагерьлары... Меңнәрчә күз чирек гасырдан соң «ярдәм итегез!» дигән сыман безнең күзләребезгә карый... Ай, ул күзләр! Моннан да кызганыч, моннан да ямансу күзләр буламыни! Булса да дөньядан ваз кичкән кешеләрдә генә булыр. Ә болар ваз кичмәгән,— алар шундый акыллылар — чирек гасыр аша безне күреп торалар... Ай, ул күзләр!.. Күзләр!.. Күрәм, бу күзләр миңа таныш... Әйе, таныш, төсмерлим мин ул күзләрне, тик кем күзләре икәнен генә тәгаен әйтә алмыйм. Бу сын, бу чырай да кайчандыр миңа таныш, якын кешене хәтерләтә... Тик таный алмыйм. Ничек таныйсың аны хәзер: җанлы скелет бит бу— чыкмаган җаны гына бар — ничек йөри әле ул дип гаҗәпләнергә генә мөмкин. Ә ул йөри — миңа таба килә...

— Ай! Ай!

Аның килүеннән куркып кинәт шулай җан әчесе белән кычкырган-дай кычкырып җибәрүемне янымда утыручы балаларым, ирем, кунакларым сикереп торганнан һәм мине кочаклый-кочаклый юатканнарыннан аңладым. «Ни булды?» да, «Ни булды?» диешәләр. Ә мин... Һушсыз кеше кебек, эндәшә алмый тик утырам. Салкын әйрән эчерттеләр, телевизорны сүндереп торырга гына башларына килмәде. Мин читкә борылып утырдым да аңыма килгәндәй булдым. Рәхәтләнеп, иркенләп тын алдым: ярый әле — бу заман икән!

Өйдәгеләр сорауларын тиз генә туктатмадылар — ә мин аларга нәрсә әйтим? Юк, әйтә алмыйм, чирек гасыр аша әле генә миңа таба, безнең көннәргә ашкынучы кешенең исемен мин аларга әйтә алмыйм. Ә күңелдән: авыз эченнән һаман кабатлыйм:

— Исәнбәк! Исәнбәгем, кадерлем!

Әйе, әйе, мин күңелемнән аңа шул сүзләрне әйттем — ник икәнен аңламыйм, сорасалар, хәзер дә аңлата алмас идем. Ай, бу кеше дигәнең! Үзеңне үзең дә тиешенчә белеп бетермисең, ә без чит кешеләр турында белдекләләнеп сөйләшергә яратабыз!

— Исәнбәгем, кадерлем!

Күздән яшьләр агалар да агалар...

Әнә ул кешеләр, ниһаять, хәлдән таеп егылдылар... Егылмаганнарын каядыр алып киттеләр — шулар белән бергә Исәнбәк абыйны да... Алар киткән яктан яңгырап автомат чиратлары безнең көнне, безнең хәтерне тишкәләп үтте... Аннан соң инде мәңгелеккә тынган җирләрне

крематорий дигән — изге кешеләрне яндырыр өчен хәшәрәт җаннар ясаган, торбалары болытларга тиеп торган тәмугка озаталар... Морҗа торбаларыннан зәп-зәңгәр күккә кап-кара төтен күтәрелә.

Безнең авыл янында кайчак ялгыш ташып чыккан нефтьне дә шулай яндыралар — шундый куе кара төтен күтәрелгәнен күрсәм, күңелем тагын актарыла, караңгылана, йөрәгем тагын сызлап тиберчеңә башлый...

— Исәнбәгем, кадерлем!

Кич җиттеме, Базы буендагы өянкеләр, өй тирәсендәге карт каеннар әллә җилдән, әллә узгандагы авыр хатирәләрдән сыгыла-сыгыла җуылдый, чайкала, шаулый башлый. Нәкъ минем төсле интегәләр шул өянкеләр, нәкъ минем кебек кемнедер, нәрсәнедер сагыналар шул каеннар. Минем еракта һәм эзсез калган яшьлегемне сагыналар бугай.

Кич җиттеме — шул каеннар, шул өянкеләр миңа киңәш бирәләр: бүгенге көнен матур, бүгенге бәхетең гүзәл — шуның кадерен бел. Яшьлек үкенечле була ул — түз, моңайма. Вакыты килер — хәзерге көннәреңне сагынырсың — артык зур уңыштан ботаклары каерылып чыккан алмагач кебек бәхетле чагыңны сагынырсың. Алмаларыңа, ямь-яшел яфракларыңа яшәү суы биргән туфракның, чирек гасырлык арадан күкрәп килгән болытлар һәм яңгырларның мәгънәсен сизеп яшә — тиешле кешеләргә рәхмәт әйтә бел.

Таң алдыннан, ни өчендер, йокыларымны бүлеп миңа гаҗәп таныш, ягымлы тавыш белән — бик еракта Илдархан тавышы белән — беренче мәхәббәтем эндәшә:

— Әйдә, ташлап кит син таңгы шатлыкларың җимерелгән төшне, язмышың ватылган җирне. Әйдә, безне күрмәгән, яман колаклар ишетмәгән һәм үткән ямьсезлекләр белән теңкәгә тия алмас җирләргә, чит җирләргә әйдә!

Ә мин җавап бирәм:

— Чит җирләрдә без үз булмабыз! Юк, Илдархан, мин инде синеке түгел. Мин инде бүтән уйлар, бүтән тормыш кешесе. Хуш, бәхил бул!

## ӨЧЕНЧЕ МОНОЛОГ

Әй, Вәкил, Вәкил! Әллә нинди кеше булып чыктың син — һич адәм аңлый торган түгел. Я әйт, эш узгач сөйләшүнең нигә хаҗәте бар? Ну, булган. Ну, беткән дә бит инде? Гомумән дә сүз белән хәл ителә торган нәрсә түгел иде ул.

Ничек инде: «нәрсә әйтер идең?» Исәнбәк абыйга? Нәркәскә? Нәрсә әйтим ди мин аларга? Үпкәләргәме? Юк инде, энекәш, булмый ул алай.

Сезнең кебек акыллы башларны күп күрдем мин. Болайрак әйтә торганнар иде: «Үзе бәхетле булган кеше бүтән кешеләрнең бәхетен җимерми»,— ди торганнар иде. Син дә шулай дисеңме? Бик дөрес. Шундый университетта укыгач ни! Менә шул, мин дә синең хәтле генә беләм эш юктан чүбек чәйнәү кагыйдәләрен. Исәнбәк абзаң да, Нәркәс җиңгәчәң дә — шул хәлдә; үзләрен кызганырга меӊ кеше кирәк аларның. Миннән бигрәк, үзләрен кимсеттеләр, кеше күзенә күренергә куркырлык дәрәҗәдә. Ә минем теләсә кая барсам да, теләсә кем күзенә күренсәм дә — йөзем ак. Диңгез миңа тубыктан, белдеңме? Белмәсәң, белеп кал: бәхетсез кешеләрне бәхетсезләр бар итә. Ә син бәхетле бул. Ишетсен колагың — сиңа мәҗбүри боерык бу. Көлмә син, әллә кем булып кыланма, адәм бул, яме.

Ну, алар минем күзне ачтылар, анысы хак. Дурак, теге елларда Базы буенда укып яткан китаплар кушканча яшәмәкче идем бит. Һава-

га очмакчы, янәсе, өскәрәк күтәрелмәкче булам. Ә мине тормыш угата[1] түбән өстери. Теге еллардан ук шулай кылә инде ул.

Хәтерлисеңдер — дүрт почмаклы очкыч ясаган ием. Күргәнем барые, бүтәннәрнең оча торганые. Тач аларныкыча ясадым, очарга тиеш ие. Тик бер хата җибәргәнмен. Син күрмәгәнсеңдер, билгеле,— коточкыч авыскал[2] малай иең бит. Ап-ак кәгазь өстенә көрән каләм белән, басма хәрефләр белән ике исем язган ием. Хата шул. Ничек, нинди исемнәр? Синеке түгел инде. Нәркәс һәм Илдархан... Бу исемнәр шулай ил күгенә менеп, җырларда мактаЛган, кыр казлары һәм аэропланнар гына кочаклап оча алган биеклеккә, Нәркәс күзләре төсле зәңгәр яктылыкка күтәрелеп, гади җир балаларының, ике сабый гашыйкның үлемсез һәм бөек мәхәббәтен ил буйлата тирбәтеп йөртсен әле, дип хыялланган идем. Үзең күрдең — күшеккән тавык кебек, лып итә дә төшә җиргә, төшә дә лып итә. Ә мин дурак шул сигналга да карамыйча, аңламыйча, Нәркәсне һаман алла дәрәҗәсенә күтәреп табынам. Ә ул... Ну, ярый, бетте, мин болай, ачу килеп кенә. Булган, беткән. Хәзер һәркем үзенчә акыллы. Нинди дер хикмәтенә зирәклек җитмәде минем, очмады каһәрең. Ә син җаен тап, ныклап өйрән һәм рәтлерәк итеп яса. Мин булдыра алмаганны син булдыр — минә булырсың кеше! Сөйгәнең исемен тәки чөй һавага, күк йөзенә язып куй. Була торган эш ул. Тик кешесен табарга кирәк. Югыйсә, шундыйлары күбрәк, син аларны илаһи зәңгәрлеккә күтәрәсең, алар синең исемне минә шушы яңгырдан калган ләмгә батыралар. Сак бул, сыналган нәмәрсә бу, олылар сүзе. Тыңла, исәр булмасаң.

Минем барып чыкмады.

Теге без көтү көткән елны күрше Хәтирәттәйләрнең сарыгы бүлтерекләгәние. Хәтерендәдер. Сарык бүлтерекләү бәхет санала. Бәләкәй баланы тоткандай тотып ихаталарына кергәч патша төшкәндәй сөенде Хәтирәттәй. Сөенчегә нәрсә бирим? ди. Юк, мин әйтәм, берни кирәтми миңа, игелегең күр, димен. Юк, Илдархан апкаччаем[3], алай килешә торган эш түгел бу, ди. Изгелек бәясе алтыннан югары торыр, дигән була. Әйтерсең, алтын күргән кеше... Бичара. Әйдә, кызык итик әле, ди. Тәкә хайван икән, әйбәтләп үстерик тә суйгач тиресен сиңа бүләк итәрмен, ди. Минә дигән алтын төсле тире, андый нәмә җирдә ятмас, дигән була.

Ятмас та шул. Ризалаштым — бер тиредән бөлмәсләр әле.

— Рәхмәт, Хәтирәттәй.

Хәтерендәдер, алтын тире турында әкият укыган идек. Алтын руна- мы шунда... Авызыңны ерма, яме, ертылып китмәсен. Ну! Хуш! Бәлки шул тире булып чыгар бу, ә? Хәзерге кебек үк тиле идем ул чакта да мин. Шулай дип уйладым да — үзем үк ышандым шуңа.

Атна-ун көндә алтын җөнле[4] бүлтерекне абзарда сыер таптап үтергән. Ә сарыкның үзен бүре күтәреп чапты...

Шундый гарип хыяллар.

Минем иң зур бәхетем — Нәркәс. Ул янымда кала бирә. Ана булган ышаныч, өмет һаман үлми. Шулай да аны да бүре алып качмасын дип, куркып йөри башладым. Армиягә китәр чак җиткәч, курка ук калдым. Кызны бүтән җәнлекләрнең сагалавын сизгәндер, мөгаен. Үземнеке итеп, ныгытып калдырыр өчен язылышырга тәкъдим иттем. Әйтерсең, ул минем хатын булгач, шуның белән бөтен нәрсә хәл итеЛә, ул бары тик минеке генә булып әверелә һәм мәңге шулай калачак.

Шундый гарип хыяллар.

---

[1] Угата — үч иткәндәй (диалект).

[2] Авыскал — таркау күңелле.

[3] Апакаччаем, апаем — үзеңнән кечеләргә яратып әйтелә торган сүз.

[4] Җөн — йон.

Армиягә киткәч, минем төп эшем, билгеле, хәрби әзерлек, икенчесе — Нәркәскә хатлар язу. Аена йөз хаттан ким түгелдер, билләһи. Шуңа күрә кадерем булмагандыр да. Син монысын да белеп тор, арттырып җибәрмә, кешедә эгоизм тәрбияләмә, сезнекечә әйтсәк. Ну, Нәркәс җавапсыз калдырмыйдыры, үпкәләп әйтү түгел. Мин хезмәт итәчәк ике елның һәр көнен, һәр сәгатен санап баруын яза. Чынлап яза ул, ышанам мин аңа хәзер дә. Алдауны белә торган түгел ул анысы. Юкка яратмаган бит инде мин аны!

Башта — Ерак көнчыгыш, аннары, үзең беләсең... Фронтка китәр алдыннан бәхилләшеп дигәндәй хат яздым. Ә ул сугыш беткәч тә егерме ел көтәргә вәгъдә биреп язды. Бу сүзләр... теге... беләсең инде... ну, белмәсәң белеп кал. Бу сүзләр инде Исәнбәк абый кайтып киткәннән соң язылган...

Ә мин, җүләр, эшелон белән үзебезнең яклардан узган чакта поездДан сикерәсем килеп, елыйсым, үксеп-үксеп елыйсым килеп барам. Сездән йөз, ике йөз чакрым ераклыктагы станцияләрдә кешеләр күргәч, аларның берсен син, икенчесен Нәркәс итеп күрәм.

Сугышта да шулай — һәр яңа авылга кергәндә, безне күрешү көтә кебек. Нәркәсне эзлим — һәр почмак, һәр урамнан. Тәтен аша, балчыклы ут, өермә аша да аны күрәм.

Син күз алдыңа китер. Елга аркылы мичкәләрдән салынган күпер буйлап чыгабыз. Беләсең инде, мин шофер бит, рульдә. Кузовта — снарядлар... Бомбежка... Дөбер-шатыр — күз ачкысыз. Ну, арттырмый әйтүем, төрле чак булды. Ә бу юлы чынлап качты курку. Югыйсә, шартлап көлең күккә очу самый ихтимал нәрсә мондый чакта, исән калу үзе бер гаҗәп. Ә мин туп-туры чыктым дөбердәп, йөк үз урынына килеп житте тәки. «За отвагу» медален шунда бирделәр.

Ну, ул чакта шунысы бар тагы — кайгыру дигән нәрсәне мин оныткан. Күңел хыял белән, алдагы кавышу, Нәркәс хатларындагы илаһи сүзләр, вәгъдәләр белән тулы!

Хәзер менә шул чакны сагынам... мәзәк тә бит — нишләтәсең. Бөтен дөньям минем сугыш беткәч җимерелде. Җиңүче булып, медальләр, орденнар ялтыратып һәм чыңлатып, күкрәк тулы намус һәм бәхет сурәтләре белән бизәлеп, отпускыга кайткач...

Каршыга Нәркәс йөгереп килгәндә, мин аны күтәреп үк алырлык һәм кирәксә кулларымда дөнья читенә кадәр илтеп җиткерерлек идем. Тик кинәт тукталгач, шунда ук күзләрендә нииндидер читсенү, курку чагылып китте. «Бу мин калдырып киткән Нәркәс түгел...» дигән уй ялтырап узды. Дөрес тә булып чыкты шул. Тел төбеннән үк сизелеп тора: һаман ярата ул... ләкин мине түгел. Исәнбәк абый хакында сөйләшү аңа рәхәтлек бирә. Тегесе үзен дә гомер буе газаплаган тынгысыз бер чир йоктырып киткән иде, мөгаен... Ух, тиле хатын! Шул тиле хәлдә дә бит минем белән яшәмәкче! Бер түшәктә яткан кешеннең бүтәннәр белән саташуын сизгән көе шуңа түзеп яшәргә тиеш идемме мин? Юк, гафу итегез. Иң авыр чакта, ут эченә кереп барганда эшли алган бит ул эшне Нәркәс!

Шул күрешүдән соң бөтенләй кайтмам, кунакка да кайтмам дип киттем. Китсәм дә, Нәркәскә бүтән кешегә тормышка чык, мине көтеп вакыт әрәм итмә, дип язсам да — күңелдә сугыш елларында янган сукыр лампа хәтле генә булса да өмет яна иде. Җилпенә иде — Нәркәс миңа ышанмас, ышанса да булган үкенүләре, әрнү, гафу үтенүләреннән соң тиз генә бүтән юләрлек эшләмәс, ашыкмас, вакытлы мавыгуын онытыр, мине оныта алмас, бүтәнне ярата алмас, дигән сукыр өмет җилпенә иде. Төнге кара күбәләк, пәри күбәләге кунды да леп итеп сүнде сукыр өмет: минем хаттан соң ярты ел узгач та Нәркәс апаң кияүгә сыпырган!

Шундый гарип хыяллар...

Ә син әйтәсең, бары тик ялгышкан дисең. Ялгышлык шул — мин исән...

Беренче кайтканда ук, хатлар языlганчы, кияүгә чыкканчы ук кичерсәмме? Акыллы сүз. Бик дөрес. Ә минем кичерергә тырышкан саен отыры йөрәк әрнүен, отыры җан котыруын кая куярсың? Гарьлек акылны томалар чиккә җиткереп талаганын күз алдына китерә алмыйсыңмы?

Менә шул, энекәш, мәгънәлерәк итеп үзең яшәп кара инде.

Һич югында бүтәнне табарга, бүтәнне яратырга кирәк иде, дөньяда пүчтәк түгелдер. Дөрес, кирәк иде. Бәлки син булдыра алырсың. Ә миннән булмады менә, гафу ит.

Күп күрдем болай хатын-кыз дигәннәрен, бик күп. Чатнап торган, сөлек кебек, чабышка чыгарга әзерләнгән аргамаклар шикелле биеп торган чибәр һәм яшь кызлар сырпаланып йөрде вакытында. Үзебезнең авылныкылар да, читләр дә. Авылыбызда мин киткәндә сабый булып калган кызлар мәхәббәт чәчеп карыйлар иде, машина фаралары шикелле... Алар миңа оятсыз тоелды. Белә-белгәннән бирле абый дип хөрмәт иткән сеңелләр... Аларга ничек инде бүтән күз белән карый алыйм. Табигать, бәхеткәме, бәхетсезлеккәме, миңа шундый нечкә оят биргән.

Нәркәснең яшьтәшләре булса, бәлки алыштыра да алырлар иде. Бәлки...

Андыйлары да очрады бугай, тик берсе дә үз кеше булып күренмәде. Күзләрендә бер генә максат — кияүгә чыгарга кирәк. Ә мәхәббәт — хыяллана алмаслык ерак хыял...

Маңгайга, яңакка катырак эләккәндә чәчри торган очкыннар төсле, минем күз алдыннан да кайберәүләр ялтырап узды һәм бик тиз юкка да чыкты.

Берсе үзен артык очсызга сатмакчы иде — күрше авылдан Мәүлия исемле хатын — бернинди хиссез кияүгә чыкмакчы иде. Мин бәя бирергә тиеш асыл сыйфатлары: язу-сызу эшендә эшли. Төскә чибәр — ике-өч бөртек кенә, кирәк хәтле генә, вак кына миң төшкән чиста йөз. Кып-кызыл яулык астыннан таш күмер төсле кара чәчләр кабарып тора. Шундый төсле үк күзләр яна... сиңа ни кирәк тагы дип кычкыра. Ә миңа кирәкми шул...

Ул моңа хәтле бер-ике ел элек бүтән кеше белән яшәп караган. Аннан отпускыга кайткан офицерлар белән буталган. Яманрак сүзләр дә ишетелде. Күңелне түгел, кулны да сала алмаячак идем. Тик чибәрнең үзенә әйтеп булмый бит аны. Шаяртырга вөҗдан кушмый. Булмый. Ә ул төшенми. Нәркәстән үзен ким санамаска тырышып гарьләнә. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела.

Клубта кичә.

Син, гадәттәгечә, баянда уйныйсың. Бер ягында — мин, икенче ягында — Мәүлия. Синең белән дуслашып, миңа якынлашмакчы. Клубта биеп йөрерлек яшьтән узганга күрә, бераз гына утырдым да сиңа:

— Мин сине урамда көтәрмен,— дип торып бастым.

Шул вакыт Мәүлия нидер пышылдагач, мине туктаттың.

— Хәзер бер-ике бию көе уйныйм да... Бергә чыгабыз.

Өчәүләп бергә кайттык. Мәүлия өйгә чакырды. Аракы чыгармакчы иде, утырмадык. Көрсенеп, ни өчендер чемодан актарырга керештe һәм ике пачка папирос чыгарды:

— Әлсә монсын алыгыз.

Рәнҗетмәс өчен бугай, ике пачканы да син алдың һәм минем кесәгә салдың. Үземне генә калдырып чыкмакчы идең, калмадым.

Мәүлия белән икәүдән-икәү генә туры килгән чаклар да булды. Әмма юк, үтер, бер рәтле сүз дә әйтә алмадым үзенә. Ниһаять, көннәрдән беркөнне бик кырыс һәм мәгънәле хөкем чыгарды бу:

— Ярый... Соңыннан үкенәчәксең только. Белеп тор,— дип китеп тә барды.

Күпмедер вакыттан соң Гадилә исемле бер кыз белән таныштык. Аның тәкъдиме буенча сәфәр киттек, үзең беләсең. Юл газаплары ничектер якынлаштырды безне һәм миндә астыртын һәм зәгыйфь өмет туды — Нәркәсне оныта алам бугай бит! Яңа бәхетемне таптым бугай. Элеккесенә һич тә охшамаган. Бусы минем үземә охшаган: яшькелт төсләр сирпеп янган коңгырт күзләр, көләч, ачык чырай...

Ләкин бәхет кыяфәтендә бәхетсезлек килгән булып чыкты. Өйләнешергә бераз акча һәм кием рәтлик дип, бер кайткач икенче тапкыр элеккеге Молотов шәһәренә киттек. Беренче юлы кайткан әйберләрне, акча күбрәк булсын дип, Гадилә тиз арада күрше-тирәләренә сатып бетергән иде. Урап кайтуыбызга Мәүлия шул кешеләргә кереп, кемнән күпме бәягә алганлыклары хакында аңлатмалар җыеп, милициягә җибәргән. Азагын беләсең инде. Мәүлиянең үкенерсең дигән сүзләрен шунда аңладым. Менә сиңа мәхәббәт!

Биш елдан соң Гадилә белән дә чит кешеләр булып очраштык... Ул үзенең барлык кешелеген, гүзәллеген әллә җуйган, әллә... һәрхәлдә, бүтән дөньяга киткән һәм, ахрысы, шактый ук пычранган... Нәркәснең нәкъ киресе! Ә миңа ул бик кирәк бит, мин Нәркәсне эзлим...

Мәхәббәттән нәфрәткә бер адым, дибез. Дөрес дисеңме шуны? Башың булса, ышанма син моңа. Бу сүзләрне үзләренең җиңелү оятын җинә алмаган бәләкәй җанлы мещаннар гына законга әверелдергән. Ышанма син аларга. Мәхәббәт төсмере хәтта хайваннарда да бар бит. Еланнарда менә андый галәмәт күргәнем юк. Беркемнең дә күрә алмаячагына башымны кисмәгә бирәм. Агу белән мәхәббәтнең катнашы юк. Мең тапкыр юк! Чын кеше мәхәббәте беркайчан да нәфрәткә әйләнми. Чын кеше мәхәббәте бәхетсез булып чыкса да, бары тик матур истәлеккә генә әверелә ул.

Гадиләнең йөгенә керә алмыйм, ә Мәүлия — елан, зәһәр елан!!

Нәркәс белән дә аерылыштык. Ә бер генә начар сүз ишеттеңме син? Аның иреннәре әйттеме шундый сүз минем хакта? Башымны кисәргә бирәм — юк. Теләсә нинди хәлдә дә! Әйе, бары тик ул гына минеке. Бары тик ул гына! Аны алыштырырлык, үземнеке диярлек, бер кан, бер җанга әйләнерлек бүтән беркемне дә таба алмадым мин. Беләм, инде таба да алмаячакмын.

Нәркәс!

Синнән дә саф һәм изгерәк кеше юк бит ул һәм шуның өчен дә гафу итә алмадым мин сине.

Вәкил, син юатма, яме, акыл да өйрәтмә, башың яшь. Барын да үзем беләм. Нинди гаепләү ди ул? Юк, тиргәсәм дә, мин аны үз кеше итеп кенә тиргим.

Һәлакәткә юлыккан өчен кешене тиргәп булмый. Ниһаять, ышана башладым бу сүзләргә. Синең сүзләрме әле алар?

Шулай шул. Сез сагынган элекке Илдарханны миң үзем дә эзлим. Аннан бигрәк — Нәркәсне... Барлык күзләрдән эзлим... Тапмасам... анысы — минем эш. Синең дәхелең юк анда. Ничек? Тагын нәрсә?

*Дәвамы бар*

## Гамил Афзал

### Борчылу

*Карт миллионер ята.*
*Йөрәк начар.*
*Авырып үтә кичләр, иртәләр.*
*Миллион өчен шуңа уңике ир*
*Йөрәкләрен тәкъдим итәләр.*

*(Телетайп хәбәре)*

*Телетайп сүзен тыңлап барам,*
*Тыңламаган көнем сирәктер.*
*Миллионерга ир йөрәге харам,*
*Эт йөрәге кую кирәктер.*

Көннәр, төннәр ясап,
Йөри бирә,
Әйләнүен белә җир шары.
Нинди көчләр бәхет алып килә,
Нинди дәһшәт көтә дөньяны!
Ни китерер тагы еллар таңы?
Күңел әрни,
Йөрәк яралы.
Кешелекнең гаҗиз булган чагы —
Егерменче гасыр азагы.
Аллага тиң булып үсми кеше,
Кыргыйлана кеше,
Ваклана.
Стронций-Туксан исни кеше,
Аяк өсте йөреп таркала.
Иң шәп егет анда —
Ата явыз,
Зәвык, йола — җаның өшерлек.
Товар булып йөри анда намус,
Хайван булып йөри кешелек.
Ир хатынын сата,
Кызын сата,
Хатыннары ирен саталар.
Кеше динен сата,
Телен сата,
Президентлар илен саталар.
Кичәге дус,
Бүген — явыз дошман.
Опиум сатып йөри базарда,
Идеясе аңа шулай кушкан —
Фашизмның артын яларга.
Ә дөньяны буа алтын җепләр,
Ышанмау һәм икейөзлелек,
Бернәрсә дә тормый якты хисләр,
Бер тиен дә тормый изгелек.
Генераллар солдатларын сата,
Палач богау сата,
Балтасын.
Хәерчеләр тишек ыштан сата,
Ягъни мирас әрәм калмасын.
Папа оҗмах сата,
Тәмуг сата,
Җае чыкса, сата алланы.
Кызлар тәнен,
Солдат итен сата,
Сатылмаган нәрсә калмады.
Судья — хөкем,
Патша халкын сата,
Закончылар закон саталар.
Ораторлар ялган пафос сата,
Министрлар портфель саталар.
Авызына шәп сигара кабып,
Крахмалга каткан якалар,
Изгелеккә кара яла ягып,
Газет тулы агу саталар.
Кеше канын сата,
Җанын сата
Бер туйганчы ашау хакына.
Бизнесменнар ваклап айны сата,
Җир сатыла,
Сулар сатыла.
Ярый әле,
Галәм бүләргә дип,
Йолдызларга менә алмыйлар,
Кояш нурын сата алмыйлар да
Кояш нурын бүлә алмыйлар.
Океаннар ярсый
Һәм чайкала.
Борчылу һәм хәвеф басылмый.
Якты өмет булып кояш яна,
Кояш изге,
Кояш сатылмый.

Сәмигулла Хәйруллин

# МУСА ӘЗЕ КАЛГАН КОЛХОЗДА

ОЧЕРК

## Юл буенда тегермән



Язның беренче сулышы сизелү белән үк бу сөзәк тауның карлары күзгә күренеп шиңә башлый, соргылт тес ала, челтәрләнә. Беренче гөрләвекләр дә шул тау битеннән үзәнлеккә таба ашыга-ашыга юл салып үтәләр. Кәрлә имәннәр, зифа каеннар арасыннан җәйнең беренче җырчылары — кәккүк тавышлары ишетелә.

Шушы тау итәгенә Түбән Тәкермән авылы сыенып утыра. Икенчесе — Югары Тәкермәне — арырак, олы юл буена, тирән ярлы инешнең ике ягына урнашкан. Күрер күзгә суы да әллә ни түгел бу инешнең. Ләкин язгы ташулар, көчле яңгырлар вакытында шаулап, ярсып ага торган гадәте бар.

Казан — Уфа тракты буйлап Чаллы ягыннан бу таба килүчеләр басу читендәге матур итеп эшләнгән капканы һәм аңа язып куелган: «Сезне Муса Җәлил исемендәге колхоз тәбрикли»,— дигән язуны күрмичә калмый. Басу түрендәге калкулыкта канатларын тырпайтып утырган җил тегермәне исә гаҗәпләндерәчәк аларны. Түбән Тәкерменгә юл тоткан кәзге матур кичтә, ихтимал, Муса Җәлил дә шул тегерменгә күз сала-сала моңсу уйларга бирелеп үткәндер. Ул вакытта бу гаҗәп тоелмагандыр. Чөнки авыр сугыш елларында җил тегермәне дә кешеләргә зур хезмәт күрсәтте, аның канатлары иртә таңнан кичке караңгыга кадәр шыгыр-шыгыр әйләнде. Әмма хәзер ул борынгы ата-бабалар истәлеге, иске дөнья белән яңа дөнья алышынган шаулы көннәрнең бер шаһите генә булып калды.

Шул тегермән яныннан бераз түбәнрәк үтүгә, сине заманча җиткерелгән алты почмаклы нарат бүрәнә йортлар, тәзек каралтылар, җәмәгать биналары каршы ала. Зур гына ике авылдан торган бу колхоз Советлар Союзы Герое, патриот-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртә.

## Иншар истәлегеннән бер-ике сүз

...Мусаның Минзәләдә политработниклар әзерләү мәктәбендә укыган чагы. Күп сәен уку, өйрәнү, күп саен әле ныклап күнегелмәгән хәрби эш — шәһәрнең тын урамнары буйлап урап керергә дә вакыт калмый. Шулай да Муса үзенең һәр буш сәгатен файдалы итеп тота белгән. Бер карыйсың, ул инде райкомда була, икенче

карыйсың, китапханәдә газета-журнал арасында күмелеп утыра, әкренләп якын-тирә колхозлар да аны үзенә тарталар. Хәрби тон белән кисәтеп-әйтеп торырга яраткан командирлар да шагыйрьнең нигә болай тынгысыз йөрүен, күңел кичерешләрен аңлый төшеп, аңа бераз гына йомшаклык күрсәткәндәй итә башлыйлар.

Һәм менә шуннан файдаланып, көннәрнең берендә, Муса Җәлил Минзәләдән утыз-утыз биш чакрым ераклыктагы Түбән Тәкермән авылына килеп юлыга. Шушы авылда яшәүче Иншар Әлькарәмованың әнисе белән рабфакта бергә укыган икән ул. Аның мондалыгын каян белгән дә, каян эзләп таба алган Муса?!

Шатлыклы очрашу, керосин лампасының тонык яктысында таң атканчы утырып сөйләшүләр. Иншар болай дип искә ала: «Бервакытны Муса абый миңа: «Нигә кил-сәм дә, син эш белән мәшгуль. Минем сиңа шигырь язып бүләк итәсем килә. Шуны-сы кызганыч, исемең рифмалашмый!» — диде.

Болай гына, шаяртып кына әйткән аны Муса, рифмасын да таба, Иншарга багыш-лап шигырь дә яза ул. Минзәләдән китәр алдыннан Муса, саубуллашу өчен дип, яңа-дан Тәкерменгә килә һәм Иншарга болай ди: «Сеңелем, мине онытмагыз. Мин хат язармын, ә сез җавапсыз калдырмагыз. Шулай язышып торырбыз...»

Шагыйрь фронтка чыгып киткәндә, минзәләлеләр белән дә саубуллаша. «Исән кайтсам, тагын күрешербез»,— ди ул. Тәкермән якларына да килеп чыгарга исәбе була аның. Әйе, әгәр исән-сау әйләнеп кайтса, үзенең кайбер эзләре калган бу якларга тагын бер килми калмас, бүгенге тәкерменлеләрнең эшләрен, тормышла-рын күреп сокланыр иде. Алар турында яңа шигырьләр тудырып, йөрәгендәге иң җылы хисләрен җиткерер иде. Алар моңа лаек. Эш сөючән күркәм кешеләр яши бу колхозда. Хыяллары да, уйлары да канатлы аларның. Бүген мин шуларның берсе, күп еллар инде хуҗалыкны җитәкләп баручы коммунист Бижан Камалов турында кыска гына итеп сөйләргә телим.

## Кулга дилбегә алганда

Бу хуҗалык, башкалар белән чагыштырганда, районда иң арттагылардан санала иде ул елларда. Сугыш михнәтләре үзен нык сиздерә иде әле. Басуларны чүп үләне басып киткән. Техника җитмәгәнлектән, туфракны җиренә җиткереп эшкәртә алмый-лар. Гектардан күп булса 5—7 центнер уңыш җыеп алына. Туган авылларын ташлап, Пермь якларына китүчеләр күбәйде. Ә колхозның үзендә басудан фермага көнлек сәлам кайтартырга да кеше җиткереп булмый иде.

Менә шундый авыр елны коммунист Бижан Камаловны колхоз председателе итеп сайладылар.

— Дилбегәне сиңа тапшырабыз,— диделәр аңа.— Арык булса да тәртә арасында ат, дилбегәне син ничек тартсаң, ничек куаласаң, ат шулай атлар...

Авыл туфрагында аунап, чирәмендә тәгәрәп үскән кеше ул Бижан Камалов. Фронтта булып кайтты. Аннары МТСта хисапчы эшен башкарды. МТСлар бетерел-гәч, колхозга бухгалтер итеп җибәрделәр. Исәп-хисап кешесенең эше, бер кара-ганда, шалт-шолт счет төймәләре тартып, кенәгәләргә саннар язып-сызып утыру гына югыйсә. Ләкин Бижан Камалов идарәдә утырырга яратмый иде, ничә карасаң да аны басуда — колхозчылар, механизаторлар янында күрергә мөмкин иде. Ул ба-суларга гашыйк иде. Менә хәзер аны ике авылдан торган зур колхозның председа-теле иттеләр. Күз күреме җитмәс иркен басулар — йөре дә, күзәт тә, колач җәеп эшлә дә...

Кулына тоттырган әлеге «дилбегәне» тарткалый башлаганчы, Бижан Камалов авыл коммунистлары белән тагын бер мәртәбә чын күңелдән сөйләшеп, киңәшеп карар-га булды.

— Я, кем нәрсә әйтергә тели? — диде председатель.— Бу хәлгә әллә сез борчыл-мыйсызмы? Күрше хуҗәмәтлеләр ел саен уңышны арттыралар, ә без бер урында таптанабыз. Кай җиребез ким алардан?

Кемдер шунда, тынлыкны бозып, авыз эченнән генә зарланып алды:

— Җир начар безнең, иптәш Камалов, алардагы кебек чыбык тертсәң, тәртә үсәрдәй җирләр юк бездә!

— Нишләп начар булсын? — диде председатель, зарланучыга сораулы караш ташлап.— Дөрес түгел бит! Шушы җирләр сугышка кадәр менә дигән уңыш биргән бит, хәзер дә бирергә тиеш һәм бирәчәк тә. Шулай бит, иптәш Юлдашев?

Җыелыштагылар агрономга таба күтәрелеп карадылар: җир докторы нәрсә әйтер икән? Яшь булса да, кыю күренә иде егет, кайсы кайда җайлап утырган кешеләргә таба күз йөртеп чыкты да өстәл янына килеп басты:

— Бижан абый дөрес әйтә,— диде кыю тавыш белән.— Җирләр начар түгел безнең, туфрак анализы шуны күрсәтә. Дөрес, урман-дала зонасына керәбез. Әмма җирнең кадерен белсәк, аңа чын хуҗаларча карасак, кимендә 19—20 центнер бирә алачак бу җирләр!..

## Җир хуҗалары кайда соң?

Әлеге җыелыштан кайткач, Бижан Камалов, алдындагы кайнар чәенә текәлгән хәлдә, шактый уйланып утырды. Җир хуҗалары кайда соң? Кемнәр алар? Председатель буларак ул үзе, агроном да, барлык колхозчылар да җир хуҗасы түгелме соң? Ә шулай да җиргә кадер-хөрмәтне беренче булып кем күрсәтергә тиеш? Шушы уйлар аның тынычлыгын тәмам югалтты. Инде суынып беткән чәен бер-ике йотып алды да ул тәрәзә каршысына килеп басты. Тагын уйга чумды, тагын ишекле-түрле йөренеп килде. Йокысы качты, ишек алдына чыкты.

Бөтен авыл тирән йокыда. Кайдадыр, урманың югары очында, казлар каңгылдашып куйды. Яңадан тынлык... Тукта, нигә соң әле болай авыл да, табигать тә тын калган? Ул җыелыштан кайтканда, басу түреннән түңгә сөрүче тракторлар гөрелтесе бик матур, бик күңелле ишетелә иде. Шунда ул гөрелтегә колак сала-сала: «Көз әйбәт килде. Болай булгач, яз чәчеләчәк барлык мәйданны түңгә сөреп калдырабыз»,— дип, эченнән сабый балаларча сөенеп тә куйган иде. Ни булган тракторларга, әллә тагын ватылып яталармы?..

...Тәкермән таулары артыннан ашыкмый гына килгән көзге караңгылык басуларны да үз кочагына бик тиз чорнап алды. Салкынча дымлы һавага миләш исе, гөлҗимеш исе таралды. Нинди матур төн! Аяз күк түрендә меңәрләгән йолдызлар, берберсенә күз кысышып, нидер серләшәләр. Нигә соң аларның кайсылары аксыл да, кайсылары саргылт, кайсылары кызгылт икән?

Басу читендәге салам өеме өстенә менеп яткан тракторчы егет Рәкыйп, шул йолдызларга таба карап, рәхәтләнеп хыялланып ята бирә. Трактор рулен плугарена тоттырган иде ул. Әйдә, булдырса-булдырмаса да, азаплансын шунда. Эш бүре түгел, урманга качмас, башланмаган озын көн бар әле.... Күз кабакларының ничек авыраюын да сизмәде, техника белән рәтле танышлыгы булмаган малайга буйсынмыйча чыгымчылаган тракторның яман үкерүен дә ишетмәде ул, эреп йокыга китте. Күпме яткандыр, әмма иңбашына кемнеңдер каты итеп төртүенә күзләрен ачып җибәрсә — колхоз председателе. Ничек сикереп торганын сизми дә калды егет, йокысы да шунда ук ачылды, ык-мык килергә тотынды.

— Их, балакай, балакай! — диде председатель, аңа ачуланып.— Без сиңа ышанып трактор тапшырдык, бөтен колхоз, барлык колхозчылар ышана, синнән эш көтәләр, ә син?!.

Тәрәннәргә салам тыгылганлыктан, машина йөртә белүе дә чамалы гына булганлыктан, азапланган, азапланган да, тракторны сүндереп, плугарь егет тә йокларга яткан икән. Яз чәчеләчәк бар мәйданны түңгә сөреп калдыр инде менә шулар белән, уңыш үстерәм дип йөр инде. Нык әләкте аларга председательдән. Алай гына да түгел, үз гаепләрен үзләре танырганга кадәр, икесен дә эштән алдылар.

Менә кайда икән ул җир хуҗалары? Менә ничек эшлиләр икән алар? Кайбер тракторчыларның көн үтсен дә, норма үтәлсен дип кенә эшләүләре, сыйфатның барын-югын да белмәүләре хакында идарәгә сигналлар кергән иде инде. Ә Рәкыйп тракторы белән булган хәл исә колхоз председателенең күзен нык ачты. Шул көннән

соң ул төп игътибарны механизаторларга, җиргә кадер-хөрмәтне башлап күрсәтергә тиеш кешеләргә юнәлдерде.

— Әйе, җиргә чын хуҗалар булдырмый торып, басуларны рәткә кертә алмыйбыз,— диде председатель колхозчыларга.— Һәр тракторчы үзе эшләгән, үзе сөргән, үзе чәчкән җиренә үзе җавап бирсен, үзен җирнең чын хуҗасы итеп сизсен. Шунсыз арттылыктан чыгу турында уйлыйсы да юк.

Бу хакта Бижан Камалов төрлечә фикер йөртеп карады, кайбер оештыру эшләре үткәрергә булды. Элеккеге өч колхоздан, берничә бригададан торган хуҗалыкта хәзер ике генә бригада иде. Бу хәл, әлбәттә, үзен нык кына сиздерә, чөнки бригадирга басуда да, фермада да булырга, кешеләрне эшкә билгеләргә, контрольлек итәргә дә кирәк иде. Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр аяк өстендә ул. Колхозчыларның эшен көннекен көнгә тикшереп, кабул итеп барырга вакыты да рәтләп калмый. Менә шул хәлне юлга салу нияте белән, колхоз председателе үз янына идарә членнарын чакырды, киңәшергә булды.

— Бригадаларны өч звенога бүлеп карыйк,— диган тәкъдим ясады.

Кайберәүләр башта моңа икеләнеп карадылар.

— Звено системасы бетерелде бит, без аны яңадан торгызырга җыенабыз. Моның өчен район башлыклары безгә кусәк күтәрәчәкләр,— дип шикләнү белдерделәр алар.

— Әлегә колхозга үзебез хуҗа, эш өчен үзебез җавап бирәбез,— диде Бижан Камалов, үз фикерендә нык торып.— Аннары бу звенолар бездә башкачарак булачак. Һәрберсенә җир мәйданы гына түгел, трактор да, башка кораллар да бүлеп бирәчәкбез. Механикалаштырылган комплекслы звенолар булачак алар. Һәр звено уңыш өчен үзе җавап бирәчәк, ягъни үз җиренең чын хуҗасы булачак. Берничә елдан соң бу звеноларның бәлки кирәге дә калмас. Ә бүген алар безгә кирәк, шунсыз җиргә чын хуҗалар булдыра алмыйбыз.

Шул ук елны колхоз, кыска сроклы курсларда укытып, уннарча яңа механизатор кадрлар әзерләде. Бу исә машиналардан ике сменада файдалану мөмкинлеге бирде. Звено башлыклары итеп тәҗрибәле игенчеләр, механизаторлар билгеләнде.

Шулай итеп, колхоз председателен борчыган нәрсә хәл ителде — җиргә чын хуҗалар табылды. Алар эшли башлауга бер ел, ике ел үтте. Беренче нәтиҗәләр дә күренде. 1964 елны колхоз бөртеклеләрнең гектарыннан 13 центнердан артык уңыш алды. Ашлыкның тулай җыемы 46 мең центнер булды. Дөресен әйтергә кирәк, җәлиллеләрнең бу кадәр ашлыкны әлегәчә бер елны да җыеп алганнары юк иде.

Коммунист Бижан Камалов җитәкчелегендәге бу артель, әнә шулай, арттылыктан чыгу юлларын эзләп, үз мөмкинлекләреннән торган саен тулырак файдалана барып, игенчелектә һәм терлекчелектә яңа үрләр яулый башлады.



## Күршеләр

Элгәртен бу колхозны район күләмендә үткәрелгән җыелышларда, киңәшмә-утырышларда еш телгә алалар иде. Мактап түгел, әлбәттә. Тәнкыйть сүзләре ишеткән саен Бижан Камалов башын түбән ия, яңак тамырларының сулкылдавын үзе сизәрлек дәрәҗәдә кызара иде. Хәзер менә бөтенләй диярлек телгә алмый башладылар. Икенчерәк төрле әйткәндә, хурлау да, мактау да юк. Сәбәбе: колхоз уртачалар рәтенә басып бара иде.

Басуларга чыгып, әйләнеп кайттымы, Бижан Камаловның күңелен сәер бер хис били башлады. Көнчелек галәмәте дә түгел иде бу, кимсенү дә түгел. Ачыграк әйткәндә, күрше Куйбышев исемендәге колхозның эшләре нык кызыксындыра, район мактанычы булган шушы хуҗалык белән ярышып карарга иде диган фикер туарга итә иде анда. Ләкин әлегә кадәр ул моны беркемгә дә сиздермәде. «Көрәшергә чыкканчы, кем белән алышырга тиешлегең чамала, туганкай»,— дип көләрләр кебек тоела иде аңа.

Күршесе Галимҗан Газизов күптәнге таныш, Бижан Камалов исәп-хисап эше башкарган МТСның директоры иде. Хәзер менә икесе дә колхоз председателе. Договор төзеп кул куешмасалар да, эшкә башлауның беренче көннәреннән үк, үзара

ярышка чыкканнар иде инде алар. Ләкин Бижан да, Галимҗан да моны бер-берсенә сиздермәделәр, күңелләрендә сер итеп саклап килделәр.

Шулай да көзге явымлы көннәрнең берендә, күршесе Галимҗан Газизов белән очрашып сөйләшкәндә, болай дип ычкындыруын үзе дә сизми калды Бижан:

— Аптырыйм әле, күрше, бу арада райком секретаре безне нигәдер бер чама белән үлчи башлады?! Сез күпме уңыш алсагыз, без дә шулкадәр җыеп алырга тиеш булабыз. Сез күпме сөт саусагыз, без дә шулай саварга тиеш...

Галимҗан Газизов күршесенең тел төбе кая таба баруын аңлап алды булса кирәк, бер мәлгә үзалдына көлемсерәп торды да:

— Ә нигә гаҗәпләнәсең моңа, секретарь дөрес эшли, минемчә,— диде.— Колхозларыбыз арасы кул сузсаң, кул җитәрлек кенә бит. Шулай булгач, эшебездә дә әллә ни аерма булырга тиеш түгел, дип уйлыйм.

— Юк шул, дускай, сезнең белән тиңләшергә безгә әле маңгай тирен чиләкләп агызырга кирәк,— диде Бижан Камалов. Ләкин эченнән ул үзе башкарачак фикердә, ягъни күршесенең сүзләре белән килешү ягында тора иде. Әмма аның сабыр табигате моны һаман да сиздертмәскә азапланды.

Алар колхоз идарәсе бинасы янында туктап калдылар. Көзге вак яңгыр сибәли иде. Аяк асты юеш. Як-якка ком-таш чәчрәтеп, олы юлдан бер өзлексез машиналар үтеп тора.

Күршесенең болай гына, хәл-әхвәл белергә генә килмәгәнлеген яхшы сизенеп тора иде Галимҗан Газизов, чөнки бергә МТСта эшләгән чактан ук күзәтеп, өйрәнеп килә: сәер холыклы кеше Бижан Камалов. Артык күп сөйләшмәс, урынсызга авыз күтәреп мактанырга да яратмас, әмма яхшылыкны тиз күреп ала, аны ныгыта белә, мөмкин булмаганнан ким эшләнсә, үзалдына гарьләнә, тынычсызлана торган кеше.

Бу минутларда күршесе турында әнә шундый уй-фикер йөрткән Галимҗан Газизов эчке бер мәгънә белән болай дип куйды:

— Бижан дускай, әйтсәм әйтим инде, сезгә хәзер чиләкләп тир түгәсе юк. Безнең үкчәгә нык басып барасыз. Әйе, бастыгыз да инде. Менә диган механизаторларың бар хәзер. Хәтерлисеңме, теге чакта ничек зарлана идең! Аннары урамнарга су керттең, ә без өзерләнәбез генә. Түбән Тәкермәндәге Культура йортыгыз үзе ни тора! Районның бер колхозында да юк бит әле ул. Тынлы оркестр да алып куйдыгыз, музыкантлар әзерлисез. Ә менә без олы юл өстендә утырабыз. Минзәләгә баручысы да, Чаллыга үтүчесе дә карап, күреп китә. Рәтле клуб та юк бит, әнә һаман шул җимерек мәчет бинасы...

— Ә мин сине таштан бик олы Культура сарае эшләтергә җыена дип ишеттем, проектын да кайтарткансыз түгелме соң инде?

«Менә бит ул, барысын да ишетеп, белеп тора! Юкка гына үткән-киткән саен хәл белергә туктамый икән».

— Җиткереп булмый, күрше, җиткереп, барысы да кирәк,— диде Галимҗан Газизов, сүзне икенчегә борып.— Менә мин әйтәм, бездә, Хуҗәмәттә, колхозара бала тудыру йорты салырга иде. Өч колхоз бергәләп, әйтик, сез, без, «Ленар» колхозы...

— Начар уй түгел, мин үзем дә шул фикер белән килгән идем әле,— диган булды Бижан Камалов.— Бала тудыру йорты гына түгел, урта мәктәп тә салдырырга иде. Күршеләр бит, араларыбыз 2—3 чакрым гына. Ә балаларыбыз урта белем алу өчен уннарча километрга йөриләр.

Шушы сөйләшүдән соң ике күрше колхоз арасындагы элемтә, иҗади дуслык тагы да ныгый төште. Алар бер-берсенең эшен элеккечә көнләшеп кенә күзәтмиләр хәзер, чын-чынлап ярышалар, кирәк чакта үзара ярдәм дә итешәләр. Муса җәлилләр Куйбышев исемендәге колхозга киләләр, тәҗрибәләрен өйрәнәләр, кимчелекләре булса, күзләренә карап әйтәләр, киңәш бирәләр, ә куйбышевлылар үз чиратларында Тәкермәнгә баралар, карыйлар, сораштыралар, файдалы тәкъдимнәрен әйтеп калдыралар.

Хәзер Хуҗәмәттә колхозара бала тудыру йорты эшли. Таштан бик зур ике катлы урта мәктәп җиткерелә. Ике күрше колхоз бергәләп эшләделәр һәм эшлиләр аларны. Кулга-кул тотынып, яңа уйлар һәм яңа планнар белән алга атлыйлар алар.

# Җитәкче дә, тәрбияче дә

Кайберәүләр колхоз председателен кичләрен бригадирларга иртәгә эш өчен наряд бирүче, идарә утырышлары үткәрүче, колхоздагы эшләргә контрольлек итүче хуҗалык кешесе сыйфатында гына күз алдына китерергә гадәтләнгәннәр. Ихтимал, кайчандыр ул шулай булгандыр да. Әмма бүгенге колхоз председателе ул җитәкче генә түгел, бәлки колхозчыларның иң якын киңәшчесе дә, тәрбиячесе дә.

Менә Бижан Камалов бүген дә, хуҗалык мәшәкатьләрен читкә куеп, колхоз идарәсендә бер егет белән сөйләшеп утыра. Кичә кич клубта гауга күтәргән, кешеләрнең тынычлыгын бозган икән бу егет.

— Яшь чакта әндыйлар гына була инде ул, Бижан абый,— дип акланырга тели егет.— Шаярып кына иде, сүз көрәштереп кенә... Күккә очырган спутникларның барысы да янып бетеп бара диде ул, ә мин юк дидем... Шуннан китте безнең бәхәс. Минем кыза торган гадәт бар, ярсыдым, сүземне юкка чыгарасы килмәде...

Бижан Камалов егеткә таба тагын бер мәртәбә сынаулы караш ташлады да үз алдына көлемсерәде. Аннары, нәрсәдер уйланып, ишекле-түрле йөренеп килде һәм каршындагы стенага эленгән портретка күрсәтеп:

— Бу кем? — диде.— Я, әйт, кем бу?

Егет күтәрелеп карады.

— Муса Җәлил...

— Тулырак, аңлаешлырак әйтсәк?..

— Шагыйрь Муса Җәлил абый инде, Советлар Союзы Герое. Сугышка киткәндә безнең Тәкермәндә дә булган, Иншар апаларда...

— Үзеңнең кичәге кыйланышың белән бөтен коллективка, патриот-шагыйрь исемен йөртүче коллективка тап төшерүеңне аңлыйсыңмы?

— Бижан абый, башка бер кайчан да булмас, шаярудан гына бит...

— Ә син уеннан уймак чыга дигән нәрсәне беләсеңме? Шунда кул күтәреп алыша башласагыз, сугышып китсәгез, бу хәл авылга гына түгел, бөтен районга ишетеләчәк, бөтен колхозга гарьлек булачак иде... Тагын бер соравым: Муса Җәлил китапларын укыганың бармы соң?

Маңгае өстендә бөрчек-бөрчек тир калка башлаган егетебез бер мәлгә ык-мык килеп торды.

— Менә бит башкалар белән сүз көрәштерергә осталыгың бар, ә минем белән юк. Димәк, аз укыйсың китапларны, аз. Менә шул, егеткәй, хәзер үк китапханәгә төшеп, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» дигән китабын яздырып ал. Ул аны фашистлар тоткынлыгында чакта, муенына палач балта салырга әзерләнгән көннәрдә язган. Менә бит нинди була чын патриот! Сиңа үз колхозыңның патриоты булу өчен тырышырга кирәк. Китапны укып чыккач, килерсең, миңа әчтәлеген сөйләрсең.

Егет чыгып киткәч, идарәдә без икәү генә калдык. Шунда Бижан Камалов миңа моннан берничә ел элек комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән Нәгыйм Фәхразиев белән ничек җәфа чигәргә туры килгәнлеген сөйләп алды. Болай эш өчен җанын-тәнен бирүче кеше була ул, техниканы да ярата. Ләкин эчүчелеккә бирелеп киткәч, бу әйбәт сыйфатларын югалта башлый. Көн саен диярлек өйдә тавыш-гауга күтәрә, хатынын кыйный, аны өйдән куып чыгару дәрәҗәсенә барып җитә. Бригадир аның белән бер дә, ике дә сөйләшә, кулыннан килгәнчә чарасын күрә, кисәтеп тә карый. Ләкин атна-ун көн басынкы йөргән Нәгыйм «яшел елан» агуы әлегүгә, яңадан начарлана башлый,

Көннәрнең берендә колхоз председателе аны үз янына чакыра. Нык әйтә ул аңа, борычлап та, суганлап та.

— Сезнең кебек чакта без сырты көйгән атларны йөгәненнән сөйри-сөйри сабан сердек, җир тырмаладык, чәчтек. Ә бүген синең кулда арык ат түгел, әр-яңа куәтле комбайн! Акчасын да, ашлыгын да чумырып бирәбез. Сиңа колхоздан кадер-хөрмәт, ә син аңа рәхмәт әйтәсе урында, таш ыргытасың. Әйе, бу кыйланышың таш ату белән бер ул! Кая синең кешелек намусың, кая оятың?!

Бижан Камаловның бу сүзләреннән, шелтәсеннән соң кычкырып җылап җибәрер хәлгә килгән Нәгыйм, башын түбән салындырып, тәлсез кешедәй тын кала.

— Соңгысы, Бижан абый, кичерегез,— ди ул, ниһаять, авыр сулап.— Гафу итегез, башка бер кайчан да...

Әйе, ул елларда председательгә бер Нәгыйм белән генә түгел, аңа охшашлы башка бик күп кешеләр белән сөйләшергә, киңәш бирергә туры килгән. Хәзер инде аларның тормышларында зур үзгәрешләр булды. Иң әһәмиятлесе: бу колхоз авылы кешеләре арасында яңа мөнәсәбәтләр ныгып урнашты, хезмәткә, җәмгыять алдындагы бурычларын үтәүгә карашлары үзгәрде. Колхоз байлыгын арттыруны үзләренең тормыш хәлен тагын да яхшыртуның, бәхетле шат тормышның төп чыганагы дип саныйлар хәзер алар.

## Рәхмәт сезгә, иптәшләр!

Тимерче Галимҗан ага Тимергалин, иртә белән эшкә килгән саен, колхоз мастерское янындагы мәйданчыкта тезелеп утырган комбайннарга, трактор-машиналарга таба озаклап карап тора. Никадәр техника! Ел саен өстәлә, ел саен яңара. Әйе, кайчандыр ат дагалаучы тимерчедән башка һөнәр иясе булмаган Тәкермәндә бүген нинди генә машиналар юк та, нинди генә һөнәр ияләре юк! Монтер-электрик, инженер-механик, тракторчы, комбайнчы, ташчы, электросварщик, экономист, киномеханик, музыкант...

Әнә шул кешеләр авылның йөзен үзгәртәләр бүген. Урамнарда — су колонкалары, йортларда — Ильич утлары, радио, телевизор. Таштан эшләнгән ике Культура йорты, магазин, мәктәп... Боларның барысын да колхозның үз осталары, шушы бер-ике ел эчендә генә үсеп чыккан үз кадрлары эшләде.

Һәм менә бүген колхозның отчет-сайлау җыелышы. Муса Җәлилләр үз авылларындагы әнә шул матур үзгәрешләрне горурлык белән телгә алачаклар бүген.

Колхоз председателе Бижан Камалов докладын башлаганчы, залдагыларга таба күз йөртеп чыкты. Әнә игенче Гаяз Әминов. Аның күкрәгендә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены балкый. Агроном Әгъләм Юлдашев, кош караучы Мәрҗән Гарипова СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең медальләре белән бүләкләнгәннәр. Әнә сарык караучы Нәҗия Салихҗанова. 150 сум күләмендәге Муса Җәлил исемендәге колхоз премиясенең беренче лауреаты. Шундый ук бер премия коммунист Гаяз Гатауллин җитәкчелегендәге бригадага да бирелде. Әнә шундый тырыш һәм хезмәт сөючән игенчеләр, терлекчеләр белән ничек горурланмаска!

Колхоз председателе Бижан Камаловның үзенең күкрәгендә дә орден. Ул — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры.

— Рәхмәт сезгә, иптәшләр! — дип башлады ул сүзен.— Сезнең уртак тырышлыгыгыз белән колхозыбыз елдан-ел яңа үрләр яулый. Уңыш күтәрелә бара, терлекчелек продуктлары арта. Кайчандыр без күршебез куйбышевлылар кебек уңыш үстерү турында хыялланa, шуңа омтыла идек. Хәзер моңа ирештек, рәхмәт сезгә, иптәшләр!..

Колхоз председателе колхоз алдынгыларын олылап телгә ала, саннар китерә. Куанычлы саннар алар, Муса Җәлил исемендәге колхозның үсеш юлларын чагылдыручы саннар...

Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең кайнар эзләре калган бу колхоз җирләрендә иҗади хезмәт кайный, аның кешеләре бердәм омтылыш белән тырышып эшлиләр.

**Т. Насыйров,**

тарих фәннәре кандидаты

# УЛ В. И. ЛЕНИН БЕЛӘН БЕРГӘ ЭШЛӘДЕ

*Мулланур Вахитов тормышын һәм революцион эшчәнлеген өйрәнү турында*




КПСС Үзәк Комитетының «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына» Тезисларында болай диелә: «Революцияне ясауда, безнең алга тарих куйган гигант бурычларны хәл итүдә эшчеләр сыйныфы, бөтен совет халкы коммунизм идеяләренә чын күңелдән бирелгәнлекләрен, батырлык һәм фидакарьлек, югары дәрәҗәдә аңлылык һәм оешканлык күрсәттеләр. Совет кешеләре революциянең җиңүенә, социализмның җиңүенә өлеш керткән көрәшчеләргә тирән ихтирам һәм рәхмәт хисләрен белдерәләр. Большевик-ленинчыларның, социалистик революция, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы геройларының истәлеге халкыбызга һәрвакыт изге булыр. Беренче бишьеллыкларда яңа заводлар, колхозлар, совхозлар корган батыр төзүчеләр— хезмәтләре белән социализм төзегән, дөньяда беренче социалистик дәүләтнең куәтен ныгыткан кешеләр һичкайчан онытылмас. Аларның батырлыгы дөньяны революцион үзгәртеп кору эшенә һәрвакыт хезмәт итәр»[1]

ВКП(б) Үзәк Комитеты «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турындагы» 1944 ел 9 август карарында ук крайның күренекле эшлеклеләрен, галимнәрен һәм революционерларын популярлаштыруның кирәклегенә күрсәткән иде. Әлбәттә, бу өлкәдә күп нәрсә эшләнде инде. Ул карар чыкканнан соң Казанда Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Камил Якупов, Галимҗан Ибраһимов, Сәхипгәрәй Сәедгалиев, Ефим Табейкин, Хәсән Урманов турында басылган әйберләр, «Халык бәхете өчен көрәшчеләр» җыентыгы — бу кирәкле һәм игелекле эштә беренче карлыгачлар булдылар.

Ләкин укучыларның күпчелеге әле Совет властен урнаштыру һәм ныгыту, социалистик төзелеш чорындагы революцион вакыйгаларда актив катнашкан И. Ходоровский, М. Дулат-Али, Н. Вахитов, И. Кожевников, Е. Маленков, М. Конов, Ш. Шәймәрданов, К. Абрамов һ. б. кешеләр турында бик аз беләләр.

Туган ягыбызның күренекле революционерларын — Октябрь революциясендә катнашкан кешеләрне, шулай ук гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы, социалистик төзелеш ветераннарын популярлаштыру киләчәктә киң колач алыр дип ышанасы килә.

Октябрь чорында татарлар арасыннан чыккан күренекле революционер Мулланур Вахитовның тормышы һәм эшчәнлеге тикшерүчеләрнең игътибарын өзлексез җәлеп итте һәм итә. Аның революцион тормыш юлын өйрәнү Совет властеның беренче

[1] «Социалистик Татарстан», 1967 ел, 25 июнь.

кечнәреннән ук башланды. 1919 елда ук инде «Шәрыкның бөек революционеры Мулланур Вахитов» дигән, вакытына күрә шактый гына күләмле истәлекләр җыентыгы чыгарылды. Аны Галимҗан Ибраһимов редакциясендә Үзәк хәрби мөселман коллегиясенең политбүлеге әзерләгән иде.

Ләкин М. Вахитовның биографиясен архив документлары нигезендә ныклап өйрәнү чынлыкта илленче еллар уртасында гына башланды. Ул вакытка кадәр чыккан зур булмаган хезмәтләр башлыча истәлекләр яки аларга аңлатма характерында иде. (1941 елда басылган «Күренекле кешеләрнең Казандагы тормышы» дигән китапта урнаштырылган Шәйхи Маннурның мәкаләсен искә алмаганда). Мәсәлән, М. Вахитовның төгәл туу көне матбугатта бары тик 1957 ел башында гына күренде[1]. М. Вахитов турында архивта табылган берничә документ, аерым алганда, аның студент елларындагы фотографияләре шул елларда Ленинградтан Казанга соратып алынды.

1958 елда Пермьда, 1960 елда Уфада В. М. Исхаковның Вахитов турындагы брошюралары басылып чыкты. 1960 елда Р. Нафиговның «Мулланур Вахитов» дигән хезмәте дөнья күрде. Эзләп тапкан чыганакларның күплеге буенча ул башка хезмәтләргә караганда уңай яктан аерылып тора. 1965 елның августында, М. Вахитовның тууына 80 ел тулу уңае белән, «Правда» газетасы үзенең 22 август санында партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Ф. А. Табеев мәкаләсен чыгарды. 1967 елда Татарстан китап нәшрияты Мулланур Вахитовның сайланма мәкаләләр, речьләр, хатлар һәм документлар җыентыгын аерым китап итеп бастырды. Аны матбугатка профессор Р. И. Нафигов әзерләде.

Шактый эш башкарылуга карамастан, Мулланур Вахитов тормышын һәм революцион эшчәнлеген тагы да өйрәнүне һәм ачыклауны таләп итүче күп кенә проблемалар һәм моментлар кала килә әле. Мәсәлән, аның Петербургта укыган һәм яшәгән чоры (1907—1916 еллар) җитәрлек өйрәнелмәгән. 1916 елда М. Вахитовның, юридик бүлекнең 4 курсында укыган чагында, психоневрологик институттан чыгарылуы һәм башка вузга керү хокукы бирелмәве билгеле.

Яманаты чыккан мәгариф министры Деляновның 1887 елның 14 июнендә раслаган кагыйдәсе буенча гаепле студентларга өч төрле җәза бирелгән: 1) 37-г статьясы буенча институттан чыгарылган студент билгеле бер шартларда яңадан кабул ителә алган, 2) 37-д статьясы буенча студент институтка кире кабул ителмәгән, 3) 37-е статьясы буенча институттан чыгарылган студент гомумән нинди дә булса вузга керү хокукыннан мәхрүм ителгән. Иң югары җәза буларак, соңгы статья политик ышанычсыз студентларга карата кулланылган һәм алар провинциягә җибәрелә торган булганнар.

М. Вахитов соңгы статьяга эләккән булган һәм юкка гына түгел, күрәсең. Мәгариф министрлыгы һәм полиция департаменты архивларын җентекләбрәк өйрәнү әйбәт булыр иде. Аларда югары уку йортларындагы тәртипсезлекләр турында ел саен махсус делолар булдырганнар. Уку округы попечительләренә дә тәртипсезлекләр турында хәбәр ителгән.

Мулланур Вахитовның 1915—1917 елларда елга транспорты эшчеләре арасында революцион эш алып баруы турында да әлегә бик аз билгеле.

Февраль буржуаз-демократик революциясе җиңгәннән соң, М. Вахитовның революцион эшчәнлеге бигрәк тә киң колач ала. Бу турыда «Хөррият» газетасының 1918 ел, 29 июль санында языла. Вахитов мөселман социалистик комитетына һәм «Кызыл Байрак» газетасына җитәкчелек итә. Милләтчел буржуазия белән көрәштә һәм татар хезмәт ияләрен социалистик революция ягына тартуда бу органнар большевикларның Казан комитетына зур ярдәм күрсәткәннәр.

Мөселман социалистик комитеты (МСК) составында большевистик фракция кайчан барлыкка килде дигән сорауны ачыклау зур әһәмияткә ия. Кайбер иптәшләр ул 1918 елның җәендә июнь киңәшмәсендә барлыкка килде дип исәплиләр. Ә кайбер документлар исә андый фракциянең 1917 елда ук булуын раслый. Мәсәлән, МСКның актив члены, ак чехлар белән сугышкан кызыл гвардия отряды командиры, партиянең XIII съезды делегаты, РКП(б)ның Татарстан, Кырым, Баку һәм Смоленск өлкә комитетлары каршындагы партия-контроль комиссияләренең озак еллар җаваплы работнигы булып торган М. М. Ибраһимовның 1936 елда төзелгән анкетасында: «ВКП(б) члены итеп 1917 ел-

---

[1] «Социалистик Татарстан», 1957 ел, 17 февраль.

ның сентябрендә МСК каршындагы РСДРП(б) партия комитеты тарафыннан кабул ителдем»[1],— дип язган.

Октябрь революциясенә кадәр үк МСК составында большевиклар фракциясенең булуы турында Я. Чанышев[2], В. Шафигуллин[3], Р. Раимов[4] һәм башкалар хәбәр итәләр. Бу мәсьәләне өйрәнү һәм ачыклау МСК эшчәнлеген, бигрәк тә аның уңай якларын дөрес яктыртырга, шулай ук Мулланур Вахитовның ул чорда партия члены булу-булмавына төгәллек кертергә мөмкинлек бирер иде.

Мөселман социалистик комитетының РСДРП(б) Үзәк Комитеты белән элемтәсен дә ачыкларга кирәк әле. Булган документаль мәгълүматлар буенча бу оешма РСДРП(б) Үзәк Комитетының җирле оешмалары адреслар кенәгәсендә[5] теркәлгән дигән фикер туа. Казанда 1917 елда басылган һәм КПСС Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм институтының Үзәк партия архивында әле дә саклана торган «1) Мөселман социалистик комитеты, 2) район комитеты (үрнәк устав) һәм 3) Мөселман социалистик комитеты каршындагы эшчеләр клубы уставлары» дигән китап МСК һәм большевиклар партиясе Үзәк Комитеты арасында элемтәнең булуын раслый.

Казанда Октябрь кораллы восстаниесе вакытында чыгып килгән «Кызыл байрак» газетасының берничә номеры сакланмавы кызганыч. Тарихның иң әһәмиятле борылыш чорында М. Вахитов эшчәнлеген төгәлрәк күрсәтергә ярдәм итәрләр иде алар. СССР фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты илебезнең башка шәһәрләрендә һәм районнарында (Астрахань, Оренбург, Уфа, Свердловск, Ленинград, Урта Азия, Себер һ. б. урыннарда) Октябрь революциясе көннәрендә чыккан газеталарны, шул исәптән «Кызыл байрак»ны эзләү буенча чаралар күрсә, бик яхшы булыр иде.

Октябрь революциясеннән соң Мулланур Вахитовның революцион эшчәнлеге күпкырлы һәм тирәннән өйрәнүне таләп итә. Бөек юлбашчы В. И. Ленин белән турыдан-туры аралашып һәм аның җитәкчелегендә эшләгән чагында М. Вахитов зур дәүләт эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелә. Аерым алганда, безнеңчә, түбәндәге моментларга игътибарны юнәлтергә кирәк.

Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман комиссариатының — барлык милли комиссариатлар арасында иң зурысының — оешу тарихы һәм башлангыч эшчәнлеге әдәбиятта җитәрлек яктыртылмаган. Гадәттә авторлар атап үтелгән комиссариатны һәм аның җирле бүлекләрен төзү турында В. И. Ленин кул куйган декретлардан өзек китерү белән генә чикләнәләр. Чынлыкта исә Үзәк мөселман комиссариаты совет милли оешмалары аппаратында эшләү өчен пролетар кадрларның җитмәве, шулай ук милләтчел буржуазиянең каршылык күрсәтү нәтиҗәсендә туган зур кыенлыклар шартларында төзелде һәм беренче адымын ясады.

«Россия мөселманнарының барысы да (!!) большевиклар хөкүмәтен әле танымаганнары юк... Эшләрен дә большевиклар хөкүмәте тәшәбес[1] илә тәшкил итеlә торган комиссариатлардан каратачаклар түгелләр[2], дигән булып, милләтчел буржуазия атап үтелгән совет комиссариатын танымаска маташты.

Бу шартларда Совет хөкүмәте һәм В. И. Ленин үзе Үзәк мөселман комиссариаты җитәкчесе итеп Совет властена чын күңелдән бирелгән һәм дәүләт эшенең бу мөһим участогын уңышлы алып бара алырлык кеше сайлау турында зур кайгыртучанлык күрсәттеләр. Бу постка билгеләнгәнче В. И. Ленинның Мулланур Вахитовны күреп сөйләшүе[3] очраклы түгел. Милләтләр эше буенча Халык комиссары И. В. Сталин да бу мәсьәләгә карата Вахитов һәм Учредительный собраниедәге мөселман фракциясенең сул өлеше членнары белән берничә әңгәмә үткәргән[4].

---

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. Ф. 15. Терк. бер. 17. Эш 381, 422 битләр.

[2] Я. Чанышев. «Армия һәм Октябрь». «Советлар власте өчен» исемле истәлекләр җыентыгы. Татарстан китап нәшрияты. 1957, 92 бит. Шул ук автор. «1917 ел Казанда». Тат. китап нәшрияты. 1968. 50 бит.

[3] Шәфигуллин Вәли. «Казан мөселман социалистлар комитеты». «Кызыл Татарстан». 1927 ел. 4 ноябрь.

[4] Р. М. Раимов. «Башкортстан АССРның төзелүе». Мәскәү. 1952. 212 бит.

[5] «Тарихи архив». № 6. 1956. 38 бит.

---

[1] Тәшәбес — теләк.

[2] «Корылтай». 1918 ел. 31 январь.

[3] В. И. Ленин һәм Татарстан. Татарстан китап нәшрияты. 1964 ел. 245 бит.

[4] «Чулпан». 1918 ел. 18 январь.

В. И. Ленин декреты буенча мөселман эшләре комиссариаты төзү һәм Мулланур Вахитовның аның җитәкчесе булырга риза-лыгы бирүе контрреволюцион буржуазияне ярсынып котырынырга мәҗбүр иткән. Милләтчел «Корылтай», «Чыңгыз баласы», «Ил» һәм башка газеталар «кызыл байракчы большевик» («Корылтай». 1918 ел, 31 январь) — Мулланур Вахитовка карата күп санлы ләгънәтләр яудырганнар. Ләкин Мулланур милләтчеләр янавыннан курыкмаган, Совет властен ныгыту өчен армый-талмый көрәш алып барган.

Комиссариат аппаратын һәм аның урыннарындагы бүлекчәләрен алдынгы пролетар һәм революцион-демократ көчләр белән тәэмин итү буенча Үзәк мөселман комиссариатының һәм аның җитәкчесе Мулланур Вахитовның эшчәнлеге әле бөтенләй ачыкланмаган диярлек. Россиядәге мөселманнар эше буенча Комиссариат төзү турында В. И. Ленин кул куйган декрет чыккач та М. Вахитов күрсәтмәсе буенча Г. Ибраһимов Төньяк фронтның мөселман хәрби комитеты торган Псков шәһәренә барып кайта[1]. Тиздән бу комитетның кайбер членнары, аннары бөтен составы Псковтан Петроградка күчә һәм Үзәк мөселман комиссариаты белән кушыла[2]. Бу комитет членнары большевиклар яки аларга теләктәшлек белдерүчеләр булалар. М. Дулат-Али (1917 елга кадәр аның фамилиясе Алиев), М. Конов (Минһаҗ Гайнетдинович, 1917 елның 13 маеннан КПСС члены), Х. Урманов, А. Алмаев һәм башкалар комиссариат һәм аның урыннардагы бүлекчәләре составына керәләр. Мәсәлән, Й. Ибраһимов хәрби бүлек мөдире, Х. Килдебеков матбугат бүлеге мөдире итеп билгеләнә[3].

Мөселман эшләре буенча комиссариат председателе буларак, М. Вахитовның Петроградта эшче һәм солдат массалары арасындагы эшен, Кызыл Армиянең беренче милли частьләрен төзүдә катнашуын тирәнтен өйрәнергә кирәк әле.

М. Вахитовның илебез башкалаларындагы революцион эшчәнлеген яктыртканда аның буржуаз-милләтчел оешмаларны — «Милли идарә», «Милли шура», «Хәрби шура» һәм башкаларны — тар-мар итүдәге ролен тулырак ачарга кирәк. Мулланур Вахитов эшчәнлегенең нәкъ шушы ягы милләтчел буржуазиядә аңа карата аеруча нәфрәт уятты һәм киләчәктә аны җәзалауларының төп сәбәбе булды.

Милләтче буржуазиянең төп оешмасын — «Милли идарә»не таратуда[1] Вахитовның ролен аеруча ассызымлап әйтеп үтәргә кирәк. «Милли идарә» 1917 елның җәендә мөселман буржуазиясе игълан иткән «милли-мәдәни мохтарият»ны тормышка практик ашыру органы булып торды. М. Вахитов «Милли идарә»не таратуда актив катнашып, «милли-мәдәни мохтарият»ка үзенең тискәре карашта торуын күрсәтте. Контрреволюцион оешма булган «Милли идарә»не бетерү буржуаз газеталарда зур ярсу тудырды. «Димәк, җинаятьнең иң бөеге эшләнде,— дип язды «Алтай» газетасы үзенең 1918 ел, 29 апрель номерында.— ...Бу татар тарихы күргән хыянәт вә җинаятьләрнең иң зурларыннан булуы белән бәрабәр милли вә мәдәни эшләргә иң дәһшәтле зарбә[2] төшерә торган бер җинаятьдер».

М. Вахитов бигрәк тә ярсулы ут астына эләгә. Милләтчел журналистлар аның турында газетаның тулы бер битен алып торган махсус мәкаләләр бастыралар. Мәсәлән, шул ук «Алтай» газетасы дүрт баганадан торган бер мәкаләсендә: «Мулланур Вахитов милли, мәдәни мохтариятыбызны хәл кылды, ләкин без теләгәнчә түгел, ә үзе һәм иптәшләре, рус, яһуди вә грузин большевиклары теләгәнчә»[3],— дип зур ачу белән язды. Казан муллаларының органы — «Иттифак» исемле реакцион газета: «Бу эшләрне башкарган кешеләр тиз көннәрдә милләт һәм тарих алдында зур җаваплылык кичерәчәкләр»[4],— дип янады. Ак чехларның һөҗүме вакытында — 1918 елның җәендә — кулга эләккән М. Вахитовның татар буржуазиясенең соравы буенча ерткычларча җәзалап үтерелүе бер дә гаҗәп түгел.

М. Вахитовның «сул» эсерларга каршы Брест солыхы төзү һәм 1918 елның җәендә «сул» эсерлар фетнәсен бастыру чорында большевиклар партиясе линиясен үткәрү өчен көрәше, Советларның V Бөтенсоюз съездында катнашуы җитәрлек өйрәнелмәгән әле. М. Вахитов катнашында төзелгән икенче татар-башкорт батальоны, башка революцион частьлар белән бергә, «сул»

---

[1] «Чулпан». 20 февраль. 1918 ел.
[2] Шунда ук. 12 апрель. 1918 ел.
[3] «Кызыл Армия». 1918 ел. 20 апрель.

[1] «Милли идарә»не бетерү турында декрет 1918 елның 24 апрелендә кабул ителде.
[2] Зарбә — зыян.
[3] «Алтай». 1918 ел. 8 май.
[4] «Иттифак». 1918 ел. 10 май.

эсерларның провокацион чыгышы вакытында Мәскәүдә совет учреждениеләрен саклауда катнашуын күрсәтергә була [1].

Мулланур Вахитовның халыклар дуслыгын һәм пролетар интернационализмны ныгыту буенча башкарган эшчәнлеген дә өйрәнү кирәк әле. Бу яктан Вахитовның Мәскәүдә 1918 елның 22 июлендә халык алдында ясаган соңгы чыгышларының берсе бигрәк тә истәлекле. М. Вахитов ул вакытта: «Дөньяны капитал золымыннан коткарырга теләгән рус революционерлары өстендә кара болытлар тупланган, бөтен Россия пролетариатының яккан утын Европа буржуазиясе сүндерергә теләгән дәһшәтле бер заманда... мөселман революционерлары һәм пролетариаты һичбер вакыт рус иптәшләреннән аерылмаячаклар, дошман кулына бирелмәячәкләр, алар белән бергә булачаклар» [2], дигән иде.

Шушы вакытка кадәр Мулланур Вахитовның Казанга ак чехлар басып кергән чордагы эшчәнлеге, кулга алынуы һәм үлүе ахырга кадәр ачыкланмаган.

Бу яктан Нәби Вахитовның «Мулланурның соңгы көннәре» һәм Нурмөхәммәт Галимовның «Чехлар кергәндә» дигән истәлекләре [3], Исхак Казаковның шушы вакытка кадәр басылмаган истәлекләре [4] зур кызыксыну тудыралар. Алар М. Вахитовның һәм аның көрәштәшләренең ул чордагы тормышларына ачыклык кертәләр.

Фронтка китәр алдыннан, Үзәк мөселман хәрби һәяте председателе буларак, Мулланур Вахитовка һәм, һәятның әгъзалары буларак, Нәби Вахитов белән Һади Маликовка Көнчыгыш фронтта Кызыл Армиянең татар-башкорт частьләрен оештыру хокукы белән Республиканың революцион хәрби Советы исеменнән махсус мандатлар бирелүе, безнеңчә, әһәмиятле факт булып тора. Санап кителгән истәлекләр М. Вахитовның Казан өчен оборона сугышларында актив катнашуын тагы бер кат раслыйлар, бу мәсьәләгә өстәмәләр һәм детальләр кертәләр.

Бу истәлекләрдә ак гвардиячеләрнең Мулланур Вахитовны кулга алу урыны һәм шартлары турында яңа мәгълүматлар бар. Авторларның күпчелеге, 1919 елда чыккан истәлекләр җыентыгына нигезләнеп, М. Вахитов Борисково поселогында кулга алынды, дип исәпли. Нәби Вахитовның әйтүе буенча, аклар совет комиссарын Казаннан 20 километрларда урнашкан Богородск авылында кулга алганнар. Моңа ышанмаска нигез юк, чөнки Нәби Вахитов үзенең истәлекләрен, фактларны җентекләп өйрәнгәч, вакыйгаларда катнашкан кешеләр белән берничә тапкыр очрашып сөйләшкәч язган. Шуның өстенә, ак интервентлар Казанны алгач, милләтчел буржуазия тарафыннан яңадан чыга башлаган «Корылтай» газетасында Мулланур Вахитовны Богородск авылында кулга алу турында рәсми белдерү булган дигән хәбәр бар. Бу газетаны башка шәһәрләрдән эзләп карарга кирәк иде. (Казанда ул юк.) СССРның Октябрь революциясе Үзәк дәүләт архивы фондларын, аерым алганда, Комуч материалларын, җентекләп карарга кирәк. Бәлки ак гвардиячеләрнең хәрби-кыр суды документларын табып булыр (1956 елда мин аларны тиз генә карап чыктым, ләкин табып булмады). М. Вахитовны шул суд карары буенча атканнар.

Н. Вахитовның истәлекләре М. Вахитовның суд процессы вакытында үз-үзен тотуын күргән бер врачның сөйләвен китерүе белән дә әһәмиятле. Үзеңне аклау өчен нәрсә әйтә аласың, дигән сорауга каршы М. Вахитов: «Мин үземә капма-каршы дошман сыйныф кулына әсир төштем. Сыйнфый дошманның нинди хөкем чыгарасын беләм. Шуңа күрә һичбер төрле дә үземне сезнең каршыда акларга тырышмыйм... Сез мине ату белән революцияне бетерә алмассыз»,— дип җавап биргән.

М. Вахитовның 1918 елда фронтка китәр алдыннан Мәскәүдә калдырган шәхси китапханәсен табарга тагы бер кат омтылып карау да начар булмас иде. Китапханә Зайцевада — Вахитовның танышында калган дигән мәгълүматлар (Совет Армиясенең Үзәк дәүләт архивында) бар.

Мулланур Вахитовның күпкырлы эшчәнлеген тулырак яктырту өчен Үзәк мөселман комиссариаты һәм аның урыннардагы бүлекчәләре чыгарган барлык совет газеталарын (алар егермедән артык булган), шулай ук архив документларын киләчәктә тирәннән өйрәнергә кирәк дип билгеләп үтәсе килә. М. Вахитов турындагы истәлекләр җыентыгын хәзерләү мәсьәләсен дә күтәреп чыгарга вакыт.

---

[1] «Милләтләр эше буенча халык комиссариаты» эшчәнлеге турында отчет. 1917 ел, 1 ноябрь — 1918 ел, 20 июнь. Советларның V съезды делегатлары өчен. Мәскәү. 1918 ел.

[2] «Хөррият». 1918 ел. 9 июль. Төрек телендә басылган.

[3] «Кызыл Татарстан». 1926 ел, 19 август.

[4] Алар художник Х. Казаковта саклана.

Ибраһим Нуруллин

# ОНЫТЫЛМАС ЕЛЛАР ШАҺИТЕ

Үлемсез Тукаебыз ел саен, гүяки, әдәбиятыбызга барлау үткәрә һәм, арадан берсен сайлап алып, менә шушысы, ди... Әсәргә Тукай бүләгенең яктысы төшә, авторына лауреат исеме тагыла. Укучының игътибары кайтадан шул әсәргә юнәлгән кебек, тәнкыйть тә аңа, яңадан бер күз ташлап, бәя биреп узарга тиеш була.

Быел исә тәнкыйтьчегә эш җиңелдән түгел. Чөнки кадерле бүләккә лаек булган әсәр — Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе — турында инде күп язылды. Өстәвенә, узган елның азагында гына Суфиян Сафуановның И. Гази иҗатына багышланган китабы[1] да басылып чыкты. Трилогия турында яңа сүз әйтим дисең икән, аны яңадан җентекләп өйрәнергә тиеш буласың. Моның өчен исә вакыт кирәк. Нишләргә! Шулай аптырап йөргәндә, башка мондый бер уй килде: ни өчен, мәсәлән, С. Сафуанов китабына тотына-тотына, кирәк икән, тәнкыйтьчене хуплап, кирәк икән, бәхәсләшеп, язучы иҗатына, ахыр килеп, аның бүләк алган әсәренә бер күз йөртеп чыкмаска!!.

Алдан ук әйтеп куйыйм, Ибраһим Газиның иҗат портретын күз алдына бастыру максаты белән язылган әлеге китап — уңышлы хезмәт. С. Сафуанов язучының беренче хәбәрдән башланып трилогиягә кадәр үсеп җиткән иҗатын күзәтә, кеше образын тудыруда, әсәрләрен композицион яктан оештыруда, тел белән эш итүдә осталыгының бер баскычтан икенчесенә күтәрелә баруын шактый ышандырырлык итеп күрсәтә.

Китапның аеруча игътибарга һәм мактауга лаеклы ягы тагын шунда: тәнкыйтьче И. Гази иҗатының үсешен реализм теориясе яктылыгында карарга омтыла. Дөрес, «реализм» сүзен ул бик сирәк куллана. Әмма анализы, фикер сөреше һаман бер нәрсәгә — И. Гази әсәрләренең типик характерларны типик хәлләрдә тасвирлау принцибына җавап бирү-бирмәү мәсьәләсенә кайтып кала. Бу турыда аеруча басым ясап әйтәсем килә. Чөнки тәнкыйтебез һаман да әле әдәбият мәсьәләләрен ныклы теория яктылыгында хәл итә алуы белән бик үк мактана алмый. Бу хәл аеруча реализм проблемаларына бәйле рәвештә күзгә ташлана.

Теорияне практика белән кушарга омтылуын хуплау белән бергә, С. Сафуанов китабында кайбер төгәлсезлекләр очравын да әйтми булмый. Бер урында тәнкыйтьче, мәсәлән, болай ди: И. Гази «аерым шәхесләр язмышын халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә бирергә» тырыша. Романда яки повестьта бу таләпне, әлбәттә, тормышка ашырырга мөмкин. Ә инде кыска хикәядә халык тормышын ничек күрсәтергә дә, аерым шәхеснең язмышын аңа ничек бәйләргә! Ф. Энгельсның реализм турындагы атаклы формуласын юл күрсәтүче йолдыз итеп алган С. Сафуанов бу урында да реализмның нигез мәсьәләсе — шәхес һәм иҗтимагый-тирәлек (мохит) мәсьәләсен күздә тоткан, әлбәттә. Ләкин фикеренең бирелеше икенче төрле уйларга мөмкинлек калдыра.

Реалистик әдәбиятның төп бурычы (бик билгеле хакыйкать булса да, кабатларга туры килә) тормышны танып белүгә, җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең асылын, мәгънәсен ачып бирүгә кайтып кала. Язучы әнә шул бурычны кеше образлары иҗат итү һәм аларны үзара билгеле бер мөнәсәбәткә кую ярдәмендә башкара. Ә кеше, К. Маркс әйткәнчә, «барлык төр иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең җыелмасы». Ягъни кешенең аңын, карашларын, теләк-омтылышларын һәм үз-үзен тотышын җәмгыятьнең

[1] Суфиян Сафуанов. Ибраһим Гази. Язучы турында китап. Татарстан китап нәшрияты. 1968 ел.

асылы, андагы иҗтимагый факторлар белгели. Кеше әнә шуларның җимеше, продукты булып тора. Димәк, реалист язучының бурычы тормышта очраган кешеләрнең гади копиясен биру янсә алдан уйланган фикерен раслау өчен сурәт уйлап чыгару түгел. Аның бурычы — иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең гәүдәләнеше булган, чынбарлык закончалыкларының бер фокустагы чагылышы булган типлар иҗат итү. Шәхес һәм тирәлек проблемасының асылы нәкъ шуңа кайтып кала. Күренә ки, шәхес һәм халык, шәхес һәм иҗтимагый тирәлек проблемалары арасында бәйләнеш булса да, алар бер үк нәрсә түгел икән. Беренчесе зур күләмле әсәрләрдә генә тормышка ашырыла алса, икенчесе реализм киртәсенә керергә теләгән теләсә нинди әсәрдән таләп ителә.

Тәнкыйтьче дөрес билгеләп үткәнчә, И. Газиның беренче хикәяләрендә зур гомумиләштерү юк әле. Шулай да С. Сафуанов язучының бик иртә, бик яшьли нәкъ менә шәхес һәм тирәлек мәсьәләсе турында уйлана башлаганын һәм шуны тормышка ашырырга омтылганын күреп алган.

Менә «Кич алтыда» хикәясе. Комсомолец Таһир, элекке акгвардеец кызына гашыйк булып, комсомол эшеннән читләшә, коллективтан аерыла. Хикәядән аңлашылганча, хикмәт бирәдә кызда гына түгел. Хикмәт башлыча тирәлекнең Таһирга ясаган йогынтысында икән. Моны соңрак автор үзе үк бер чыгышында бик һәйбәт аңлатып биргән. Гаеп Таһирның үзендә генә түгел, ди ул. Егерменче елларның ахырында комсомол ячейкаларының эш стилендә борылыш булган. Әмма кайбер ячейкалар, үз эшләрен үзгәртеп кора алмыйча, искечә куалый биргәннәр. «Кич алтыда» хикәясендә гәүдәләндерелгән ячейка да — әнә шул типтагы ячейкаларның берсе. Ул ячейка яшьләр массасының таза теләкләре белән хисаплашмый. Таһир — әнә шул консерваторлык системасының «корбаны».

С. Сафуанов И. Газиның сугышка кадәрге беренче хикәяләренә генә түгел, бәлки «Бригадир кыз» повестена да хас тагын бер үзенчәлекне, дөресрәге, кимчелекне күреп алган. Язучы реализмның төп мәсьәләсен сәнгатьчә хәл итү юнәлешендә әһәмиятле генә омтылышлар ясаса да, кеше образларын җанландыруда схематиклыктан арынып җитмәгән икән әле. Әгәр уңай персонажны ул һәр яктан яхшы итеп күрсәтсә, тискәре персонажларны, тәнкыйтьче әйткәнчә, «начарлыклары беренче күрүдә үк күзгә бәрелеп торырдай бер яклы итеп» сурәтли. Бу хәл иң элек язучының тәҗрибәсе җитеп бетмәү белән аңлатыла, әлбәттә. Әмма схематизм шаукымы, моннан тыш, шул чор әдәбиятының гомуми торышы, ул елларның кайбер әдәби-эстетик принциплары белән дә бәйләнгән. Моны аңлау өчен, тагын теориягә мөрәҗәгать итик.

Мәгълүм булганча, кешенең тумыштан килә торган темпераменты, сәләт дәрәҗәсе, аны бүтән кешеләрдән аерып тора торган характер сыйфатлары була. Тирәлек, иҗтимагый мөнәсәбәтләр шәхеснең үз-үзен тотышына билгеле бер юнәлеш бирсә дә, индивидуаль характерны бөтенләй үк юкка чыгара алмый. Алай гына да түгел, соңгысы шәхеснең язмышында кайвакыт хәлиткеч роль уйнарга да мөмкин. Менә ни өчен индивидуальлек белән гомумилекнең органик берлеген тәшкил иткән реалистик кеше образын Ф. Энгельс типик характер дип атаган. Менә ни өчен А. М. Горький каләме белән түбәндәге сүзләр язылган: «Һич бәхәссез ки, «сыйнфый сыйфат» — «психиканы» билгеле бер рәвешкә китерә торган төп һәм хәлиткеч нәрсә». Ләкин «тасвир итеlә торган берәмлекнең [кеше образының — И. Н.], гомум сыйнфый сыйфаттан тыш, үзе өчен аеруча характерлы булган, ахыр чиктә аның социаль кыланышын [поведение] билгели торган индивидуаль үзәген табарга кирәк»[1].

Игътибар итик, чын реалистик сәнгатьтә әлеге индивидуаль үзәк, кешенең үзенә генә, тик үзенә генә хас булган берәр сыйфаты шул кадәр зур әһәмияткә ия ки, хәтта ул бу кешенең социаль яктан үз-үзен тотышын да билгеләргә мөмкин икән. Әгәр шулай булмаса, без, мәсәлән, ярлы катлаудан чыгып, реакционерга, янсә, фабрикант гаиләсендә туып, революционерга әверелгән кешеләрне һәм аларның әдәбияттагы образларын берничек тә аңлый һәм аңлата алмас идек.

Революциядән соңгы елларда язучыларның «сыйнфый сыйфат»ка аеруча басым ясаулары һәм кайбер очракта моның схематизмга алып китүе табигый хәл иде. Ерак барасы юк, менә Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте. Андагы биш егетнең уй-хисләре, кылган гамәлләре математик төгәллегендә социаль хәлләреннән чыга. Гали, кулак малае буларак, совет властена каршы актив көрәшче, Фазыл мулла улы — Галимәр ягыннан тора торган, ахырга таба урталыкта калган интеллигент. Урта хәлле крестьян баласы Гыйлаҗи алдын-артын карый-карый, бик үк чәчрәп чыкмыйча гына революция өчен көрәшүчеләр сафына килсә, ярлы крестьян улы Солтан көрәшнең үзгәнә икеләнүсез ташлана, орден тагып кайта. Кечкенәдән үк батрак булып киткән ятим Шаһбаз турында әйтсә дә юк: ул гражданнар сугышының легендар каһарманына әверелә. Тик шунысы бар, бу очракта Г. Ибраһимовның гаять зур таланты аны схематизмнан саклап калган.

И. Газиның да дошман сыйныф вәкилләрен каралтыбрак бирүе, ә комсомол яшьләрне «бизәбрәк» күрсәтүе, тәҗрибә җитмәүдән тыш, шул ук нәрсә — «индивидуаль» үзәккә җитәрлек игътибар итмичә, «сыйнфый сыйфат»ны кабартыбрак күрсәтү

---

[1] М. Горький. Собрание сочинений в тридцати томах. Рус телендә. 26 том, 1953 ел. 414—415 битләр.

белән аңлатыла. Әмма, тәнкыйтьче фикеренчә, И. Гази сугышка кадәр үк, аеруча «Катя Сорокина» повестендә җанлы, катлаулы һәм тормышчан типлар булдыру юнәлешендә уңышлы гына адым ясаган. Тик шулай да әлеге «индивидуаль үзәк»не «сыйнфый сыйфат» белән органик рәвештә куша башлау, димәк, И. Гази реализмының яңа баскычка күтәрелүе Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Дөрес, сугышның үзен күрмичә язган беренче хикәяләрендә без тагын схематизм белән очрашабыз. Язучы, мәсәлән, гитлерчы образларын бигәндә карикатурага бирелеп киткәли. Әмма «Алар өчәү иде», «Без әле очрашырбыз» һәм башка кайбер хикәяләре инде андый гөнаһтан азат.

«Алар өчәү иде» хикәясе үзенең кырыс реализмы белән аерылып тора. Менә әсәрнең төп герое лейтенант Сөләйманов. Аңа дошман тылына үтеп кереп, күпер шартлату кебек гаять җаваплы бурыч тапшырыла. Бу вакыт аның уе, фикере, зиһене гел шул задание белән генә мәшгуль булырга тиеш иде кебек. Ләкин ул, азмы-күпме баш вата да, «баргач күренер әле, барыбер син дигәнчә булмый ул» дип кул селти, һәм уйлары ихтыярсыздан авылга, укыткан мәктәбенә, гаиләсенә, яраткан улына күчеп китә.

Менә алар юлга чыгалар. Үзәкләргә үтә торган ачы җил каршы исә. Чиратлашып алдан баралар, арттан атлаучылар алдагының аркасына ышыкланалар. «Сөләймановка күптән алга чыгарга, Коненконы алыштырырга вакыт. Ә аның җилгә чыгасы килми. Тагын бер-ике минут кына шулай барыйм әле», дип уйлый ул. Ләкин моннан әле Сөләймановның ваемсыз кеше булуы яисә эгоистлыгы килеп чыкмый. Шушы һәм шуңа охшаш детальләр, лейтенант Сөләймановны кешегә хас йомшаклыклардан азат булмаган гап-гади, җанлы кеше кыяфәтендә күз алдына бастыруга хезмәт итәләр.

Тагын шунысы кызык: автор «иң авыры — иң ансаты булып чыкты» ди дә, күпер шартлату эпизодын язып тормыйча, өч бөртек сугышчының күп санлы дошманнар чолганышында калуларын, бөҗрадан ычкынып частька кайту өчен, ярсып сугышуларын тасвирлауга зур урын бирә. Аны совет сугышчыларының көндәлек тормышы, аларның минут саен булып тора, ләкин күзгә ташланмый торган батырлыклары кызыксындыра. Нәрсә көч бирә аларга! Билгеле инде, илдә социализм төзү процессында формалашкан кешелек сыйфатлары, атап әйткәндә, совет патриотизмы. Бу турыда язучы үз исеменнән бер сүз дә әйтми. Персонажларның үз-үзләрен тотышыннан, уй-фикер, хис-кичерешләреннән, үткән тормышлары турында чамалап кына бирелгән мәгълүматларыннан аңлашыла ул.

Кыскасы, И. Гази карап торышка «кечкенә», гади кешенең күңел байлыгын, Ватаны өчен җаваплылык хисен, шул җаваплылыктан туа торган батырлыгын күрсәтә. Тәнкыйтьче хаклы: алар, нинди генә батырлык эшләмәсеннәр, барыбер үзләренең гадилекләрен, «җир кешесе» булуларын онытмыйлар. Әйе, Сөләймановның өеннән хат алгач, яисә Азов даласында япа-ялгыз басып торган чагында авылы, семьясы турында уйлануларында һәм үзен авызыннан ут чыга торган командир итеп түгел, бәлки акыллы укытучы кебек тотуында шул чорның бөек хакыйкате гәүдәләнә. Юк, совет кешеләре сугыш чукмарлары түгел, алар тыныч хезмәт кешеләре. Солдат шинеле киеп, кулларына корал алып, тиңсез батырлык үрнәге күрсәтүләренә карамастан, тыныч хезмәт кешеләре булып калалар, дигән хакыйкать бу.

«Без әле очрашырбыз» повестендагы Дәүләтшин һәм Разия дә хезмәт ярдәмендә җирдә матурлык урнаштыру максаты белән яшәгәннәр. Аларның да шул тыныч хезмәтне өзгән фашист илбасарларына нәфрәте, сугыштагы фидакарьлекләре социалистик чынбарлыкның асылы белән бәйләнештә күрсәтелгән. Әмма рухы, язучының кеше образын тудыру алымнары ягыннан повесть «Алар өчәү иде» хикәясеннән аерылып тора. Бу үзенчәлек, тәнкыйтьче әйткәнчә, «сугыш героикасын романтик планда» чагылдыруда күренә. Әсәргә киң тукталмастан тик шуны гына әйтик: аяусыз һәм кырыс реализм тарафдәры И. Гази иҗатына романтизм буяулары килеп керә. Язучының моннан соңгы иҗаты шул ук реализм юнәлешендә үссә дә, әлеге романтизм алымнары да эзсез югалмый, аның реализмын тагын да баета, күтәрә һәм әчтән яктырта.

Сугышка кадәр үк яза башлаган «Онытылмас еллар» романы өстендә эшләү И. Газиның сугыштан соңгы иҗат гомерен тутырып тора. Ләкин ул, гражданин буларак, социаль заказ үтәү йөзеннән, зур эшен бүлеп торып, күп кенә бүтән әсәрләр язды. Шулардан «Алмагачлар чәчәк ата» повесте һәм «Гади кешеләр» романы аерата игътибарга лаеклы.

Тәнкыйтьче бер урында «Алмагачлар чәчәк ата» повестенә карата болай ди: «И. Гази үз геройларының типик характеры ачылу өчен типик шартлар итеп әнә шул бакча үстерү өчен көрәш вакыйгаларын ала». Бирелә бер төгәлсезлек киткән: тәнкыйтьче типик хәлләр (шартлар түгел — И. Н.) төшенчәсен тарайтып аңлый, аны обстановка (конкрет бер бакча үстерүгә кагылышлы кешеләр, вакыйгалар, детальләр) белән бутый. Ф. Энгельсның мәгълүм хатыннан типик хәлләрнең «типик характерларны урап алган һәм аларны хәрәкәт иттерә (курсив минеке — И. Н.) торган»[1] иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кайтып калганлыгы аңлашыла. Игътибар итик, типик хәлләр геройның үз-үзен тотышын билгели, аны билгеле бер юнәлештә эш башкарыр-

[1] К. Маркс и Ф. Энгельс об искусстве. Рус телендә. 1 том. 11 бит.

га мәҗбүр итә. И. Гази повестендагы бакча үстерү вакыйгаларына карата моны әйтеп буламы! Әлбәттә, юк. Чөнки бу вакыйгалар үзләре Гаяздан, аның активлыгыннан, аның башлап йөрүеннән килеп чыгалар. Ул вакыйгаларны Гаяз тудыра. Ә Гаязның инициативасы, активлыгы һәм эшчәнлеге кайдан килә! Әнә шул сорауга җавап, ягъни геройның активлыгын китереп чыгарган, аны уңышка яисә уңышсызлыкка алып килгән иҗтимагый күренешләрне генә типик хәлләр дип әйтергә мөмкин.

Сугыштан соңгы елларда колхоз авылының хәле, мәгълүм булганча, җиңелдән түгел иде. Сугыш китергән бәла-казалардан тыш, авыл хуҗалыгын идарә итүдәге кимчелекләр һәм хаталар аның үсешен җитди тоткарлый иде. Күкрәп алма биргән бакчаларны, налог политикасының кысуы аркасында, кисеп ташлау очракларын гына искә төшерик. Әнә шул хәлдән чыгу, авыл хуҗалыгын тиешле дәрәҗәгә күтәрү өчен партиягә һәм гомумән халкыбызга 10—15 ел буе героик эш башкарырга туры килде.

Ә безнең Гаяз нишли! Армиядән кайта да биш мең төп алмагачлы, кура җиләкле, карлыганлы бакча ясап куя. Колхоз председателе Гыймади агайның кирелэнеп йөрүен искә алмаганда, телгә алып сөйләрлек авырлык һәм киртәләр булмый. «Килде, күрде, җиңде»! Күренә ки, повестьның төп герое Гаяз типик хәлләргә куелмаган. Әсәрнең шушы кимчелеген тәнкыйтьче дә күргән. Әмма теоретик төгәлсезлек аңа моның сәбәпләрен ачып бирергә комачаулаган.

Бу уңай белән тагын бер кат теория ишеген шакырга туры килә.

Югарыда без «индивидуаль үзәккә» ия булган типик характер иҗат итү һәм аны иҗтимагый тирәлек җимеше итеп күрсәтү турында, ягъни реализмның нигез принциплары турында сүз алып барган идек. Әмма бу принциплар, әйтик, критик реализмда да тулысынча тормышка ашырыла. Ә менә социалистик реализм әдәбиятында эш ничегрәк тора соң! Шәхес һәм тирәлек проблемасы биредә ничек хәл ителә!

Басым ясап әйтергә кирәк, социалистик реализмда да персонажлар иң элек үзләренең характерына хас рәвештә хәрәкәт итәләр. Биредә дә аларның уй-фикерләре, иҗтимагый тормыштагы урыннары социаль-экономик, иҗтимагый-политик мөнәсәбәтләр белән билгеләнә. Алар да иҗтимагый тирәлек җимешләре итеп күрсәтеләләр. Ләкин социалистик реализм әдәбиятында типик уңай характер «продукт» булып кына калмый. Ул үз чиратында иҗтимагый тирәлеккә йогынты ясый торган, аны үзгәртү өчен көрәшә торган актив көч итеп тасвирлана.

Тулаем алганда, татар совет әдәбиятында әнә шул таләпләр тормышка ашырылса да, аеруча 40 елларда, ул принципларны бозу очраклары күзгә ташланды. Беренчедән, уңай геройга психологик катлаулылык җитми иде, аның индивидуаль характеры җитәрлек тәсмерләнми иде. Икенчедән — бусы бигрәк тә игътибарга лаеклы,— геройның тирәлеккә йогынты ясау сыйфаты, иҗтимагый активлыгы чамасыз күпертелеп тә, тирәлек белән бәйләнеше, конкрет типик хәлләр җимеше булу хасияте ачылып җитми иде. Нәтиҗәдә мондый персонажлар чынбарлыкны күз ачып йомганчы үзгәртеп ташлый торган әкият геройлары булып чыгалар иде. Күргәнебезчә, «Алмагачлар чәчәк ата» повесте — нәкъ менә шуның характерлы мисалы булып тора [1].

«Гади кешеләр» романына күчеп, иң элек шуны әйтәсе килә: куәтле нефть промышленносте республикабызның кыяфәтен үзгәрткән кебек, кешеләрең аңына, үз-үзен тотышына, уй-хисләренә бик күп яңалыклар алып килде. Тормышыбыздагы әнә шул үзгәрешләрне сәнгатьчә күрсәтүдән әдәбият та читтә кала алмый иде. Моңарчы татар язучыларының игътибарыннан читтәрәк тора торган өр-яңа тормыш материалын үзләштерү һәм кыска вакыт эчендә әйбәт роман язу өчен, билгеле, гражданлык бурычын тоюдан тыш, тормышны, кеше күңелен белү һәм талант кирәк. Бу сыйфатлар И. Газида бар, һәм ул, шуларга таянып, үз өстенә алган бурычны уңышлы үтәп чыкты.

Билгеле, беренче коймак төерле була, дигәндәй, романның күңелне канәгатьләндереп җиткерми торган яклары да бардыр. Әмма, «Алмагачлар чәчәк ата» повестеннән аермалы буларак, «Гади кешеләр»дә шәхес һәм тирәлек арасындагы катлаулы мөнәсәбәт төп иҗат методыбыз таләпләре яктылыгын да дөрес хәл ителгән.

С. Сафуанов уңай һәм тискәре образ турында, романдагы персонажларны шул категорияләргә кертү-кертмәү турында кирәгеннән артыграк сөйләсә дә, ахыр чиктә дөрес нәтиҗәгә килә: аларның иң зур күпчелеге уңай да, тискәре дә персонаж түгел, бәлки җанлы кешеләр. Һәркайсының дип әйтерлек үзенә генә хас характер сыйфатлары бар. Тагын да әһәмиятлерәге шул: һәр персонажның үз-үзен тотышындагы, уй-хисләрендәге, дөньяга карашындагы уңай һәм тискәре сыйфатлары күктән төшмәгән, яисә биологик факторларга гына кайтып калмый. Беренчеләре социалистик яшәеш нормаларыннан үсеп чыкса, икенче-

---

[1] Соңгы елларда татар әдәбиятында социалистик реализмның уңышларыннан тыш, капма-каршы тенденцияне дә шөйләргә мөмкин. Персонажда җан да, кан да бар, характер да сизелә, тирәлек белән бәйләнеше дә җитәрлек. Әмма тирәлек дигән нәрсә бик тар алына. Илебезнең социаль-экономик һәм иҗтимагый-политик тәртипләре булудан бигрәк, ул төге яки бу сәбәпләр белән тормышыбызга килеп кергән авыру яклар, кимчелекләр һәм авырлыклар җыелмасына гына кайтып кала. Нәтиҗәдә герой әнә шундый «тирәлек»нең корбаны булудан ерак китә алмый.

ләре исә — җәмгыятьнең асылы белән каршылыкта булган кимчелекләр һәм аварлыклар нәтиҗәсе. Мәсәлән, романның төп герое Мансур Габитовның эш сөючәнлеге, буровое өчен янып-көюе социалистик хезмәтнең кешене затландыручы асылыннан чыга. Әмма шул ук Габитов, алга узмыйча, урталар рәтендә яшәргә тырыша, кирәкле материалларны куплап һәм алдан алып, җиргә күмеп куя янсә хатынын эшкә кертмичә кухняга һәм бала бишеге янына бәйләп куярга тырыша. Героендагы бу сыйфатларның, шәхси кимчелек кенә булмыйча, объектив хәл нәтиҗәсе икәнлеген дә язучы сәнгать чаралары ярдәмендә күрсәтеп бирә алган. Ни өчен Габитов, мәсәлән, «запаслы мужик» булып киткән! Чөнки тәэминат бүлеге начар эшли. Ни өчен ул урталыкны сөя! Чөнки рекорд куючыларны, күргәзмә әсбабына әверелдереп, эштән аеру кебек зарарлы практика яши. Ни өчен хатынын эшләтмәскә тырыша! Чөнки нефтьчеләрнең конкуреш шартларын яхшыртуга игътибар җитми...

Буркontораның баш инженеры Алмаев образы да гаять гыйбрәтле. Язучы, Алмаевның үтә саклык күрсәтүче «вак эшләр рыцаре»нә әверелү процессын сәнгатьчә күрсәтеп биргән кебек, тәнкыйтьче исә бу образга яшеренгән тирән мәгънәне ачә алган.

Шул ук вакытта И. Газиның Мансур Габитовы һәм башка геройлары бер урында катып калган кешеләр түгел. Производствоның үзе белән берлектә үсәләр, үзгәрәләр. Карашлары киңәя, чатлы-ботлы яклары кими. Алар үзләренә тапшырылган участок интересын бөтен промысел, нефть промышленносте, ул гына да түгел, бөтен ил интересы белән бәйләп карый башлыйлар. Кыскасы, алар инде тирәлек продукты гына булып калмыйлар, әнә шул тирәлеккә йогынты ясый торган көчкә әвереләләр.

Кешеләрнең әнә шулай тураю, үсү, рухи баю процессында, партиянең җитәкчелек ролен күрсәтүгә дә язучы зур игътибар биргән. Әнә шул уңай белән парторг Камышев образы турында берничә сүз әйтәсе килә. Тәнкыйтьче фикеренчә, «Гади кешеләр» романында И. Гази партия җитәкчесе образын тасвирлауда алга адым ясаган, әмма бу кыен мәсьәләне ахырынача хәл итеп җиткерә алмаган. Әйе, роман дөньяга чыккан елларда тәнкыйть И. Газиның Камышевын хуплап каршы алган иде. Бүген исә, бу парторг белән кайтадан аралашкач, аның алдында без бик үк эреп китмибез. Ләкин гаделлек йөзеннән шуны да әйтик, И. Газидан соң да әдәбиятыбызда «менә инде бу партия эшчесе», «менә инде бу тере кеше!» дип әйтерлек образ тудырыла алганы юк. Хикмәт нәрсәдә! Ни өчен безнең әсәрләрдәге партия работниклары, бер калыптан сугылган төсле, бертөслеләр! Ни өчен барысы да сабыр холыклы, җитди кыяфәтле, барысы да бик акыллы (автор бирә алган дәрәҗәдә, билгеле), барысының да чигәсенә чал кергән, барысы да гел өйрәтә, гел мораль укый!. Күрәсең, И. Гази да әнә шул принциптан котылып җитә алмаган. Гади генә бер сорау туа: тормышның үзендә парторглар барысы да бер төслемени соң! Сабырлары янында кызулары, үтә сак кылanучылары янында тәвәккәлләре, акыллылары янында «чамалылары», намуслылары янында бармагы үзенә кәкреләре юкмыни!

Роман дөньяга чыккан вакытта ук күңелгә мондый сорау килгән иде: әгәр язучы характеры белән ярсу атны хәтерләткән Гыйлмановны (буркontора директоры) әсәргә парторг сыйфатында кертсә, ничек булыр иде! Әйе, кызулыгы аркасында ялгышлар җибәрер иде. Ләкин бит мич башында яткан кеше генә ялгышмый. Хәтта аның да егылып төшеп хаталануы мөмкин. Ичмаса, бер оригиналь җитәкче образы дөньяга килгән булыр иде...

Ниһаять, Ибраһим Газиның тәсбихындагы бисмилласына — аңа мактаулы исем китергән «Онытылмас еллар» әсәренә киләбез.

...Менә сигез яшьлек Хәлим, атасына тагылып, кәҗә бәтие кебек сикергәли-сикергәли, тау башындагы тегерменгә бара. Җәйге аяз көн. Тирә-якта тормыш кайный: күбәләкләр очынгалап йөри, чикерткәләр сикерә, тургай сайрый.

Тауга күтәрелгән саен офык киңәя бара. Әнә киң басулар, куксел урман, әнә еракта, бик еракта зәңгәр тасмадай сузылып киткән Идел... Хәлимнең дә күңелендә аяз. Шулай булмыйни, тирә-якта — киң дөнья, янында — барлык әтиләрдән дә яхшы әти. Җитмәсә, Галиулла улына баю турында, Хәлимнең дә, Малик бай малае кебек, аягына хром итек, башына хәтфә кәләпүш киеп, алма сатарга китәчәге турында бик ышанып сөйли. Ата-анасыз калып, күп михнәтләр чигәсе кечкенә Хәлимнең әле ике йоклап бер төшенә дә керми...

Алар Малик бай тегерменендә чакта, кинәт кара болыт пәйда була, җил күтәрелә, яшен яшьни, күк күкри һәм коеп яңгыр ява башлый. Ул да булмый, табигать тагын тынып кала, ялтырап кояш чыга, һава сафлана, юынып, чистарып өлгергән үләнчәчәкләр рәхәтләнеп тын алалар. Ә кичен, кояш баеп ай калыкканда, ата белән ул өй нигезендә бер-берсенә сыенышып утыралар. Шунда Хәлим сорап куя:

— Әти, без кайчан баербыз икән соң!

— Кызыл кар яугач, улым. Әйдә, кереп ятыйк.

Әсәр әнә шулай башланып китә. Шушы беренче эпизодларда ук инндидер символик мәгънә, киләчәккә ымлау бардыр төсле. Тауга күтәрелү, офыкларның киңәюе, җил-давыл, яшенле яңгыр, һаваның сафлануы, җирнең яшәреп китүе, кызыл кар...

Хәлимгә кагылышлы рәвештә С. Сафуанов мондый бер кызыклы фикер әйтә. «Гадәттә язучылар,— ди ул,— үз геройларын ике аспектта сурәтләүчән булалар. Бер төрле образлар үзләре вакыйгаларны әйдәп бәрып, тарихны хәрәкәткә китерүче

итеп биреләләр... Ә икенче төр персонажлар исә социаль вакыйгалар үсешенең аңа ничек йогынты ясавын ачу планында сурәтләнәләр». Беренчеләренә әсәрнең олы геройлары кертелсә, икенчеләренә мисал итеп Хәлим китерелә. Бу фикер тик кечкенә бер төзәтмә сорый. Социалистик реализм язучысының «олы геройлары» (сүз, билгеле, уңай дип йөртелә торган персонажлар турында бара), югарыда әйтелгәнчә, бер үк вакытта һәм «социаль вакыйгалар үсешенең» җимеше, һәм «вакыйгаларны әйдәп барып, тарихны хәрәкәткә китерүче» итеп тасвирланалар. Хәлимгә килгәндә исә, биредә «яки-яки»гә урын юк. Ул, әле бала гына булганга, нигездә икенче аспектта гына, социаль тәрбия объекты итеп кенә күрсәтелә ала. Әмма шунысы бар: социалистик реализм язучысы буларак, И. Гази үзенең кечкенә героен потенциаль актив герой итеп тасвирлый. Аңлаешлырак итеп әйтсәк, малайның «Канатланыр чак»тагы Хәлимгә,— авылларда уполномоченный сыйфатында ныклы һәм дөрес политика үткәрергә куәте һәм кыюлыгы җиткән Хәлимгә әвереләчәген күз уңында тотып эш итә. Моның өчен язучы иң элек авыл малайлары арасыннан тумыштан ук үткер, зиһенле, җитез, «ябыграк булса да, эре сөякле, нык тәнле, каты куллы» малайны сайлап ала. Шуның өстенә ул үзенең Хәлимен теләсә нинди вакыйгалар, ситуацияләр һәм иҗтимагый хәлләргә түгел, бәлки нәкъ менә булачак актив һәм идеяле көрәшче сыйфатлары тәрбияли торган хәлләргә куя, әнә шул вакыйгаларның, шул хәлләрнең малайны ничек итеп үзгәртүен, чыныктыруын күрсәтә.

Безнең Хәлимнең балачагы киеренке һәм давыллы елларга туры килә. Империалистик сугыш, февраль революциясе, Бөек Октябрь, гражданнар сугышы, аклар һәм кызыллар, ачлыкка каршы көрәш, халык хуҗалыгын торгызу.

Озакламый вакыйгалар Хәлимне иртә, бик иртә уен дөньясыннан тартып алалар да күз яше, кан, михнәт белән тулы чынбарлык эченә кертеп җибәрәләр. Баю турындагы нигезсез өметне тәмам чәлпәрәмә китереп, әтисе үлеп китә. Моннан соң, капчык тотып, соранып йөрү, тозга дип барып, үлем баржасына эләгү, аннан качкач, Т. пристанендә ач килеш каңгырап йөрү, Т. шәһәрен алган Шәрифҗан отрядына тап булып, кулга винтовка төшерү, пулемет җитәкләп бару һ. б.

Аннары — балалар йорты. Хәлим, әшәкелеккә өстерәүче атаман Тимер йодрыкны җиңеп, балалар арасында авторитет яулап ала, «кызыл» атаман сыйфатында Тимер йодрык шайкасына каршы көрәшә башлый. Тырышып уку, җәмәгать эшләре, комсомолга керү, беренче мәхәббәт...

Шулай итеп, күргәнебезчә, Хәлим гаҗәеп тере һәм үзенчәлекле характер булып күз алдына килеп баса. Басынкы да ул, тиктормас та, уенга да хирес, эшкә дә булдыклы. Шул ук вакытта Хәлим, үз тиңнәренә хас булган сыйфатларны җыеп алып, тип дәрәҗәсенә күтәрелгән. Ул инде адым саен очрый торган үсмер меңнәрдән бер малай гына түгел. Ул, зур вакыйгалар чорына туры килеп, шул вакыйгаларның эзенчән туган малай. Ул — давыллы еллар җимеше. Ул гына да түгел, Хәлим хәзер үк инде үз чиратында тирәлеккә зурмы-кечкенәме тәэсир ясый башлый, тирәлекнең тискәре күренешләренә карыша, уңай якларының җиңүе өчен азмы-күпме өлеш кертә. Кыскасы, бер тамчы суда кояш чагылгандай, гади авыл малае Хәлим образында шул заманның күп кенә характерлы яклары, революциянең кырыс гуманизмы сурәт һәм картина рәвешендә күз алдына килеп баса.

Әсәр турында фикер йөртүне Хәлимнән башлап җибәрүемнең һәм бу образга шактый зур урын бирүемнең ике сәбәбе бар. Берсе шул: «Онытылмас еллар» турында язган тәнкыйтьчеләр, малайсытыпмыйдыр, Хәлимгә игътибар итмичәрәк узалар, күбрәк олылар турында, олылар катнашкан вакыйгалар турында гына сөйлиләр. С. Сафуанов китабы бу яктан беркадәр аерылып торса да, биредә дә Хәлимгә урын аның яшенә карабрак бирелгән.

Икенче сәбәп исә трилогиянең композицион үзенчәлеген аңлау һәм жанрын билгеләү ихтыяҗы белән бәйле. Автор үзенең әсәрен повесть дип атаган һәм хәзергә кадәр аның повесть булуын дәгъва итә. Тәнкыйтьчеләрнең бер өлеше автор белән килешкән хәлдә, икенче өлеше әсәргә роман таныкнамәсе бирүне яклый. С. Сафуанов соңгы караштa тора һәм, фикерен раслау өчен, В. Г. Белинскийны һәм «Клим Самгин» авторы А. М. Горькийны шаһитлеккә чакыра. Әмма беренчесе бу очракта шаһитлеккә ярап бетмәс. Чөнки Белинский заманында повесть дип хикәяне атаганнар, һәм бөек тәнкыйтьченең повесть турындагы сүзләрен хикәя жанрына бирелгән билгеләмә итеп карарга кирәк. Ә инде «Клим Самгин»га бәйләнешле фараз чыннан да кызыклы. Горький үзенең дүрттомлык эпопеясен «повесть» дип атаган икән, С. Сафуановча, моны «тарихи хикәят (повествование) мәгънәсендә» аңларга кирәк.

Мин дә «Онытылмас еллар»ны роман төренә кертәм, һәм дәлилем мондый. Әгәр әсәр Хәлим турында гына булса, анда сүз Хәлим катнашкан вакыйгалар һәм Хәлим аралашкан кешеләр турында гына барса, ул, әлбәттә, повесть төренә керер иде. Бит Горькийның «Клим Самгин»ны повесть дип атавына нигез бар: әсәрнең башыннан ахырына кадәр үзәктә бер персонаж — Клим Самгин. 30—40 ел эчендә булып үткән хисапсыз күп вакыйгаларның берсе дә Самгин катнашыннан, Самгин күзәтүеннән читтә калмый. Ләкин моннан әле «Клим Самгин» чыннан да гадәти повесть икән, дигән нәрсә аңлашылмасын. Ул чынлыкта эпопея, һәм «повесть» термины тәнкыйтьче әйткән мәгънәдә кулланыла.

«Онытылмас еллар» әсәренә кайтсак, биредә Хәлимнең чагыштырмача кечкенә тормыш юлыннан тыш, Хәлимгә туп-туры кагылмый, янсә аз кагыла торган зур вакыйгалар һәм шул вакыйгаларны алга әй-

дәүче олы кешеләр бар. Малайның әсәрдән озак-озак югалып торуы, мәсәлән, очраклы хәл түгел. Әсәр, күп планлы ук булмаса да, берничә эздән бара торган сюжет тезмәсен берләштерә. Әнә шуңа күрә аны «повесть» кысасына гына сыйдыра алмыйсың.

Әсәрнең композициясенә килсәк, аның бер үзенчәлеге әйтелде бугай: күп кенә вакыйгалар Хәлимгә кагылмый, «олылар юлы» белән Хәлим сукмагы еш кына кушылмыйча бара. Моны мәгълүм дәрәҗәдә әсәрнең кимчелеге итеп карарга кирәк, әлбәттә. Сәбәбен күрсәтү исә кыен түгел. Язучы башта «ятим балалар тормышыннан зуррак бер хикәя» язу максаты белән эшкә керешкән. Тора-бара күрә: Хәлим тормышын зур социаль вакыйгалардан, олыларның иҗтимагый эшчәнлегеннән башка тасвирлап булмый. Әнә шулай әсәргә Хәлимгә катышы чамалы булган сюжет сызыклары килеп керә. И. Гази, әйтерсең лә, башта «сыярбыз әле» дип, кечерәк бер өй салып куйган да, соңыннан планның ялгыш булганлыгын абайлап, өен сүтеп мәшәкатьләнергә теләмичә, аңа ябыштырып салаcала, зур бина калкытып куйган. Язучы файдасына шуны әйтергә мөмкин: гади күзгә бу бинаның әлеге кимчелеге бик үк ташланып тормый. Ул башта ук бер аның планы белән салынган бина кебек тоела. Өстән караганда, чагыштырмача мөстәкыйль күренгән Хәлим сызыгы да чынлыкта алай ук түгел. Ул әсәрнең идея эчтәлеген баета, көрәш вакыйгаларын киләчәк белән бәйли. Бу турыда тәнкыйтьче болай ди: Хәлим һәм аның яшьтәшләрен автор «көрәш эстафетасын кулга алырга әзерләнүчеләр итеп күрсәтә», «тарихның өзлексезлеген, тормышның туктаусыз үсә баруын философик яктан раслый».

Инде килеп, әсәрне роман итә торган, ягъни билгеле бер төбәктә Совет власте урнаштыру һәм аны саклап калу өчен барган көрәш вакыйгаларына һәм шул вакыйгаларда катнашкан персонажларга, дөресрәге, И. Газиның шул образларны тудыру принципларына тукталып китик.

Бу уңай белән А. М. Горькийның югарыда китерелгән сүзләре яңадан искә төшә. Чөнки «сыйнфый сыйфат»ны «индивидуаль үзәк» белән кушу таләбе «Онытылмас еллар» трилогиясендә аеруча оста һәм тулы итеп тормышка ашырылган.

Әсәрдә катнашучы персонажлар, әлбәттә, иң элек теге яки бу социаль катлауның вәкилләре булып гәүдәләнәләр. Аларның психологиясе, үз-үзен тотышы, вакыйгаларда катнашу үзенчәлеге әлеге катлауның социаль хәле белән билгеләнә. Тәнкыйтьче мәсьәләнең бу ягын җентекләп һәм ышандырырлык итеп тикшергән. Менә, кешечә яшәргә омтылып, үзен-үзе белми эшләгән, аннары саулыгын бетереп, баю турында буш хыялларга бирелгән, һәм бәхеткә ирешә алмыйча, үлеп киткән ярлы крестьян Гапиулла. Менә икенче бер фәкыйрь крестьян — Бер ярым Миңнулла. Ул инде, Гапиулладан аермалы буларак, каһәрле тормышның корбаны гына булып калмый, акрынлап шул тормышны үзгәртү өчен көрәшүчеләрнең башлап йөрүчеләренә әверелә. Гафият исә — урта хәлле крестьян. В. И. Ленинның крестьян психологиясендәге икелеклелек турындагы мәгълүм сүзләре, Гафияткә карап әйтелгән кебек, тулысынча туры килеп тора.

Тәнкыйтьче әйтмешли, «шәһәргә китеп пролетар мохиткә эләгү, Столяров кебек аңлы большевикларның турыдан-туры йогынтысы астында эшләү» Якупны партия сафына китерә һәм өз күләмендә барган революцион көрәшнең җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрә. Армиядә булып кайту һәм Якуп йогынтысына эләгү ярлы крестьян баласы Шәрифҗанны революция солдаты итеп үстерә. Малик — Малик инде, кулак. Аның бөтен фигыле, эше, кыланышы кулакча.

Әйе, болар барысы да дөрес. Бу һәм моннан башка персонажларның әнә шул «сыйнфый сыйфатлары», социаль психологиянең гәүдәләнеше булулары әсәрне махсус тикшергәндә генә ачылып китә. Ә инде гади укучы күзе белән укыганда, алар, гүяки, тормышның үзеннән тотып алып, әсәргә кертеп җибәрелгән җанлы, конкрет, гап-гади кешеләр. Һәркайсының үз йөзе, үз кыланышы бар, һәркайсы кабатланмас характер. Биредә инде әлеге дә баягы «индивидуаль үзәк» дигән нәрсә калкып чыга.

Шул ук Миңнулланы алыйк. Тәнкыйтьче хаклы: әсәрдә иң җанлы, иң үзенчәлекле образ бу. Буйга артып китеп, аркылыга җитми калганга «Бер ярым» дигән кушамат алган бу крестьян ач карынга мәзәк сөйләп күңелен юатуы, җор теле, беркадәр дуамаллыгы белән аерылып тора. Революцион көрәш эченә ул үз сукмагыннан, үзенең мәзәк адым-хәрәкәтләре белән килеп керә. Язучының зур уңышы булган бер ярым Миңнулла образы турында С. Сафуанов китабында әйтелгәннәр белән тулысынча килешкән хәлдә, шул фикерләргә куәт йөзеннән ике эпизодка гына тукталып узыйм.

Шәһәрдән икмәк отряды килгәч, Миңнулла, җиң сызганып, отрядка булышып йөри, ахыр чиктә Маликның яшерен базын табып бирә. Шуннан чыккан икмәкнең бер өлеше, закон буенча, тапкан кешегә тия икән. Миңнулла абзагыз нишли! Тота да, Петербург эшчеләре ашасын дип, икмәктән баш тарта. Ә бит шул көнне Хупҗамал түти белән алар соңгы оннарын пешереп ашаганнар. Күренә ки, Миңнуллада хосуси милекчелек чире алай ук ташып тормый.

Шул ук Миңнулла, советның иң актив члены, ярлыларның «атаманы» булуына карамастан, алпавыт утарыннан алып кайткан өч атның икесен алырга теләүче көрәштәшләренә кендек тотып каршы тора. Хикмәт, күрәсең, хосуси милекчелектә генә түгел. Кәҗә бәтие чаклы аты белән бөтен авыл каршында адәм көлкесе булып йөри торган Миңнулла гомер буе яхшы атка тиенү хыялы белән яшәгән икән, аңардан ни көтәсең! Сөлек кебек өч ат киртәңә килеп кергәч, «сыйнфый сыйфат»ың да бер мәлгә чигенеп тора икән шул.

Янсә Гафиятне алыйк. Ул таза тормыш-

лы урта хәлле крестьян. Комсызның комсызы, саранның сараны. Үз шырпысын сызмас, үз тәмәкесен тартмас. Хатыны казанга чумар салганда да санап тора икән. Кыскасы, иртәгәге кулак бу. (Чынлап та, «Канатланыр чак» китабыннан күренгәнчә, нэп чорында, батрак тота башлап, ул кулакка әверелә язып кала.)

Әнә шул потенциаль кулак, эчке икеләнүләрдән азат булмаса да, трилогиянең баштагы ике кисәгендә Миңнуллалар арасында йөри, авыл Советы члены буларак, ярлыларга турылыклы кала. Шунысы кызык, хуҗалыгы ягыннан Гафияттән күп калыша торган Габсаттар ачлык елны Малик кулында коралга әйләнгәндә дә, Гафият Миңнуллалар белән араны өзми. Хикмәт урта хәлле крестьянның, алпавытлар кире кайтмагае дип, Советка сыенуында гына түгел, әлбәттә. Хикмәт, моннан тыш, Гафият белән Малик арасында күп еллардан бирле килә торган шәхси дошманлыкта. Күпмедер печән өчен башланып, бер тапкыр якалашуга китергән, соңрак исә кесә эчендә йодрык күрсәтүдән, күп дигәндә, Малик хуҗалыгына вак-төяк зыян китерүдән узмаган (көчле белән көрәшмә!) дошманлык була бу. Менә моны без әлеге «индивидуаль узак»ның характерлы мисалы итеп карыйбыз.

Бүтән персонажларга озаклап тукталырга хаҗәт юк. Аларның да һәркайсысы — берсендә калкурак, икенчесендә тоныграк булса да — индивидуаль характерга ия. Якуп беренче китапта образ буларак игътибарны бик үк җәлеп итми иде. Әмма икенче китапта баený, күркәмләнә бара. Дошман лагерендагы персонажлардан Малик кулак янсә Дәүләтьяров турында да берсе «кулак», икенчесе «милләтче» дигән язу ябыштырылган курчаклар дип әйтеп булмый. Икесе дә — җанлы кеше, икесе дә — индивидуаль һәм типик сыйфатларның уңышлы җыелмасы.

И. Газиның без тукталып киткән һәм биредә телгә алынмаган күп кенә персонажлары, күреп үткәнебезчә, реалистик принциптан чыгып иҗат ителгәннәр. Ләкин бу әле аларда сәнгатькә хас арттыру, калкытып кую, үткенәйтү, романтизмнан килә торган кайбер алымнарны куллану юк дигән сүз түгел. Әмма болар барысы да чама тойгысын югалтмыйча эшләнгән. Романтизм алымнары да реализм принципларында күзгә керел тормас дәрәҗәдә эрелгән.

Шул ук вакытта кеше образын романтик планда тасвирлау да И. Газига ят түгел. Моның бер чагылышын «Без әле очрашырбыз» повестенда күргән идек. «Онытылмас еллар» романында да язучы вакытвакыт әнә шул алымнарга мөрәҗәгать итә. Бу яктан, мәсәлән, Федюшкин, Шәрифҗан, Мәгъсүмә образлары һәм алар катнашкан вакыйгалар кызыклы. Федюшкин әсәргә күк күкрәтеп килеп керә, күк күкрәтеп яши, көрәшә, абына-сөртенә, чатлы-ботлы якларын күрсәтеп куя. Ахыр чиктә, укучының мәхәббәтен яулап алып, һәлак тә була. Башта бик артык күзгә ташланмаган Шәрифҗан тора-бара укучы күзендә үсә, зурая, маһабәт фигурага әверелә. Чека председателе дәрәҗәсенә ирешкән Шәрифҗан, билгеле, үзенең кызыл галифесы һәм күн курткасы белән генә түгел, бәлки революциягә чын күңелдән бирелгәнлеге, кызу канлы булуы һәм тәвәккәллеге белән аерылып тора. Укытучы кыз Мәгъсүмәгә булган кайнар һәм куәтле мәхәббәте аны тагын да яктыртыбрак җибәрә, образга салынган романтик буяуларны тагын да куерта төшә.

Мәгъсүмә турында исә тәнкыйтьче сүзләрен кабатлау белән чикләнү дә җитәр төсле. «Романтик югарылыкка күтәреп» сурәтләнгән бу кыз «бөтен романга лирик җылылык» биреп тора.

Романтизмнан килә торган әнә шул алымнар әсәрнең реализмы белән һич тә каршылыкка керми, киресенчә, аны эчтән яктырта, баета, калкыта төшә.

Тагын шуны әйтәсе килә: «Онытылмас еллар» романында, шул заманның нәкъ үзендәгечә, драматизм һәм комизм, күз яше һәм елмаю, кан һәм яшәү дәрте, үлем һәм тормыш бер-берсе белән аралашып килә, бер-берсен тутыра, тулыландыра.

Шулай итеп, безнең күз алдыннан дистәләгән җанлы геройлар, дистәләгән язмышлар уза. Һәм бу геройларны теге яки бу принципның кеше кыяфәтендәге гәүдәләнеше генә дип әйтә алмыйсың.

Шул ук вакытта һәр персонажның шәхси язмышы тегеләйме, болаймы революциягә килеп тоташа. Әнә шушы гаҗәеп тере геройлар, революциянең олы хакыйкатен гәүдәләндерү белән бергә, аның татар халкы тормышындагы үзенчәлекле бизәк һәм оттенокларын ачып бирәләр. Трилогия тарихка гади иллюстрация булудан, әлбәттә, бик ерак тора.

* * *

С. Сафуанов китабына тотына-тотына, без И. Газиның иҗаты буйлап атладык һәм «Онытылмас еллар» эченә килеп кердек, беркадәр гизгәч, юлыбызны төгәлләдек һәм күрдек: язучының иҗат гомере гаять кызыклы һәм гыйбрәтле икән. Аның бик күп әсәрләре, местәкыйль кыйммәткә ия булу белән бергә, иҗатында манара булып калкып тора торган романы дәрәҗәсенә күтәрелү өчен баскыч булып та хезмәт иткәннәр. Тагын Тукай күз алдына килә. Гүяки ул, чак кына елмаеп, болай ди: «Рәхмәт, туганнар, сүземне екмадыгыз. Әйберне таный беләсез икән».

**Рафаэль Мостафин**

# МУСА КӨРӘШТӘШЛӘРЕ

## Әхәт Аднашев

*Быелның 25 августында Плетцензее дигән фашист төрмәсендә Муса Җәлил һәм аның сугышчан уң көрәштәшенең батырларча үлеменә чирек гасыр тулды.*

*Безнең журнал битләрендә Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең ничек җәзалап үтерелүе турында немец язучысы Леон Небенцаль тапкан яңа документлар хакында әйтелгән иде инде («Казан утлары», 1968 ел, № 5).*

*Без түбәндә укучыларга язучы Р. Мостафинның герой-шагыйрьнең моңа кадәр билгеле булмаган көрәштәшләре турындагы язмаларын тәкъдим итәбез.*

Аны җәзалап үтерү турындагы карточкада белешмәләр бик аз: 1918 елның 12 декабрендә Петропавловск шәһәрендә туган. Сугышка кадәрниндидер Штецнайк дигән җирдә торган. Атасы Мәхмүт Аднашев белән анасы Өммикамал Аднашева да шунда яшәгәннәр. Һөнәре буенча пешекче (?) булган. Өйләнмәгән. 1944 елның 25 августында 12 сәгать 33 минутта үлгән. Үлемнең сәбәбе — башын кисү.

Шулай да бу белешмәләр эзләнүне башлап җибәрү өчен җитәрлек иде.

Яңа документлар табылу турында «Казан утлары» журналында материаллар басылып чыкканнан соң, укучылардан күп кенә хатлар килде. Хатларның берсендә Мәхмүт Аднашев белән Өммикамал Аднашеваларның (кыз чактагы фамилиясе Билалова) Мамадыш өязендә туып үсүләре һәм революциягә кадәр үк Петропавловск шәһәренә күчеп китүләре турында әйтелгән иде. Икенче бер укучы Петропавловск шәһәрендә 1918 елгы загс архивы документларын актарган, ләкин, барлык документлар да исән-сау саклануга карамастан, Аднашев турында бернинди дә белешмә таба алмаган. Кайбер укучылар үзләренең киңәшләрен яздылар. Мәсәлән, Түбән Кама шәһәреннән Мулюков безгә билгеле булмаган Штецнайкның, мөгаен, элеккеге алтын прискасы, хәзерге Төньяк Казагыстан өлкәсендәге Степняк шәһәре булырга тиешлеге турында әйтеп язды. Ә бу өлкәнең үзәге — Петропавловск шәһәре.

Мин Петропавловск шәһәрендә чыга торган «Ленинское знамя» газетасына мәкалә яздым. Анда Аднашев турында үземә билгеле булган белешмәләрне әйттем. Мәкалә газетада басылып чыгуның икенче көнендә үк редакциягә заводларның берсендә мастер булып эшләүче Наил Моратов килә. Ул Аднашевларны яхшы белүе, чыннан да аларның Степняк шәһәрендә яшәүләре турында сөйли. Пенсионер Бакиев та редакциягә бу турыда яза. Аларның әйтүе буенча, Әхәтнең әнисе инде вафат икән, ә әтисе 1958 елны пенсиягә чыккан.

«Ленинское знамя» хәбәрчесе В. Шестерников, болар турында белгәч, Степняк шәһәренә китә. Аднашевларны анда күпләр беләләр икән: беренче очраган кеше үк Шестерниковка аларның өен күрсәтә. Мәхмүт агай «Золотопродснаб»та туктаусыз егерме биш елдан артык кассир булып эшләгән карт коммунист, шәһәрнең хөрмәтле кешесе икән. Өйләре янында зур ботакларын киң җәеп үсеп утырган өрәңге агачын моннан утыз еллар элек, армиягә китәр алдыннан, Әхәт утырткан булган.

Шестерниковны, инде сиксән яшь булуына карамастан, әле аягында шактый нык басып йөрүче, чал чәчле карт каршы ала.

В. Шестерников, танышу белән үк, нинди максат белән килгәнен әйтә. Улының исемен ишеткәч тә Мәхмүт агай йөрәген тотып һушыннан яза...

Җәзалап үтерү турындагы белешмәләр дөрес булып чыга. Бары тик туган елын гына ялгыш язганнар. Әхәт 1918 елда түгел, 1917 елда туган икән. Петропавловск шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлаган. 1929 елда Аднашевлар гаиләсе Степняк шәһәренә күчә. Әхәт Щучинск уку-укыту комбинатында бухгалтерлар курсында укый. Ләкин аңа бухгалтер булып эшләргә туры килми, 1938 елны армиягә алына.

Көнбатыш Украинаны һәм Белоруссияне азат итүдә катнаша, аннары Львов шәһәрендә кавалерия частьларында хезмәт итә. Командование аны кече командирлар мәктәбенә укырга җибәрә. Мәктәпне отличнo билгеләренә генә тәмамлап, Әхәт пулемет расчеты командиры булып чыга. Фашистлар белән сугыш башлануның беренче көннән үк дошманга каршы көрәш сафына баса. Чигенү ачысын да татый. Ләкин аның фронттан язган хатлары җиңүгә тирән ышаныч белән сугарылган.

«Әни һәм әти, исәнмесез,— дип яза ул хатларының берсендә.— Сезгә кайнар фронт сәламе җибәрәм һәм тормышыгызда, эшегездә уңышлар теләп калам.

Гитлер бандаларын җимерүгә катнашуны бөек намус эшем дип саныйм. Без аларны кыйныйбыз һәм яңа көч белән кыйнарбыз. Фашист козгыннарының тырнаклары ычкынмаслык булып кысылып калуы хәзер һәркем өчен ачык... Алар безнең илебез киңлекләрендә һәлак булып калачаклар.

**Хәрәкәттәге Кызыл Армия, хәрби почта станциясе**
**№264, 12 сентябрь, 1941 ел».**

1942 елның 8 февралендә язган хатында ул болай ди:

«Полк комсомол бюросының җаваплы секретаре булып эшлим. Шунда сүземне бетерәм — вакыт юк. Гел алга һәм алга барабыз.

**Өченче гвардия кавалерия полкы».**

Кадровый хәрби кеше, политрук, полк кадәр полкның комсомол җитәкчесе, чын коммунист-ленинчы Әхәт Аднашевның фашист әсирлегендә яшерен оешма җитәкчеләреннән берсе булуы әлбәттә очраклы хәл түгел.

Әхәт фронттан соңгы хатын 1942 елның 27 маенда җибәрә. Берничә ай хат килмәгәч, атасы-анасы, борчылып, ул хезмәт иткән частька хат язалар.

Мәхмүт ага белән Өммикамал апа өчен, туганнары өчен бик зур кайгы алып килә җавап хаты.

«Исәнмесез, минем дустым Әхәт Мәхмүтовичның гаиләсе! — дип яза Әхәтнең фронтташ иптәше.— Сез Әхәтнең язмышы белән кызыксынасыз. Ул Смоленскида регуляр гаскәрләр белән кушылу өчен барган сугышларда 1942 елның июлендә үлде. Бу турыда безнең полкның политругы да әйтте. Ул аны күргән. Шулай итеп Сезнең улыгыз инде исән түгел. Ул батырларча һәлак булды, соңгы сулышына кадәр хәшәрәтләрне кырды. Без, аның яктәшләре, исән-саулар, һаман бер үк полкта хезмәт итәбез. Улыгызның үчен алырбыз».

Бер ай чамасы вакыт үткәч, фронттан тагы бер хәбәр килеп төшә.

«Шуны хәбәр итәм,— дип яза подполковник Горбачев.— Көнбатыш фронты буенча 1942 елның 11 августында чыгарылган 0888 номерлы приказ нигезендә Әхәт Мәхмүт улы Аднашев немец илбасарларына каршы көрәш фронтында командование заданиеләрен үрнәк төстә башкарганы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләндә».

Аднашевлар күңелендә өмет уяна: бәлки исәндер. Тагын частька ачыклап хәбәр итүләрен сорап хат язалар. Бу юлы килгән җавап ул кадәр катгый булмый инде:

«Сезнең улыгыз, Аднашев Әхәт Мәхмүт улы, Совет Ватаны өчен барган сугышларда хәрби антына тап төшермәде, фронтта кыюлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәтте, 1942 елның августында хәбәрсез югалды».

Ә Оборона министрлыгыннан аларга: «Үлгәннәр исемлегендә дә, ярадан үлгәннәр исемлегендә дә, хәбәрсез югалганнар исемлегендә дә юк»,— дип җавап бирәләр...

Мәхмүт ага Аднашев 25 ел буена шулай итеп улы турында берни дә белмәгән.

Кызганычка каршы, безгә әле Әхәтнең яшерен оешмадагы эшчәнлеге билгеле түгел. Без аның, беркайчан аш-су белән шөгыльләнмәвенә карамастан, үзен пешекче дип яздыруын гына беләбез. Димәк, конспирация шуны таләп иткән. Едлин группасының исән калган членнары да, Берлин оешмасына катнашучылар да аның турында белмиләр. Мөгаен, Әхәт Аднашев, нык әзерлекле егет буларак, яшерен оешмада махсус үзбаш эш башкаргандыр.

## Сәлим Бохаров

Аның исеме дә Леон Небенцаль архивлардан Шарлоттенбург загсы документларын тапкач билгеле булды. Муса Җәлил көрәштәшләре турындагы унбер карточканың берсе Башкортстан егете, моңа кадәр исеме билгеле булмаган Сәлим Бохаров турында иде.

Бу документның сүзгә сүз тәрҗемәсе болай:

**«Берлин, Шарлоттенбург, 26 август, 1944 ел. Кара эшче Сәлим Бохаров, мөселман, Уфадан, Дортсагайда [!] яшәгән, 1944 елның 25 августында, 12 сәгать 36 минутта Берлинда, Шарлоттенбургта, Кенигсдам, 7 дә үлде.**

**1915 елның 15 июнендә Заргайда [!] — Уфада [Россия] туган.**

**Атасы — Гиматов-Бохаров.**

**Анасы — Сабира Бохарова, кыз чагында — Фариза [!]**

**Ул [Сәлим Бохаров, ред.] Мария Бохаровага — кыз чактагы фамилиясе Көчу — өйләнгән булган.**

**Берлинда, Мантейфельштрассе, 10 да торучы надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэрның телдән күрсәтүе буенча язып алынды. Аңа бу белешмәләр билгеле һәм ул үлемнең шаһиты булуы турында әйтте.**

**Укылды, расланды һәм кул куелды — Пауль Дюррхауэр.**

**Төп нөсхә белән тәңгәл килүе раслана.**

**Берлин, Шарлоттенбург, 26 август, 1944 ел.**

**Загс хезмәткәре: Глюк кушуы буенча.**

**Үлемнең сәбәбе — башын кисү».**

Документтан күренгәнчә, Бохаровны иң соңыннан җәзалыйлар. Аның күз алдында фашистлар өч минут саен ун иптәшен эшафотка менгерәләр һәм җәзалап үтерәләр.

Регистрация номерыннан күренгәнчә, Сәлим Бохаровны җәзалау турында карточка да иң соңыннан тутырыла. Глюк ашыккан: алдагы төндә бомбага тотудан үлгән кешеләрне дә исәпкә алырга кирәк булган. Баштарак «җәзалап үтерүнең шаһиты» Пауль Дюррхауэр аңа немец колагына бик үк ятышлы булмаган татар исемнәрен хәрефләп әйтеп торган булса, соңгарак, ахры, Глюк ничек аңласа шулай теркәп куйгандыр. Болай да инде ул җәзалап үтерүгә киткән вакыттан да озаграк язып маташкан.

Менә шуңа күрә дә карточкада төгәлсезлекләр күп.

— Кем булган соң ул Бохаров?

Бу сорауны мин исән калган җәлилчеләрнең барысына да диярлек бирдем. Җаваплар канәгатьләнерлек булмады: берсе дә Сәлим Бохаровны белмәделәр, аның турында ишеткәннәре дә юк. Рушат Хисаметдиновча, Сәлим Бохаров, Әхәт Аднашев кебек үк, Крушинодагы яшерен оешма члены булырга тиеш. Ә бу оешманың эшчәнлеге турында, кызганычка каршы, без әле бик аз беләбез...

Бердәнбер һәм бик күп мәртәбәләр сыналган ысул калды: матбугат аша мөрәҗәгать итү. Ләкин бу юлы минем мәкаләгә карата бик озак хатлар килми торды. Ниһаять, 1968 елның ахырында Башкортстанның Миякә районыннан Бохараевлардан

хат алдым. Алар кулына «Казан утлары» журналы очраклы гына килеп кергән һәм алар, минем мәкаләмне укыгач, Сәлим Бохаров безнең туган кеше түгелме икән, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Үзара хат язышa башладык. Шул хатлар буенча түбәндәгеләр билгеле булды:

Галләнур Мостафа улы Бохараев 1916 еллар тирәсендә Кыргы-Миякә авылында туган. Сугышка кадәр Миякә дәүләт банкысында бухгалтер булып эшләгән. Аңа кадәр Казанда бухгалтерлар курсында укыган. 1940 елны армиягә алынган. Башта Алкино станциясендә хезмәт иткән, аннары Троицк шәһәрендә полковая школаны бетергән һәм Латвия ССРның Двинск шәһәренә күчерелгән. Соңгы хаты 1941 елның 17 июнендә язылган. Шуннан соң — менә инде тиздән утыз ел тула — аның язмышы турында бернинди хәбәр юк. Дөрес, Бохараевлар үзләре дә эзләтү чарасын күргәннәр — аларга әйткәннәр: мондый зур сугышта хәбәрсез югалганнарны эзләп табу мөмкин түгел, дигәннәр.

Бер нәрсәне искә төшерик: 1942 елның җәендә Двинск янындагы лагерьда хәрби әсир Гумеров (Җәлил) булган. Ләкин... Нәтиҗә чыгарырга ашыкмыйк.

Шулай итеп, фамилияләр шактый якын, ләкин исемнәр туры килми. Атасының исеме документта, кызганычка каршы, күрсәтелмәгән. Гиматов-Бохаров дигән ике фамилия каян килгән? Бу турыда Бохараев туганнары берни дә әйтә алмадылар. Әсирлектә совет кешеләренең бүтән фамилияләр һәм исемнәр белән йөрүләре безгә мәгълүм Җәлил — Гумеров, Гарәф, Фәхретдинов — Дим Алишев, Гайнан Курмаш — Григорий Курмаш исемнәре белән йөргән. Кайбер аерымлыкларның булуы табигый. Әмма туган җире, соңгы эшләгән урыны (алары буталырга да мөмкин) һәм әнисенең исеме туры килми. Галләнурның әнисе Гөлҗамал исемле, Сабирага да, Фәризә яки Фәридәгә дә туры килми. Шулай ук Галләнурның туган елын да табып булмады. Таныклык язуы сакланмаган, хәтта әнисе дә туган аен һәм көен хәтерләми.

Күренгәнчә, охшаш булмаган моментлар охшашларына караганда күбрәк та. Ләкин бу версияне яклый торган бер деталь бар: Галләнурның хатыны Мария Куч исемле рус кызы. Мондый сирәк очрый торган фамилиянең туры килүе очраклы гына булырга мөмкин түгел... Кызганычка каршы, хәзергә әле Мария Кучның табылганы юк. Ул Миякә районыннан күптән инде киткән һәм Бохараевлар белән бәйләнеш тотмый. Ә балалары булмаган. Мөгаен, ул хәзер бүтән фамилия белән йөри торгандыр.

Эзләнүләрнең әле хәзергә нәтиҗә биргәне юк.

Әминә Җәлилова

# КОЯШ ЧЫККАН АЛМАН ҖИРЕНДӘ

Германия-СССР дуслыгы җәмгыяте мине быел Германия Демократик Республикасына чакырып алды. Мин анда май аеның дүртеннән егермесенә чаклы булдым.

Ул илгә мин катлаулы кичерешләр һәм уйлар белән бардым. Берлинга якынлашкан саен күңелем үзе ашкынды, үзе, авыр хатирәгә бирелеп, тәшвишләнеп, борчылып килүендә иде. Шушында бит, кайнар каннар белән сугарылган Германия җирендә, Берлинда, минем ирем, татар совет шагыйре Муса Җәлил үзенең яшь гомерен фида иткән. Ул — җир йөзендә яшәүче халыклар бәхете һәм аларның иреклә тормышы өчен корбан киткән миллионнарча батырлар сафының алдынгысы булган.

Кеше ышанмаслык авыр шартларда асралуына — Берлин төрмәсе Моабит тоткыны булуына да карамастан, ул немец халкының киләчәге хакында уйланган. Германияне, атаклы Маркс, Энгельс, Гете һәм Бетховеннар ватанын ирекле, көшелекле, чәчәк атучы ил итеп күрәсе килгән Җәлилнең. Үзенең «Алман илендә» дигән мәгълүм шигырендә ул, үз дуслары, үз фикердәшләренә мөрәҗәгать итеп:

> **Борыгыз муенын комсыз карчыганың,**
> **Кояш чыксын Алман җиренә,—**

дигән иде.

Немец халкына Маркс, Энгельс, Гете, Бетховеннарны кабат кайтару көннәрен Җәлил күрә алмады.

Шушы елның 7 нче октябрендә Германия Демократик Республикасы төзелүгә 20 ел тула. Мин анда бик шатлыклы көннәрдә — Германиянең фашизм кулыннан котылуына 24 ел тулу көнен тантана иткән чакта булдым. Немец дусларыбызның олылары да һәм кечеләре дә бу көнне шатланып бәйрәм итүләрен күрдем. Советлар Союзыннан килгән кунак сыйфатында ул тантанада катнаша алуыма мин бик бәхетлемен.

Фашизмнан азат ителү көннәреннән соң узган 24 ел — олы тарих өчен әллә ни зур гомер түгел. Бүгенге чор кешеләре өчен ул инде — үткән бер көн, яшьләр өчен — тарих кына. Әмма аерым бер илнең язмышында ул бик зур урын били.

Бу хакта Германия — СССР дуслыгы җәмгыяте җитәкчесе Лютер Больц докладында бик дәлилле сөйләнде. Немец халкының шушы 24 ел дәверендә ирешкәннәре, уңышлары, андагы үзгәрешләр ышандырырлык иде. Тантаналы җыелыштан соң безнең ил кинорежиссеры Роман Карменның немец дуслар ярдәмендә төшерелгән «Берлин илтәше» кинофильмы күрсәтелде. Ул фильм ике ил арасындагы дуслыкның гыйбрәтле бер күренеше булды. Фильм бик күп нәрсәләр хакында сөйли.

Берлинда Совет сугышчылары күмелгән һәйкәл-бакчага зиярат кыла алуымны мин аеруча бер канәгатьләнү белән әйтеп үтәр идем. Трептов-паркка мин чәчәкләр бәйләме илттем һәм фашизмга каршы көрәштә үз гомерләрен корбан иткән батыр сугышчыларыбызга илебез сәламен ирештердем. Чирек гасыр узган. Трептов-парк каберлекләрендәге чәчәкләрнең әле бер дә шиңгән чагы булмады, дип әйтәләр! Халыкның җылы хисе шиңми. Трептов-парктан узганда һәр даим син: «Сак бул! Бүгенге өчен нинди хак түләнгәнен онытма!» — дигәннәрне ишеткәндәй буласың. Моңа җавап итеп һәйкәл-паркта булучы миллионнарның йөрәге: «Бары да истә, бары да йөрәктә»,— дип тибәдер шикелле.



**Берлиндагы тормозлар заводы директоры, шундагы Муса Җәлил исемендәге бригада башлыгы һәм Леон Небенцаль, (сулдан икенче) Әминә Җәлиловага бригаданың эш күрсәткечләре турында грамота тапшыралар.**



Бүген монда, Берлин үзәгендә, фашизм корбаннары каберлеге алдында тынычлыкны саклап яңа Германия Милли Халык Армиясенең яшь солдатлары сакта тора. Кара гранит ташлар өстендә яз, яшәрү билгесе — сулмас чәчәкләр бәйләме.

Берлинда миңа шулай ук Совет Армиясе сугышчылары белән дә очрашырга туры килде. Халыклар бәхете, дөнья тынычлыгы өчен изге сакта алар да, коралдаш дуслары, немец солдатлары белән кулга-кул тотышып бер сафта торалар. Германия Демократик Республикасы халкының тыныч хезмәте уяу саклана.

Германиядә мин берничә шәһәрдә булдым. Аларның һәрберсендә әле үткән сугыш яралары беленеп, төелып тора. Дөрес, сугыш җәрәхәтләрен төзәйтү юлында монда күп эшләр эшләнә. Шәһәр кварталлары яңабаштан төзеләләр. Берлин өстендә төзелеш краннары күпләп күтәрелгәннәр — илдә зур ярыш бара: ил үзенең бәйсезлек бәйрәме — Октябрь көннәрен бәхетле каршылаячак.

Дрезден каласына мин бик дулкынланып юл алдым. Бу шәһәрнең Мюнхен мәйданындагы суд залында Муса Җәлил һәм аның көрәштәш дуслары хөкем алдына басалар. Хәрби суд аларга үлем җәзасы чыгара. Бинаның ишек алдында аларга һәйкәл куелган. Бу корылма синең күңелдә олы сагыш һәм үтерүчеләргә карата нәфрәт хисләрен генә уятып калмый, монда син көшенең какшамас көчкә һәм ихтыярга ия булуына инанасың.

Үлемгә хөкем ителүчеләрнең бүлем-камералары юеш һәм салкыннар. Кечкенә тәрәзәләрдә тимер челтәр. Тоткыннарның аяусыз хәле күз алдына килә. Хәзер бу бинада югары уку йорты. Монда яңа чор кешеләре — белемгә омтылучан, яңача карашлы, фашизмны дошман санаган яшь буын тәрбияләнә. 24 ел элек бу бинада шундый ук яшьләр, антифашистлар, үлем көтеп ятканнар.

Әгәр бу Бухенвальд турында да бераз сөйләп үтмәсәм, минем истәлекләрем тулы булмас иде шикелле. Мин ул җан тетрәткеч үлем лагере хакында байтакны укып һәм ишетеп белә идем. Әмма ул урынны үз күзләрең белән күрү — әйтеп бирә алмаслык газаплы кичереш. Ирексездән күз яшьләре түгелә.

Кешелек дөньясыннан көлеп, гитлерчылар Бухенвальд баракларын Гете, Шиллер, Бах кебек мәгълүм гуманистлар яшәп, кешелеккә дан җырлаган Веймар шәһәре каршына, Эттерсберг тавы итәгенә урнаштырган булганнар. Капканың корыч рәшәт-

кәләренә «Һәркемгә — үз теләгәне» дигән мыскыллаулы сүзләр язылган. Төрле мыскыллау, мәсхәрәләү юллары белән эсэсовчылар тоткыннарның рухын төшермәкче, тез идермәкче булганнар. Бу лагерьда аларның явызлык кылуларының чиге юк. Боларны күргән бер кеше дә битараф булып кала алмас, шул кадәр кан коеп яуланган тынычлыкны саклау өчен бар көчен куяр, дип уйлыйсың.

ГДРга барыр алдыннан миңа анда бик авыр, күңелсез минутлар кичерергә туры килер дип кайгырган идем. Ул җирләрдә бит минем якын кешем — ирем үзенең үтә газаплы көннәрен уздырган. Һәм ул туган иленнән, якты дөньядан мәңгегә-мәңгегә аерылган җирләр алар...

Әмма шул ук вакытта, мин анда ялгыз булмаячагымны, якында чын дусларның булырын да онытмадым. Арада иң якыны, немец антифашисты, журналист Леон Небенцаль һәм аның тормыш иптәше Ильза. Муса Җәлил шигырьләрен укып белүче һәр немецка һәм шулай ук һәр совет кешесенә Леон Небенцаль исеме яхшы таныш. Леон Небенцаль Җәлил тормышының соңгы айларын ачыклауга күп көч куйган, күп еллар эзләнгән кеше. Җәлил һәм җәлилчеләрнең соңгы көн трагедиясен дә аның аша беләбез. Болар һич онытылмаслык.

Леон белән Ильза ГДР шәһәрләренә сәяхәт вакытында да минем янда булдылар. Минем өчен кадерле урыннарны күрсәттеләр, ил тормышы белән, немец халкы белән таныштырдылар. Миңа булган ихтирам-хөрмәтләре, олылап каршы алулары, авыр минутларда җылы сүз таба алганнары өчен минем аларга зур рәхмәтләр ирештерәсем килә.

Берничә ел элек, Мәскәүдә мин Муса Җәлилнең шигырьләрен немецчага тәрҗемә иткән һәм «Кызыл ромашка» исемле фильмга киносценарий язган Эрих Миллер (Мильштат) белән дә танышкан идем. Шул чакта без аның белән якыннан дуслаштык. Миллерның авыру булуына да карамастан, Берлинда без кабат очраштык. Немец халкына Муса Җәлил сүзләрен ирештергән кешегә минем рәхмәтем чиксез зур булды һәм булыр.

Тагын бер танышлык хакында җентекләбрәк сөйлисем килә. Танышу хат аша булды. Берлин шәһәрендәге тормоз заводы коллективыннан бер бригада үзләренә Муса Җәлил исеме бирелүен, шагыйрьне бик ихтирам итүләрен язган иделәр. Шунда баргач, минем бу кешеләр белән якыннан танышасым килде. Сменадан соң, заводның бер бүлмәсендә очраштык. Очрашуда Небенцальлар да катнашты. Бригада завод инженерларын һәм экономистларын берләштерә икән. Яхшы эшләре өчен аларга Социалистик хезмәт бригадасы исеме дә бирелгән. Шул бригаданың фашизмга каршы көрәшүчеләрдән берәүнең батыр исемен йөртүе — Совет халкына, Җәлил һәм җәлилче батырларга немец хезмәткәрләренең олы ихтирамы билгесе, әлбәттә.

Муса Җәлил исемен йөртүче бригада эшләгән завод коллективы традицияләргә дә бай икән. Беренче эшчеләр Советы да 1918 елда шушы заводта оештырылган.

Без озак сөйләшеп утырдык. Муса хакында аларның күбрәк беләселәре килде. Соңыннан немец иптәшләр үз телләрендә Мусаның күп кенә шигырьләрен укыдылар.

Муса исемен йөртүче бригада Германия — СССР дуслыгы җәмгыятенә керә. Үзенең тырыш хезмәте белән ике ил арасындагы дуслыкны ныгытуга, немец халкы яшәгән илдә кабат фашизм сөремен булдырмауга күп көч куя. Германия — СССР дуслыгы җәмгыятендә андыйлар — меңнәр.

ГДРда булганда миңа бу оешманың җитәкчеләре белән дә, гади кешеләре белән дә күп очрашырга туры килде. Ул очрашулар минем күңелдә җылы хис калдырдылар. Бик күп яхшы кешеләр белән танышу бәхетен татыдым, немец дусларыбызның эше һәм тормышы хакында белүем бермә-бер артты. Бу сәяхәт минем бик күп хатирәләремне яңартты, күңелгә күп нәрсә бирде.

Мусаның Германия турындагы матур хыялы Германия Демократик Республикасында тормышка ашырылуы чиксез куандырды.

Мин Социализм кояшы нурларыннан яктырган, яңабаштан үзгәреп, үсеп килүче иркле илне күрдем. Ул илдә яңадан-яңа, эчкерсез һәм чын дуслар таптым.

Күңелләрне берләштерүче шушы дуслыктан да олырак хәзинәнең җирдә булуы мөмкин дә түгелдер! дип уйландым мин, ул ил белән хушлашкан чагымда.

Йосыф Гәрәй

# СҮЗ ҖЫЯРГА КИЛЕГЕЗ!

Татар тел гыйлеме тиздән бер юбилей үткәрәчәк. 1775 елда Казанда иң тәүге сүзлек төзелгән. Аның авторы гимназия укытучысы Сәгыйт Хәлфин булган [1]. Икенче булып, 1804 елда И. Гиганов сүзлеге чыга. 1833—35 елларда инде Троянскийның ике томлык татарча-русча сүзлеге басыла. Бөтен сүзлекләрне җыйганда, бу көнгәчә берничә дистә сүзлек чыккан. Шуларның иң соңгысы — «Татарча-русча сүзлек» (Мәскәү. 1966 ел).

Монда 38 мең чамасы сүз тупланган. Алар арасында яңа сүзләр дә бар. Телдән төшмәсә дә, сүзлекләрдән төшкән сүзләр дә кире кайткан.

1955—59 елларда чыккан 4 томлык русча-татарча сүзлек таррак иде. Әллә нигә, әллә бик җәелеп китмәс өчен, анда күп сүз бөтенләй кулланылмаган. Мәсәлән, «жирный» сүзен тәрҗемә иткәндә «түлле» (түл җыйный), «көр» (мал) сүзләре алынмаган. «Желание»не хәтта «арзу» дип әйтергә дә кирәк иде: бу сүзне бөтен классиклар кулланган бит. «Житейский» сүзен ник «гадәти» дип тә әйтмәскә? «Здоровье» — саулык, сәламәтлек, тазалык кынамы? «Сихәтлек» сүзе нигә юк? Зилзилә (землетрясение), золым (зло), мәшһүр (знаменитый), әләм, ту (флаг, знамя), хәят (жизнь) сүзләре дә никтер төшеп калган. Күп булмаса да, сүзлектә русча сүзне хата аңлату күренешләре дә очраштыргалый. Мәсәлән, золотоносная жила — «алтынлы катлам» дип бирелгән.

Ун ел да үтмәде, менә бу «Татарча-русча» сүзлек чыкты. Алда әйткән **сихәтлек, зилзилә, мәшһүр, хәят, золым, көр** (симез мәгънәсендә) кебек сүзләр монда тулы хокук алганнар. Дөрес, монда да **түл** сүзенең бер мәгънәсе генә ачылган.

Игътибар белән актарсаң, байлык күп табыла бу китапта. **Арча** сүзен «ар» (удмурт) сүзеннән килә, дип аңлатучы «галимнәр» дә бар иде. Сүзлек «**арча**»ның агач исеме булуын төшендерә. Ул гынамы? **Ясень** татарча «корычагач» икән, **проказаны** «махау», **трахоманы** «кырма», диләр, күрәсең. Урманда «купшы чыпчык» (щегол), тугайда «кыргавыл» (фазан), суда «чөгә» (безнең якларда: чөкә, чока — стерлядь) яши, яланда «кырлач», «кындырак» үләннәре үсә, ди яңа сүзлек.

Бүрек элек кырпулы булган. Кырпуы бара-бара «көгән» хәлгә килгән. Җил «кырачъ», чырай «төмсә» булырга мөмкин икән. «Наурүз» (примула), «энҗе гөле» (гортензия), «миләүшә» (фиалка), «зәгъфран» (шафран) гөлләренең исеме, җисеменә муафыйк дигәндәй, нинди сылу! Елганың шап ага торган урынын «ургыл», тирән урынын «чоңгыл», диләр. Курдегезме, бу сүзлектә асыл сүзләр никадәр күп.

Монда бер «баш» сүзенең генә кырыкка якын мәгънәсе бирелә. «Кара»ның да мәгънәсе егермегә якын бугай (гәрчә бөтен мәгънә төсмерләре ачылып бетмәсә дә). Борынгы төрки сүзләр дә ишле күренә. (Мәсәлән, «ям чабу», «төмән» (ун мең), «чәчән» (импровизатор), «япан» (дала), «иннек», «сөрмә», «кына», «кершән», «сандал» һ. б.). Аерым сөйләшләргә хас сүз-кәлимәләр дә күренгәли («урамал», «алчак» (йөз), «тәүгә», «тәңгәл», «иләмән», «каңгыру», «кома-

---

[1] Дөрес, Хәлфингә чаклы да сүзлекләр төзелгән. Мәсәлән, Петр I нче вакытында, 1740 елда һәм соңрак та, Екатерина II нче заманында да, мондый эш башкарылган. Ләкин бу эш мәгърифәт максатында эшләнмәгән. Бу сүзлекләр тууга патша хөкүмәтенең миссионерлык политикасы, татарларны чукындыру теләге сәбәп булган.

лак», «ырыс», «комкалак» h. б.). «Шәрык», «шәраб», «шәрех», «тәфсил» ише гарәп, фарсы сүзләре дә калмаган, чөнки алар да бик кирәк.

Бер сүзне дә кирәкми дип әйтеп булмый. Сүз — ул халыкның гасырларча килгән тоемы, беләме, уңышы, тәҗрибәсе, хатасы (мәсәлән, «күк капусы», «фал ачу» сүзләре)... Кыскасы, сүз — тормыш җимеше. Сүз — этнография, тарих, идеология, хыял, өмет, теләк, сагыш, корал... Шуңа күрә, бу китапта кулланудан төшкән, искергән сүзләр күренгәләсә дә (мәсәлән, «камус» — сүзлек, «һәҗү» — сатира, «һәндәсә» — геометрия h. б.), без моңа һич каршы түгел. Сүз, халык әйтмешли, ашарга сорамый. Язылсын, саклансын. Киләчәк буын галимнәргә рәхмәт әйтер.

Аннан, сүз үлә, дигәч тә, бөтенләй үлми ул. Документ, иске китаплар h. б. саклана. Димәк, иске сүзләр сүзлекләрдә урын алырга тиеш.

Авторларга бер нәрсә өчен генә — ник сүзләрне аз алдыгыз, дип кенә тел тидереп була.

Ник сүзлектә сүз аз? Урманда агач, суда балык, сүзлектә сүз аз булса, ямансу да, хәвеф тә. Бик күп кирәкле сүзләр кермәгән шул. Әйтик, Г. Ибраһимовның «Табигать балалары»ндагы байтак сүз төшеп калган: көнитеш, эшәнчек, аңар (ә «шуңар» бар), чыпак (чапак тел), алын (кишәрлек), чынаяк-саба, балкылдау. Бәлки, берәү: «Ул искерәк әсәр бит», дияр. Яңаны алабыз. Шигъри телле Ф. Хөснинең «Кайсысына өйләнимі?» исемле кечкенә генә хикәясендә күренгән шундый берәгәйле сүзләргә дикъкать юк: «...язып бетермәле түгел», «ачуым килмәгәе», «кызый», «җан-кисәге», «каш-күз», «тыз-тыз», «гыйшык-мыйшык»... «Сабантуй» хикәясен алсак, анда «риясызлык», «түгел-түгелен», «шәлъяулык» h. б. табыла. Бу сүзләр кирәкми дип кем әйтер икән? Һәр хикәядә «югалган» сүз табылгач, сүз җыюда пөхтәлек сизелә дип була микән соң? Телгә ифрат бай икенче язучы Ә. Еникидә дә галимнәр күзенә чалынмаган сүзләр күп кенә. Мәсәлән, «Яшь ленинчы» газетасында басылган «Җиз кыңгырау» дигән хикәядә генә 8 сүз табыла: «җиңгәчәй», «кыркуы», «һии» (ымлык), «аңардан», «яткырмакчы», «чәпелдәтү», «үтерердәй», «хода белсен». Шул газетада (1968 ел. 37 сан) моннан башка да берничә сүз табыла: «дикъкать», «барылу» (фикергә), «киләнде» h. б. Бу бит балалар газетасында! Ә башка матбугатта ниләр юктыр!

Сүзлекне актарып утырганда гына да күпме сүз хәтергә килә. «Аркан», «йөзтүбән», «чалкан» кебек сүзләрне алгач, «кабырган», «баштүбән» ник юк? «Эшчән», «җырчан», «сөйләүчән»... сүзе бар. «Әрләшчән», «биючән», «тик ятучан» кая? «Киленле» булгач, «кызлы» да кирәк (кызлы җиргә кода килер). «Бабакай», «кызкай», «егеткәй», «балакай» кергән. Иркәй», «хатынкай» калган. «Карачы» күренә, «килчә», «күрчә» юк. «Яугалау», «ургалау», «үткәләү», «баргалау» кирәк икән, «төшкәләү», «күтәргәләү» кирәк түгелмени? «Ям» (почтовая станция) алынгач, ник «даруга» (борынгы административ-территориаль бүленеш), «ык» (елга, су), «чура» (кол, сакчы, иптәш), «талай» («Акмулла хурлык күпде талай-талай») кебек сүзләрне дә алу кирәк. Сүзлектә «нәрсә» сүзе күренә. Ә «нәстә», «нәстәкәй», «нәмәрсәкәй» сүзләре ник алынмаган икән?

Борыннан килгән төрки сүзләрне башка телдәгечә язу белән дә килешеп булмый. «Курган», «барыйш», «казначей» дип түгел, «корган», «барыш», «казанчы», ягъни «хәзиначе» рәвешендә язу кирәк иде.

Урыны килгәч, моны да әйтик инде, **азамат** «слуга народа» түгел. Ник «Башкортча-русча сүзлек» хатасын кабатларга? Азамат — ул мәшһүр, дәрәҗәле һәм хәтта олпат шәхес. «Байтирәк» тал түгел, җылы яктагы пирамидаль тополь һәм тарихи төрки ыру. «Тәрәшле» озын җитен түгел икәнен һәрбер әби белә. Тәрәшле (тәрәшел) җитен сүсеннән дә, киндер сүсеннән дә була иде. «Мүкәләү», «көймә» түгел (Г. Тукай, Г. Ибраһимов алай язмыйлар иде), «мүкәйләү», «кимә» (кимә килә... эзе юк...). Әдәби телне ят якка тартмаска кирәк. Шикер әле, «көймә» (кибитка) сүзе урынына Казанда матбугатка үрмәләп бара торган гарип «күмә» сүзе бу китапка язылмаган. Ул да керсә, нишләрбез? «Өй»не «ү» дип атарга калыр! «Аның каравы» дигән нәмәрсә дә дөрес түгел. Бу кереш сүз булып йөри торган куш сүз русча **зато, наоборот, все же...** дип тәрҗемә ителә. Дөресе «аның каруы» булырга тиеш. Димәк, киресе, капма-каршысы. Бу тамырдан сүзләр байтак: карулашу, каршы, карышу h. б. Ул шулай кереп киткән инде, диючә табылыр, мөгаен. Хатаны соңлап булса да төзәтү яхшы. Соң «көзлектә»не хуп күргәч, «кичлектә», «язлыкта», «кышлыкта», «җәйләктә»ләрне ник хур итәргә! «Мәсхәрәләшү», «чукышу», «макташу», «хурлашу» китапка пәек, ә «бергәләшү», «чәкәшү» ник юк! Бер төзек

юл алу зарурдыр бит. Гомумән, фигыль формаларын күрсәтүдә башбаштаклык сизелә. «Белгәләү» юк. «Белешкәләү» бар. Бер автор «йөрештергәләү»не ала. Икенчесе «күрештергәләү»не кирәк тапмый. «Караштыргалау» булгач, «баргалаштыру» да булсын иде...

Шунысы да кызык, «ике» тамырыннан егермеләп сүз табылган, «биш» тамырыннан алты сүз генә һ. б. Ник алай ул? Гыйльми хезмәттә бер тәртип кирәктер бит.

Сүзе туры килгәндә, кеше исемнәре дә күрсәтелгән: «Фәсәхәт», «Зөбәрҗәт», «Фазыл», «Вафа» һ. б. Ә ник Энҗе, Җиһан, Мөхәррәм, Фаик, Хатирә, Өлфәт, Хәтимәләр калган? Бу — балага исем сайлауга ярдәм итәр иде. Юкса бик чит-ят исемнәр тулды бит: Айрат (алтай телендә — «ярлы»), Артур (зур аю), Флюс (чир исеме), Сайра (балык), Эдуард (байлык җыючы), Римма (сөяк), Риф (яр буе) һ. б. Ә күп гасырлар буена килгән гүзәл, мәгънәле исемнәр никтер балаларга кушылмый.

Бер талай сүз нигәдер бик тар аңлашылган иптәшләргә. «Чулай ябалагы» бармы? Бар. «Хөрәсән ялкау» да очраштыргалый. «Күбә» — тимер кием бит. «Җир-су» — туган як бит ул. «Җор» — сәләтле, булдыклы кеше. «Җөдәү ат» — ябык атны шулай да диләр. «Һушлы»ның синонимы — зирәк, «һиммәт»неке — батыр, базык. «Каран» — караңгы дигәне була. «Түбә» — ыру, ыруг. «Казан» — борынгыча «Газан» — кеше исеме. «Кабан» сүзе элек табак, тәлинкә мәгънәсендә дә кулланылган. «Элгәртен» — «борынгы» түгел, «элгәре», «әвәл». «баштан» мәгънәсендә дә йөри. (Элгәртен син әйт, аннан мин әйтәм.)

Алда «килмәле», «йөрмәле», «күрмәгәе», «бармагаe» кебек сүзләргә дикъкать кирәк, дип әйткән идек. Шундый хәл «барырлар» (барырга кирәк иде), «күрерләр» (күрү тиеш булган) калыбына нисбәтән дә яшәп килә. Бу формалар — җанлы телдә бик кирәк, гадәти, актив сүзләр. Ә грамматикаларда, сүзлекләрдә күренмиләр.

Искермәгән байтак сүзгә «искергән» мөһере басыла. «Шөйлә», «һанүз», «һәрдаим», «җәһәт» (ул җәһәттән), «карар кылу», «фәрман», «фида», фәлсәфә», «кәмит»... сыман сүзләр һәр өйдә даими кулланыла. Ник искерсен алар? Җир сөргән тирән тутыгамыни?

Ә ник сүз эзләп академик Радлов җәнапләренә мөрәҗәгать итмәскә! Анда нинди генә сүзләр юк! Ул бит моннан йөз ел элек актив булган ни тиклем татар сүзен туплап калдырган («тиклем» сүзе З. Бәширидән). Без рәхмәт белән күмгән Радлов мирасыннан хәзер күп сүз кулланылмый. Ләкин алар арасында бик әтеш сүзләр бар. Мисал: «авык» (миг, мгновение), «азар» (хәтер калу, үпкә), «юсык» (зиннәтле, купшы), «шөрек» (слива), «сармаша» (плющ), «усан» (ялыктыргыч, күңелсез), «торык» (ике багана арасы; димәк, пролет), «ту[illegible]ыя» (башлы суган) һәм бик күп башкалар. Бу сүзләрнең, әлбәттә, яшәргә хакы бар. Ә аларны тергезү бурычы язучы, журналистлардан элек галимнәр өстенә төшә.

Сүз җыярга безнең якларга да килеп чыгыгыз, гыйззәтле галимнәр. Ык, Сөн елгалары аша күперләр күп. Башкортстанда татарча сөйләшкән халык бер миллионнан аша. Бездә дә бик хаҗәт сүзләр күп:

Җигәрле [1], үзчән кешеләр күрерсез. Алар ачамай төшкән өзгеч, кукырлар, «шайтан шурпасы» чөмерүчеләр белән, «каруга кару» (ягъни карышы кешегә каршы) дигәндәй, бик нәгыз алышалар. Без дә Чирмешән, Чәрмәсән (үләннән исем алган елгалар) буенда мал-кара түл җыя. Яшьләр бездә иптәшләнәләр; кәбен (никах) мәҗлесләре үткәрәләр.

Ә авыл исемнәре нинди! Мәскәү (борынгы «тозак» сүзеннән кеше исеме), Бүздәк (үлән исеме), Бакай (елга ерыны), Малаяз («мал аязы» — яланы), уңлап Тукай авылы. Мин белгәне генә дүрт Туратау!

Ә фамилияләр ниндирәк! Чаныш! Байтирәк! Енникәй! Янгалыч! Биглов! Карамыш! Кайбыч! Манат! Кирәй! Болар бар да төрки сүз. Тик мәгънәләре генә бик ачылып бетмәгән. Гафил булмагыз. Килегез, иптәшләр, сүз җыярга.

Тәртмә тел, дип гаепләштән булмасын, иптәшләр. Тырнактән кара эзләү түгел бу рецензия. Ырымбурча әйтсәк, «акыллашу», Уфача — «маслихәт кору» бу. Сүзлекнең кыйммәтен без һич тә төшерергә теләмәдек. Бик файдалы, үтә зарур китап ул.

Тел белеме үсәр. Безнең гомердә дә тулы сүзлекләр чыгар, дип ышанабыз.

---

[1] Сүзлектә юк сүзләрнең астына сызылды.

**Яхъя Абдуллин**

философия фәннәре кандидаты

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕНӘ КАРАТА

Россия кул астында яшәгән күпчелек халыкларда феодаль богауларга, рухи тунлык һәм торгынлык күренешләренә каршы көрәшнең беренче баскычларында мәгърифәтчеләр торган. Алар урта гасырлардан килгән искелек калдыкларына каршы кыю чыкканнар, шәхеснең ирекле булырга тиешлеген яклаганнар, кешегә, аның акылына дан җырлаганнар, үзләренең эшчәнлекләре белән халык массалары арасына революцион идеяләрнең үтеп керүе өчен уңдырышлы туфрак әзерләп калдырганнар.

Россия составына кергән аерым халыклар тормышының үзенчәлекле шартлары, аларның икътисади (экономик), сәяси һәм рухи үсешләрендәге үзгәлекләр ул халыклардагы мәгърифәтчелек идеологиясенең эчтәлегенә һәм характерына да мәгълүм бер эз салган, мәгърифәтчелек идеяләренең чыганакларын, туу һәм килеп чыгу вакытын, шулай ук иҗтимагый тормышның төрле мәсьәләләренә төрлечә якын килү үзенчәлекләрен билгеләгән. Мәгърифәтчелек идеологиясенең төрле халыкларда төрлечәрәк барлыкка килүе һәм үсүе турында сөйли торган әлеге үзенчәлекләрне ачыклау алардагы рухи тормышның ничегрәк үсүен, алар арасында дөньяга революцион карашның ничек барлыкка килүен һәм тагын да камильләшүен, марксистик-ленинчыл тәгълиматның урнашуын дөрес аңлау һәм аңлату өчен дә гаять әһәмиятле.

Бездә мәгърифәтчелек идеяләрен беренче тапкыр XIX йөзнең башларында Г. Утыз-Имәни (1730—1815), Г. Курсави (1788—1814) һәм И. Хәлфиннәр (1778—1829) күтәреп чыга. Урта гасырлардан калган тәртипләрне тәнкыйть итү эшен шулар башлап җибәрә, халыкка дөньяви белемнәр бирү, татар һәм рус халыкларын тормыш, мәдәният мәсьәләләрендә бер-берсенә якынайту идеясен башлап шулар күтәрә. Шулай да, иҗтимагый-политик һәм идея агымы буларак, татар мәгърифәтчелеге руслардыкыннан соңрак, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, XIX йөзнең икенче яртысында гына тәмам формалашып җитә. Бу — татар тормышының үзенчәлекле шартлары белән аңлатыла торган нәрсә. Заманында татарлар яшәгән өлкәләр Россия империясенең чикләре саналган. Бу җирләрдә яшәгән татар халкы экономик яктан гына түгел, милли яктан да рәхимсез изүгә дучар ителгән. Шулар өстенә, хезмәт иясе массаларын күп гасырлар буена дини идеология йогынтысында тәрбияләп килгәннәр. Укыту эше кадим муллалар һәм ишаннар кулында булган. Алар, мәктәп һәм мәдрәсәләргә дөньяви белемнәрне кертмәү өчен, һәртөрле киртәләр корганнар, яңалык яралгыларына рәхимсез рәвештә каршы чыгып һәм хөр фикернең теләсә нинди формаларын шәфкатьсез эзәрлекләп, халыкны дин сөреме белән агуларга, аны торгынлыкта тотарга тырышканнар. Изелгән халык вәкилләренең, рус хезмәт ияләре белән берләшеп, помещиклар строена каршы көрәшкә күтәрелүеннән котгы очкан патша самодержавиесе мөселман руханиларына бу мәсьәләдә һәртөрле ярдәм һәм теләктәшлек күрсәткән. Менә болар барысы да татарлар арасында мәгърифәтчелек идеяләренең тууы,

формалашу һәм үсү процессын күпмедер вакытка тоткарлап торган.

Әмма Европа, барыннан да бигрәк Россия өстеннән искән азатлык җилләре акрынлап татарлар арасына да үтеп керә башлый. XIX — йөзнең урталарында татар халкы гасырларга сузылган йокыдан уяна һәм тормышның алга барышын тоткарлап килгән иске традицияләрне вату, җимерү эшенә керешә. Шул эшләрнең башында торучылар барлыкка килә. Алар бездәге мәгърифәтчелек идеологиясенең вәкилләре була. Мәгърифәтчеләр тормышының яңа формаларын алга сөрәләр, томаналык, наданлык һәм торгынлык күренешләренә каршы көрәшәләр, урта гасыр идеологиясеннән дөньяви фәннәргә күчүне, шәхес ирекен яклап чыгалар.

Россиянең кайбер башка халыклары белән чагыштырганда, үзгәреш җилләре безгә бераз соңгарып килеп җитә. Әмма бер килеп җиткәч, бик давыллы һәм кызу төс ала. Чөнки бу вакытларда инде Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләр тәмам ныгып җитә, зур тизлек белән промышленность үсә башлый. Бу процесска татар халкы да килеп кушыла, татарлар арасында социаль аерымлану көчәя, милли буржуазия формалаша. Бу нәрсә бездәге мәгърифәтчелек идеяләренең үсешенә үз эзен сала. Ярты гасырлык вакыт эчендә татар мәгърифәтчелеге үзенең югары ноктасына күтәрелеп җитә, шуннан каршылыклар полосасына килеп керә һәм XX йөзнең башларында үз урынын тагын да алдынгырак идеологиягә — башта революцион демократик, бераз соңрак марксистик-ленинчыл идеологиягә бирә.

XIX йөзнең икенче яртысындагы танылган мәгърифәтчеләр булып К. Насыйри (1825—1902), Х. Фәезханов (1821—1866), Г. Ильяси (1856—1895), Ф. Халиди (1850—1923), М. Акмулла (1831—1895) һәм З. Бигиевләр (1870—1902) саналып йөртелә. Алар белән бергә, мәгърифәтчелек идеологиясенең үсешенә күренекле тарих галиме һәм фикер иясе Ш. Мәрҗани (1818—1889) һәм талантлы татар прозаигы М. Акъегет (1864—1923) зур өлеш кертәләр. Соңгы вакытларда Ш. Мәрҗани һәм М. Акъегетнең иҗат эшчәнлеге берьяклырак бәяләнеп килде. Дөрес, XIX йөз әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә М. Акъегетнең әдәби иҗаты шактый тәфсыйллы тикшерелә, тик монда да аның мәгърифәтчелек хәрәкәтендә, иҗтимагый фикер үсеше тарихында тоткан роле һәм урыны мәсьәләсе читләтеп үтелә. Ш. Мәрҗани исә озак вакытлар буе гел дини реформатор буларак кына каралып киленде. Хәлбуки, бездәге иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүгә күп көч куйган Галимҗан Ибраһимов аларның исемен һәрвакыт К. Насыйрилар һәм татар мәгърифәтчелегенең башка танылган вәкилләре белән янәшә куеп йөртте [1]. Ш. Мәрҗанине ул бөек остазыбыз, таңыбызның чулпаны дип [2], ә М. Акъегетне үзенү дәверендә яңа татар әдәбиятына беренче нигез ташы салган беренче яңа татар әдибе, татар реализм әдәбиятының атасы [3], дип бәяләде.

Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан кебек әдипләребез дә Ш. Мәрҗанинең иҗат эшчәнлегенә гаять югары бәя биргәннәр. Үзенең «Шиһап хәзрәт» исемле шигырендә Тукай аны «мәгарифкә әүвәл башлап адым салган» кыйммәтле зат дип атый. Русның атаклы тарих галиме, академик В. В. Бартольд Мәрҗанине татарлар арасындагы алдынгы хәрәкәткә нигез салучы дип бәяли [4].

Үзенең тормыш юлы, татар мохитендә биләгән урыны, иҗатының характеры һәм иҗтимагый мәсьәләләргә якын килү рәвеше ягыннан Шиһабетдин Мәрҗани искиткеч кызыклы, шул ук вакытта гаять каршылыклы шәхес. Аның иҗатында әллә никадәр каршылыклар, бер сайлаган юлдан кире чигенү моментларын очратырга мөмкин. Әмма, әнә шундый капма-каршы яклары булуга да карамастан, ул кыю рәвештә феодаль богауларга, наданлыкка, томаналыкка һәм рухи торгынлыкка кискен рәвештә каршы чыккан, уку-укыту эшләрендәге схоластиканы тәнкыйтьләгән, уку йортларына дөньяви фәннәр кертелүен яклап чыккан алдынгы карашлы кешеләрнең беренчеләреннән була. Үзе дин әһеле булуга да карамастан, ул татарларны рус

---

[1] Г. Ибраһимов. Каюм Насыйриларның тарихи урыннары. «Каюм Насыйри» исемле җыентык. Казан. 1922 ел; Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы. «Безнең юл» журналы. 1922 ел. 1 сан.

[2] Г. Ибраһимов. Бөек остазыбызның кайбер тәэллифләре. «Аң» журналы. 1915 ел. 1 сан.

[3] Г. Ибраһимов. Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы. «Безнең юл» журналы. 1922 ел. 1 сан; Татарның соңгы тарихында өч дәвер. «Татарстан хәбәрләре» газетасы. 1922 ел. 20 март саны.

[4] В. Бартольд. Ислам. Рус телендә. Петроград. 1918 ел. 87 бит.

телен өйрәнергә чакырып чыга, математика һәм рус теле укытучылары хәзерләү максаты белән Казанда Учительская школа ачылгач, үзен чолгап алган даирәнең ризасызлык белдерүенә дә карамастан, шул мәктәпкә укытучы булып бара. Ш. Мәрҗани тормышындагы һәм иҗат эшчәнлегендәге нәкъ әнә шул соңгы момент хәлиткеч иде, һәм аның эшчәнлегенең менә шул ягы халкыбыз тарихының мәгълүм бер этабында объектив рәвештә уңай роль уйный.

Ш. Мәрҗанинең тарихи ролен һәм урынын берьяклы бәяләүдә, иҗатындагы каршылыклардан тыш, аның дин әһеле булуы да шактый зур роль уйнады шикелле. Хәлбуки, дин әһелләре башка халыкларның мәгърифәтчеләре арасында да очрый. Мәсәлән, күренекле француз философы һәм мәгърифәтчесе Кондильяк, мәгърифәтче һәм утопик коммунист Мабли, немец мәгърифәтчесе Гердер һәм башкалар дин әһелләре булганнар. Инде татар мәгърифәтчелегенә килгәндә, аларның күбесе (я кәсепләре, я чыгышлары һәм белемнәре буенча) руханилар даирәсенә караы татар тормышының материаль һәм рухи үзенчәлекләре белән аңлатыла торган нәрсә. Ул заманнарда бездә дөньяви мәктәпләр булмаган, хөкүмәт хисабына яшәгән рәсми уку йортларына исә татарларны кертмәгәннәр. Нәтиҗәдә алар фән белән шөгыльләнә яки хөкүмәт учрежденияләрендә эшли алмаганнар. Беренче рус революциясенә кадәр татар телендә газета-журналлар чыгару тыелган. Шуңа күрә дөньяви белем алган кешеләребез дә бөтенләй диярлек булмаган. Халыкның иң белемле өлешен дин әһелләре, муллалар тәшкил иткән. Шуңа күрә алдынгы карашлы кешеләр дә башлыча шул даирәдән чыккан.

Дөресен әйтергә кирәк, руханилар арасыннан чыккан кешеләрнең алдынгы карашларны, якты фикерне хуплаулары ул вакыттагы татар дөньясы өчен аерым әһәмияткә ия булган. Эш шунда ки, төрле сәбәпләр аркасында, ул замандагы татар халкы алдында мулла, дин әһелләре аерым абруй белән файдаланган. Чөнки ул иң белемле һәм корьән сүзләрен аңларлык бердәнбер кеше саналган. Аның һәр сүзе бәхәссез хакыйкать төсендә кабул ителгән. Бохарада укып кайткан муллаларның даны исә тагын да зуррак булган.

Менә бервакыт, уйламаганда-көтмәгәндә дигәндәй, корьәнне һәм хәдисләрне иң шәп белгән, җитмәсә мәшһүр Бохараның үзендә гыйлем эстәп кайткан иң белемле мулла Ш. Мәрҗани диннең догмаларын тәнкыйть итеп чыга, адәм балаларына фикер хөрлеге даулый, алай гына да түгел, әгәр шәригатьтә фәнни дәлилләргә каршылык була икән, «дөреслеге ачык мәгълүм нәрсәне инкарь итүгә караганда, шәригать күрсәтмәсен үзгәртеп аңлау яхшырак» булыр, дип үк җиббәрә [1].

Дин әһелләре авызыннан чыккан мондый сүзләр үз дәверендә зур яңгыраш тудырган, күпләрне дин догмаларына шикләнеп карарга мәҗбүр иткән һәм аларга иске традицияләр богавыннан котылырга булышкан.

«Без нинди мирастан баш тартабыз?» дигән хезмәтендә В. И. Ленин мәгърифәтчелекне феодаль торгынлыкның, урта гасырдан килгән томаналыкның, социаль изүнең явыз дошманы итеп характерлый һәм шул ук вакытта, асылы белән буржуаз характерда булуына да карамастан, аның ул вакыттагы шартларда халык массалары интересларына һәм иҗтимагый прогресска хезмәт итүенә басым ясый. Ул вакытларда «бөрлык иҗтимагый мәсьәләләр крепостное правога һәм аның калдыкларына каршы көрәшүгә кайтып кала иде,— ди В. И. Ленин.— Яңа иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр һәм аларның каршылыклары ул вакытта әле яралгы хәлендә иде. Шуңа күрә, ул вакытта буржуазия идеологларында үз файдаларын күзәтү һич булмады; киресенчә... алар бөтен кешенең рәхәттә яшәячәгенә тәмам чын күңелдән ышандылар һәм шуны чын күңелдән теләделәр...»[2]. Бу — XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән татар мәгърифәтчеләре өчен дә хас нәрсә иде.

Башка халыкларның мәгърифәтчеләре кебек үк, алар татар тормышындагы искелек, кыргыйлык калдыкларына каршы көрәшәләр һәм үз эшчәнлекләре белән яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, буржуаз мөнәсәбәтләрнең ныклап урнашуына булышалар. Шуның белән бергә, әлеге яңа мөнәсәбәт-

---

[1] Ш. Мәрҗани. Мокатдимате китабе Вафиятель-асляф вә тахиятель-ахляф. Татарча кулъязмасы СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында. 18—19 битләр.

[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. Таткитнәш. 2 том. 499 бит.

ләр халыкны прогресс юлына, мәгърифәт һәм муллык юлына китереп чыгарыр, дип чын күңелдән ышанып яшиләр.

Әмма татар мәгърифәтчеләре үзләренең эшчәнлекләрен капиталистик мөнәсәбәтләр үзләренең әшәке якларын инде сиздерә башлаган дәвердә башлап җибәрәләр. Өстәвенә алар изелгән халыкның, милли бәйсезлек өчен көрәшеп килгән халыкның вәкилләре булалар. Бу аларның иҗат эшчәнлегенә дә йогынты ясамый калмый. Аларның әсәрләрендә, кызыл җеп булып, социаль гаделсезлеккә һәм изүгә каршы, шул исәптән милли изүгә каршы да, протест авазлары сузылып бара. Алар комсызлыкны, мөлкәтле сыйныфлар арасында хөкем сөргән ерткычлыкны фаш итәләр, акча кечәнә корылган җәмгыятьнең яман шешләрен ачып салалар. Үзенең «Фәвакиһел җөләса» исемле әсәрендә К. Насыйри байлыкны һәртөрле бәла-казаның, ызгыш-талашның һәм гаделсезлекнең чыганагы, дип бәяли. Абыйсы Габделхайга адресланган хатларының берсендә, Казан халкының авыр тормышын тасвирлап, зур ачыну белән: «...халык бик бетерештә. Зарланмаган беркем дә юк», дип яза. Авылда йөреп кайтканнан соң язган тагын бер хатында крестьяннарның авыр хәлен сурәтли: «Өйгә кайтып килдем, белдем, күрдем һәм ишеттем. Нәрсә белдең, нәрсә күрдең, нәрсә ишеттең? — дип сорарсың. Белгәнем — зур хәерчелек. Ул чиктән ашкан. Күргәнем — атлары юк. Бөтен вакыйга менә шул»[1]. Мәгърифәтче шагыйрь М. Акмулла исә, социаль тигезсезлек күренешләренә тукталып, шигырьләренең берсендә болай ди:

> **Гаҗәп, һәркем гани булса,**
> **Аңа хөсне дидар әйләр;**
> **Фәкыйрь мескенгә пәрва юк,**
> **Мәзәлләт берлә зар әйләр**[2].

Г. Ильяси, Ф. Халиди, З. Бигиев кебек әдипләр дә изүгә корылган җәмгыятьнең ямьсез якларын кыю рәвештә фаш итәләр.

Әмма ни генә димик, аларның тәнкыйте ахырга кадәр эзлекле булмый әле. Бу, барыннан да бигрәк, татар мәгърифәтчеләренең хезмәт ияләрен хәерчелектә яшәргә мәҗбүр иткән сәбәпләргә социаль-экономик бәя бирүгә кадәр күтәрелеп җитә алмауларында һәм революцион рухтагы нәтиҗәләр ясаудан шактый ерак торуларында күренә. Яшәп килгән җәмгыятьнең җитешсезлекләрен алар, нигездә, гуманизм ноктасыннан чыгып фаш итәләр. Социаль каршылыкларның асылын аңламаганлыктан, алар, үзләренең рус һәм Көнбатыш Европадагы элгәреләре кебек үк, «халыкның бер сыйныфын да аерым рәвештә игътибар үзәгенә алмыйлар», «гомумән халык турында гына түгел, хәтта гомумән милләт турында»[1] сөйлиләр.

Үзенең алда искә алынган хезмәтендә, XIX йөзнең 40—60 елларындагы рус мәгърифәтчелегенә тукталып, В. И. Ленин аларга хас өч билгене күрсәтә: 1) «Крепостное право һәм аның калдыкларына»... дошманлык; 2) «Мәгариф эшен, иркле идарәне, азатлыкны, тормышның европача формаларын» кайнар рәвештә яклау; 3) халык массаларының, башлыча крестьяннарның интересларын күзәтеп, крепостное правоны һәм аның калдыкларын бетерү барлык кешеләр өчен бәхетле тормыш китерәчәк дип чын күңелдән ышану[2].

Теге яки бу формада, теге яки бу дәрәҗәдә өлеге сыйфатлар XIX йөзнең икенче яртысындагы безнең мәгърифәтчеләргә дә хас була. XIX йөзнең 40—60 елларындагы рус мәгърифәтчеләре кебек үк, алар крепостное право калдыкларына дошмани күз белән карыйлар, мәгариф эшен, иркле үзидарәне, азатлыкны, тормышның европача формаларын яклыйлар, халык массаларының, беренче чиратта крестьяннарның, интересларын яклыйлар һәм феодализм калдыкларын бетерү барлык кеше өчен бәхетле тормыш китерер дип чын күңелдән ышаналар.

Шуның белән бергә, бездә бу сыйфатлар, үзенең күп кенә хезмәтләрендә И. Нуруллин дөрес билгеләп үткәнчә[3], шактый үзенчәлекле төс ала, үл сыйфатларның кайберләре шактый калку, икенчеләре исә, киресенчә, йомшаграк чагылыш таба.

Дини китапларда язылганнарга сүзсез ышану, дин догмаларының халык тормышын басып торуы, уку-укыту эшләрендәге схоластика, борынгылар сүзенә сукырлар-

---

[1] Каюм Насыйри (1825—1945). Тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни сессия материаллары. Казан. 1948 ел. 122 бит.

[2] «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 7 сан. 119 бит.

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Таткитнәш. 2 том. 520 бит.

[2] В. И. Ленин. Әсәрләренең тулы җыелмасы. Рус телендә. 2 том. 319 бит.

[3] И. Нуруллин. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан. 1966 ел; Мәгърифәтчелек реализмы турында. «Казан утлары» журналы. 1968 ел. 4 сан.

ча иярү, үткәннең үле традицияләре алдында баш ию һәм шуннан килеп чыга торган торгынлык, туңлык, томаналык — менә шулар татар тормышындагы искелек калдыкларының аеруча ямьсез һәм котсыз күренешләре булып саналган. Урта гасырлардан калган шул ямьсез күренешләр, кара пәрдә булып, татар тормышын каплап килгән, татар халкына иҗтимагый тормышның актуаль мәсьәләләрен күрергә комачаулаган, аның игътибарын җир йөзендә бәхет өчен актив эшчәнлек алып барудан читкә юнәлтергә тырышкан.

Татар мәгърифәтчеләре үзләренең төп көчләрен искелекнең әнә шул калдыкларына каршы юнәлтәләр, Г. Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, «тәкълиддән иҗдиһатка, нәкыльдән акылга, алладан бәндәгә, күктән җиргә, хыялдан тормышка, диннән гыйлемгә, ахирәттән дөньяга»[1] күчүнең зарурилыгын дәлилләп чыгалар. Дин тарихы һәм мифология урынына, алар халыкның чын тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүне яклыйлар, халык тормышына караган әйберләрне, тарихи истәлекләрне һәм фольклор әсәрләрен җыялар, шуларга нигезләнеп, халык иҗаты һәм тарих буенча гыйльми хезмәтләр язалар. Әгәр моңарчы уку-укыту эшләре халыкка чит гарәп телендә алып барылса, мәгърифәтчеләр балаларны үз ана телләрендә укытуны яклап чыгалар, татар телен өйрәнү һәм фәнни эшкәртүне башлап җибәрәләр, татар теленең морфологиясенә һәм синтаксисына караган дәреслекләр өстендә эшлиләр.

Искелек калдыкларын рәхимсез төстә фаш итеп һәм аларны вату-җимерү эшенең зарурлыгын дәлилләп чыксалар да, ул чагында әле татар мәгърифәтчеләре иҗтимагый төзелештәге искелек калдыкларының яшәвен тәэмин иткән, халыкны авыр, караңгы тормышка дучар иткән социаль-экономик сәбәпләрне күрмиләр һәм күрә дә алмыйлар иде. Алар халык массаларын кызганалар, аның авыр хәлен җиңеләйтергә тырышып карыйлар, кыенлыклардан чыгу юлларын эзлиләр. Әмма алар татар дөньясын буып торган рухи торгынлык, катып калганлык һәм туңлык күренешләре халыкның наданлыгыннан, мәдәни түбәнлектән, фәнни белемнәрнең йомшак таралуыннан килә дип уйлыйлар. Шуңа күрә дә, халыкны агарту, аны фән белән коралландыру һәм мәдәниятен үстерү мәсьәләләрен алар беренче планга куялар. Аларның әсәрләрендә, мәгърифәтчеләр эшчәнлеген характерлый торган башка моментларның икенче планга калдырылып, төп урынның халыкны агарту, халык арасында фәнни белемнәр тарату, уку-укыту эшләрен юлга салу һәм укыту эшендәге схоластикага каршы көрәш мәсьәләләренә бирелүе нәкъ әнә шуның белән аңлатыла да.

Татар мәгърифәтчелегенең тагын бер үзенчәлеге шунда ки, алар күп кенә рус һәм Европа мәгърифәтчеләреннән аермалы буларак, дәвернең актуаль проблемаларын хәл итү юлларын эзләгәндә, патшаларга һәм укымышлы дворяннарга түгел, ә гомумән кеше акылына һәм аның хисләренә мөрәҗәгать итәләр. Чөнки, изелгән милләт вәкилләре буларак, рус патшасыннан һәм помещиклардан мәрхәмәт көтүнең мәгънәсезлек икәнен алар бик яхшы аңлаганнар. Ул чагында татар җәмгыяте белән җитәкчелек иткән ярым надан мулла һәм ишаннардан нидер көтүне тагын да зуррак мәгънәсезлек санаганнар. Ахыр килеп, татар мәгърифәтчеләренең тарих аренасына киң халык массаларының гомуми хәрәкәте якынлашып килгән бер чорда күтәрелеп чыгуы да аз роль уйнамаган.

Татарларга феодализм чорыннан калган иң авыр мирасларның берсе милли һәм дини изү иде. Татарларга карата патша хөкүмәте ачыктан-ачык руслаштыру политикасы алып бара, аның мәдәниятен, телен эзәрлекли, политик хокукларын чикли. Экономик һәм социаль изү хезмәт ияләре җилкәсенә авыр йөк булып төшә. Аларны түли алмаслык налоглар һәм салымнар белән җәфалыйлар. Россия крестьяннарын гомер-гомергә иза чиктергән җирсезлек татарларны тагын да ныграк кыса. Сембер губернасының Зирекле күл авылында, мәсәлән, татарлар (564 җан, яки 197 хуҗалык) һәм чувашлар (410 җан, яки 131 хуҗалык) элек-электән бергә яшәгән. 1861 елгы реформадан соң чувашларга 3959 дисәтинә җир, ә татарларга, сан ягыннан күбрәк булуларына да карамастан, 2966 дисәтинә генә җир беркетелә[1]. Узган йөзнең 80 еллары башында Казан губернасындагы татар крестьяннарының 56,8 проценты авыл пролетариаты хәлендә яшәгән[2].

[1] Г. Ибраһимов. Каюм Насыйриларның тарихи урыннары. «Каюм Насыйри» исемле җыентык. Казан. 1922 ел. 6 бит.

[1] «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 4 сан. 77 бит.

[2] Татарстан АССР тарихы. Рус телендә. Казан. 1968 ел. 208—209 битләр.

Мондый шартларда татар мәгърифәтчеләре өчен иң кыен мәсьәләләрнең берсе милли изүгә мөнәсәбәт булып исәпләнсә, икенчесе рус халкына, аның мәдәниятенә һәм теленә мөнәсәбәт мәсьәләсе саналган. Татар мәгърифәтчелегенең тагын бер үзенчәлеге шушы мәсьәләгә якын килү һәм аны ничек хәл итүдә күренә. Эш шунда ки, патша хөкүмәтенең татарларга карата алып барган милли һәм дини изү политикасы тәэсирсез калмый. Рус хөкүмәтенең татарларга каршы политикасын рус халкына да күчереп, рус халкын рус хөкүмәте һәм христиан миссионерлары белән бер итеп күрсәтеп, мөселман руханилары русларга каршы киң пропаганда эше алып баралар. Дин әһелләре өйрәтүе буенча русның һәрнәрсәсе, шул исәптән теле һәм мәдәнияте дә, монафыйк, көфер, икенче төрле әйткәндә язык, гөнаһ саналган. Тарихтан без беләбез: руслар белән бергәләшеп, татар хезмәт ияләре патшага һәм помещикларга каршы көрәшкә бер генә мәртәбә күтәрелмәгәннәр. Изүчеләргә каршы бергәләп көрәшүнең аеруча гыйбрәтле мисалы төсендә Пугачев восстаниесен күрсәтергә мөмкин булыр иде. Әмма шулай да патша самодержавиесе татар халкын экономик һәм дини-милли яктан нык кыскан бер чорда мөселман руханилары тарафыннан алып барылган әлеге пропаганда да бөтенләй эзсез үк калмый.

Сүз дә юк, үз халкының уллары буларак, татар мәгърифәтчеләре милли изүгә читтән генә карап тора алмаганнар: аны хөкем иткәннәр, аңа каршы көрәшкәннәр. Инде татар мәгърифәтчеләренең элгәрләреннән берсе булган С. Хәлфин (1742—1785) үк халыкларның тигез хокуклылыгын яклап чыга. Каюм Насыйриның күпчелек әсәрләрендә шундый ук идеяләр уздырыла. Татар мәгърифәтчелегенең икенче бер күренекле вәкиле Ш. Мәрҗәни үзенең «Мокатдимате китабе Вафиятель-аслеф вә тахиятель-ахляф» исемле хезмәтендә фәнни иҗатта төрле халыкларның тигез хокуклы булырга тиешлеген һәрьяктан дәлилләп чыга һәм тегә яки бу милләтне өстен куярга маташу омтылышларына кире мөнәсәбәт белдерә.

Шуның белән бергә, югары дин әһелләреннән аермалы буларак, мәгърифәтчеләр русларны татарларга каршы кую юлына басмыйлар, киресенчә, рус һәм татар халыкларының үзара якынаюларын яклыйлар, рус мәдәниятен һәм аның телен өйрәнергә чакыралар. Шушы юнәлештә күп төрле практик эшчәнлек алып баралар. К. Насыйри, мәсәлән, татар балаларына рус телен өйрәтү эшен башлап җибәрә, татар халкын рус мәдәнияте үрнәкләре, шул исәптән рус әдәбияты әсәрләре белән дә таныштыра. XIX йөзнең ахырларында тәрҗемә эше киң колач ала. Күп кенә күренекле рус прозаикларының, шагыйрьләренең һәм драматургларының әсәрләре татар телендә басылып чыга.

Шуның белән бергә, мәгърифәтчеләр рус арасында татар халкының тормыш-көнкүрешен, аның телен һәм әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен популярлаштыруга да зур игътибар бирәләр. Шул ук К. Насыйри, әйтик, рус уку йортларында татар теле укыта, университет каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең әгъзасы була, җәмгыять утырышларында татарның фольклоры, йола-гадәтләре турында докладлар ясый. Археология җәмгыятенең эшчәнлегендә Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Г. Ильясилар актив катнаша. Әлеге мәгърифәтчеләрнең барысы да рус матбугатында татар халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, мәдәнияте хакында язылган мәкаләләре белән катнашып киләләр. Аларның бу эшчәнлеге русларга татар халкының тормышы һәм тарихы белән танышырга ярдәм итә, милли киртәләрне вату-җимерү эшенә булыша.

Билгеле булганча, ул заманнарда татар хатын-кызларының язмышы гаять авыр иде. Мөселман дине аларга ирләр белән тигез хокук бирмәде. Хатын-кыз һәртөрле җәмәгать эшләреннән читләштерелгән хәлдә яши, гаилә тормышының бөтен авырлыгы алар җилкәсендә иде. Шуңа күрә хатын-кыз азатлыгы, аларның тигез хокуклылыгы кебек мәсьәләләрне татар мәгърифәтчеләре иң актуаль проблемаларның берсе төсендә күтәреп чыгалар. Бу да татар мәгърифәтчелегенең бер үзенчәлегенә керә.

Хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен, беренче буларак, татар шагыйре Г. Кандалый (1797—1860) күтәрә. Үз шигырьләрендә ул гади авыл кызының матурлыгына дан җырлый, аның ихтыяр көченә һәм турылыклылыгына соклана, хатын-кызның авыр язмышы өчен борчыла. XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән мәгърифәтчеләр аның карашларын алга таба үстерәләр, татар хатын-кызларының авыр хәлдә изелеп яшәвен тәнкыйтьләп чыгалар. Бу тәнкыйть З. Бигиев һәм Г. Ильяси әсәрләрендә аеруча кискен куела. Шул ук вакытта алар

үзләре күрергә теләгән идеал хатын-кыз образларын да тудыралар. Мәгърифәтчелек әдәбиятының беренче үрнәге саналган «Хисаметдин менла» повестенда, мәсәлән, Хәнифә, иске традицияләргә һәм әти-әниләре теләгенә каршы барып, үз язмышын үзе хәл итә. Бу образ белән автор хатын-кызның ирекккә омтылышын сурәтли. Икенче бер мәгърифәтче язучы З. Бигиев үзенең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле әсәрендә хатын-кызның ирләр белән тигез хокукын тәэмин иткән, аларга гаилә һәм җәмәгать эшләрендә катнашу мөмкинлеге тудырган җәмгыятьне үзенең идеалы төсендә тасвирлый.

Кешене, аның әхлаки йөзен беренче планга кую — татар мәгърифәтчелеге өчен характерлы үзенчәлекләрнең тагын берсе әнә шул. Биредә без гуманизм һәм гаделлек мәсьәләләрен һәрвакыт үзәккә куеп килгән татар әдәбиятының һәм иҗтимагый фикеренең уңай традицияләре дәвам итүен күрәбез. Милли торгынлык, томаналык һәм катып калганлык күренешләреннән котылуның бер юлы шәхеснең әхлак ягыннан камилләшүендә дип ышанган мәгърифәтчеләр ул традицияләрне тагын да баеталар, алга таба үстерәләр.

Шуннан чыгып, кайбер авторлар татар мәгърифәтчелеген әхлак төзәтү белән генә шөгыльләнгән бер агым итеп күрсәтмәкче булалар. Хәлбуки, мондый караш белән килешүе кыен. Әхлак мәсьәләләре белән беррәттән, мәгърифәтчеләрнең дөньяга карашларында иҗтимагый-политик мәсьәләләр, шулай ук фән, чынбарлыкны фәнни танып-белү мәсьәләләре дә зур урын тота. Тегеләйме-болаймы, алар шушы һәм дөньяга караш белән бәйләнешле башка мәсьәләләрне дә кузгаталар һәм хәл итәләр. Ләкин алар эшчәнлегенең ул яклары тиешенчә өйрәнелмәгән. Бәла бары шунда гына. Соңгы ун ел эчендә татар мәгърифәтчелегенә багышланган күп кенә фундаменталь хезмәтләр басылып чыкты. Әмма аларда күбрәк мәгърифәтчеләрнең әдәби, өлешчә генә иҗтимагый-политик карашлары яктыртыла. Аларның философик карашлары исә тикшеренүчеләр игътибарыннан бөтенләй читтә кала килә. Хәлбуки, мәгърифәтчеләрнең дөньяга карашлары гаять катлаулы һәм каршылыклы. Аларның дөньяга карашларын һәрьяклап тикшерми торып, мәгърифәтчеләрнең иҗатына дөрес бия бирү һәм татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләрен төрле яклап ачу кыен эш.

Мәгърифәтчеләрнең дөньяга карашларында үзләре яшәгән дәвернең рухы чагылган һәм чагылмый кала да алмаган. Ул вакыттагы татар мөхитына мөселман диненең, мөселман руханиларының йогынтысы шактый көчле була. Хаким идеология буларак, дин һәртөрле хөр фикерне кысып, буып тора. Мондый шартларда мәгърифәтчеләр үзләре дә дөньяга дини-идеалистик караш йогынтысыннан бөтенләй үк азат була алмыйлар иде. Аларның мәгариф эшен, аң-белем таратуны һәм шәхесне әхлак ягыннан камилләштерүне кискен социаль мәсьәләләрне чишүнең бердәнбер һәм хәлиткеч юлы дип исәпләүләре үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Шуның белән бергә, тормышның конкрет күренешләрен тикшергәндә, реаль вакыйгалар турында сүз барганда, татар мәгърифәтчеләренең карашларында материалистик тенденцияләр һәм диалектика элементлары да сизелми түгел.

Татар мәгърифәтчеләренең дөньяга карашларында эзлексезлек, дини-идеалистик идеологиягә ташлама ясау моментларын күргәндә артык гаҗәпләнмәскә кирәктер. Андый нәрсә башка халыкларның фикер ияләренә дә хас күренеш. Дөньяга идеалистик караш моментларыннан, мәсәлән, күренекле немец мәгърифәтчеләре Г. Лессинг (1729—1781) һәм И. Гете (1749—1832) котыла алмаган. Рус мәгърифәтчелек фикеренең Н. И. Новиков (1744—1818) һәм П. Я. Чаадаев (1794—1856) кебек аерым вәкилләре дә дини-мистик идеологиягә ташлама ясаганнар. Дөрес, Чаадаев турында сөйләгәндә, мистик идеяләрнең аңа маска өчен кирәк булуын да истән чыгармаска кирәк. Тагын шул кадәресен оныттырга ярамый: аерым илләрдә, мәгълүм бер шартларда, бигрәк тә сыйнфый мөнәсәбәтләр ачыкланып җитмәгән очракларда, алдынгы фикерле көчләрнең дөньяга караш өлкәсендә үз дошманнарына каршы көрәше бер төрле идеалистик агымнарны икенчеләренә каршы кую формасында да барган. Мәсәлән, яңарыш эпохасының башлангыч чорында алдынгы карашлы фикер ияләренең платонизм позицияләреннән торып аристотелизмга каршы чыгулары, яңа замандагы сунятсенизм һәм гандизм хәрәкәте нәкъ әнә шулай була. Шуңа охшаганрак нәрсәне без Ш. Мәрҗани эшчәнлегендә дә күрәбез. Үзе дини-идеалистик караш позициясендә торса да, ул мистиканы, фанатизмны тәнкыйть итеп чыга, кешә аңының иске традицияләр һәм схо-

ластика агуыннан азат булырга тиешлеген яклый. Корьән догмаларына берсүзсез ышану урынына, ул рационализмны байрак итә, фәнне, фәнни танып белүне алга сөрә. Күп санлы хезмәтләрендә Мәрҗани чынбарлыкка рационалистик якын килүнең матур үрнәкләрен бирә, бу исә, үз чиратында, аны дини караш белән сыеша алмастай нәтиҗәләр ясауга китерә.

Татар мәгърифәтчеләре яшәгән һәм иҗат иткән шартларда дөньяга дини-идеалистик карашны шул рәвешчә ярым-йорты тәнкыйть итү дә прогрессив роль уйный, урта гасырлардан килгән схоластик идеологиянең җимерелүенә, материалистик идея һәм карашларның таралуына булыша.

* * *

Нинди генә идеологик системаны алып карама, аңа үз эпохасында хакимлек иткән рух йогынтысы сизелә. Аның нигезен кешеләрнең иҗтимагый яшәеше, алар тормышының материаль шартлары билгели. Идеологик установкаларның характеры һәм төп тенденцияләре нәкъ шулар белән бәйләнә дә.

Бу яктан карагандa, татар мәгърифәтчелек идеологиясенең барлыкка килүе Россиядәге капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше тәэсирендә татар халкының материаль һәм рухи тормышында туган мәгълүм үзгәрешләр белән аңлатыла. Ләкин шуның белән бергә, марксизм-ленинизм тәгълиматы дөрес өйрәткәнчә, җәмгыятьнең идея тормышы билгеле күләмдә мөстәкыйльлеккә ия һәм ул үзенең эчке табигатенә хас законнар нигезендә үсә. Төгә яки бу эпоханың идея-политик карашларына иске традицияләр дә йогынты ясый. Инде бөтен бер халыкның идеологик системасы турында сүз барганда, аңа үзе белән аралашып яшәгән башка халыкларның идеологик тәэсир ясавын да истән чыгармаска кирәк. Икенче төрле әйткәндә, һәр идеологик системаның, материаль чыганаклардан тыш, идея чыганаклары да була әле.

Татар мәгърифәтчелек идеологиясенә хас чыганакларның үзенчәлеге әлеге идеология барлыкка килгән дәвердәге тарихи шартларның, милли традицияләрнең, элекке һәм хәзерге халыкара бәйләнешләрнең характеры белән билгеләнә. Шулар арасыннан игътибарны барыннан да элегрәк үзенә тартканы — татар иҗтимагый-политик фикерәнең алдынгы традицияләре, беренче чиратта, гуманизм, гаделлек һәм изүнең һәртөрле формаларына тирән нәфрәт идеяләре. К. Галинең «Йосыф һәм Зөләйха»сы (XII йөз ахыры), Сараиның «Гөлстан»ы (XIV йөз), Мөхәммәдъярның «Төхфәи Мәрдән» һәм «Нуры содур» (XVI йөз) поэмалары, борынгы татар әдәбиятының башка истәлекләре буйдан-буйга әлеге идеяләр белән сугарылган. Хәтта кайбер суфи шагыйрьләрнең әсәрләрендә дә, урыны-урыны белән, социаль изү, комсызлык, вәхшилек күренешләренә каршы нәфрәт авазлары яңгырап китә. Андый мотивлар, мәсәлән, XVII йөз шагыйре М. Колый иҗатында нык сизелә. Татар мәгърифәтчеләренең элгәреләреннән булган Г. Утыз-Имәни, Г. Курсави, И. Хәлфиннәрнең әсәрләре дә шул ук идеяләр белән сугарылган. Әлеге фикер ияләре һәм җәмгать эшлеклеләренең иҗат мирасы иҗтимагый фикер өлкәсендәге прогрессив тенденцияләрнең үсешенә уңай йогынты ясый. XIX йөзнең икенче яртысындагы татар мәгърифәтчеләре шул тенденцияләрнең варисы итеп санарга кирәк; үзләренең дөньяга карашларын формалаштырганда, татар мәгърифәтчеләре әлеге чыганактан идея материалы алалар, иҗтимагый һәм философик фикерне алга таба үстереп, яңа баскычка күтәрәләр.

Бездә мәгърифәтчелек идеологиясенең тууы татар иҗтимагый-политик фикеренең Көнчыгыштан Көнбатышка, бигрәк тә Россиягә таба йөз белән борылган дәверенә туры килә. Шуңа күрә русның алдынгы иҗтимагый-политик һәм философик фикерә татар мәгърифәтчелек идеологиясенең икенче бер мөһим һәм хәлиткеч чыганагы булып исәпләнергә тиеш. Ул татар мәгърифәтчеләренең фикерләү рәвешенә йогынты ясый, аларның актуаль мәсьәләләргә якын килү алымнарын һәм идея-политик омтылышларын билгели.

Татар мәгърифәтчеләренең зур күпчелеге яшәгән Казан шәһәрендә моның өчен уңай шартлар була. Русның күренекле революцион демократы А. И. Герцен үзенең «Провинциядән хатлар» исемле әсәрендә ул чордагы Казанны Шәрык белән Гарепнең, бигрәк тә, рус мәдәнияте белән шәрык мәдәниятенең бергә очрашкан урыны дип атый һәм кәрван-сарай белән чагыштыра. Әлеге хатларында ул: бирелә Шәрык һәм Гарептән килә торган ике башлангыч бар, алар бер-берсенә йогынты ясыйлар,

үзара якынаялар, дип яза [1]. Өстәвенә Казан — университет үзәкләренең дә берсе була. Казан университетында Н. И. Лобачевский (1792—1856), И. М. Симонов (1794—1855), А. М. Бутлеров (1828—1886) кебек мәшһүр галимнәр эшли. Университет профессорлары арасында алдынгы карашлы кешеләр дә аз булмый. 60 еллар башында университетта тарих дәресләрен А. П. Щапов (1830—1876) алып бара, үз лекцияләрендә ул рус революцион-демократларының карашларын алга сөрә. Н. Г. Чернышевский, Н. А. Добролюбов, А. И. Герценнарның фикерләре университетның революцион рухтагы студентлары тарафыннан да киң таратыла.

Болар барысы да татар халкының алдынгы карашлы вәкилләрен рус мәдәниятенә, алдынгы рус фәненә якынайту өчен уңай мөмкинлекләр тудыра. Барлык татар мәгърифәтчеләре диярлек рус халкының мәдәниятен, телен әйбәт беләләр, рус галимнәре белән даими элемтәдә яшиләр. К. Насыйриның, мәсәлән, әтисе үк русча белгән, әтисе тәэсирендә ул үзе дә яшьли рус телен өйрәнә, рус мәдәнияте белән таныша. Х. Фәезханов, ирекле тыңлаучы сыйфатында, университетка лекцияләр тыңларга йөри, соңыннан үзе үк шунда укытучы була, каллиграфия, татар, төрек, гарәп, фарсы телләре буенча дәресләр бирә. 1855 елда, Казан университетының шәрык разряды Петербургка күчерелгәч, ул башкалага китә, анда күренекле галим булып таныла.

З. Бигиев үзенең күп вакытын, русча китаплар укып, Ростов китапханәсендә уздыра. М. Акъегетнең яшьлек еллары руслар арасында уза.

Алдынгы рус галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре белән якыннан таныш булу, алар белән даими элемтәдә яшәү дә татар мәгърифәтчеләренең дөньяга карашлары формалашуга уңай йогынты ясый. К. Насыйри, Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗанилар университетның В. В. Радлов, А. К. Казимбек, И. Ф. Готвальд, М. Ф. Катанов, Е. Малов кебек галимнәрен әйбәт белгәннәр, кайберләре белән хәтта дуслар да булганнар. Моннан тыш Х. Фәезханов Петербургның күп кенә галимнәре белән аралашып яши. Алар арасында В. Р. Розен, В. В. Вельяминов-Зернов, В. А. Дорн, П. И. Лерх кебек мәшһүр галимнәр, В. В. Стасов кебек алдынгы карашлы җәмәгать эшлеклеләре бар. Үзе Петербургтагы фән яңалыкларыннан хәбәрдар булу, фәннең актуаль мәсьәләләре хакындагы бәхәсләрне күзәтеп барудан тыш, яңалыклар белән ул укытучысы Ш. Мәрҗанине дә таныштырып тора, аңа башкала галимнәре белән иҗади бәйләнешкә керергә булыша.

Шундый бәйләнешләр аркасында татар мәгърифәтчеләре XIX йөзнең урталарында һәм икенче яртысында рус фәнендә һәм иҗтимагый фикер өлкәсендә барган үзгәрешләрне белеп торалар, алдынгы фикер ияләренең һәм җәмәгать эшлеклеләренең дөньяга карашлары белән танышып баралар. Мондый танышлыкның уңай йогынтысы булмый калмый, билгеле. Әлеге йогынты теге яки бу дәрәҗәдә аларның фикер агышына тәэсир итә, аларга татар халкын рухи торгынлык, томаналык һәм наданлык күренешләреннән чыгару юлларын табарга булыша. Рус фәне, рус мәдәнияте аша татарлар арасына Көнбатышның алдынгы идеяләре үтеп керә. Руслар белән аралашу, рус әдәбиятын уку аркасында, татар халкының алдынгы вәкилләре Көнбатыш Европаның фәне, философик һәм иҗтимагый фикерләре белән танышалар.

Татарларның гарәпләр, Урта Азия халыклары, Иран һәм башка Шәрык илләре белән икътисади-мәдәни бәйләнешләре исә борын-борыннан ук килгән. Аларның зур сәүдә юллары өстендә утырулары бу эштә уңай роль уйнаган. Бу бәйләнешләр, ахыр килеп, дин уртаклыгы һәм, өлешчә, тел уртаклыгы белән тагын да ныгытылган. XVI йөздә Татарстанны рус дәүләте составына кушу да әлеге бәйләнешләрне өзә алмаган. Монда татарларның Шәрык белән булган традицион бәйләнешләрен саклауда рус хөкүмәтенең кызыксынуы да аз роль уйнамаган. Рус хөкүмәте татар сәүдәгәрләрен Көнчыгыш белән сәүдә эшендә арадашчы итеп, ә йомышлы татарларны дипломатик максатларда файдалана. Сәүдәгәрләр һәм йомышлы кешеләр, Шәрык илләрендә йөргәндә, аларның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте белән танышалар, файдалы дип тапканнарын туган илләренә алып кайтып тараталар. Сәүдә карваннарына ияреп, Бохара, Сәмәрканд якларына татар яшьләре дә китә. 7—10 елдан, дин әһелләре яки мөгаллимнәр булып, алар кирәдән туган илләренә әйләнеп кайтканнар. Шулай итеп, Көнчыгыштан безгә товарлар гына түгел, идеяләр дә үтеп кергән.

---

[1] Литературное наследие. Рус телендә. СССР Фәннәр академиясе басмасы, 1955 ел. 19 бит.

Бу вакытларда Шәрык илләрендә әле реакция көчләренең, искелекнең һәм дин калдыкларының позициясе шактый нык була. Шуңа күрә ул яклардан безгә дини фанатизм, схоластика һәм башка реакцион идеяләр дә шактый күп килә. Әмма анда да гел кара фикер генә хөкем сермәгән, хөр фикер яралгылары да булган, билгеле. Анда Әбүгалисина, Фирдәүси, Хәйям, Низами, Сәгъди, Нәвои, Әль-Фараби, Әль-Бируни кебек бөтен дөньяга мәшһүр акыл ияләре яшәгән. Дини фанатизм һәм суфичылык әсәрләреннән аермалы буларак, аларның хезмәтләре чынбарлык, тормыш мәсьәләләренә багышланган, аларның иҗаты гуманизм һәм гаделлек идеяләре белән сугарылган. Татар халкының иң яхшы уллары үзләренең игътибарларын барыннан да бигрәк Шәрык фәне, философиясе һәм иҗтимагый-политик фикеренең әнә шул традицияләренә юнәлтәләр. Хәтта схоластиканың оясы саналган кадим мәдрәсәләрендә дә, дин кануннары белән бергә, Әбүгалисина, Низами, Фирдәүси, Нәвои кебек бөек фикер ияләренең әсәрләре өйрәнелә. Аларның әсәрләре кулдан-кулга йөри. Казан университетының фәнни китапханәсендә Нәвоиның XVI йөздә күчерелгән биш поэмасының кулъязмалары әле бүген дә саклана.

Татар мәгърифәтчеләре Шәрык халыкларының әнә шул алдынгы иҗтимагый һәм философик фикерләрен, аларның гуманизм хисләре белән сугарылган әдәбиятын яхшы белгәннәр. Көнчыгышның алдынгы фикер ияләре турында алар бик югары фикердә торганнар. Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләренә укырга баргач, мәсәлән, Ш. Мәрҗани үзенең күп вакытын бу шәһәрләрнең бай китапханәләрендә Шәрык әдәбияты җәүһәрләрен өйрәнеп уздыра. Аның әсәрләрендә Әбүгалисинага тирән хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре зур урын били. Үзенең «...Вафиятель-асляф вә тахиятель-ахляф» исемле хезмәтендә Әбүгалисинаны ул иң бөек шәхесләрнең берсе, белеменең киңлеге, акыл һәм фикеренең камиллеге ягыннан сирәк очрый торган талант иясе дип бәяли. Нәвои турында да Мәрҗани гаять югары фикердә, аны Хорасанидагы иң мәшһүр һәм иң популяр галимнәрнең берсе һәм кимсетелгән, өлешсез калганнарның яклаучысы дип атый.

Әбүгалисина, Нәвои кебек акыл ияләре К. Насыйри иҗатына да уңай йогынты ясаган. Аларның әсәрләре К. Насыйри өчен илһам чыганагы булып саналган. Шәрык әдәбиятының бик күп үрнәкләрен ул татар теленә тәрҗемә иткән, алардагы образлардан файдаланып оригиналь әсәрләр язган.

Татар мәгърифәтчеләре Шәрыкның борынгы әдипләрен һәм галимнәрен өйрәнү белән генә чикләнмиләр, алар үзләренең Шәрыктагы замандашлары белән дә даими элемтәдә яшиләр. Х. Фәезханов, мәсәлән, казакъ халкының күренекле мәгърифәтчесе Ч. Валиханов белән дустанә мөнәсәбәтләрдә була, тормышның төрле мәсьәләләре буенча фикер алышып һәм ярдәмләшеп яши. Гарәп һәм фарсы телләре аша татар мәгърифәтчеләре антик әдәбият һәм философия белән танышалар. Шул кадәресен басым ясап әйтергә кирәк, күпчелек татар мәгърифәтчеләре борынгы грек һәм рим философиясен, аларның иҗтимагый һәм әдәби фикерен шактый әйбәт беләләр. «...Васыятель-асляф вә тахиятель-ахляф» исемле әсәрендә Ш. Мәрҗани, мәсәлән, Аристотель, Платон, Пифагор кебек антик философларның дөньяга карашларын җентекләп тикшерә, аларга үз бәясен бирә. Мәрҗанинең ул фикерләре бүген дә игътибарга лаек.

Шулай итеп, башка күп кенә халыкларның мәгърифәтчелек идеологиясеннән аермалы буларак, татар мәгърифәтчелеге үзенең тамырлары белән һәм Шәрыкка һәм Гәрепкә барып тоташа. Барлыкка килгән вакытта ук ул үз җирлегендәге һәм чит, бигрәк тә рус җирлегендәге уңай традицияләргә таяна. Идея чыганакларының күп яклылыгы шулай ук татар мәгърифәтчелегенә хас үзенчәлек.

* * *

В. И. Ленин «Бердәнбер дөрес революцион теория булган марксизмны Россия ярты гасырлык тарих — тиңдәшсез җәфа чигү һәм корбаннар бирү, тиңдәшсез революцион героизм күрсәтү, әйтеп бишанмаслык энергия кую һәм чын күңелдән эзләнү, өйрәнү, практикада сынап карау, күңел кайту, тикшерү, Европа тәҗрибәсен чагыштырып карау тарихы белән чын-чыннан газап чигеп үзләштерде»[1],— дип язды.

Төрле тарихи шартларда яшәү нәтиҗәсендә, Россиядәге һәр халык марксизм-ленинизмга үз юлы белән барган. Татар тормышының баштагы этапларында бу юлның башында мәгърифәтчеләр торган. Аларның эшчәнлегендә һәм иҗатында та-

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Таткитнәш. 31 том. 10 бит.

тар халкының үз киләчәге һәм караңгылыктан, томаналыктан чыгу юлларын эзләве чагыла.

Мәгърифәтчеләр тарих аренасына күтәрелгән дәверләрдә татар халкын искелек калдыклары изеп-басып тора һәм дөньяны ул дин пәрдәсе аша карап бәяли иде. Халыкның алдынгы уллары буларак, мәгърифәтчеләр искелекнең бөтен төрле формаларына каршы рәхимсез ут ачалар, алар фикер хөрлеген яклыйлар, искергән традиция һәм догмаларны җимереп ташларга чакыралар. Аларның мондый кыю эшчәнлекләре халыкка иске карашлардан арынырга ярдәм итә, тормышка аек акыл белән карарга өйрәтә, ахыр килеп, революцион идеяләрнең үтеп керүе өчен уңай җирлек әзерли.

Татар мәгърифәтчеләренең эшчәнлеге Урта Азия һәм Казагыстандагы төрки телле халыклар өчен дә уңай роль уйный. Күренекле казакъ галиме һәм әдибе М. Әүэзов Абай Кунанбаевның сайланма әсәрләренә язган кереш сүзендә, татар һәм казакъ мәгърифәтчеләре арасындагы бәйләнеш мәсьәләләренә тукталып, А. Кунанбаев татарның беренче мәгърифәтчесе Ш. Мәрҗани әсәрләрен әйбәт белгән, ди [1]. Татарның мәгърифәтчелек йогынтысындагы мәктәпләре һәм уку йортлары Россиянең Шәрык халыклары өчен мәгариф һәм мәдәният кадрлары хәзерләүдә, алардагы уку-укыту эшләрен юлга салуда күп ярдәм итә.

Бездә хәзер марксистик-ленинчыл идеология тантана итә. Советлар иленең башка халыклары кебек үк, татар халкы бердәм сафларда коммунизмга атлый. Монда мәгърифәтчеләрнең дә өлеше бар. Алар ашлап калдырган туфракта ахырдан татар революцион-демократлары үсеп чыга, соңгылары исә үз чиратларында хезмәт иярәренә марксизм-ленинизмны үзләштерергә җирлек хәзерләделәр.

---

[1] Абай Кунанбаев. Лирика и поэмы. Рус телендә. Мәскәү. 1940 ел, 26 бит.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

# ЛЕГЕНДАР СЕВАСТОПОЛЬДӘ

*Юл язмалары*

### Диңгез фонында һәйкәлләр һәм чәчәкләр



Юлга чыгар алдыннан без Усман ага Закиров кабинетына җыелдык. Ул дүртебезне дә барлап, күздән үткәрде дә, гадәтенчә, үзенә хас күтәренке күңел белән: «Менә делегация тулы составта. Татарстан нефтьчеләре килә! — Ярыйсы гына авторитетлы яңгырый бит, ә! Сезне Севастопольдә әнә шулай кабул итәрләр. Бөтен илгә мәгълүм герой-шәһәрнең хезмәт ияләре үрнәк коммунистик тәртипләр урнаштыру өчен көрәш башлап җибәргәннәр. Севастополь кешеләреннән менә шушы патриотик башлангычны өйрәнү, анда булган уңай тәҗрибәне, алдынгы алымнарны үзләштерү — сезнең төп бурыч шул»,— диде.

Менә ул — легендар Севастополь!

Беренче карауга ук аның диңгез гаванена хас үзенчәлекләре күзгә бәрелә. Мәһабәт биналары һәм архитектура ансамбльләре бухта суының зәңгәрсу фонында соклангыч матур булып күренәләр. Төзелеш планында да диңгезчә почерк: яшеллек белән аралаш торак массивлары, ярдан ук башланып, дулкыннарның дәвамы рәвешендә тауларга таба күтәрелә баралар. Проспектлар киң, мәйданнар иркен. Гомумән, диңгез холкына ятышлы, ташып торган колач һәм фантазия!

Ә урыны нинди, бухтасы!

Табигый шартлары да, стратегик ягы да туры килгән шундый уңышлы урынны табып, шәһәр-крепость салырга полководец Суворовның даһиларча алдан күрүчәнлеге кирәк булган. Ике йөз ел буена тарих моны күп тапкырлар раслады.

«1854—1855 еллардагы Севастополь оборонасы Панорамасы» — тарихи истәлекләрнең кыйммәтле хәзинәсе. Махсус түгәрәк бинаның эчке стеналары әйләнәсенә Малахов курганда барган сугыш күренешләре төшерелгән. Картинаның сюжеты бөек язучы Л. Н. Толстойның «Герое рус халкы булган бу Севастополь эпопеясе үзенең бөек эзләрен Россиядә озак вакытлар саклар»,— дигән сүзләрен художество образында чагылдыра. Монда заманында тиңе булмаган каты сугышлар булган. Дошман 175 мең кешедән торган гаскәр белән, 160 батареяның уты ярдәмендә, шәһәргә һөҗүм итә. Төп удар Малахов курганга юнәлдерелә. Севастопольнең 85 меңле гарнизоны, атаклы флот башлыклары В. А. Корнилов, П. С. Нахимов һәм В. И. Истомин җитәкчелегендә, 349 көн буена актив оборона сугышлары алып бара. Севастопольне саклаучылар Англия, Франция һәм Төркиянең басып алу планнарын өзәләр, ныклык-



Менә ул легендар Севастополь. Диңгездән күренеше.

лары белән бөтен дөньяны таң калдыралар. Әлеге Панорама тарихның менә шушы битләрен тамашачыларның күз алдына китерә. Аны караганда үзеңне йөз еллар элек булган вакыйгалар эчендә хис итәсең.

Биредә шушы оборона сугышларында һәлак булган корбаннарга багышланган бер гранит обелиск бар. Ул бухта өстеннән мәһабәт булып күтәрелә. Аның башындагы канатларын җәйгән бөркет — мәңгелек дан символы, Севастопольнең эмблемасы.


Бу шәһәргә немец басып алучыларына каршы да 250 көн буена оборона сугышлары алып барырга туры килә. «Совершенный» миноносецы матрослары, өлкән лейтенант Матюхин җитәкчелегендә, ахыр чиккә кадәр Малахов курганны үз кулларында тотып, фашистларга каршылык күрсәтәләр. «Полундра» белән контратакага күтәрелгән морякларның ачулы, усал кыяфәтләре гитлерчыларга куркыныч була. Хәтта яралылар да сугыш кырын ташлап китми. Авыр яраланган матрос Дмитрий Альтер өзелгән телефон чыбыкларын тоткан килеш үлә. Аның гәүдәсе аша ялганган телефон ярдәмендә, яр буе батареялары дошман өстенә атуларын дәвам иттерәләр...

Малахов курган шәһәр өстеннән биек һәм горур булып күтәрелә. Аның мәйданында хәзер чорыбызның күренекле кешеләре, геройлары үз куллары белән утырткан Халыклар дуслыгы бакчасы үстерелә. Бастионнарда тирән тынлык, тупларның көпшәләре эченә чыпчыклар оялаган...

Сапун тауга экскурсия аеруча кызыклы булды. Анда без Севастопольне азат итү көннәрендәге вакыйгалар белән таныштык. 1944 елның язында, корыч ташкындай һөҗүм итеп килүче совет гаскәрләре, немецларның таулар өстеннән «таш фронт» булып үткән оборона сызыкларына һөҗүм башлыйлар. Барлык кораллларның җимергеч уты Сапун тауга туплана. Аның башы ут атып торган вулкан шикелле ялкынга, төтенгә чорнала. Штурмчы частьлар бер удар белән дошман утырган биеклекне алалар һәм туры юлдан Севастополь урамнарына бәреп керәләр.

Хәзер шул тау башындагы ярым түгәрәк бинага «1944 елның маенда Сапун тауны штурмлау» диорамасы урнашкан. Аның полотносында, чынбарлыкка охшатып, шушы зур сугышның бер фрагменты, бер секунды күрсәтелә. Әнә өлкән лейтенант

Дзигунский үз гәүдәсе белән дошман ДОТын каплаган. Матрос Аверкин, пычак тотып, траншеядагы фашистлар өстенә ташланган. Рядовой Яцуненко, полк байрагын күтәреп, биеклеккә таба омтыла. Штурмда катнашучы Советлар Союзы Герое Паликахин отзывлар журналына: «Диорамада мин үземне (башы бәйләнгән), лейтенант Головняны, сержант Гунько/ны һәм башка иптәшләремне күрдем»,— дип язган. Диораманың тирә-ягындагы мәйданында шул вакыттагы күренеш сакланган. Тау башыннан биек һәйкәл күтәрелә, ә томанлы түбәнлеккә «Золотая балка» совхозының җимеш бакчалары һәм виноград плантацияләре җәелгән.



Малахов Курган капкасы.

Әйе, Севастополь авыр сынауларны кичергән шәһәр. Фотодокументларга һәм күргән кешеләрнең сөйләүләренә караганда, ул көннәрне аңа карарга кызганыч була. Шәһәрдә булган 6400 йорттан берничә генә бина исән кала. Җимерелгән, янып күмергә әйләнгән кварталлар өстеннән кара сөрем күтәрелә. Менә шундый хәлдә калган шәһәрне бүгенге чәчәк ату дәрәҗәсенә күтәрү өчен никадәр гигант көч һәм тырышлык кирәк булган! Әгәр беренче оборонадан соң аны торгызуга 50 ел вакыт үткән булса, бу юлы ул биш ел эчендә аякка бастырыла. Анда яшәүчеләр саны да башта 2 мең булса, ярты елдан 50 меңгә, ә хәзер 220 меңгә җитә. Бүген аның Ленин, Нахимов районнарында 40 тан артык эре промышленность предприятиесе бар. Диңгез порты исә илебездәге иң эре промысел базаларының берсе булып тора.

Диңгез климаты һәм көньяк кояшының шифалы нурлары бик килешә, ахры, монда хәтта таш кыялар да яшел үсентеләр белән капланганнар. Кая гына барсаң да — матур итеп җыештырылган аллеялар, газоннар һәм меңнәрчә чәчәклардән торган клумбалар синең даими юлдашларың.

## Севастопольчеләр көрәшнең алгы сафларында

Җәйнең кояшлы бер матур иртәсендә легендар шәһәр безне әнә шулай бульварлары, чәчәкләре белән елмаеп каршылады. Ә кешеләре белән, хуҗалары белән күрешү тагын да куңеллерәк булды. Эшне шәһәр Советыннан башладык. Безнең Андрей Петрович, сүзнең башы итеп, өстәлгә ике шешә чыгарып куйды да гаҗәпкә калган иптәшләргә: «Менә бусы сезгә истәлек бүләге — корабльләргә ягулыкка китә торган Татарстан нефте»,— диде һәм хуҗаларны безнең миссия белән таныштырды.

Эш барышында без герой-шәһәрнең предприятиеләрендә, культура-көнкүреш учреждениеләрендә булдык, тормышы һәм кешеләре белән таныштык. Севастопольнең даны, барыннан да элек, аның кешеләрендә, кешеләренең эшләрендә һәм бүгенге тырыш хезмәтләрендә.

Биредә яшәүче халык үзенең тормышы һәм хезмәте белән диңгезгә бәйле. Кешеләр шушы диңгез буенда туалар, башта йөрергә, аннан йөзәргә өйрәнәләр, аның саф һавасын сулап үсәләр. Диңгез аларны чыныктыра, хезмәткә һәм кыенлыкларны җиңәргә өйрәтә.

Севастополь — данлы традицияләр шәһәре, дигән идек. Ул традицияләр, иң авыр сынауларны да узып, буыннан-буынга күчә киләләр. Бүген хезмәт фронтында өлкән буынның сугышчан традицияләре кабатлана. Коммунистларча яшәргә! — хәзер бу лозунг тормыш законы булып, кешеләрнең хезмәтләрендә, көнкүрешләрендә һәм уйларында гәүдәләнә.

Безгә рудниклар идарәсе коллективы турында сөйләделәр. Болай була: идарәнең эшче-хезмәткәрләре үз инициативалары белән өстәмә производство объектлары төзергә керешәләр. Эш сәгатьләреннән соң алар тагын эшкә — тау буендагы төзелеш мәйданына ашыгалар. Нәтиҗәдә — яңа транспортер төзелә. Руда таудан бер километрга сузылган конвейер аша туры фабрикага бирелә башлый. Производство куәте сизелерлек арта һәм бер ел эчендә планда каралган 2,8 миллион тонна урынына 4 миллион тонна руда чыгарыла башлый.

Су-канал идарәсендә дә шундый ук күтәренкелек — 440 кешедән торган коллектив члennары барысы да коммунистик хезмәт ударниклары. Шәһәрне су белән тәэмин итү эше аларның ышанычлы кулларында. Василий Усов фронттан туп-туры үзенең гидроузелына кайта, җимерелгән корылмаларны торгызу һәм монтажлау эшләрендә катнаша. Менә инде 30 елдан артык ул Кара Елганың болганчык суларын фильтр аша чистартып уткәрә. Йөз меңнәрчә кешеләр шул суны эчәләр. Шундагы гидрокорылмалар системасының өлкән инженеры Евгения Тисленко безне үзенең эш-хәлләре белән таныштырып йөрде: тирә-якта диңгез булса да, су мәсьәләсе биредә бик җитди проблема — ул шәһәргә менә шушы йөзәр километрга сузылган трубалар аша, катлаулы юлдан килә икән.

Герой-шәһәрдә вакыттан алга үтеп, коммунизм баскычына күтәрелеп килүче разведчиклар күп. Аларның үскәннән-үсә бара торган хәрәкәтләрендә ике йөз предприятие һәм учреждение, өч йөздән артык цех һәм бригада, 55 мең чамасы кеше катнаша.

Севастопольдә яшәүче һәр дүрт кешенең берсе укый: — вузлар, техникумнар, кичке мәктәпләр — гөр килеп тора. Уку мәсьәләсе безнең Әлмәт, Җәлил кебек шәһәрләрдә дә начар куелмаган анысы, эшче кеше хәзер укуның кадерен белә. Безне ул гаҗәпләндермәде, безне таң калдырган нәрсә Севастопольдәге соклангыч җәмәгать тәртибе булды. Монда 50 меңнән артык кеше үз теләкләре белән ирекле рәвештә җәмәгать эшләрендә катнаша. Хезмәт ияләре вәкилләре сыйфатында 804 депутат Советларның хуҗалык һәм культура төзелеше өлкәсендәге эшләре белән идарә итә. Башкарма комитетлар каршында штаттан тыш бүлекләр һәм комиссияләр эшли. Шәһәр буенча йөзләрчә халык дружинасы һәм иптәшләр суды, аларда катнашучы 24 мең кешедән торган актив җәмәгать тәртибен саклау эшләрендә катнашалар. Дружиналар, районнар һәм участоклар буенча, халык җыела торган караңгы урыннарны, хәтта аерым йортларны да контроль астына алганнар. Безнең өчен үрнәк буларак, герой-шәһәрдә дружиналарда катнашу массовый төс алган. Мәсәлән, электростанция поселогында өч кешенең берсе дружиначы, ә кайбер семьялар тулаем дружиначылар. Тәртип саклауда, яшьләр белән беррәттән, өлкән яшьтәгеләр, хәтта пенсионерлар да актив катнаша. Отставкадагы полковник Г. Духовский, 1 нче ранг капитаны П. Хандог, яшьләре 60 тан югары булуга карамастан, үзләре башлап, патрульлек итәргә чыгалар. Күп кенә дружиналар белән запастагы офицерлар җитәкчелек итә. Билгеле, тормышта күпне күргән, тәҗрибәле кешеләрнең халык арасында сүзләре үтә, файдалы киңәшләре бик күпләргә төзәлергә, дөрес юлга басарга ярдәм итә. Хәзер биредә тәртип бозулар гадәттән тыш хәл булып исәпләнелә.

Җәмгыять файдасына ирекле рәвештә хезмәт күрсәтүнең иң актив һәм сыналган формасы буларак, коммунистик өмәләр герой-шәһәрдә массовый төс алганнар. Меңлә-

гән кеше, төп хезмәтләреннән бушаган арада, тау-ташларны ватып тигезлиләр, чокырларны күмәләр, юллар салалар, мәйданнарны җыештыралар, агачлар һәм чәчәкләр утырталар.

Корабльләр ягындагы Н. Островский урамы кайчандыр ташландык хәлдә булган. Ә хәзер анда — күзге кебек асфальт, тигез рәтләрдә үскән агачлар, чәчәкләр белән тулы клумбалар...

Янгынчылар да вакытларын бушка үткәрмиләр икән: ел саен унар төп агач утыртып үстерергә йөкләмә алганнар. Рядовой Дмитрий Данчук исә соңгы елларда 500 төп агач утыртып үстергән.

Без, кайда гына булсак та, кешеләрнең тәртип һәм чисталык турында кайгыртуларын күрдек. Ушаков мәйданында шулай кызыклы бер хәлне күзәтергә туры килде. Үтеп барышлый, бер яшь кеше, иптәшләре белән сүзгә мавыгып, әллә игътибарсызлыктанмы, сукмакка папирос төпчеге ташлады. Ләкин шунда ук өлкән яшьләрдәге берәү аларны туктатты да, әлеге төпчекне алырга мәҗбүр итте. Кем соң ул, шәһәр урамнарын үзенең өе кебек күреп, тәртип саклаучы кеше? Кызыксына торгач, бу кеше Мелиотополь урамы, 21 йортта торучы Иван Федорович Босов булып чыкты. Ул үз гомерендә күпне күргән, күп диңгезләрне кичкән һәм бирелдәге оборона сугышларында катнашкан кеше икән. Заманында водолаз булган, гражданнар сугышы чорында батырылган эскадра корабльләрен күтәрүдә катнашкан, су астындагы «Свободная Россия» линкорыннан бомбалар бушатышкан. Барысын бергә кушып санаганда, ул 4 елга якын гомерен су астында үткәргән. Иван Федорович хәзер пенсиядә, бакчачылык белән шөгыльләнә, күршедәге мәктәп укучыларына җимеш бакчасы үстерергә булыша. Билгеле, мондый кешеләр тормышны яраталар һәм яшьләрне дә аның кадерен белергә, матурлыгын сакларга өйрәтәләр. Яки менә Р. Заудальский. Ул алдынгы шофер, өстәвенә, автоинспекциядә штаттан тыш инспектор һәм газета хәбәрчесе дә. Әйләнә-тирәгә хуҗаларча күз белән карый: тәртип бозып йөрүче лихач шоферларны вакытында тыеп туктата, җәмәгатьчелекне юлларның тәзеклеген һәм чисталыгын сакларга чакыра. Дворник булып эшләүче Кузнецова һәм Спиридоновалар тыйнак, ләкин тынгысыз хезмәтләре белән мактауга лаеклылар — коммунистик хезмәт ударниклары. Бирелдә һәркем аларның хезмәтенә хөрмәт белән карый: урамнарны чүпләргә, тәртип бозарга рөхсәт ителми! Юкса, үзеңне шунда ук «яшел патруль» туктата: «Ярамый, бу бит — Севастополь!»

Ярамый, бу бит — Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Җәлил...» дигән сүзләрне Татарстан шәһәрләренә дә матур бер кагыйдә итеп кертәсе иде!

Һәрбер яшәүчегә 15 квадрат метр яшеллек!

Бу — гади арифметика гына түгел, халыкны көрәшкә туплый торган өндәмә. Севастополь кешеләре ел саен 80—100 мең төп агач, 150—200 мең төп куак һәм миллионнарча төп чәчәк утырталар.

Йортларын тыштан күрдек — эчтәге квартиралары ниндиләр, көнкүрешләре ничек икән?

Үзебезне кызыксындырган шундый, көндәлек тормышка бәйләнешле сораулар белән без, Горпищенко урамындагы 11 йортлар идарәсенә бардык. Анда безнә Петр Алексеевич Ничаев үзенең хуҗалыгы һәм эшләре белән таныштырды. Чыннан да, кая гына карама, тәзеклек һәм пөхтәлек күзгә бәрелеп тора. Бишәр катлы йортларның декоратив төсләрдәге фасадлары күңелгә ятышлылар. Балконнары үрмә гөлләр һәм чәчәкләр белән тулы. Ә кер киптерү һәм балалар уйнату өчен ишек алларында махсус урыннар җайланган. Йорт идарәләре яшеллеккә күмелгән, чиста итеп себерелгән.

Безгә балалар бакчасы — «Василек» бик ошады. Җәмәгатьчелек тәртибендә оештырылган бу бакчада 60 бала тәрбияләнә. Аның урынын, бүлмәләрен йортлар идарәсе тапкан, җиһазларын якындагы завод бүләк иткән, ә аш-суны фабрика-кухня пешереп китерә. Ата-аналар баланы тәрбияләү өчен айга 15 сум акча түлиләр. Бакчаның мөдире, врачы һәм сестрасы, төп эшләре өстенә, үз теләкләре белән бирегә килеп эшлиләр. Штатта фәкать 2 тәрбияче һәм 2 җыештыручы гына тотыла. Бу бакчадагы тәрбия эшләренең нәтиҗәләреннән балалар үзләре дә һәм ата-аналар да бик канәгать.

Шул ук йортлар идарәсе каршындагы балалар клубы — «Андромер», чын мәгънәсе белән, мәктәптән тыш тәрбия эшләренең штабы булып әверелгән. Аның бай җиһазландырылган китапханәсе, түгәрәк занятиеләре үткәрү өчен бүлмәләре һәм зур



Нахимов проспекты. Уңда Луначарский исемендәге драма театры бинасы.

залы бар. Анда укытучылар һәм тәрбиячеләр җәмәгатьчелек тәртибендә занятиеләр, уеннар һәм спорт ярышлары үткәрәләр. Шул ук клуб каршында футбол командасы, тимурчылар дружинасы һәм «яшел патруль» штаблары оештырылган.

Петр Алексеевич үз идарәсенә карый торган йортларда яшәүчеләр турында аеруча җылылык белән сөйләде. Йорт комитетлары һәм күршеләр һәр семьяның хәле белән якыннан кызыксынып торалар, семья бәхетенә бергәләп куаналар, авырлык килсә, булышалар. Эшче Злобинның хатыны авырып больницага эләгә. Өйдә — берсеннән-берсе яшь өч бала. Күршедә яшәүче ике комсомолка, Надя белән Люба, алмашлап балаларны карыйлар, квартираны юалар һәм җыештыралар.

Картлар һәм инвалидларга булышу, авыруларны тәрбияләү, продуктлар һәм дарулар алып кайтып бирү, өйгә врач чакыру һәм башка шуның кебек эшләрне дә игелекле эшләр бюролары башкара. Аның йөздән артык өстәле бар. Алар бәйрәм кичәләре үткәрү, туй ясау, аш-су әзерләү буенча да киңәшләр бирәләр, әгәр кирәк булса, ярдәм дә күрсәтәләр.

Ательеларда, цехларда производство процесслары эреләндереп, узәкләштереп корылган. Уннарча мастерлар бердәм технология контроле астында тигез ритм белән эшлиләр. Сатучысыз магазиннар, буфетлар, прокат пунктлары, пассажирларның үз иркенә куелган шәһәр транспорты, контрольсез театрлар, кешеләрнең үз намусына тапшырылган башка шундый яңача тәртипләр гадәткә керә.

Севастополь — культурасы белән дә дан казанган шәһәр. Бирегә культура учреждениеләренең киң челтәре: клублар, музейлар, театрлар һәм китапханәләр — барысы да халыкның үсә барган эстетик һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен тырышалар. Шәһәрдә китапханәләрнең саны гына да 68 гә тула. Алар хәзинәсендәге

миллион томнан артык китапны 90 мең кеше кулдан-кулга йөртеп укый. Шәхси китапханәләрнең эше аеруча игътибарга лаеклы. Запастагы офицер П. Саенко, шушында оборона сугышларында контужен булып, гомерлеккә сәламәтлеген югалткан кеше. Явыз чир аны вакыт-вакыт түшәккә үк егып сала. Озын көннәр, еллар буена өйдән чыкмыйча, бер мәгънәсезгә шулай ятырга ул теләми һәм үзенең өендә китапханә филиалы ача. Акрынлап укучылар да килә башлый, китапханәнең үзенең активы һәм дуслары барлыкка килә. Хәзер шәһәрдә җәмәгатьчелек тәртибендә оешкан әнә шундый 17 китапханә бар.

Севастопольчеләр музыканы яраталар. Әллә диңгез шавы җыр булып яңгыраганга, әллә йөрәктәге дәртле хисләр диңгездәй ташып торганга, клубларда, мәйданнарда, корабльләрдә — һәркайда да күңел күтәренкелеге хакимлек итә, барысы да җырлыйлар. Егерменче елларда ук бу шәһәр музыкаль культура үзәге булып әверелә. Хәзер бирендә дүрт махсус мәктәп квалификацияле музыкантлар әзерли, Кара диңгез флотының җыр-бию ансамбле — бөтен илгә танылган коллектив — үзенең концерт чыгышларын шушыннан башлый. Традицион бәйрәмнәрдә һәм кичәләрдә үзешчән сәнгать коллективларының чыгышлары тантана үзәгендә булалар. Ә оркестрның нинди генә төрләре юк: симфоник, эстрада, халык инструментлары, кыллы һәм тынлы музыка кораллары оркестрлары — барысын бергә кушып санаганда 50 гә якын оркестр!

Көннәрнең берсендә безнең делегацияне шәһәр Советы Башкарма комитеты председателе Павел Макарович Стенковой кабул итте. Сүз Севастополь кешеләренең патриотик башлангычы турында барды.

— Коммунистларча яшәргә! Бу лозунгны тормыш үзе куйды,— диде шәһәр башлыгы.— Алдынгы эшчеләр, без аларны маяклар дип атыйбыз, аны күтәреп чыктылар: «Легендар Севастопольнең данын тагын да арттырыйк, аны коммунистик хезмәт, үрнәк җәмәгать тәртибе һәм югары культуралы шәһәр итик»,— диделәр. Бу хәрәкәт бик тиз арада масса төсе алды, аңа яңадан-яңа коллективлар кушылды. Шулай итеп бу хәрәкәт бөтен халык көрәшенә әверелде. Без шундый гигант эшләргә керешкәндә, үзебезнең эчке мөмкинлекләребездән чыгып эш итәргә, беренче чиратта, кешеләребезнең иҗади инициативасына, киң җәмәгатьчелекнең актив булышлыгына таянырга исәп тоттык. һәм ялгышмадык. Бу хәрәкәтнең җимешләре һәркайда ачык күренә...

## Туган ягыбызның даны балкыр

Писмән һәм Чатыр таулары башларыннан Сапун тау күренми. Ләкин аралар ерак булса да, йөрәкләр якын, омтылышлар уртак, теләкләр бер.

Анда да таулар, бездә дә таулар. Бездәге таулар, дулкыннар рәвешендә күтәрелә барып, Урал сыртына тоташалар. Бездә диңгез юк, аның караны, киң басулар, дулкынланып торган иген басулары бер дә диңгездән ким түгел. Аны иңләп, коры җир корабльләре — комбайннар мул уңыш яуларга, штурмга чыгалар.

Билгеле, безнең якларда һәйкәлләр ул кадәр үк күп түгел. Әмма бездә нефть вышкалары күп. Алар гүя җир тирәнлегеннән үсеп чыкканнар да бөтен дөньяны иңләп алганнар. Товар паркларының гигант баклары, нефть эшкәртү корылмалары, насос һәм компрессор станцияләре җирле ландшафт фонында аерылып торалар. Болар зур нефть ягының үзенә генә хас булган тантаналы картинасын ташкил итәләр. Алар — хыялдан чынбарлыкка әверелгән индустриянең терәк пунктлары, бирендәге кайнап торган тормышның бастионнары!

Татарстанның эшчеләр сыйныфына куәтле нефтьчеләр коллективы өстәлде. Буровойларда, промысел мәйданнарында кара алтын өчен көрәштә беренче ударниклар — хезмәт геройлары үсеп чыктылар. Санасаң, күпләр алар — Севастополь геройлары кебек үк исемнәре бөтен илгә танылган, алтын йолдызлы кешеләр. Нефть өчен көрәштә коммунистик хезмәт ударникларының һәм коллективларының сафлары үскәннән-үсә бара. Бу мактаулы исемне яулап алуга керешкән «Әлмәтнефть» промыселлар идарәсенең эшче-хезмәткәрләре бишьеллыкны срогыннан элек үтәү өчен, илебезнең барлык нефтьчеләренә мөрәҗәгать иттеләр һәм бөтенсоюз социалистик ярышын башлап җибәрделәр.

Ягыбызның географик картасы үзгәрде, таулар ышыгындагы үзәнлекләрдә яңа промышленность һәм культура үзәкләре — Әлмәт, Лениногорск шәһәрләре, Азнакай, Актүбә кебек эшчеләр поселоклары барлыкка килделәр. Иске Бөгелмә танымаслык булып яңарды. Хәзерге заман стилендәге төзелешләрнең тулы комплектыннан торган бу торак пунктлары елдан-ел үсә, төзекләнә һәм матурлана баралар. Аларның һәркайсының инде, кыска гына булса да, тарихы, танылган кешеләре бар һәм үзләренә хас традицияләре дә формалашып килә.

Яңа шәһәрләр, яңа кешеләр, яңача — коммунистларча яшәү! Хәзер бу патриотик лозунг кешеләрнең көндәлек тормышына кереп бара. Урыны белән инде бездә дә, Севастопольдәге кебек, үрнәк җәмәгать тәртибе һәм югары культура өчен көрәшне конкрет фактларда күрергә була. Нефтьчеләрнең башкаласы булган Әлмәттә генә дә меңләгән кешеләр өмәләргә чыгып, шәһәрне төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләрендә катнашалар, спорт мәйданнарын җиһазландыралар. Дружиначылар хәрәкәте дә торган саен активлаша бара.

Нефтькә бай Әлкәй, Сөләй, Ташлыяр һәм Чишмә мәйданнары уртасында үзенең промыселлар базасы белән эшчеләр поселогы — Җәлил үсеп чыкты. Биредә промыселлар идарәсе эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм механизаторлар яшиләр. Идарәнең җитәкчеләре, аерым алганда, идарә начальнигы Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, танылган нефтьче Галимҗан Әхмәдиев, поселокны тагын да үстерү һәм анда яшәүчеләргә культуралы көнкүреш шартлары тудыру буенча ныклы кайгыртучанлык күрсәтәләр. Биредә Культура сарае һәм башка көнкүреш объектлары төзү эшләре генераль планда каралган масштаб белән дәвам иттерелә. Урындагы эчке мөмкинлекләрдән чыгып, музыка мәктәбе, су бассейны, стадион һәм спорт корылмалары комплексы төзелде, табигый урман эчендә культура һәм ял паркы җиһазландырыла. Яшәүчеләрнең актив катнашы белән, Севастополь кешеләре үрнәгендә, поселокны тагын да төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләре алып барыла.

Шулай да туган якларда коммунистик тәртипләр урнаштыру буенча севастопольчеләр үрнәгендә эшлисе эшләр күп әле, тормышыбызны хәзерге заман культурасына тиң итеп бизәргә, бакчалар һәм чәчәкләр үстерергә өйрәнәсебез бар. Бу турыда кызыксынуны, кайгыртучанлыкны иң әүвәл үзебездән, кешеләребез арасындагы мөнәсәбәтләрдән башларга һәм, бөтен халык эше итеп, җәмгыять интереслары югарылыгына күтәрергә кирәк. Һәркем үз коллективының актив члены, үз шәһәренең патриоты да булуын конкрет эшләр белән күрсәтергә тиеш.

Легендар Севастопольнең данлы традицияләре безнең якларга да күчәрләр. Республикабызның нефть индустриясе краенда коммунистик хезмәт, үрнәк җәмәгать тәртибе һәм югары культура урнаштырырбыз.

**Кәшиф ЗАРИПОВ.**

Әнәс Камал

# АНЫ ҮЗ ЮЛЫННАН ТАЙПЫЛДЫРМАКЧЫЛАР ИДЕ

*Галиәсгар Камал турында истәлекләр китабыннан*



Иске бистәнең чүплек башыннан Кабан күленә таба барган урамын Евангелистовская [1], шуңа янәшә яткан урамны Сенная [2], һәм Печән базары мәчете янында шул урамнарны аркылыга кискән урамны Московская [3] дип йөртәләр иде.

Нәкъ менә шул урамнар чатында, нәкъ менә шул мәчет янында мәшһүр «көфер почмагы» — атаклы Печән базарының кыл уртасы.

Нишләп «көфер почмагы» дип атаганнар соң ул чатлыкны? Чөнки бу базар чатына җыен эшлексез, җыен гайбәтче — барлык җәяүле сәүдәгәрләр җыйнала торган булган. Бу — алыш-биреш итә торган, сәүдә биржасы сыман урын. Монда җыйналучыларның күбесе ишанга кул биргән мөритләр. Алар узган-барган артыннан сүгенеп, эт шикелле өреп калучылар — телләре авызларына сыймаучылар.

Болар костюм кигән, ак яка куйган, галстук таккан кешеләр артыннан:

— Ләгънәт камыты кигән! Инде тавык аягы гына тагасың калган! Дөньядан язган җәдит, йөзең кара булгыры! — дип акыралар. Алар өчен һәрбер эшләпә кигән кеше — «кяфер!»; ирләр алдында йөзен капларга өлгермәгән хатын-кыз — «эштән чыккан, оятсыз!»; чәче җитә төшкән, мыегын «сөннәтчә» кыска кырыкмаган шәкерт «шифыр», күмер карагы!», тагын әллә кем, тагын әллә нинди гөнаһлар кылган дәһри...

Алар гел юкка бәйләнергә, сугышырга-кыйнашырга гына торалар. Чөнки алар уенча русча белү дә, газит-журнал уку да, театрга, «томанный картинә» карарга бару да, хәтта гармун уйнау, җырлау, рәсем ясау да зур гаеп. Алай гына да түгел, гөнаһ!

Алар: «Без кадим, без мөэмин-мөселман!» дип күкрәк сугып мактанучылар. Күз буяу өчен генә мәчеткә кереп, өйлә намазын укыйлар. Әмма алардан һәркайчан тончып беткән сыра, куй мае исе аңкый. Алар, Җамали яки Рамазан «харчүннәгенә» [4] чәйгә керәбез, дигән булып, «пирәшләп» [5] кенә торалар. Чәйнеккә чәй урынына сыра салдырып китертәләр дә, аны чынаякка бүлеп, кайнар чәй эчкәндәгечә, өрә-өрә капкан булып кыланалар. Куен кесәләреннән «мәгъҗүн» өзелми [6]. Шуны борчак кадәр генә кабып, кәнә буе мәлҗерәп, хыялланып йөриләр. Тел астына вак тәмәке салып, шуны каз тизәген чәйнәгәндәй чәйнәп, көнозын ямь-яшел төкерек төкереп йөриләр. Ахшам җитте исә шкаф сыман вак кибетләрен ябып, «Болгар», «Амур» гостиницаларындагы рестораннарга чабалар, аерым номерларга бикләнеп, төннәр буенча типтереләр. Моннан да әшәкерәкләре — «кызыл фонарьлы йортларга» йөрүчеләре дә юк

---

[1] Хәзерге Татарстан урамы.

[2] Хәзерге Париж Коммунасы урамы.

[3] Хәзерге Киров урамы.

[4] Харчевня — чәйханә.

[5] Сыралап.

[6] Әфьюн катнаштырып ясалган исерткеч.

түгел!.. Бу итчеләр, тиречеләр, ончылар һәм шуның ише имгәкләрнең Акком асты, Күл буе, Әҗем, Тегәрҗеп урамнарында үз йортлары, үз мунчалары, үзмал-туарлары һәм хатын, бала-чагалары бар. Хәтта кайберәүләрнең икешәр аты, икешәр сыеры булган кебек, ике-өч хатыннары да бар...

Печән базары мәчетенең ишеге төбендә үк — базарның нәкъ уртасында «кәфер почмагы» атаманнарыннан берсе Мөхәммәтҗан Хафизның кибете. Аңа каршы ук Җиңги Садыйкның мех товарлары кибете тора.

Мөхәммәтҗан Хафиз белән Җиңги Садыйк бик якын әшнәләр. Икесе дә «Гәреч юлы»[1] ягынныкы булып, икесе дә авыл һөнәрчеләренең җилекләрен суырып, башта имана сатып алып, аннан соң ярлы-ябагайга яңа икмәккәчә бурычка биреп тору юлы белән баеган, ахырында Казанга килеп эш җәеп җибәргән кешеләр. Бай дигәчтен дә Мөхәммәтҗан Хафиз Җиңги Садыйк кадәр үк колачын артык киң җәя алмаган. Башта ул авыл арасында җәяүле сатучы — «кырык тартмачы» булса, шәһәргә килгәч, «шкафчы»га гына әйләнгән.

Җиңги Садыйк магазинының ишек өстендә алтын хәрефләр белән: «Торговой дом Садык Хәйбуллин» дип язылган вывеска да бар. Аның магазины белән рәттән Үтәгәннәр, арырак Үтәмешләр, каршы якта Гайнетдин Сабитовлар һәм башкаларның кибетләре, «Борадәрән Кәримовлар мәтбагасы»[2] да, «Васита» китапханәсе дә ерак түгел.

Садыйк Хәйбуллин Казанның зур байларыннан санала. Аның Тегәрҗеп[3] урамында асты таш, өсте агачтан салдырган зур йорты, таш кладовое, зур-зур амбар-курасы, җитмеш төп алмагачлы җиләк-җимеш бакчасы, шундук ак мунчасы һәм түбә очына ай куйдырып эшләткән беседкасына кадәр бар. Һәм «Питырбурда» да, Уфада да шундый ук мех магазиннары бар. Ул үз товарлары белән Мәкәрҗәгә дә, Минзәләгә дә, Эрбет ярминкәсенә дә йөри. «Йөри» дигәч тә, бу эшләрнең берсен дә диярлек ул үзе башкармый. Аларны ул иң ышанычлы туганнарына, дусларына тапшырган. Үзе алар өстеннән күз-колак булып кына тора. Аның чын мәгънәсендә компаньон булган, уртак файдадан тиешенчә өлеш ала торган эш йөртүчеләре дә, шулай ук, дәрәҗәсенә карата гына хезмәт хакы ала торган түбәнге хезмәтчеләре дә җитәрлек.

Ул һәркөнне иртәнге намазгача йокыдан тора, тәһарәт алмас борын ук хуҗалыгын барлап чыга. Эленке-салынкы йөргән хезмәтчеләрне кисәтә. Күбесенчә аш өендә бутала, пешекче хатыннар эшенә тыгыла. «Ит-майны күп тотасыз, утынны күп бетерәсез, чәй-шикәрнең чамасын, икмәкнең кадерен белмисез»,— дип җенләнеп йөри. Әгәр дә аныңча булмаса, икмәк-күмәчне үз кулы белән турый, чәйнеккә чәйне үзе сала. Шикәр ваткычы алып, шикәрне үзе ваклый. «Заманалар авырайды. Әйберләр кыйбатланганнан-кыйбатлана бара, шикәрне тешегезгә сызырып кына эчегез!» — дип үгетли. Менә шундый вакчыллыгы, «хатыншалыгы» өчен аңа «Җиңги Садыйк» кушаматы тагылган.

Өйдәге эшләрен бетергәч, ул, ат җиктереп, кибетенә чыгып китә. Анда кибет арасында йомышка-юлга йөрүче малайларның колакларын бора, кәефенә ошамаган, инде мыек чыгарган, мутрак киенә башлаган приказчикларын тотып яңаклаудан да тайчанмый.

Ул чамадан тыш холыксыз кешеләрнең берсе. Ачулана башласа, кәҗә сакалы туктаусыз селкенә, сарыкныкы шикелле соры күзләре тагын да тона, ач яңаклары тагын да агара, күгәрә... Какча гәүдәсе калтырана. Кибеттә шулай юкка-барга бәйләнеп йөри торгач, өйлә намазының килеп җиткәнен сизми дә кала. Ул кибетенең арткы бүлмәсендә генә тәһарәт ала да чапан-чалма киеп мәчеткә кереп китә. Аннан чыккач, үзенә иш булырлык дәрәҗәле байларга гына ияреп, чәйгә керә: ике тиенлек чәй эчә, өч тиенлек пәрәмәч ашый. Бик карыны ачкан чакларда гына ярты «пуртсы» пылау да китерткәли. Аны чәй ташучы половойлар бер дә яратмыйлар. Чөнки ул җан көеге, бәйләнчек байга бер як белән дә ярап булмый. Чәй катырак кайнаган булса да, пәрәмәчнең көйгәнрәге туры килсә дә, тәлинкәдәге пылауның кашык белән басканда мае агып чыкмаса да, җенләнә, нәзек тавыш белән чинарга тотына, кухняга кире

---

[1] Хәзерге Дөбъяз ягы.

[2] Типография.

[3] Хәзерге Гражданская урамы.

йөгертеп, яңадан китертә. Ә үзе шулкадәр саран, күзеңә кырып салырга сукыр бер тиен чәйлек бирмәс!

Кичен өйгә кайтып кергәч, аның бөтен эше залга бикләнеп акча санау. Бу эшкә ул олы улын да, кечесен дә катнаштырмый. Беренчесе, инде өйләнгән кеше булса да, бик аңгыра, икенчесе — буйга җиткән бик зиһенле егет, ләкин әтисен төпсез галушка утыртырга гына чамалап йөрүче мут, купшының берсе. Акча санаганда аның янына доверенные гына керә ала.

«Кызыл авыз» приказчикларга ияреп, типтерә-аза башлаган кече малайны күптән башлы-күзле итәргә вакыт җиткән. Ләкин аннан элек апасы Бибигайшәне кияүгә бирәсе, юньле урынга тапшырасы бар. Шуңарчы төпчек малайны өйләндерү кеше арасында килешкән эш саналмый.

Улына кыз табу кыен эш түгел, әмма Бибигайшәне өйдән озату мәсьәләсе күп төрле сәбәпләргә бәйләнгән. Беренчедән, Бибигайшә, теска-биткә чибәр, акыллы булса да, зәгыйфь гәүдәле. Икенчедән, аны кияүгә алырга теләүчеләр күп булса да, алар аның үзенә түгел, зур приданнарына кызыгып кына яучылыйлар. Өстәвенә, бу яучылаучыларның күбесе сәүдә эшләре чыгырыннан чыккан, бөлә башлаган тол ирләр яки укып-укып та мәгънә чыкмаган карт шәкертләр. Бай егетләренә килсәк, аларны Бибигайшә үзе дә әллә ни өнәми. Чөнки боларның күбесе бозык табигатьле, мәгънәсез адәм имгәкләре. Андый йорт тотмас аяклы казалар белән дөнья корып булмасын Садыйк хаҗи үзе дә, кызы Гайшә дә бик яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә, Бибигайшә очраган бер кешегә кияүгә чыгарга ашыкмый. Һәм үзенә кияүне ул ярлырак, ләкин аңлы, булдыклы шәкертләр арасыннан эзләргә карар кыла.

Мәдрәсәдә, бай кияве булып алып, муллалыкка үрләргә, хәтта бай булса, тол карчыкларга өйләнергә дә әзер торучы пишкадәмнәр[1] аз түгел иде түгелен!.. Алар, Гайшә күңеленә коткы салырга теләп, озын-озын гыйшык хатларын да җибәргәлиләр. Ләкин Гайшә алданмый, аның яшь йөрәге нәрсәгәдер өметләнә, кемнедер эзләнә иде... Ниһаять, ул үзенең күңел кошын очратә!.. Бу егет әтисе Садыйк байда эшләүче оста камчатчы Галиәкбәрнең олы улы, Мөхәммәдия мәдрәсәсенең галиясендә[2], соңгы сыйныфта укучы Галиәсгар була...

Беренче мәртәбә ул аны үзләрендә уздырылган аш-су мәҗлесендә күрә һәм бер күз төшерү белән үк гашыйк була. Гайшә сайлаган егет шәкертләр арасында иң матуры, иң акыллысы, буйга зур булмаса да, зифа гәүдәлесе. Зур йомры башлы, киң маңгайлы, тирән һәм уйчан карашлы егет иде ул. Бу егетнең җәмәгать сәкесендә, мәдрәсәдә иске тәртипләргә каршы коткы таратучылар арасында булуы, ниндидер көлке, яшерен газета чыгаруда катнашканы өчен, күп кенә шелтәләр алганын ишетсә дә, Гайшә, аларны гаепкә санамады, егет кешедә андый гына гаепләр булмыйммы соң, дип кул гына селтәде. Күңеле кемгә төшкәнен әнисе Бибикамалдан да яшермичә:

— Әнием, бәгырем, сезнең мине бәхетле итәргә теләвегезгә һич тә шикләнмим... Зинһар, хәстәренә керешегез, мине әнә шул камчатчыгызның улына кияүгә бирегез! — дип әйтеп салды. Әйтеп кенә дә калмады, елый-елый сорады.

Эш зурга китте. Серне Садыйк хаҗига да ачып салмыйча булдыра алмадылар. Садыйк бай баштарак киреләнгән булып маташты: «Тапкансыз икән егет, мөфти хәзрәткә, дамуллабызга каршы сүз каткан, җәдитләр, дәһриләр белән аралаша башлаган кызыл авызлардан башкалар да бетмәгәндер әле».— дигән булды. Ләкин шуны да әйтергә кирәк, Садыйк бай Галиәсгарне күптән ошатып йөри һәм моның сәбәбе дә бар иде.

Хаҗи Пелэтән[3] урамы башында, ике бистә арасында иске зират өстенә мәчет салдырырга керешкән һәм ул тиздән өлгерергә тиеш иде. Шуңа күрә, бу мәчеткә кем мулла булса, шул кеше Бибигайшәнең кияве дә булырга тиеш. Садыйк хаҗи фикеренчә, Галиәсгарнең мулла булырлыгы да, кияү булырлыгы да бик бар.

Дөрес, Галиәсгарнең хөр фикерлелеге, үз хәлфәләренә, дамуллага һәм байларга буйсынмавы, мәдрәсәдә төрле гаугаларга сәбәпче булуы, ниндидер китаплар яза башлавы турында хаҗи ишеткәләгән иде. «Ләкин мондый заманда бөтенләй үк саф,

---

[1] Мәдрәсәне күптән тәмамлап, муллалык көтеп ятучы карт шәкертләр.

[2] Шул заманның югары мәктәбе.

[3] Хәзерге Салих Сәйдәшев урамы.

судан пакь, сөттән ак булган кияүне каян тапмак кирәк?» — дип уйлады ул. «Башына тай типмәгән булса, өйләнгәч, ипкә керер әле. Байлык кадерен кем белми? Бөтенләй ук башсыз булмаса, ризыкка арт куймас. Атасы Галиәкбәр дә бик диндар, бик уңган кеше, шаять ул да үз упына үзе хуҗа була алыр. Бер йөгәнләп алсам, мин дә коры тотармын. Ничек кенә булмасын, аллага тәвәккәлләп, шушы егетне кулдан ычкындырмаска кирәк!» — диде ул. Һәм кияүне аулау юлына керешге.

Бибигайшә дә тик кенә ятмады. Аш-су остасы буларак, бу йортка өнисе Бибикамалга булышырга килеп йөрүче Мәүгыйзә абыстайга аеруча илтифат күрсәтә башлады. Өйгә ул килеп керде исә: «Һай, минем икенче әнием дә бар бит дөньяда! Күрегезче, ул килеп кергәч өйләребез ничек ямьләнде, нурланып китте!» — дип, ермәгән җиргә дә утыртмады.

Шулай итеп, алар бик тиз дуслашып киттеләр. Мәүгыйзә абыстай өенә кайткач та Бибигайшәнең уңганлыкларын сөйләп бетерә алмады, бигрәк тә улы Галиәсгар өйдә чакта мактарга тырышты.

Галиәкбәр улы Галиәсгарның русча укый башлаганын күптән белсә дә, «адрес язарга өйрәнер, ичмасам»,— дип, моңарчы сүз әйтмәгән иде. Хәзер инде аның «театр уеннары» карап йөри башлавын ишеткәч, «бозылып китмәгәе бу бала» дип коты алынды. Аның бөтен уе Галиәсгарне яхшы гына кызга өйләндерү, булдырып булса, мулла итү яки хәлфәлеккә урнаштыру иде. Соңгы вакытларда хуҗаның да бик юмартланып китүе, гомердә булмаганча, ригая күрсәтеп, үзләренә килеп йөрүе, Галиәсгар турында сораштырып торуына Галиәкбәр аптырый башлаган иде. Мәүгыйзәнең дә ирләр алдында Бибигайшәне гел мактаганын ишеткәч, эшнең кая таба барганын сизенеп алды ул. «Җиңги Садыйк юкка гына кыбырсып йөри торган бәндәме? Йөрер, бар! Димәк, ул безнең Галиәсгарне кызы Бибигайшәгә кияү итәргә чамалый? Хәерлегә булсын! Әмма дә күркәм эш булыр иде бу...» — дип хыялланды камчатчы. Шундук Галиәсгарнең тезгенен тарта төшәргә, бик иркенәйтеп йөрмәскә, форсатны кулдан ычкындырмыйча, итәкне җыебрак йөрергә кирәк, дигән карарга килде...

Тора-бара Бибигайшә, Галиәсгардан китаплар соратып алдыру сылтавы белән, аңа хатлар да яза башлады. Галиәсгар да хатка каршы хат язмыйча булдыра алмады. Ләкин шунысы кызык, бай кызы дини китаплардан бигрәк, яңарак чыккан китапларны сората иде. Галиәсгарга бер бай кызының мондый яңа, «дөньяви» әсәрләр белән кызыксынуы гаҗәбрәк тоелды һәм Бибигайшәгә язган җавап хатларында, кызның дөньяга карашын белер өчен, төрле-төрле сораулар язып җибәрде. Кызга шул гына кирәк иде: бер сорауга биш җавап биреп, хатларын озын-озын итеп язарга керешге. Галиәсгарга кызның шулай аңлы булуы бик ошады, һәм ул аннан бер дә яшереп тормыйча, үзенең күңелендә яткан яңа фикерләрен ачып сала башлады, нәкъ менә шул вакытларда гына матбугатта күренә башлаган өр-яңа китапларны кызга күндерде. Шулай итеп, кыз белән егет арасында фикерләр алышу элемтәсе урнашты.

Бай кызы, Галиәсгарнең тулысынча олы җанлы кеше икәнлегенә төшенгәннән соң, үзенең соңгы бер хатында бөтен эч серләрен ачып салмыйча булдыра алмады. Бибигайшәнең озын хатында шундый юллар да бар иде:

«Хөрмәтле Галиәсгар әфәнде!

Сезнең белән безнең арада хатлар аша барган танышлыкның уңай яки кире якка хәл кылыныр вакыты җитте. Сезгә мәгълүм, безнең гаилә белән сезнең гаилә туганлык җепләре белән бәйләнү алдында тора. Ягъни сезнең ризалык белән мин озаклямыйча сезнең хәләл җефетегез булырга тиешле кыз. Яшермичә әйтәм, мин сездән бик разый. Мин сезне күреп тә, укып та бик яхшы беләм. Ләкин сез мине ишетеп кенә беләсез, оят булса да, яшермичә әйтергә кирәк, мин сезне җәлеп итәрлек гүзәл кызлардан түгелмен. Ләкин, минем аңлавымча, сезгә бөек максатларыгызга ирешү өчен, эшләрегездә булышучы, аңлы гомер юлдашы кирәк. Мин сезне аңладым... Мин сезнең тирән фикерләрегез алдында түбәнчелек белән баш иям. Әгәр дә мин үземнең бик үк зур булмаган белемем һәм тәҗрибәләрем белән сезнең зур эшләрегезне вөҗүткә ашыруда кечкенә генә ярдәмчегез һәм дустыгыз була алсам, үземне гомерем буена бәхетлеләрдән санар идем!

Сез гали белем алган, аңлы, мәгърифәт хезмәтчесе булып җитештегез. Әгәр дә сез милләтебезнең олуглары алдында үзегезнең яңа карашларыгыз белән ачыктаначык чыксагыз, зур алгышлык эшләячәксез. Бу мәсьәләдә беркадәр «хәйләи шәргыя»

ясавыгызны үтенер идем. Сезгә, форсаттан файдаланып, никах шартларын, һәм минем белән биргә бирелә торган приданнарны кабул иткәндә яхшы булыр. Мәсәлән, придан итеп бирелә торган йортыбызда без аерым, тыныч һәм дә сәгадәтле гомер кичерү мөмкинлеген табачакбыз. Моның өстенә, акчалата бирелә торган дәүләт тә, сезгә матбугат эшен җәеп җибәрүдә файдалы булыр дип уйлыйм. Никахтан, аерым гаилә булып яши башлаганнан соң да сез үз ихтыярыгызны күрсәтергә соңга калмаслыз дип ышанам. Зинһар, гафу итегез, мин сезнең дә, үземнең дә бәхетле булуыбызны телим. Ышаныгыз, мин гомерем буена сезнең тугрылыклы дустыгыз булырмын һәм сезнең хезмәтләрегездә кулымнан килгәнче ярдәмче булырга тырышырмын.

Яңадан бер кат түбәнчелек белән гафу үтенеп, сезнең тормыш юлыгызга ак бәхетләр теләп:

Бибигайшә Садыйк кызы
Хәйбуллина».

* * *

Галиәсгар Камалетдинов мәдрәсәдә укыган чакта ук гаҗәп сәер табигатьле бер егет булган. Ул бер эшкә бирелдеме, гел шуның белән генә мавыгып, дөньясын оныта һәм шул эшен тәгәлләми торып тукталмый икән. Башка шәкертләр кызларга гашыйк булып, кавышу турында хыялланалар. Кабан күле буена, бакыр бабай бакчасына йөриләр. Ә Галиәсгар мондый якка бөтенләй һәвәс түгел, киресенчә, аның үзенә кызлардан гыйшык хатлары килә. Ләкин ул аларның берсенә дә җавап язмый диярлек. Язса да ул җавап күңел суындыра торган, салкын акыл белән язылган хат кына була. Ләкин мәдрәсәдә мәхәббәт хатларын аның кебек оста яза белүче булмаганга, барлык гашыйк егетләр аңа киләләр. Нишләптер ул, кешеләр мәхәббәтен яхшы аңлый, аларның эченә тирәнтен керә белә, ә үзенә килсәң, бу мәсьәләдә ул йомыкый.

Үзен Бибигайшәгә өйләндерергә йөрүләрен белгәч тә, артык борчылмый. Бибигайшәнең буе-сыны, төсе бите белән дә артык кызыксынмый. Булачак кәләшенең карточкасын китереп күрсәткән яучы карчыкка ул:

— Карасана, Мәмдуха абыстай, бу кыз чибәр генә күренә бит? — дип елмаеп кына куя.— Бу яктан сүз юк, адәм фәрештә булмас. Акылы ничек, акылы? Мине сайлап, дус күреп, тапканыма риза булып торырлыкмы? Син миңа шунысын әйт, Мәмдуха абыстай. Югыйсә мин ярлы гына егет, ул мине гомерем буена табалап, кәһәрләп тормасмы?

— Әй улым, куй юк сүзеңне! Син дигән сулуы юк. Әйтсәм әйтим инде, ул сиңа күптән гашыйк булган!.. «Күңелем анда гына, Галиәсгардан бүтәннең, хур егете булса да, кирәге юк», кына, ди, белдеңме, Галиәсгар. Бәхетең бар икән, Казанда бер дигән кызга өйләнәсең бит. Приданнары, бирнәләре генә ни тора. Асты таш, өсте агач ике катлы йорт, банкта кыз исеменә салынган ун мең тәңкә акча, туй итәргә бер мең...— дип тезә Мәмдуха карчык.

Галиәкбәр мулланың Садыйк хаҗи кызына өйләнүе турындагы хәбәр дамулла Галимҗан хәзрәткә дә ирешә. Бер җомгада Садыйк хаҗи белән Галиәкбәрне очратып:

— Бик күркәм эш башлагансыз, бик мәгъкуль, миннән хәер-фатиха! — ди. Шундук: — Ул егетне вакытында кулга алуыгыз яхшы булган. Югыйсә, теге җәдитләргә, кызыл авызларга ияреп китеп, юлдан язуы да бик ихтимал иде...— дип өсти.

Озак та үтми, зур итеп туй ясала. Егет кыз өендә айдан артык кияү булып ята. Бу арада Садыйк байның кызына придан итеп алынган Зур Мещан[1] урамындагы йорты да өлгерә. Гомеренә юньле квартир күрмәгән Галиәкбәр абзый гаиләсе шул йортның аскы катына күчеп тора башлый.

Кияү белән яшь бикәч яшисе югары өйдә дә бөтен нәрсә әзер. Яңа квартирада яңа җиһаз! Вена урындыклары, кызыл агачтан савыт-саба шкафы, комод, сугулы француз стена сәгате, баганалы, түшәмгә кадәр күтәрелгән, бимский пыяладан ясалган көзге, идәндә Иран паласлары, тәрәзәләрдә кисә пәрдәләр, ишекләрдә хәтфә

[1] Хәзерге Нариман урамы, йорт № 48.

чаршаулар һәм башкалар. Кухняда да бөтен кирәк-ярак җитешле. Бер чиләк су сыешлы Тула самовары үзе генә ни тора! Шунысы гаҗәп, ике кешелек гаилә өчен самоварның шундый зуры нигә кирәк булды икән? Бу инде Җиңги Садыйкның юмартлыгын күрсәтү өчен, юри шулай эшләнгәндер. Янәсе, менә мин нинди юмарт, мин кызымнан, киявемнән җанымны да кызганмыйм, имеш!

Ләкин Галиәсгар Камалетдинов, өйдәге артык купшы җиһазларга бик шаккатмый. Ул бу өйгә күченеп килүе белән өч бүлмәне карап чыгып, аларга канәгатьләнсә дә:

— Ә кайда язу өстәле? Кайда китап шкафы? — дип сораганын сизми дә кала. Үзенә аерым бүлмә булдыру, язу өстәле, китап шкафы алу аның күптәнге хыялы була. Ләкин кияүенең язучы булуы белән бөтенләй кызыксынмаган кара бай, андый нәрсәләр турында кайгыртуны башына да китерә алмаган икән.

Бибигайшә сөекле Галиәсгаренең кәефе кырылганны күреп:

— Өстәле дә, шкафы да булыр, Галиәсгар, бер дә уйлама. Үзебез ничек телибез, шулай яшәрбез! — ди.

Озак та үтми, Садыйк хаҗи салдыра торган мәчет эшләнеп тә бетә, Галиәсгарне муллалыкка кыстый башлыйлар. Ләкин хөр фикерләр белән яши башлаган Галиәсгар бу эштән кискен рәвештә баш тарта һәм: «Әгәр дә сез мине мондый булмастай эшкә кыстый башласагыз, гафу итәсез. Мин сезнең мондый шарт куясыгызны белмәгән идем. Шуңа күрә, үзем теләгәнчә яшәү өчен, укуымны дәвам итү өчен, барысыннан да ваз кичәргә мәҗбүрмен!» — дип куркыта. Аның мондый катгый белдерүеннән каушап калган атасы белән каенатасы, нишләргә белмичә, барлык кардәш-ыругны җыеп, зур гаилә киңәшмәсе уздыралар. Мондый хурлыклы гауганы халык арасында фаш итмәс өчен, Галиәсгарнең соңгы теләген һәм ачык җавабын сорыйлар.

Галиәсгар горур һәм нык тора:

— ...Сез минем мулла булырга теләгем юклыкны күптән белә идегез. Ачык әйтим, минем халык җилкәсендә соры корт булып яшисем килми. Һәм мин моны булдыра да алмыйм. Намусым кушмый. Шуңа күрә сез мине ул эшкә кыстамагыз. Миңа үзем теләгәнчә эшләп, үземчә яшәргә ирек бирегез! — ди ул.

— Теләгең нәрсә соң синең? — диләр тегеләр.

— Нәрсә булсын, халыкка аң-белем тарату, караңгы дөньяны якты итеп кору...

— Нәрсә, нәрсә?! Син дөнья болгатмакчы, патшага каршы бармакчы буласыңмы, оятсыз?

— Юк,— ди Галиәсгар,— мин андый дәрәҗәдәге кечкә ия кеше түгел! Минем теләк әле бик кечкенәдә: мин китап кибете ачам! — дип җавап бирә.

«Кибет» сүзен ишеткәч, үзләре дә шул кәсеп белән көн күргән агай-эненең бераз ярсулары басыла. Һәм, «кияүне» башкага күндереп булмасын аңлаганнан соң, аның бу эшенә ризалык биреп киңәшмәдән таралалар.

Г. Камал, халыкны агарту эшенә булышлык итү теләге белән, 1901 нче елда «Мәгариф көтепханәсе» исемендә китаплар сату һәм бастыру ширкәте оештыра. «Йолдыз» газетасының махсус хәбәрчесе сыйфатында Төркиягә — Истамбулга китә. Аннан бик күп төрекчә әдәби китаплар һәм башка товарлар алып кайта.

Галиәкбәр белән Садыйк хаҗи бу кибет дин юлында хезмәт итәр, анда иман шартлары, корьән тәфсилләре сатылыр, дип өметләнсәләр дә, ялгышалар. «Мәгариф көтепханәсе» бөтенләй яңача эш итә. Анда, иң беренче чиратта, шул замандагы матур әдәбият китаплары һәм язу-канцелярия товарлары сатыла башлый.

Шулай итеп, Галиәсгар Камал, дошманнарына бирешмичә, үзенең киләчәк әдәби эшләренә юл сала һәм Җиңги Садыйкның кул астыннан чыгып, үзе дигәнчә көн күрә башлый.

# ЯКТЫ ИСТӘЛЕГЕ КҮҢЕЛ ТҮРЕНДӘ

**Ярослав Галанның үтерелүенә 20 ел тулу уңае белән**

1949 елның 24 октябрь иртәсе. Украина халкының талантлы әдибе Ярослав Галан үзенең Львов шәһәрендәге эш бүлмәсендә «Азат кешенең бөеклеге» исемле мәкаләсен төгәлләп утыра. Тик соңгы ноктаны куярга өлгерми: империализм ялчыларына сатылган ерткыч бандитлар аны балта белән чабып үтерәләр...

Шул фаҗигале вакыйгалардан бирле нәкъ егерме ел гомер узды. Аның хезмәт кешеләрен ирек һәм бәхет өчен көрәшкә чакырып язган ялкынлы мәкалә һәм памфлетлары, илебез чикләрен атлап чыгып, еракларга таралды. Ярослав Галанны хәзер бөтен дөнья халыклары тәкъдир итә. Бу кадәресен барыбыз да беләбез. Әмма аның 1941 ел ахырларында һәм 1942 ел башларында Казанда яшәвен, гади генә татар кешеләрендә квартирада торуын, ихтимал, һәркем дә белмидер әле.

...Аннан бирле күп еллар узган, күп сулар аккан. Шулай да Казандагы промтовар кибетләренең берсендә директор булып эшләүче Нурмөхәммәт ага Кәримов ул көннәрне яхшы хәтерли һәм сагынып искә төшерә:

— Ярослав Александрович белән бер гаилә кешеләредәй килешеп һәм бик тату яшәдек. Гаҗәп мөлаем һәм әдәпле, тыйнак һәм кечелекле бер кеше иде. Дөресен әйтергә кирәк, андый ук әйбәт кешеләр сирәк очраучан. Квартирабыз бәләкәй генә ике бүлмәдән гыйбарәт иде. Бүлмәләрнең берсендә әнием белән ике кыз туганым яшәде, икенчесендә — Галан белән мин. Эш мәсьәләсенә килгәндә, ныклы бер тәртипкә күнеккән кеше булуы белән аерылып тора иде. Бер тотындымы, баш-аягы белән дигәндәй, эшкә чума: игътибарын чит нәрсәләргә юнәлтмәс, юк-барга бүленмәс...

Н. Кәримов аның вакытлыча фашистлар аяк астында калган туган якларын бик сагынуы, фронтка китәргә ашкынып яшәве турында сөйли. Хәер, бу кадәресе әдипнең көндәлек дәфтәрендә сакланып калган язмалар белән дә раслана:

> *«1941 елның 20 октябре. Казан. Армиягә җибәрүләрен сорап, гариза яздым. Дөрес, элеккө сәламәтлек юк инде югын, аяк бик сызлый. Ләкин болай башкалар кан койганны, башкалар җәфа чиккәнне генә карап торсам, җиңүдән соң ни йөз белән яшәрмен? Инде сугыш кырларында уларга туры килә икән, кешеләр күңелендә якты истәлегем калыр һәм, Стрый паркы (Львов шәһәрендәге парк — И. С.) шавына кушылып, минем дә язылып бетмәгән калган җырларым яңгырар».*

...Нурмөхәммәт ага сөйләгәннәрне аның сеңелесе Җәмилә ханым Кәримова тагын да ачыклый һәм тулыландыра төшә:

«Килгән шәпләргә Галан гаять арык һәм ябык чырайлы иде...

Бервакыт Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә» романын алып кайтып биргәнемне хәтерлим. Үзенең сөйләвенә караганда, ул аңа үзенең яза торган мәкаләләренең берсенә өзекләр сайлап алу өчен кирәк булган икән. Гел генә татар халкының кунакчыллыгы һәм сугышта күрсәткән батырлыклары, халыклар дуслыгы хакында берәр кызыклы әсәр язам әле дип, җыенып-вәгъдә итеп йөрде...»

Ул заманнарда Кәримовлар белән күрше квартирада яшәгән Эмма Моисеевна Айзенман да исән булып чыкты. Элеккечә үк ул Ульяновлар урамында. Ярослав Галан торган өлеге йортта ук яши икән. Шактый олы яшьләрдә булуына карамастан, сугыш елларын яхшы хәтерли. Галанның бәхете бар икән, юмарт һәм әйбәт күңелле кешеләргә туры килде, ди. Үзләре дә кыен шартларда яшәсәләр һәм дүрт җанга нибары 19 квадрат метр зурлыгындагы квартирада торсалар да, Кәримовлар аңа эшләү өчен уңай шартлар тудырырга тырыштылар. Бай гына китапханәләре бар иде, әдип кешегә анысы да бик ярап куйды. Нурмөхәммәт аны үзе белән Академия театрына татарча спектакльләр карарга да алып йөри иде, ди Айзенман.

Эмма Моисеевнадан, мөмкин булса, Галан торган бүлмәне күрсәтүен сорыйм. Кәримовлар күчеп киткәч, квартирны икегә бүлгәннәр. Шунлыктан элекке обстановка шактый үзгәргән. Кухня тәрәзәсе аша тонык яктылык төшкән тар гына коридорга үтәбез.

— Кухня элек тә шушында идеме? — дип сорыйм.

— Әйе, шушында иде. Менә шушы ишектән Галан кухня аша үзе торган бүлмәгә керел-чыгып йөри иде.

Каяндыр ачкыч табып, Кәримовлар яшәгән квартираны ача. Ак буяулы зур ишектән эчкә бүлмәгә узабыз. Өч тәрәзәсе дә кояш батышына караган җыйнак кына бүлмә. Эмма Моисеевна сөйли-аңлата тора:

— Менә монда,— ди ул,— ишектән керүгә сулъякка күрсәтеп,— Нурмөхәммәтнең караваты тора иде. Менә бу ике тәрәзә каршында — язу өстәле. Галан һәрвакыт шул өстәл янында эшләп утырыр иде. Өстәлдән аз гына сулдарак — аның ятагы.

— Бүлмәдә башка бернәрсә дә юк идеме?

— Әйе, оныта язганмын. Менә бу стенага күрше бүлмәгә керә торган ишек уелган иде. Кәримовлар китеп, квартира икегә бүленгәч, аны бикләделәр. Шул ишекнең уң ягында, менә бу төштәрәк борынгы комод, сулъягында китаплар белән тулы этажерка тора иде. Галан әнә шул этажеркадагы китаплар белән файдаланды инде...

Әйтәсе дә юк, бик эшчән, тырыш һәм мөлаем бер кеше иде, мәрхүм...

...Украина халкының талантлы улы Ярослав Галан безнең шәһәребездә нибары бернечә ай яши. Ә Казан кешеләре, күрәсез, аның якты истәлеген әле бүген дә кадерләп саклыйлар.

**И. СИБГАТУЛЛИН.**

# *ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...*

**Фатих Хөсни**

# ҮЗЕМНЕ ЮГАЛТТЫМ!

хикәя

Каравыл кычкырырлык әллә ни юк, болай кызык өчен генә кычкырам. Хәтта, мин әйтер идем, ярыйсы нәрсә ул бакча дигәннәре. Җәйге эсселәрдә изүеңне чишеп верандада яңа пешкән җиләк салып чәй эчүләре үзе генә дә ни тора. Әгәр дә инде, өлгерлегең житеп, завод материалыннан, я башка шундый берәр төзелештән отход исәбенә «законлаштырып» алган пыяла һәм бетоннан ике катлап, мансардалар чыгарып вилла да ясатып җибәрсәң, аның верандасында — югарыгы катта чәй эчеп утырулары шәпнең аргы ягыдыр. Җирдә йөрүче вак-төяк кешеләрнең башларына төкер дә утыр чия төшләреңне. Бусын инде — идеаль күзлектән карап әйтәм.

Минем үземнең, мәсәлән, алай икенче катка ук үрләгәнем юк, шулай да Обсерваториядәге бакчамның файдасын күрмим түгел. Чәчрәп торган беренче файдасы шул: җәйгә чыксам, бакча белән шәһәр арасында чабулап йөреп, кулга каләм ала алмыйм.

Башка файдалары да тими түгел, алары әкренләп үз чираты белән. Хәзергә сүз минем турыда бармый, бик күп, бик күп башка кешеләр турында бара, шул беррәттән минем ике баҗа турында һәм, урын калса, чак кына минем хатын турында барыр. Кыскасы, шәшындык лабаса шул шәһәр арты бакчаларыбыз белән! Юлда эзе дә күренми башлаган, төшкән бере себереп алынып, әлеге шул бакчаларыбызга китә торган ат тизәге белән ант итеп әйтәм бу сүзләрне.

Бик еракка китмичә, иң элек уртанчы баҗадан башлыйм. Пожарный командада эшли бу. Бер тәүлек дежур торып чыккач, ике буш көнен кайдадыр сдельно эшләп, аз-маз акча төшерә. Алай итмәс иде, юрган кыска. Башка тартса, аяк шыр. Җитмәсә тагын хатынының башы чирдән чыкмый. Балалар бәләкәй. Кыскасы, кайда инде моның бакчада эшләр кешесе һәм вакыты. Шул булып шул килгән беркөнне.

— Баҗай җаным,— ди бу, тәмле телләнеп,— кер хәлемә, биреп тор ике йөз сум. Ике йөз сум үземнеке бар, дүрт йөзгә бер җирдә чиртергә тора, өе белән биш еллык бакча, панимаешь.

Әйтерсең, баҗасы банкир, сейфларны шыңгырдатып кына ачасы да... Шулай да күңелнең йомшак чагына туры килде, алдын-артын

уйлыйм. Бура төпләрен (мин акчаны бурада тотам, караклар ишетә күрмәсен тагы!) кырып-себереп җыйганда, мәйтәм... Шул ук вакытта, ничек тә булса бирми калу ягын да уйлап, шулай ук бик тәмле тел-ләнеп:

— Соң анысын алуын алырсың да,— мин әйтәм. Өлкән баҗай булa-рак, бик акыллы күренергә тырышып.— Кем эшләр соң синең ул бак-чаңда? Үзеңнең арка кашырлык та вакытың юк, хатының...

Шунда шул, моның азырткан җиренә тия яздым бугай, дип куркып һәм гомумән күңелем нечкәреп:

— Акчасын аның кыра-себерә торгач, бәлки табарга да булыр иде,— дип әйтеп ташламасынмы без фәкыйрегез.

Бу нечкәрүем өчен соңыннан мина әләкте әләгүен, ләкин баҗайның җавабы бөтенесен оныттырырлык булды.

— Эшләү турында уйлаган юк,— диде ул, авызын хәйләкәр ерып,— эшләр вакыт тимәс тә тимәс. Но бит хатынга чыдар хәл юк, малай. Фәләннәрнең бакчасы бар, төгәннәр алганнар, нишләп без генә бакча-сыз калырга тиеш, ди, күз дә ачырмый.

Фәләннәрнең бакчасы бар, төгәннәр алганнар — менә ул безнең башка җитә торган бәла кайда! Өлкән баҗайның бакчасы бар, уртан-чы баҗай алды, ничек инде кече баҗай алардан калышып торырга тиеш. Атна-ун көн уздымы икән, кече баҗай йөгереп килгән. Бусы электромонтер, ярты гомере багана башында уза. Шуннан — багана башыннан торып, дөньядагы бөтен хәл-әхвәлне күреп тора. Әйтеп кара син аңа «акчам юк» дип, әлеге шул биек багана башыннан ул синең кесәңне генә түгел, җаныңны әллә кайчан күреп алган. Хәер, монысы эшне коры тотты, икеме-өчме ай дигәндә бакчаны да, бакчадагы өйне дә ялтыратып куйды. Һәм шулай беркөнне, илһамым килеп, язарга дип кенә торганда, ай-ваена карамыйча, җилтерәтеп бакчасын һәм бакчада-гы өен юарга алып та китте. Менә сезгә бакча дигәннең аяк астыннан килеп чыккан икенче файдасы.

Баҗалар белән эш бетте, хәзер үземә күчәм. Без инде әллә кайчан-гы тәҗрибәле бакчачы. «Тәҗрибәле бакчачы» диюем шуннан, быел, мәсәлән, бөтен кешедән элек помидор ашарга ниятләп, март азагыннан ук тәрәзә төбебезгә бер ящик помидор үсентесе җиткереп, кая куярга белмичә, чыгарып ташладык. Аннары шул ук ящикка гөл магазиның-нан яңа балчык сатып алып кайтып, яңа орлык сибеп, яңа үсентеләр җиткердек. Болар шулхәтле әкәмәт китте, үсеп түшәмгә житә башлагач, бакчага күчереп утыртып һәм салкыннан өшетеп, көчкә котылдык. Аннары базардан хәләл акчабызга яңа үсентеләр сатып алып, кеше рәтеннән һәм бик пөхтәләп яңаларын утырттык. Һәм бусы инде тәгаен җимешле булыр... дип көтеп торганда, бар икән күрәселәрем, бусы икенче яктан яңагыма китереп сукты. Бусы, кыска гына итеп әйткәндә, мине хатынсыз калдырды. Ябышып катты бит хатыным әлеге шул кеше рәтеннән утырткан шәп помидорларына!

Коры сүз колакны ертмасын дип бер мисал китерәм: беркөнне шулай эштән соң бик тәүфыйклы булып җыелышында калып, җыелы-шында Израил сугыш чукмарларына җен ачуларым белән йодрык күр-сәтеп, бик тә чатнап, ишектән үк «Чәй, хатын, чәй!» дип аваз салып кайтып керсәм, ни күрим, юк өйдә хатыным. Зерә коелып төшмәдем, шулай да, хатынсыз өйгә кайтып керү күңелсез икән. Югыйсә, аптыра-сы түгел, газны борасы да куясы чәйнекне. Биш минуттан чәй өстәлдә булачак, юа башла коргаксыган бугазыңны. Юк шул, белмисез икән сез мине, кара-каршы чекерәешеп һәм бераз әйткәләшә-әйткәләшә утырмасак, үтми безнең бугаздан ризык. Шул коргаксыган бугаз белән сәгать сигезгә хәтле көттем хатынны — юк хатын. Сәгать тугызга хәтле көттем хатынны — юк хатын. Сәгать унга хәтле көттем хатынны — юк

хатын. Мин үзем алай көнче кеше түгел, аллага шөкер, моңа тиклем хатыным да көнләшерлек сәбәп ясамады, ә бу кичне, салкын гына шуып, вәсвәсә керде бит эчкә: «Белмәссең кеше күңелен... җитмәсә, кайдандыр башына килеп, кырлап-сырлап тегелгән күлмәк сатып алып кайткан иде», дип уйлыйм эчтән. Хәер, бик алай ташып чыкмадым, кайнаган чәйнек, пешкән «Экстра» чәе плитада утырып калды, кипшергән бугазымны ачудан зур бер стакан салкын су белән коендырдым да ятып йокладым.

Төннең бер вакытында, беренче татлы йокымның «промфинпланын» тутырып уянгач, хатыным-җан кисәгемне сагынып (шулай җиде төн уртасында хатынымны сагына торган алама гадәтем бар минем!), янынарак елышып карасам, пәри бу мина, терсәге белән генә этә: әй, йокыны бүлдермә әле, синнән башка эт булып кайткан кеше, янәсе.

Авызы белән әйтми ул бу сүзләрне, терсәге белән әйтә. Эш болайга киткәч, минем дә мыек кабарды. Йокысы белән исәпләшеп тормадым, җавапка тарттырдым хатынны. Бактың исә, гөнаһсызга йокысын бүлдергән икәнмен җаным-бәгыремнең. Әлеге шул бакча-ләгънәт гаепле, имеш. Ишеткән бу радиодан кырау буласы дип, үзегез беләсез, акча түләп алып утырткан помидор җәл. «Юл буе вагонда кәгазьдән калпачоклар ясап бардым, кеше көлә, ә мин помидорларым харап булмагае, дип җыламыйм гына», ди. Тавышыннан сизеп торам, анда җыламаган, хәзер мина иркәләнеп җылый мескенкәем. Йөз төп помидорга йөз калпачок ясарга, берәм-берәм, ипләп кенә каплап чыгарга кирәк. Җитмәсә, кырауны җибәрмәскә тырышып, бакча кырыена ут ягып маташкан. Ул уты, артык дөрләп китеп, күрше бакчаларына, күрше йортларына таба телен сузарга тотынган. Кыскасы, изаланган бичара. Андый чакта нишлисең? Күнәсең, билгеле. Һәм шул сагынган көйгә әйләнәсең дә йоклап китәсең...

«Ничава... Иртә бар!» дип авызын ерып тора булыр бер ише кеше. Бакчаң булгач, иртә булмый икән шул менә. Иртәгесен, мин торганчы хатыным торып, кичтән каплаган калпачокларын алырга дип китеп барган. Менә бу булды бакчабызның күренеп торган өченче файдасы.

Дүртенче файдасы шул булды — дусларымны югалттым. Электә, Казандагы ныклы адресларын белгән чакта, еш булмаса да барып чыккалый идем — бер туры килмәсә, бер туры килә кеше. Мин үзем, үземә кунак килгәндә каядыр йомыш белән чыгып киткән атлы булып күренергә яратсам да, иптәшләргә кунак булып барырга иренмим. Бер барганда очратмасам, икенче барам. Ә бу бакча-тәре килеп чыккач, бер барасың, ике барасың, өч барасың — юк та юк, бакчасына чапкан.

Алай-болай урамда очратсаң, якты чырай күрсәтә үзе — күгәрчен урынына гөрли, хәтта бакчасына «килеп чыгарга» чакыра. Мин, беркатлы сабый, аның ул сүзенә ышана калып:

— Кайда соң синең бакчаң? — дип кайтарып сорыйм.

— Ә-ә-әнә анда, Чыңгыз ягында,— ди бу, йомшак кына сузып. Ә үзе каядыр Яңа бистә ягына таба күрсәтә. Торып тор, Яңа бистә ягына барырга өлгерербез. Шул ук вакытта, бу килештән, Чыңгыз ягы да бик томанлы булып чыкты бит әле, малай. Шулай итеп, шартла, үл, юл ябык дуслар ягына.

Аның каравы Казан белән Обсерватория арасындагы юл ачык — әле тегe якка, әле бу якка чаба бирәм. Монда кайтсам, тынлык сагындыра да җиләк-җимеш сагындыра — бакчага китәм. Анда барып берикене кунмыйм — шәһәр сагындыра, шау-шу сагындыра, кино-театр сагындыра — шәһәргә чабам. Һич югы футболны сылтау итеп чабам. Хатын әрләп кала — мин инде аның әрләвенә күнеккән. «Бик әйбәт... Юлда булу — кеше күрү, яңа сүз ишетү ул!» ди булыр бер ише гидай халык. Юк шул, җаннарым. Күргәннәрем — барысы да шул кырык күр-

гән бакча кошлары, җырлары — гел шул бер җыр: тирес кайдан аласың да алмагачның төбе саен ничә чиләк су саласың? Һәм башка, һәм башка шуның ишеләр.

Шулай да беркөнне бер яңа сүз ишеттем.

— Малай имтиханда сөртенде, көзен ВУЗга керә алмаса, ул җан көеген кая куярга булыр инде? — дип аһырып куйды минем каршыда утырып баручы берәү. Миңа әйтмәде, үзе белән янәшә утырып баручы, сүзләренә караганда, күптәнге таныш кешесенә әйтте. Тавышыннан ишетеп калдым: борчылып, танышыннан нинди дә булса киңәш сорагандай итеп әйтте. Шуңа тегесе нинди җавап бирде дисезме?

Элек, авызына су капкандай, берни дә дәшми барды һәм кинәт, чебен тоткандай, сөенеп һәм балкып болай дип сөйләп китте:

— Малай дигәннән, минем Рөстәмне беләсең инде син, сорви-голова иде бит малай чагында. Әйтмәгәнем булсын, хәйран йорт җанлы булып чыкты шул. Кушкан, төртеп күрсәткән кеше юк, беркөнне бу, чистый үз белдеге белән, урманнан кечти арбага төяп куак кисеп алып кайткан. Бакча әйләнәсенә кош та үтеп кермәслек итеп, читән тотып куйды. Берәүнең булса, кушып та эшләмәс андый эшне.

Кош та үтеп кермәгәч, ул нинди бакча була ди инде! Юк, әлеге хәсрәт адәмнең башы аңа җитми. Ә теге күршесендә утырып баручы танышының ачыктан-ачык кайгысын бүлешүне көтеп әйткән сүзләрен тыңларга башы җитмәде дә җитмәде. Болай да туң йөрәк булып туган кайбер адәм балаларын әнә ничек ташка әйләндерде ул бакча-ләгыйнь.

Кешене әйткән булам, ә үзем? Ә үзем?

Җәй булса, кулга каләм алмавым белән бер мактандым инде. Җыелыш-фәлән булып узганын ике-өч көн соңга калып ишетәм. Сакалга өч көнгә бер пәке тидерә алсам — шуңа бик канәгать. Язга чykканда гына иптәшемнең хатыны үлеп китте, җиткән малае белән икәве генә калдылар, хәлләре бик үк җырлап тормый булыр. Ай ярымнан бирле, барып, хәлләрен белергә дип план корып йөрим, ә барып чыга алганым юк. Утыз биш елдан бирле безнең якларда булмаган авылдашым, Казаннан узышлый мине сорашып, күрергә теләп йөргән. «Алар өйдә юк, бакчада», дип телефон номерын әйтмәгәннәр, ә ул көнне мин өйдә идем. Өйгә киләләр — без бакчада калабыз. Бакчага эзләп килеп чыгалар, нәкъ шул көнне гөнаһ шомлыгы, мин өйгә кайтып киткән булам.

Беркөнне шулай, бакчада да түгел, өйдә дә түгел, ни сизгер кеше — хәтта хатын да испәп таба алмый торган җирдә, портка төшеп, туктап торган пароходның ресторанына кереп утырдым. Соңга калып булса да штрих: гомумән, пароходларны мин бик яратам. Әлеге шул бакчакамытны муенга кигәнче җәйләрен пароходка утырып йөргәли дә идем. Кыскасы, пароходны бик сагынганмын. Ачык тәрәзәдән саф һава кереп тора, ак алъяпкычлы, нечкә билле официанткалар килгәләп-киткәләп йөри, болай да бик йомшак күңелле кеше, мин шул утырган җиремдә яхшы ук йомшап киткәнмен. Әлеге шул бакча-шомлык гаепле, кичә агач төпләрен йомшартып, эт булып арылган иде. Җитмәсә тагын пароходы да бик тирбәтеп алып бара, имеш.

Бер заман уянып китсәм, әй, кеше әйтеп кеше ышанмас: бакча да юк, янымда өй дә юк, хатын да юк, кесәдә билет та юк, билет сораган кеше дә юк — полный хөрлек! Ә пароход бара да бара.

Кешеләр йоклап беткән иде, палубага чыктым да тауларга карап:

— Әйтегез, мин кайда? — дип, бар тавышыма кычкырдым. Һәм, әйтергә кирәк, уйламаганда килеп чыккан шушы мажаралы сәяхәтем һәм кеше күрмәгәндә шулай бер илереп кычкыруым белән җанымны сытып яткан бакчамнан үч алдым.

*Июнь, 1969*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КОЯШ АЛЫП КИЛДЕЛӘР

Чын мәгънәдә дуслык тантанасы һәм иҗат бәйрәме булып истә калган бу көннәрдә — РСФСРда Үзбәк әдәбияты һәм сәнгате декадасы Горькийда башланып безнең Татарстан җирләрендә ике көн дәвам иткәндә — газета битләрендә үзбәк дусларыбызның сәнгате белән әдәбиятына кайнар ихтирам, зур хөрмәт һәм чиксез соклану белдергән шундый сүзләр бик еш күренде: «Алар кояш алып килделәр!» Әйе, кызыл розалар, ак мамык, шаулы бакчалар яшеллеге һәм йөзләгән-меңләгән завод-фабрикалар силуэты белән чигелгән искиткеч зур келәмне хәтерләткән кояшлы республикадан безгә кунакка үзбәк җырлары һәм шигырьләре, үзбәк китаплары һәм нәфис фильмнары, әдипләр, артистлар, рәссамнар һәм композиторлар — барлыгы 350 кеше килде.

Дусларыбыз Казан белән, Татарстанда Ленин исеменә бәйле урыннар (университет, музей, Кокушкино) белән таныштылар, иҗат оешмаларында очраштылар, эшчеләр һәм игенчеләр коллективларында чыгыш ясадылар. Халык аларны сәхнәләрдә һәм экраннарда күрде, радиодан тыңлады, аларның китапларын һәм сувенирларын алды, аларны чын күңелдән алкышлады. Кунакларны каршылаганда Казан вокзалыннан ук башланган ягымлы музыка, җыр һәм бию аларны юлбашчыбыз Ленинның туган каласы Ульяновскига озаткан минутларга кадәр тантана итте.

Декаданың Казандагы көннәрен башлап җибәргән тантаналы җыелыш В. И. Качалов исемендәге драма театрында уздырылды. Аны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев ачты. Беренче сүзне КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев сөйләде һәм кунакларга Ленин рәсеме төшерелгән барельеф тапшырды. Аннары сүзне Үзбәкстан ССР Верховный Советы Президиумы председателе Я. С. Насретдинова алды һәм ул да, үз чиратында, үзбәк халкы исеменнән алып килгән истәлек бүләкләрен бирде.

Декадага Ташкенттан хәзерге совет әдәбиятының иң күренекле вәкилләре — Үзбәкстан язучылар союзы идарәсе председателе Камил Яшен, халык шагыйрьләре Зөлфия һәм Уйгун, шагыйрь һәм прозаик Хәмид Голәм, Әсгать Мохтар, прозаик Ибраһим Рәхим, шагыйрьләр Рамз Бабаҗан, Мирмөхсин, Гөлчәһрә Нуруллаева, филология фәннәре докторлары Х. Абдусаматов, Л. Каюмов, язучы Сафаров, Кара-Калпак шагыйре Хуҗаназаров, «Звезда востока» исемле русча әдәби журнал редакторы Г. Владимиров иптәшләр килгәннәр иде. Алар белән бергә чыгышларда РСФСР язучылары союзы исеменнән Франц Таурин, Антонина Коптяева, Юрий Рытхэу һәм үз язучыларыбыздан Х. Туфан, С. Хәким, Г. Ахунов һәм башкалар актив катнашты. Очрашулар В. И. Ленин, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәк куйганда, Язучылар союзында, М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында, халыкара яшьләр лагере «Волга»да һәм хәрби частьларның берсендә үткәрелде.

РСФСРда Үзбәк әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрен Казанда үткәрү уңае белән һәм ирешкән иҗади уңышлары өчен үзбәк дусларыбызның 10 коллективы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамоталары белән бүләкләнде. Менә алар: халык биюләрен башкаручы атказанган дәүләт ансамбле «Бахор», Үзбәкстан дәүләт филармониясенең «Шатлык» исемле җыр һәм бию ансамбле, шул ук филармониянең Хорезмдагы «Лязги» ансамбле, Кара-Калпак дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле, халык артисты Батыр Закиров җитәкчелегендәге эстрада группасы, Үзбәкстан ССРның язучылар, композиторлар, художниклар һәм кинематографистлар союзлары, Үзбәкстан ССР театр җәмгыяте.

Соңгы кичәсе Мәскәүдә тәмамланган декада турындагы куанычлы һәм онытылмас тәэсирләрне, үзбәк дусларыбызның берсе, Үзбәкстан Фәннәр Академиясе член-корреспонденты Иззат Солтанов «Литературная газета»да түбәндәгечә язып белдерде: «Бирегә, дөньяга иң бөек юлбашчыны һәм фикер иясен биргән Иделдәге борынгы калаларда, без бик күп кешеләр белән танышканда, хезмәт ияләре белән очрашканда һәм укучылар алдында чыгышлар ясаганда аеруча зур дулкынлану кичердек: чөнки алар бит барысы да Ленин якташлары иделәр!.. Иделлеләр безне, үзбәк әдипләрен һәм артистларын, ихлас күңел белән, кайнар хисләр белән кабул иттеләр! Бирегә, Россиянең йөрәге итеп саналган үзәкләрдә, үзбәк сүзләре нәкъ безнең үз өебездәгечә үк иркен һәм көчле яңгырады...»

## ЛЕНИН БУЛГАН ҖИРЛӘРДӘ

Бу маршрут Абаканнан башланды да Красноярск өлкәсендә Ленин булган урыннар буйлап (Минусинск, Шушенское, Красноярск) дәвам итте. СССР Язучылары Союзы оештырган зур бер төркем язучылар — Мәскәүдән Лев Кассиль, Мария Прилежаева, Маргарита Алигер, Ирина Левченко һәм тагын унлап әдип, Ленинградтан

Даниил Гранин белән Владимир Таропыгин, Белоруссиядән Евдокия Лось белән Микола Аврамчик, Әрмәнстаннан Сильва Капутикян, Грузиядән Алио Мирцхулава, Таҗикстаннан Җәләл Икрами, Татарстаннан Зәки Нури, Башкортстаннан Әнвәр Бикчәнтәев, Кыргызстаннан Омар Солтанов, Латвиядән Милда Лозберга, Литвадан Юзас Мацявичус — Ленин темасына язылган әсәрләрне пропагандалап, искиткеч киң, куәтле индустрия крае саналган Красноярск җирләрендә бик күп чыгыш ясадылар, лениниананы яңа әсәрләр белән баету өчен материал өйрәнделәр, завод-фабрика клубларында һәм культура сарайларында эшчеләр белән очраштылар, Красноярскида һәм Саяно-Шушенскоеда гигант электр станцияләрен төзүчеләрнең эше белән таныштылар. «Тугандаш әдәбиятлар атналыгы» дип аталган бу сәяхәт һәм бу очрашулар халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгы тантанасы, эшлекле иҗат бәйрәме булып үтте. Әдипләр аны «В. И. Ленин һәм совет әдәбияты» дигән темага теоретик конференциядә сөйләшү белән тәмамладылар.

## НӘШРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Татарстан дәүләт китап нәшриятының эшли башлавына 50 ел тулу көне киң катлау укучылар, җәмәгать оешмалары, язучылар, Мәскәү, Куйбышев, Уфа, Чебоксар калаларыннан вәкилләр катнашы белән эшлекле һәм истәлекле иҗат бәйрәме буларак билгеләп үтелде. Актерлар йортында үткәрелгән тантаналы кичәдә юбилярны Партиянең өлкә комитеты, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев котлады. Шунда ук совет әдәбиятын үстерүдә һәм китап бастыруны оештыруда ирешкән уңышлары өчен китап нәшриятын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының мактау грамотасы белән бүләкләү турында указ укылды һәм мактау грамотасы нәшриятка тапшырылды. Журналистлар һәм язучылар, эшчеләр һәм нефтьчеләр, игенчеләр һәм хәрби хезмәткәрләр, мәгариф эшлеклеләре һәм комсомоллар исеменнән сөйләүчеләр нәшриятны, аның күп санлы работникларын бәйрәм көне һәм бүләкләнү уңае белән чын күңелдән тәбрикләделәр. Ә нәшриятта күп еллар буена уңышлы эшләгәннәре өчен лаеклы бүләк алучылар аз түгел иде: Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем 3 кешегә, СССР Министрлар Советы каршындагы матбугат комитеты һәм Культура работниклары профсоюзының Үзәк Комитеты карары белән «Матбугат отличнигы» значогы 4 кешегә һәм мактау грамотасы 3 кешегә, РСФСР Министрлар Советы каршындагы матбугат комитеты һәм Культура работниклары профсоюзының Үзәк Комитеты мактау грамотасы 6 кешегә, КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының мактау грамотасы 10 кешегә (шул җөмләдән Язучылар союзы членнары Сафа Сабиров, Тихон Журавлев, Шамил Рәкыйпов), Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының мактау грамотасы 5 кешегә, Культура работниклары профсоюзының Татарстан өлкә комитетының мактау грамотасы 12 кешегә һәм Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсенең мактау грамотасы 21 кешегә бирелде. Нәшрият директоры Г. К. Камалиев, баш редактор Х. Я. Гобәйдуллин һәм редактор Ф. Гайнанова иптәшләрнең эшчәнлеге РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирү белән билгеләнде.

Нәшриятыбызны Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» редакциясе түбәндәгечә котладылар:

## СӘЛАМ СИҢА, ИПТӘШ НӘШРИЯТ!

*Сәлам 50 яшь тутырып, акыл һәм зирәклек җыеп, көр тавыш белән, тулы көчкә сөйли башлаган көнеңдә.*

*Без синең белән аеруча якын, бер-беребезгә аеруча киракле кешеләр бит. 50 ел эчендә Татарстан китап нәшрияты татар язучыларының меңләгән кульъязмаларын ташка бастырып, китаплар итеп, нәфис әдәбият сөючеләргә тапшырды. Меңләгән, ун меңләгән, йөз меңләгән данә итеп, таутау итеп, ерак калаларга, авылларга җибәрде һәм шуның белән ул хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүгә зур өлеш кертте.*

*Моннан берничә көн элек бөтен дөньяга атаклы итальян балалар язучысы Джанни Родари Казанда булып, безнең нәшрият чыгарган «Зәңгәр ук сәяхәте» китабына болай дип язды:*

*«Мин Казанда бик күп яхшы кешеләрне һәм үземнең китабымны очраттым. Мин китабым язмышына сокланам, чөнки ул татарча сөйли бела, ә мин татарча белмим. Хәер, бер сүз беләм икән: Рәхмәт!»*

*Әйе, хөрмәтле нәшрият, син күп төрле телләрдәге китапларны татарча сөйләтеп, татар укучыларын дөнья культурасы белән дә таныштырасың.*

*Сәлам сиңа, мәйдан тоткан илле яшьлек баһадир!*

*Котлы булсын бәйрәмең!*
*Уңышларың гел артып торсын!*

**Татарстан язучылар союзы идарәсе**

## КАЛӘМДӘШ ДУСЛАР!

*Борын-борыннан иң якын күршеләрне ут күршеләре дигәннәр. Ягъни алар бербере белән якты һәм җылы бүлешеп, берберенә изге ниятләр һәм яхшы теләкләр белән яшәгәннәр.*

*Сез — безнең ут күршеләребез. Бар булганын бергә бүлешеп, бер шатлык белән шатланып, бер ук борчулар белән борчылып яшәгән дусларыбыз!*

*Журналыбызның бик күп авторлары һәм сотрудниклары сездә хезмәт чыныгуы алган, редакторлык мәктәбенең әлифбасын нәшриятта өйрәнгән кешеләр һәм инде җитлеккән әдипләр.*

*Юмарт кулның байлыгы бүлеп биргән саен арта ул. Нәшриятның үзендә дә югары*

*белемле, үз эшен бик яхшы белгән һәм чын күңелдән яратып эшләгән редакторлар, художниклар, корректорлар, техник редакторлар һәм башка бик күп белгечләр бар. Алар кулы аша үткән китаплар илебезнең төрле урыннарында үзләренең укучыларын таптылар. Бу китаплар эчтәлекләре һәм художество оформлениеләре ягыннан елдан ел баерак, матуррак була баралар. Шуңа күрә дә алар кибет киштәләрендә озак ятмый.*

*Бәйрәм көнендә Сезгә теләгебез шул: уңышларыгыз, шатлыкларыгыз мул булсын!*

*Илле еллык хезмәт бәйрәмегез белән тәбрик итәбез Сезне, якын дуслар.*

**Ут күршегез — «Казан утлары».**


*1 август, 1969 ел.*

## ДЖАННИ РОДАРИ — КАЗАН КУНАГЫ

Италиянең күренекле балалар язучысы бездә кунакта булды. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары белән танышты. Ленин темасына әсәрләр язу өчен, ул Владимир Ильичның университеттагы мемориаль бүлмәсе, Казан һәм Ленино-Кокушкино музейларындагы материалларны аеруча җентекләп өйрәнде.

Язучылар союзында безнең әдипләр белән очрашу вакытында Джанни Родари республикабызда әдәбият, сәнгать һәм культура өлкәсендәге казанышлар, язучыларның иҗат планнары һәм эш шартлары турында тирән кызыксынып сорашты һәм ишеткәннәрен куен дәфтәренә яза барды. Татарстан китап нәшрияты директоры Г. К. Камалиев хөрмәтле кунакка аның Казанда чыккан ике китабын бүләк итте.

Дустыбыз Родари «Казан утлары» журналына үзенең яңа әсәрләрен җибәрәчәк.



*Д. Родари (уртада) М. Зарипов һәм Г. Ахуновлар белән.*

## «ВИТЕБСКОЕ ПОДПОЛЬЕ» ДИГӘН ЯҢА КИТАП ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Бу китап күптән түгел Белоруссиядә басылып чыга. Анда фашистларга каршы Витебск өлкәсе җирләрендә сугышкан татарлар — Муса Җәлил оештырган «Идел-Урал» легионы кешеләре турында да шактый күп язылган һәм Идел татарлары батальонының партизаннар ягына чыгуы Витебск подпольесының зур җиңүе буларак бәяләнә. 1943 елның 19 февралендә каршы төндә махсус эшелон белән Витебскига китерелгән, батальон Бабиничи һәм Белынович авылларына озатыла. Бу турыда подпольечылар шушы төнне үк партизаннарга тулы мәгълүмат бирәләр. Партизаннар белән күрешү, алар янына чыгу инициативасын үз өсләренә алучылар менә кемнәр була: батальон командирының (немец майоры Зекс) адъютанты Тажиев, взвод командирлары Юсупов, Галиев, Трубкин, Лотфуллин, штаб ротасы командиры Мөхәммәтов һәм аның ярдәмчесе Рәхимов, врач Жуков, ветврач Муталло, хуҗалык бүлекчәсеннән Рәхимов. Сеньково авылының Нина исемле кызы (фамилиясе Буйниченко) аларга Сысоев житәкчелегендәге партизаннар отряды белән элемтәгә керергә ярдәм итә («Пропуск сыйфатында үзенең кызыл яулыгын һәм записка бирә»).

Батальонның баш күтәрүе вакыйгасы китапта партизан А. Н. Немыкин исеменнән түбәндәгечә тасвирлана: «1943 елның 22 феврале төнендә» Двинаның сулъяк ярында гранаталар шартлау һәм автомат чиратлары ишетелде — татарлар гитлерчы команда составын юк иттеләр. Ярты сәгатьтән соң барысы да тынды. Иртәнге сәгать 8 дә беренче Витебск партизаннар бригадасына барлык техникасы, сугыш припаслары, азык әйберләре, кием-салымнары, атлары белән алты йөзгә якын татар сугышчылары килеп кушылды. Бу совет армиясенең 25 еллыгы көнендә булды. Партизаннар да, тугандаш татарлар да чиксез шатландылар, күпләренең күзләрендә яшь. Шунда ук дулкынландыргыч митинг үткәрелде.

Ләкин үзләренең җәфалану һәм кимсетелүләре өчен патриотларның байтагы фашистлар белән хисаплаша алмады. Шофер тарафыннан кисәтелгән майор Зекс үзенә ярдәм чакыртырга өлгергән булган. Гитлерчылар Витебскидан Сеньково авылына тиз генә җәзалау отряды җибәргәннәр. Очынып килеп, алар соңгы кешеләр булып чыгачак Жуковны, Тажиевны, Рәхимовны һәм күп кенә башкаларны кулга алалар. Күреп торган кешеләр фашистларның патриот татарларны ерткычларча җәзалап үтерүләрен сөйлиләр.

Партизаннар ягына чыккан сугышчылар фашист басып алучыларга каршы батырларча сугыштылар. Мәсәлән, 28 февральдә Сысоев отряды Щелбов урманнарында җәзалаучыларның чолгау боҗрасын өзә һәм дошман тылына үтеп кереп җимергеч удар ясый, ә татарларның төп группасы Сысоев отрядында иде. Поповичи авылы районын-

да отряд фашистларның 6 танкысын, автомашинасын юкка чыгара һәм берничә гитлерчы солдатны пленга ала. Бу операциядә Тимошенко, Сергиенко, Хафизов, Юсупов һәм Сәйфетдинов үзләрен аеруча күрсәтәләр. Шулай ук сугышчы Гарнаев, батальон комсоргы Әхмәт Зыятдинович Галиев зур каһарманлык эшли».

## «КАМА ТАҢНАРЫ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

Әдәби берләшмә членнары Фәннур Сафин, Фәния Хуҗиәхмәтова, Мизхәт Хәбибуллин, Айдар Хәлим химиклар көненә багышланган тапшыруда катнашып, республика телевидениесендә чыгыш ясадылар.

Яшь авторлар Түбән Кама шәһәренең бүгенгесе һәм киләчәге, аның культура тормышы турында сөйләделәр, яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

Түбән Кама шәһәренең 46 номерлы техник училищесында (директоры Нәҗип Гафиятуллин) әдәби журналларны күп алдыралар, кичәләр еш оештырыла, концертлар куела. Шундый кичәләрнең берсе Муса Җәлилгә багышлап үткәрелде.

Муса Җәлил шигырьләрен русча һәм татарча иң яхшы укучыларга бүләк итеп Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил китаплары тапшырылды.

* * *

Берләшмә членнары З. Сәмигуллин, Р. Хисмәтуллин, В. Зәйнетдинов, Ф. Сафин, Р. Юнусов, А. Хәлим шәһәрнең медицина училищесында, нетфехимия техникумында, бишенче номерлы урта мәктәптә укучылар белән очрашып хәзерге татар әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ӘДИПЛӘР ЙОРТЫ

Актерлар йорты... Композиторларның концерт залы... Художниклар өчен иҗат мастерское... Болар барысы да Казанда бар инде. Күптән түгел Язучылар союзы идарәсендә Казанда салынырга тиешле әдипләр йорты проектының эскизы тикшерелде һәм хупланды. Аның 300 дән артык кеше сыйдырышлы зур залы, иҗади очрашулар өчен конференц-залы, китапханәсе, Язучылар союзы идарәсе, аның иҗат секцияләре, әдәбиятны пропагандалау бюросы, «Казан утлары» журналы редакциясе һәм Литфондның Татарстан бүлекчәсе өчен аерым бүлмәләре, ашханәсе, фотолабораториясе һәм кунак бүлмәсе булырга тиеш. Бинаның урыны Карл Маркс урамы белән Комлев урамы кисешкән чатта, Художниклар йорты белән Сәнгать музее янында булуы планлаштырыла.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210